КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Гөлнур КОРБАНОВА. Кышларның төннәре бик озын... *Шигырьләр.* 3
Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Бик. *Повесть.* 8
Рәшит БӘШӘР. Бозлык чорын исән-сау кичәсе бар... *Шигырьләр.* 68
Фирдәвес ЗАРИФ. Киләчәккә кем соң юл салыр?!. *Шигырьләр.* 129
Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА. Кышкы бер төн. *Хикәя.* 133
Гөлзадә ӘХТӘМОВА. Өмет уты балкып торсын җанда. *Шигырьләр.* 139

«АҺ, ТУГАН КАУМЕМ ГАЗИЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Асия ЮНЫСОВА. Хатыннар сүрәсе. *Бәян.* 72

«КАЗАН УТЛАРЫ»НЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Разил ВӘЛИЕВ. Яктырак яна «Казан утлары». 142

«Казан утлары» – минем язмышымда: Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Гомерлек юлдашым. 146

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Равил РАХМАНИ. Еракка китүләр... сагындыра *(Мөдәррис Әгъләмовның тууына – 75 ел).* ..150

ХӘТЕР

Рафаил ХӘКИМОВ. Сибгат Хәким урамында *(Сибгат Хәкимнең тууына – 110 ел).* 155
Рафис КОРБАН. Шигырь эзләп китте *(Фәиз Зөлкарнәйнең тууына – 70 ел).* 161

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Диләвәр ОСМАН. Татарлыкны дәвам иткән егет, кызлар туармы? *Шигырьләр.* *(Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәләре).* 163
Сәйран СӨЛӘЙМАН. Мәдхияләр язды шагыйрь... *Шигырьләр.* *(Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ тәрҗемәләре).* 165

Фән: Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Бер кеше – берәгәйле кеше! 167

Китап күзәтү: Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Әманәт ителгән дәфтәрләр. 172

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Батырларны данлаган каләм иясе *(Габдрахман Әпсәләмовның тууына – 110 ел).* 176
Якты яшен булып язылды... *(Зәки Нуриның тууына – 100 ел).* *Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* 177

Шаян сәхифә: Әхәт САФИУЛЛИН. Уены-чыны бергә. 178

Печән базары: Зиннур МАНСУРОВ. Парчалар. 180

2021 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге. 184

«Казан утлары» архивыннан. 148
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 190

КАЗАН УТЛАРЫ
№ 12 (1190) 2021

БАШ МӨХӘРРИР –
Рөстәм Госман улы
ГАЛИУЛЛИН

ИДАРӘ:
Ирада Әюпова
Разил Вәлиев
Рәдиф Гаташ
Искәндәр Гыйләҗев
Айрат Зарипов
Дания Заһидуллина
Ркаил Зәйдулла
Илгиз Зәйниев
Илфак Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Газинур Морат
Рүзәл Мөхәммәтшин
Айдар Сәлимгәрәев
Равил Фәйзуллин
Илсур Һадиуллин
Данис Шакиров
Ленар Шәех

Баш мөхәррир урынбасары: **Вакыйф Нуриев.**
Җаваплы сәркатип: **Ландыш Әбүдәрова.**
Бүлек мөхәррирләре: **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан, Рамил Ханнанов.**
Мөхәррирләр: **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
Сайт мөхәррире: **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
Исәп-хисап бүлеге: **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
Машина йөртүче: **Наил Кадыйров.**

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).
Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).
Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).
Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 25.11.2021, график буенча 29.11.2021, басылып чыгу вакыты 01.12.2021.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-3964. Тираж 14046.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2021 ел

Гөлнур
Корбанова

КЫШЛАРНЫҢ ТӨННӘРЕ БИК ОЗЫН...

Декабрьнең бере

Юк бакчада гөлләр, юк агачта бөре.
Урамымда – ак кыш. Декабрьнең бере.
Тып-тын калган дөнья. Тып-тын калган. Тере.
Дөнья буйлап йөри декабрьнең бере.
Ничек кыш гел ак соң? Нидә икән сере?
Кояшы да ап-ак. Декабрьнең бере.
Серен ачар иде, юк кышларның теле.
Дәшми генә тора декабрьнең бере.
Килеп бара ак кыш. Адымнары эре.
Бүген әле бары декабрьнең бере.

***

Ява карлар, куна карлар иңнәремә,
шөкер итәм бу карларны күргәнемә.
Шөкер итәм бу көннәрне күргәнемә,
көннәр буе нидер эшләп йөргәнемә.
Яратам мин кышның карын, бураннарын,
бураннарның адаштырмый торганнарын,
бураннарның тансык кына булганнарын,
сагындырып урамнарга тулганнарын.
Карлар ява, карлар ява, ишеп-ишеп,
аклыгыннан якты кала җанга күчеп,
аклыгыннан аклык кала җанга күчеп,
бу аклыкны таптавы да әллә ничек...

Гөлнур КОРБАНОВА (1979) – *шагыйрә; «Уемның куены», «Утлы яшеннәргә кагылсаң», «Аю булу кыенмы?» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Бүре баласы

БАЛЛАДА

1

Кышкы төннең зәһәр салкыннары. Ап-ак кына урман юллары.
Ишетелде урман эчләрендә бүре баласының улавы.

Ул адашкан иде урманында, кайтыр юлын мең кат эзләде.
Кар өстендә серле юллар булып сызылып калды бүре эзләре.

Үз юлларын йолдызларга карап, айга карап таба юлсызлар.
Ләкин бүген бар да тып-тын иде, сүз дәшмиләр иде йолдызлар.

Бик еракта әнә авыл балкый, йортларында кояш-ут яна.
Барыр иде – бара алмый гына, бүре булып тугач дөньяга.

Үз хәлен ул ничек аңлатыр соң, бүре телен белми авыллар...
Туңар инде. Яз җитүгә, аны кар астыннан табып алырлар.

2

Туңып барган бүре баласында алсу гына өмет яктырды –
карт бүреләр сүзен хәтерләде: «Ул кешеләр гаҗәп акыллы...

Кеше халкы юллар сала белә, урманны да алар булдырган.
Ә ул урман хәзер әнә күпме җан иясе өчен йорт булган».

Шулай булгач, кеше аңлар мине, ишетмәгән чакта бүреләр.
Ризык бирер, яраларны бәйләр, кешеләрне бөек зат, диләр.

Бүре килде авыл кырыена, талчыгулы иде бу төне.
Утлар яна кайбер йортларында – аны көтүләре түгелме?

Бүре керде авыл урамына, ул кергәнне беркем күрмәде.
Бераз гына ашап җылынырга тели иде бүре йөрәге.

3

Йөрде бүре авыл урамында, очрамасмы диеп берәрсе...
Бик тә килде бүре баласының кеше дигән затны күрәсе.

Аһ бүрекәй, нәни бүрекәем... Соң шул инде, сине күрделәр.
Нәфрәт уты иде йөзләрендә – әллә кеше, әллә... бүреләр.

«Бүре килгән, әнә, бүре килгән! Сак булыгыз, зыян итмәсен!»
Һәм берәве бик сакланып кына тартты кинәт мылтык тәтесен.

Ап-ак карлар төште агачлардан, кошлар очты ярып һаваны.
Кар өстендә нәни бүре ята, бүре ята... Башы яралы.

Кыргыйлыкка кемнән өйрәнәсен бүре хәзер белер иде дә...
...Өзәр булып тимер чылбырларын әрнүеннән ярсып, эт өрә...

***

Шулкадәр тын ага елгалар,
елгалар шулкадәр тын ага.
«Су үргә акмас», дип җырларлар.
Тыңлама беркемне, тыңлама!

Кышларның төннәре бик озын.
Сабырың беткәндә кышларда,
«Бу елны яз килми», диярләр.
Ышанма ул сүзгә, ышанма!

Шулкадәр тын ага елгалар,
бардыр ла үрләргә акканы.
Язларсыз ел булмас. Таңнарның
юктыр ул кояшсыз атканы.

Ялгышып, өметсез сүзләрен
кемнәрдер теләсә әйтергә,
тыңлама беркемне! Бары тик
Аллаһның рәхмәтен хәтерлә!

***

Сездә ни хәл? Бездә карлар ява...
Мамык карын коя гына болыт.
Үзән өсләренә аклык иңә,
тәү карларның кыюлыгы булып.

Сездә ни хәл? Бездән көзләр китә...
Кышлар тора өскә ишелергә.
Җанда җылы булса, кыш салкынын
җиңел бит ул, җиңел кичерергә.

Куна карлар, куна учак төсле
янып торган миләш өсләренә.
Кышны каршыларга чыккан җирдән
карап калдым киткән көзләремә.

Сездә ни хәл?..

***

Офыкларга кадәр ерак әле,
ерак әле миңа шәфәкъларга,
баш очымда – кояш эсселеге,
үзәннәрем – куе чәчәкләрдә.
Беркөн, әнкәй, кояш сүрелгәндә,
дөньяларым көзгә күмелгәндә,
көлмәкләрең киеп караганда,
синекедәй чәчләр агарганда,
көзгеләргә карап көенгәндә,
кулларымның көче кимегәндә,
мин аңлармын синең күңелеңне,
мин тоярмын һәрбер күзәнәгең.

Миндә булыр синекедәй күзләр,
һәм күрермен дөнья үзгәргәнен:
без кайтмаган көннең озынлыгын,
кояшының хәтсез кызулыгын;
саксыз әйткән сүзнең авырлыгын,
дәшмәвеңне, җыеп сабырлыгың;
балалардан көткән җылылыгың,
җылылыкның нинди олылыгын
мин аңлармын беркөн. Аңлаганда,
сагыш ургып тулыр күңелемә.
Һәм шул чакта син булмассың, әнкәй...
Син булмассың – үксеп түгелергә.
Сагынуга түзалмыйча ул җан
сине эзләр, синсез сукмаклардан,
үткәннәрне салыр хәтерләргә,
юатырга теләр. Кадерләргә.
...Аланнарым алсу чәчәкләрдә,
Ерак әле, ерак шәфәкъларга...

***

Дөньяларым көязләнә, көязләнә, көзләнә.
Җәй дә китәргә ашыкмый, китмәскә үзсүзләнә.
И көзләрнең купшылыгы! И көзләрнең ямьнәре!
Җәйнең хәле ничек икән, кыен микән хәлләре?
Уйлый микән гөлләренең, китүенә, суласын,
ә шулай да китүләрнең кайтуларсыз булмасын
белә микән китәр җәйләр? Ник белмәсен... Беләдер.
Бар дөньяда – моңлы тынлык, бәлки, шуңа күрәдер.
Дөнья тулы тып-тын моңлык, дөнья тулы көз генә,
бакчаларда яфрак-яфрак җәй йөрәге өзелә.
Бу көннәрнең бизәк булып күңелдә калырлыгы...
Көзләрнең матурлыгы да, җәйләрнең сабырлыгы...

***

Бу якта нәкъ шулай алланып, таң ата.
Бу якта таңнарда сандугач уята.
Бу якта гөлләрне тибрәтеп, җил исә,
көннәре кояшлы, болытлы – төрлечә.
Кышлары калышмый бездәге кышлардан,
язлары бездәге язларга охшаган.
Болытлар тын гына, тын булып агалар.
яңгырлар нәкъ шулай шыбырдап явалар.
Каеннар, әйтерсең, яшь кызлар – сөйкемле.
Бу якта барсы да бездәге шикелле.
Бу якта төшәдер туган як искә гел.
Туган як барыбер, барыбер үзгәдер!
Бу якта, аһ, күңел шулкадәр сагына.
Бу якта бар да бар, юк туган як кына.

***

Әнкәйнең күңеле киң күкләр сымандыр,
Әнкәйнең күңеленә зур кояш сыйгандыр.

«Кызым» дип дәшсә дә, җылыныр йөрәгең.
Әнкәем, бу җырым – сиңа бер бүләгем.

Әнкәйле гомерләр ягымлы язга тиң,
Һәркемгә әнкәйле гомерләр телим мин.
Балам дип, гел сызар әнкәйләр бәгыре,
Әнкәйләр булганда, без һаман кадерле.

Әнкәйләр кебек зат табылмас эзләп тә,
Рәхмәтләр әйтергә җитмәс күк сүзләр дә.
Әнкәйләр янында никадәр мәрхәмәт.
Барысы өчен дә, әнкәем, мең рәхмәт.

***

Очасың, уйныйсың, күбәләк.
Син ниләр уйлыйсың, күбәләк?

Көннәрең узалар уенда,
Күбәләк, ниләр бар уеңда?

Канатың кагасың, дәшмисең,
Гүя син бер гамьсез яшисең.

Күбәләк, күбәләк, акыллым,
Күр әле, күр әле бал кортын.

Гомерең заяга үткәнгә
Үпкәләп йөрерсең кемнәргә?

Гөлләрнең хуш исе исертә,
Гомерләр узар ул ничек тә.

Кояш дип очасың утларга,
Күбәләк, уйлале туктарга.

Күбәләк, әллә син оныттың:
Гомерең – бер йотым, бер йотым.

Канатың – чигүле гүзәллек,
Фаҗигаң – үзәкне өзәрлек.

Син диеп сызуы бәгырьнең,
Күбәләк, күбәләк, кадерлем.

***

Сагынып каршылыйм язларны,
язларның беренче иртәсен.
Яз килә. Яз көлә. Яз белә
дөньяны кояшлы итәсен.

Һәр җирдә яз йөрер. Урамда
Яз чыгар елмаеп каршыга.
Кояшын өләшер. Кояшы
Үзендә кимемәс тамчы да.

Яз йөрер уятып таңнарда.
Язларда шифалы җил исәр.
Язларның тылсымлы тавышы
Кагылган җирләрдә гөл үсәр.

Хатирә яңара язларда.
Яз килеп, киткәндә кышлардан.
Бу язлар кемнәрнең ише соң?..
Язларны кемгәдер охшатам...

Айгөл Әхмәтгалиева

БИК

ПОВЕСТЬ

Галия, 2019 ел.

Ишек бикле иде.

Блииин!

Хаусмайстерда запас ачкыч бар дип сөенерлек түгел – биш минут элек кенә кипкән керләрне күтәреп, мин баскычтан менгәндә, «ауф видерзейн, Галэ!» – дип елмая-елмая чыгып китте. Ак фетр эшләпәсенең уң як читеннән озын булып җеп асылынып төшкән иде – hausmeister герр Оттоның адымына ияреп җилфердәвенә көлүдән чак тыелып карап калдым.

Менә хәзер үз хәлемнән утырып еларлык.

Шалтыратсам, борылып та килер иде, бәлки. Айфон бүлмәдә, караватжәймәсендә Билли Айлиш көенә җырлап утыра әнә. Әни шалтыратадыр. «Тавышын аерып куярлык булгач, нигә кирәк икән соң ул телефон?» – дип, әтигә зарлана-зарлана, кабат-кабат үҗәтләнеп җыюы, ахры.

Тәк... Мин бу бикле ишекне җимереп булса да, эчкә үтәргә тиеш.

Электр плитәсендә балык шулпасы пешеп утыра. Ташымасын дип, капкачын ачыбрак калдырган идем калдыруын. Тик менә болай коридорда тагын ун минут таптанып торсам, шулпада балыкның эзе дә күренмәячәк, изелеп бетәчәк.

Кызык, мин кыска шорты, кендеккә дә җитмәгән кыска майкадан, аягыма баш бармакка гына элгән ак башмак киеп, кулымдагы «Ваниш»ны чарасызлыктан әйләндергәләп, салкын коридорда, балык турында уйланып торам!

Блииин!

«Блиин» дип әйтергә ярамый! Сүгенгән кебегрәк килеп чыга. «Телеңне паразит сүзләр белән пычратма», – дидеме әни?! Бик хәтерлим, төзәлергә тырышам. Тик бу минутта түгел...

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА (1973) – *язучы; М.Кашгарый исемендәге халыкара премия лауреаты. «Синең өчен яшим», «Баланнарда бал тәме», «Таллыкүлдә былбыл бар» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Ачкычны үзең белән алып йөрергә кирәклеге турында әйтсәләр, ни була иде? Ишекне япкач, эчтән бикләнеп калуы турында мин каян белергә тиеш?

Гарьлектән елыйсым килә иде. Тик күз яшьләре түгеп, үземне кызганып утырсам, ул арада балык үзе генә түгел, шулпасының да юкка чыгачагы көн кебек ачык иде.

Тагын балык!

Ишекне ничек ачу турында уйла син!

Берәрсендә телефон, телефонында герр Оттоның номеры булмый калмас дигән өмет белән икенче каттагы бөтен ишекне кагып чыктым. Ник берсендә бер кеше заты булсын!

Өченче катта да тавыш-тын юк кебек иде. Хәер, алай дисәм...

– Сез монда яшисезме? Минем ишек бикләнде. Булыша алмассызмы?..
– Алманча беләм дип йөр син, иң кирәктә бөтен сүзне үз урынына куеп буламыни әле аны...

Коридордан миңа каршы килүче ак футболкалы егетнең, аңламагандай, күзен тутырып каравын күргәч, тиз генә инглизчәгә күчтем.

Бер як чите генә кырып алынган чәче дә, яңак читеннән сызык кына булып төшкән сакал-мыегы да сары дисәң сары түгел, җирән дисәң – җирән түгел, аңлаешсыз бер төстә булып, көләсене китерә иде. Шул җирлектә зур зәңгәр күзләре тагын да зураеп киткәндәй күренә.

Ул да минем кыяфәтемнән кызык таптымы – ирен читләренә җиңелчә елмаю таралды.

– О’кей! Ачкычыгыз бармы?

Ачкыч булса, менә болай коридорда каңгырап йөрер идемме инде?

– Ачкыч бүлмәдә калды. Мин кер юу бүлмәсенә генә чыккан идем. Ишек эчтән бикләнгән. Хаусмайстерда запас ачкыч бар, тик ул кайтып китте.

Шушы рәвешле, сүзләрне төгәл итеп сайлап кына чәйнәп каптырганны да аңламасаң, вакыт әрәм итеп юлымда торма ичмаса...

Гомер булмаганны, мин күңелемнән әллә үзем белән, әллә таныш булмаган шушы егет кисәге белән пычакка-пычак килеп әрепләшә идем. «Нервный тик» дип, менә шушындый чакта әйтәләрдер, мөгаен.

– Ничәнче катта яшисең? Бәлки, тәрәзәң ачыктыр? – Егет минем уйларымнан бихәбәр булып, тагын елмайды.

Эх, иртән тәрәзәнең бер ягын киң итеп, каерып ачып куйган идем дә соң! Бал кортына охшаган бөҗәк әрсезләнеп кереп җитмәсә, ул әле дә шул рәвешле торыр иде.

Тәрәзәне үз кулларым белән шапылдатып яптым да өстәге форточканы гына беркадәр ачып калдырдым. Мондагы кер машиналарына мәдхия укый-укый, бу юлы кара чалбар, кара футболка ишеләрне кочагыма сонып, янә аска төшеп киттем. Менүемә... Кем уйлаган? Югыйсә Регенсбургка килеп, шушы торакка урнашуыма өченче көн, ничә чыгып, ничә керергә өлгердем – моңарчы ишекне, өйдән үк ияреп килгән гадәт буенча гел бикләп йөреш иде. Алай гынамы? Бикләгәч, ышаныр өчен, этеп тә карый идем әле. Хәзер күз күнегә башлады: монда кухня да уртак, һәркемнең әйберсе ничек куйган – шулай тора; берәү дә үзенең порошогын күтәреп йөрми, келлердагы – безнеңчә подвал инде анысы – вешерайда калдыра да

китә. Хәер, әлеге дә баягы, илдән ияреп килгән гадәт – мин генә ванишны үземнән калдырмый күтәреп мендем бит әле менә.

Әлбәттә, татарча уйлаганымның барысын да тәрҗемә итеп тормадым. Бүлмәмнең икенче катта икәнлеген, форточканың ачык калганын җыйнак кына итеп, алманча аңлатырга маташтым. Инглизчәм шәп минем, тик бирегә алман телен ныклап өйрәнергә дип килгәнмен икән, мөмкинлек туган саен телне күнектерә торырга кирәк бит!

– Әйдә, берәр нәрсә уйлап табарбыз!.. – Мине әллә кайчаннан белә диярсең – егет, сабый баланы җитәкләгәндәй, кулымнан әләктереп тә алды. Аның сөякчел бармаклары арасында бәләкәй генә учым юк булды да куйды.

– Исемең ничек? Мин – Райнер.

Казандагы күршебез Райнур абыйга әйтәсе булыр әле, исемеңне чәлгәннәр дип. Алайса, «безнең Кукмарада гына мондый исем» дип, борын чөеп йөргән була...

– Ә мин – Галия.

Кулымны җай белән ялт кына ычкындырдым да Райнердан алга уздым, ишекне ачтым, ишегалдына чыктым.

Ул әллә аптырап, әллә көлеп, башын чайкады. Минем арттан теркелдәгән шәйгә:

– Галэ? Шулаймы? Дөресме? – диде ул, дөрес булмаса, шунда ук төзәтергә әзер бер тавыш белән.

– Гали-я! – дип кабатладым мин, баш бармакка элгән башмакларымның урамда мәзәк тавыш чыгарып чәпелдәвенә игътибар итеп. – Син каян, Италиядәнме? – Өченче каттагы итальян студентларының кайберсе белән танышырга өлгергән идем. Бу сорауны шуңа гына биргән идем.

– Юк, мин шушыннан, Регенсбургтан. Дусларым янына кунакка килгән идем. – Егет кулы белән каршыдагы интернат тарафына, аның артына кулы белән төртеп күрсәтте. – N урамында үз йортыбыз белән торабыз.

– Димәк, син немец милләтеннән? – Әйтәм аны алманча бер акцентсыз, чип-чиста сөйләшә. Круто! Кыяфәте әллә ни дан булмаса да – һәрхәлдә, җирән сакал минем өчен түгел! – тел шәп!

– Әйе. Ә син Франциядән, шулаймы?

Егетнең болай диюеннән иренемне бер читкә кыегайтып, кызганыч елмаерга маташтым. Германиягә килүемә өченче көн – өченче кешегә үземнең һич кенә дә француз түгеллегемне, Россиядән, татар кызы икәнемне аңлатырга маташам. Таш гасырда яшиләр, диярсең – Татарстанның кайда икәнен белмиләр! «Казакъстан?» – диде кичә генә берсе, Та-тар-стан дип, иҗеккә бүлеп, басым ясап әйтүемне колак читенә дә элмичә. «Чуваак!» – дияр иде Владик, әгәр моны ишетсә...

– Ноу! Россиядән мин. Татарстаннан, Казаннан!

Райнер минем җавабымны үзенең кыркылган яктагы баш миендә әйләндергән-тулгандырган арада урам якка караган тәрәзәмнең форточкасына көләргә дә, еларга да белми төбәлдем. Бер юаныч – ул чыннан да ачык иде; тик могҗиза белән каяндыр баскыч тапкан очракта да мин аннан ничек сыярга тиеш? Кайчан да булса форточкадан шуышырга тиешлегемне белсәм, өйдә чагында әнинең өчпочмак-пилмәннәрен чүт кенә азрак ашаган булыр идем...

– Казан? «Рубин»?

Вау! Райнер Казанны, алай гына да түгел, футбол командасын белә?!

– Әйе! – дидем, сөенечемне яшереп тормыйча. – Әллә булганың бар?

– Әлегә юк... Менә бу синең тәрәзәме? – Нечкә генә йөзек ялтыраган чәнти бармагы, минем күз карашыма ияреп, форточкага төбәлде. Райнер, аннан ике кулы белән биленә таянып, тирә-якка күз ташлады.

Минем бүлмә икенче катта саналса да, ишегалдыннан килеп кергәндә, нәкъ беренче каттагы кебек: туп-турыга атладың – шалт та шолт ишекне ачтың... Урам якка чыксаң, аста инде беренче кат тәрәзәләре дә күренә, бүлмәмнең дә шактый биектә икәнлеге күзгә ташлана. Ул як чокырлы-калкулыклы булып, без менә шунда аптырап басып тора идек.

– Син минем шультернга баса аласыңмы?

Шультерн, шультерн... Алманча мин әле бу сүзгә барып җитмәгән идем...

Райнер, моны шунда ук аңлап, ике кулы белән иңсәләренә төртеп күрсәтте. Димәк, мин шунда басып, форточкага үрмәләргә тиеш?

Ужас!..

Казанда Элвин Грей концертында Владикның җилкәсенә утырып, котыра-котыра биегәнем бар анысы. Ләкин ул бит Владик кына, үзебезнең Вәлид иде!

Ә монда беренче очраган немец егетенең – местный бит әле, җитмәсә! – җилкәсенә аяк белән басып, симезрәк мәче сыярлык кына тәрәзә уемыннан керергә тиешмен! Керә алсам...

Тик минем өчен сайлау мөмкинлеге юк иде. Лавр салынган балык шулпасының исе икеләнеп торырга җай калдырмады. Ярар, Владик әйтмешли, «пять минут позора – и ты на работе!» Һай, нәрсә булды соң әле бу, тотам да шул Вәлидне искә төшерәм...

«Позор» ук тоелмаса да, кыска ак шортиктан килеш, башта чүгәләп утырган Райнерның иңсәсенә, аннан стенага тотына-тотына тәрәзә бусагасына басарга маташу бик үк күңелле түгел иде. Ачуны китереп, көлү өянәге дә биләп алды, җитмәсә. Андый чакта тиз генә туктатам, димә, мине. Бу егет кисәге дә минем камырдан булдымы – көлүемне йоктырып, ул да шаркылдый башлады. Көлгән шәйгә аның гәүдәсе селкенә, ә минем ярты гәүдә эчкә шуышырга маташа. «Күкрәкләрем кечкенә» дип зарланып йөри идем, әле ярый шушыннан да зур булмаган, ул чагында кысылып калырга да күп сорамассың монда...

Аякларым эчтә тәрәзә төбен эзләп тапкач кына туктадым көлүдән. Нормально! Чәч – гөнҗәлә, терсәк сыдырылып кызарган, аның каравы – мин бүлмәдә!

Иң беренче эш итеп плитә янына ташландым. Нәрсә булсын ашка? Матур гына пешеп утырган. Зур кашык белән болгаткан арада балык кисәкләре дә күренде. Изелмәгән, тозланмаган, барысы да о’кей, димәк!

Пәрдәне читкә тартып, урамга күз салсам, Райнер, башмакларымны кулына тотып, һаман шунда басып тора. Әй, Алла бәндәсе... Вәлид булса, әллә кайчан ялтырап, ишектән кереп җитәр иде инде...

Караватта яткан телефон, минем янәшәдә икәнне белгәндәй, таләпчән тавыш белән җырларга тотынды. Карамасам да беләм: ватсаптан әни эзли.

Иркен суларга мөмкинлек бирегез миңа! Лассен зи михь майне фрайхайт генисен. Lassen Sie mich meine Freiheit genießen!

– Әни, мин бераз соңрак үзем шалтыратам, яме. Әле сөйләшә алмыйм. Бар да тәртип! – Әнинең: «Нишләп алмыйсың, берәр нәрсә булдымы әллә, ашарыңа бармы, бүлмәң салкын түгелме?..» кебек сораулар тезгәнен көтмәдем, ялт та йолт үзем тезеп салдым да ишекне ачып, коридорга башымны тыктым. Ярдәмчемне бүлмәгә чакырыргамы, әллә, рәхмәт әйтеп, ишек төбеннән борып кына җибәримме?.. Керсен әле, немецча сөйләшә-сөйләшә чәй эчәрбез...

Ул минем бүлмәне бик җентекләп карап чыкты, ревизор диярсең! Хәер, бүлмә тек бүлмә инде. Берүземә бик җиткән! Бирегә килгән студентларның барысына да эләкми әле ул, кухнясы үзендә, юыну бүлмәсе үзендә. Душ кабинасына тиклем бар! Килер алдыннан анкета тутырганда: «Общага өчен нинди таләпләрегез бар?» дигән графага «университетка якын булсын» дип язган идем, менә, нәкъ шундый тулай торактан әзерләп куйганнар! Аның янәшәсендә психоневрологик интернат барын башта белмәгән идем белүен. Хәер, Германиядә андый интернатлар да, мондый авырулар да бик күп икәнлеген, җәмгыятьнең бу хәлне бик тыныч, гадәти кабул итүен килгән көнне үк әйтеп куйдылар, куркырга кирәкми дип, үзләренчә юаттылар да хәтта...

Райнер, рөхсәт сорап, шүрлектәге китапларымны алып карады, бауга тезелгән фотографияләрне дә өйрәнгәндәй итте.

– Бу – минем әти, монысы – әни. Монысы – дус кызларым, монысы майн фройнд... – дип таныштырып та алдым.

– Аңламадым, монысы да егетең, монысы да? – дип гаҗәпсенеп сорап куйды ул, Кол Шәриф мәчете янында дусларым белән төшкән фотода Владикка, Ленарга, Азаматка аерым-аерым күрсәтеп.

– Егетем түгел. Алар минем дусларым!

Аңлаштык: немецча «дустым» һәм «дус егетем» төрлечә әйтелә икән. Майн фройнд дисәң – минем дустым, безнеңчә, егетем дигән сүз; айн фройн фон мир – бер дустым дигәнне аңлата.

Менә бит, беренче дәрестә үк файдалы мәгълүмат!

Әле генә танышкан немец егете белән бер тәлинкәдән (чөнки минем кухняда әлегә бердәнбер!) балык ашы ашап утырганны, аның үз гомерендә беренче тапкыр, мин кыстаганга гына сөтле чәй эчеп караганын, шул «блюдо»га шаккатканын телефоннан сөйләсәм, әнигә шунда ук шок булачак! Юк, Райнерның чәйгә шаккатуын ишетүдән түгел... Минем, үз бүлмәмә! Егет затын кунакка чакыруым! Аның белән икәү чөкердәшеп сөйләшеп утыруым! Егетнең немец милләтеннән булуы!!! Моны ничек башка сыйдырмак кирәк?..

Райнер Германия, Регенсбург турында тарих укытучысы шикелле бик оста итеп сөйләде. Үзе университетта юрист булырга укый икән. Вәт кругозор кешедә! «Кругозор» дигәнне немецчага да, татарчага да тиз генә тәрҗемә итә алмадым, дөньяга караш диюем әллә ничек, таррак булды да калды.

Без аның белән әллә кайчангы танышлар шикелле быдыр-быдыр сөйләштек тә сөйләштек. Шәп! Әгәр көн саен мин телемне шулай алманча игәүләп торсам, С 1 дәрәҗәсенә барып җитү өчен ничә ай кирәк булыр икән?..

Райнерны озатуга, айфонның янә сабырсызланып, тавыш бирүен көтеп тормадым, видеозвоноктан әнигә шалтыратырга ашыктым.

– Бая тавышың мәзәгрәк иде. Берәр нәрсә булмагандыр бит? – Әнидән мин көткән сорау!

– Бар да яхшы, әни! Бүлмәмдә кунак бар иде. – Әйттем инде. Барыбер телем кычытып торачак...

Ишек бикләнүе турында да, Райнер белән икәү чәй эчүебезне дә тәфсилләп сөйләп алдым. Әнинең йөзе башта аптыраулы төскә керде, аннан беркадәр борчылу, тора-бара курку, шелтәләү төсмере дә чагыла башлады.

– Алдыңны-артыңны карап йөр! Нимес егетенә күзең төшә күрмәсен! Әбиеңә әйтә күрмә ялгыш... Нимесләр бит алар...

Нәрсә дип әйтим... Бу очрашу да, әнием белән сөйләшү дә, гәрчә кырык кат ишеткән сүзләр булса да, миндә ят, сәер бер тойгы уятты. Яңа кешеләр, яңа төрле яшәү рәвеше белән танышу нәтиҗәсе дисәм, үземне дә, башкаларны да алдармын кебек. Күңелемдә – аңлаешсыз тойгы. Мин әле Германиягә, аның кешеләренә ияләшеп кенә киләм. Бу илне яңача кабул итәсем, өйдә әбиемнең, әнинең минем башка сеңдерергә тырышканнарын кире кагасым, дөньяның бер урында гына тормаганлыгын, алга барганын, үткәннәрдән качу кирәклеген раслыйсым килә. Урамда – егерме беренче гасыр! 75 елга якын элек булган сугыш вакыйгаларына кат-кат әйләнеп кайту, аның өчен бүгенгеләрне гаепләү кемгә, ни өчен кирәк? Мәсәлән, миңа кирәкми! Ни өчен әле бүгенге яшь алман егет-кызларын мин үземә дошман итеп кабул итәргә тиеш? Әйе, бәлки, аларның бабайлары кайчандыр СССР дигән илгә каршы сугышкандыр, тик оныкларның ни гаебе бар? Һәм мин ни өчен аларга якынаюдан куркырга тиеш?

Яшермим: тарихтан, сәясәттән белемем белән артык мактана алмыйм. Тик, алай дигәч тә, Бөек Ватан сугышы турында берни белмим, диюем түгел. Мәктәптә дәреслекләрдә нәрсә язылган – шуны укыдым, шуны кабатлап сөйләп, билге алдым. Мин генә түгел, барыбыз да инде. Май ае якынлашса, реферат язарга, презентация ясарга кушып теңкәгә тияләр иде анысы. Аннан кем инде баш авыртуы ясап торсын: фото куясың, сугышта катнашкан бабаңның кайда туганлыгын, нинди фронтта булганлыгын, орден-медальләрен санап чыгасың – менә сиңа презентация. Түбән сыйныфларда укыганда, бөтенебезгә әниләр йә укытучылар язып бирә иде, шул бер биография бит инде ул – унберенчене бетергәнче бизәлешен генә үзгәртеп, тик ияреп йөри.

Мин бабайларымны күреп калган кеше түгел.

Әтиемнең әнисе Миңлегөл – хәзер безнең белән Казанда яши. Авылда нигезен калдырып, шәһәргә килгәч биреште әле ул. Биреште дип, туксан яшь тулганда, шулай йөреп торгач, шәп инде! Күзлексез җеп саплый! Колагы ишетеп бетерми бетерүен, алай да үзенә кирәген эләктереп ала! Хәтере – супер! Хан заманындагы вакыйгаларны елы-ае белән искә ала, егыл да кит. Мин монда кичә ятлаган сүзлекне бүген искә төшерә алмый тинтерим... Менә аның әтисе – Газизулла бабай Бөек Ватан сугышында катнашкан. «Хәбәрсез югалды» дигән кәгазь генә килгән, шуның белән вәссәлам. Иске альбомда саргаеп беткән, йөзләре рәтләп күренмәгән дә бер фото бар, артына «Сагынмалыкка бер истәлек. Газизулла, Хәнифә, кызларыбыз Миңлегөл, Рәйханә белән. Төшелде Сахалинда, Октябрьский пасёлыгы, Медвежка пункытында. 1941 йыл, дүртенче гыйнвар» дип хаталы итеп язылган. Шуннан гайре ул Газизулла бабай турында берни белмим диярлек. Әбием, ул фотоны кулына алса, торып-торып: «Кит инде,

шул гомер кеше тиклем кеше хәбәрсез була аламыни, сөякләре кайларда череп ятадыр», – дип, күз яше түгеп ала. Шуңа күрә әни, йөрәген бозмасын дип, ул альбомны балконга, иске төргәкләр янына яшереп тә куйган иде. Тапмас диген! Бервакыт әбием: «Ник шулай кадерсезләп аттыгыз? Хәбәрсез югалды дигәч тә, ул минем әткәй бит!» – дип, сабый бала кебек еламсырап күтәреп кергән иде. Шуннан бирле ул фото залда, стенканың өске киштәсендә тора.

Миңлегөл әбиемнең ире Әхтәм – анысы да минем бабай була инде – сугыштан исән кайткан кайтуын. Тик башта немецларда әсирлектә булган, аннан кайткач, безнең илдә төрмәдә утырган. Аның турында әти дә артык белми бугай, белеп тә, безгә әйтмәде микән. Әллә бабай чыннан да беркемгә берни сөйләмәгәнме – монысы миңа сер. Мин туганда, Әхтәм бабай үлгән иде инде, авылда әбием ялгызы гына көн күрә иде.

Мәктәпкә дип, реферат язып биргәндә, Әхтәм бабайның әсирлек еллары турында әни бер сүз дә кертмәгән иде. Университетка укырга кергәч кенә, бабай биографиясендә кайбер елларның җитеп бетмәвенә игътибар иттем мин. Шул чагында әти: «Әткәй пленник булгач, телен теш арасында тотарга күнеккән иде, салып алган чагында гына бераз сөйләп ала, айнык чагында ул темага сүзне келәшчә белән дә тартып чыгарып булмый иде. Эх, сөйләтеп калмаганбыз шул!» – дип ачынып әйтеп куйды.

Ике бабайның берсен дә күреп белмәгәнгәме, мин аларның язмышын да, фаҗигасен дә Миңлегөл әбием кебек кабул итә алмыйм. Тормыш шулай бара инде. Сугышлар да булган, кемнәрдер үлеп калган, кемдер кайткан. Ә без бит яшибез, бүгенге белән, киләчәк белән яшибез!

Минем грант буенча Германиягә укырга китәргә җыенганымны белгәч, әбием үпкәләде. Гомер булмаганча, каты итеп, ныклап. Башка чакта: «Яшьләрнеке яшьләрчә. Үзең кара», – дип, җиңел генә көлемсери торган әбиемне алыштырып куйдылар, диярсең: ике аягыңның берсен атлатмас идем дип, каты-каты сүзләр дә әйтеп ташлады.

– Туксан яшем тулганда, шушындый хурлык күрермен дип уйламаган идем! – диде ул, әйтерсең, мин бер-бер җинаять кылган!

– Столько не живут! – дип, үзалдыма уенга борырга тырышуымны бик тиз ишетеп, үпкәсе тагын да көчәйде.

– Бөтенебезнең тормышын җимерде шул ләгънәт фашистлар! – диде әбием, агач каләм кебек катыланып, ялангачланып беткән бармаклары белән күз төбендәге җыерчыкларга тулган яшь тамчыларын сөртә-сөртә. – Әткәйнең хәбәрсез югалды дигән кәгазен тотып, никадәр зык күрдем!.. Бүтәннәр шикелле фронтовик баласы дип тә, чутка кертмәделәр бит мине! Каһәр суккан Гитлер аркасында! Тәмугта да муены асты-өстенә килгере!..

Миңа авыр иде. Бу буын кешеләренең хәзерге Германия һәм Гитлер – икесе ике төшенчә икәнен аңламауларын аңлау авыр иде.

Артык сүзләр сөйләмәсәләр дә, әти белән әнинең дә карашларын беркадәр чамалыйм. Аларның да бу ил турында күзаллаулары фашизм темасыннан ерак китми кебек...

Һаман бер сорау башымда бөтерелә әле: артка әйләнеп карау кирәкме соң ул, кем өчен кирәк? Йозакка биклә дә куй, ачкычын ыргыт. Кая ташлаганыңны оныт. Үткәннәр тик калсын шунда бикләнеп... Киләчәк

белән яшәргә кирәк. Урамда – егерме беренче гасыр, яңа гасыр! Ерак бабам Газизулланың Германия белән сугыштан кайтмавын, хәбәрсез югалуын, Әхтәм бабамның әсирлеккә эләгүен сәбәп итеп, мин бүген бу илне дошман күрергә тиешме? Теләсәң, үзеңнекендә дә тирә-яктагы һәркемне шулай кабул итәргә мөмкин. Подъездда чүп савыты янына көн саен аракы шешәләре тезеп куйган күршеләрне. Мәктәптә синең фикереңне түгел, китапка язып куелган әзер җавапны гына таләп иткән кайбер укытучыларны. Автобуска сыңар аягың белән атлауга, «оплачиваем проезд!» дип, котсыз тавыш белән каршыңа килгән кондукторны. Көн саен өй телефонына шалтыратып: «Без пластик тәрәзәләрне бушлай тикшерәбез...» – дип, теңкәгә тиючеләрне. Елга буенда ял иткән җирләрендә үз артларыннан бер өем хәшәрәт чүп калдырып киткәннәрне. Юлдан «зебра» аша чыгып барганыңны күреп тә, өстеңә менәрдәй булып узып киткән шофёрларны. Поликлиникада сорау бирергә дип кабинет ишегеннән башыңны тыксаң: «Не видишь что ли – у меня человек сидит!» – дип акырып җибәрергә генә торган участок табибын. Анда человек утыра! Әйтерсең, мин кеше түгел – курчак... Әйтерсең, минем бер-бер гаебем бар.

Тукта! Бәлки, чыннан да, минем гаебем бардыр? Дөньяга тууымда. Кеше булып яшәвемдә. Кайсыдыр илдә, кайсыдыр шәһәрдә көн күрүемдә... Кызык. Күршенең, укытучының, кондукторның, табибның... гаебен бик тиз таптым бит. Барысы да гаепле икән, ул «барысы да» дигән төшенчәгә мин дә керсәм?..

Ай, әллә нинди катлаулы, борма-борма сораулар белән башымны катырмыйм әле. Әти миңа бәләкәй чагымда ук: «Холкың тач Миңлегөл әбиеңнеке», – ди иде. Әллә хаклы булган инде? Кара, карт әбиләр шикелле, ничек фәлсәфә корып утырам!

Киттем әле.

Дайте мне насладиться свободой!

Иркен суларга мөмкинлек бирегез миңа! Лассен зи михь майне фрайхайт генисен. Lassen Sie mich meine Freiheit genießen!

Газизулла, 1939 ел.

> Алыслардан гына күренә микән Агыйделкәйләрнең ак ташы?
> Кайда гына йөрмәй, ниләр күрмәй татар иркәенең сау башы...

Кичәле-бүгенле Газизулланың теленнән шушы җыр төшми. Колагына аю басмаса да, моң дигәнең чишмә-чишмә итеп бирелмәгән анысы. Шулай да җырлыйсы киләдер инде. Сөйләшеп булмый, уйлаганыңны кычкырып әйтә торган түгел, кайчагында башыңа килгән уйлардан үзең дә өркеп китә торган заман шул, җырлап юансаң гына... Ул аны әллә ничек итеп, борын астыннан гына, иреннәрен ачар-ачмас кына, бәгыренең әллә кай җиреннән өзеп-өзеп кенә алып җырлый. Сүзләрен дә үзенчә үзгәртеп бетерүе, башкорт ягыннан булган баҗасы Ирәндеккәйнең ак ташы дип көйгә салса, Газизулланың Агыйдел дип өзгәләнүе.

– Карасана, әллә соң Иркенбайның хәлен белеп кайтасыңмы? – Хәнифә, мич сыларга дип әзерләгән измәне кулы белән янә бер кат болгаткан

җиреннән, сабыр булырга тырышып, шулай диде. Ишек кашагасы ясап булашкан иренең, дөньясында берүзе калган кешедәй өзлексез җыр шыңгырдатуы яшь хатынның теңкәсенә тигәндәй иде. Җитмәсә, измәнең әллә комы, әллә кызыл балчыгы азрак булганмы – бер дә йомшак кына, уңай гына килгәндәй түгел. Елганың көтү йөргән аръягыннан җыеп кайткан ат тизәген күбрәк кушып җибәргәнме...

– Үзем дә уйлаган идем аны... – Газизулла эшен төгәлләгән икән, түргәрәк үтеп, үзе ясаган ишеккә сынаулы күз белән карап торды. Канәгать иде, ахрысы, биленә буып бәйләгән киндер алъяпкычын сүтеп ташлады. – Кайтышлый Хәкимулла абыйга сугылып, Миңлегөл белән Рәйханәне дә кереп алырмын, бүген үзебездә йокларлар.

Хәнифә, иренең сүзләренә сәерсенеп, башын күтәрде. Ни сәке ясалмаган, ни мичнең эше бетмәгән, ашыкмаса да ярар иде, өй эченә бераз кот кунгач кына иркен сулап урнашырлар иде. Шулай да иренә каршы килергә базнат итмәде:

– Ярар, атасы. Идәнгә тезелербез дә ятарбыз, – диде ул, маңгаена төшереп бәйләгән бөрчекле яулыгы астыннан янә сабыр караш ташлап. – Җәһәт кенә сылап бетерсәм, иртәгәгә кибеп тә куяр. Акшарлап, агып та җибәрербез. Көлгә көлчә тезәрбез, Алла боерса. – Хатынның әлегәчә моңсурак йөзенә сизелер-сизелмәс кенә яктылык йөгерде, ике каш арасына нәзек кенә булып сузылган буразна да языла төште, муенындагы гәрәбә муенсадан кояш нуры агылды. Тик әлеге нур шул минутта ук күләгәгә әверелде дә төпсез күлдәй күренгән куе зәңгәр күзләргә ягылды. – Улкаемның җаны оҗмахтадыр, әй, төшемдә матур итеп күрдем үзекәен... – Сыгылмалы куе керфекләр күбәләк канатыдай лепердәп куйды.

– Без генә монда тәмугта калдык... – Яшь атаның да кояш ашаган какча йөзе тагын да каракучкылланды, яңак сөякләре биеште. Күмердәй күзләрендә ачу, үпкә, рәнҗү – әллә ничә тойгы барысы берьюлы чагылып алды.

– Алай димә. Безгә язганы шулдыр... – Хәнифә, кеше-мазар тыңлап тора күрмәсен дигәндәй, тәрәзәгә борылып карады.

– Киттем. Чардуганның тактасы кубарга итмәде микән, аны да караштырасы булыр....

Яңа ишек тавышсыз гына ачылып ябылды.

«Ниләр күрмәй татар иркәенең сау башы...»

Ирнең әрнү тулы күңеле янә шушы сүзләр булып ыңгыраушты.

Газизулланың озын чандыр гәүдәсе зират ягына борылып, күздән югалганчы, Хәнифәнең кулы эшкә бармады. Ул әле пыяла өлгеләре ныклап утырып та бетмәгән яңа тәрәзәдән урам очына төбәлеп каткан килеш кадакланып торуын белде. Бер бирелгән гомерне адәм рәтле итеп, түгелмичәчелми генә яшәсәң икән лә ул... Эшләгәненнең куанычын күреп, балаларың белән чөкердәшеп, булганына шөкер итеп. Юк бит, юк. Учка сыярлык бәхетеңә сөенергә дә өлгермисең, капыл кына чайпалдыралар да куялар...

Хатын, болай басып торса, йөрәк турысыннан күтәрелергә иткән кайнар дулкынның күзләргә тозлы тамчы булып бәреп чыгасын чамалады да көрсенеп, мич алдына иелде. Кулына ягылып калган яшькелт-соры балчык җыерчык-җыерчык ясап кибәргә өлгергән иде, дуамал хәрәкәт

белән ләгәнгә уң кулын батырып, баягыча измәне әвәләргә тотынды. Гүя ат тизәге, ком, кызыл балчык, җирдән килеп җиргә киткәннәрнең кисәтүле авазы булып уфылдый, сызгыра, елый; Хәнифә исә, тыңларга да, ишетергә дә теләмәгәндәй, аның саен отыры усалланып, бармаклары, йодрыгы белән измәне болгата, тәя... Бераздан тынычлана төште, хәрәкәтләре салмакланды. Аның кулларына карышусыз буйсынган ләгән дә идән тактасына дык-дык килеп бәрелүдән туктады. Хәнифә, сыйфатын тикшерергә теләп, балчыкны учына йомарлады да, бармакларына җылылык таралганын көтеп, берничә минут шулай тын торды. Әйтерсең, ул яңа гына салынган мичне сыларга түгел, курчаклар ясарга җыена. Шушы балчыктан курчакның үзең теләгәнен әвәләргә мөмкин шул: берәвесен, әнә, башын югары күтәртеп, бөркет карашлы итеп яса; икенчесенә, җилкәсен җиргә иелдерерлек итеп, бөкре яса; өченчесенең муенына җеп тагып куй да үзең теләгән көйгә биет...

Хәнифә, сәер уйларына ияреп, чыннан да курчак ясап маташуын үзе дә абайламаган иде. Учында йомры башлы бала сыны пәйда булгач кына айнып киткәнен тойды. Утка пешкәндәй, аны ләгәнгә ыргытты. Бер яше тула дигәндә, тәпи басып, «әннә» дип теле ачылып килгәндә, гүр иясе булып куйган Иркенбаен уйлады да тагын җаны актарылды.

Мичне барыбер сыларга кирәк иде. Газизулласы, әнә, балаларны алып кайтам, диде бит. Үзебезнең йортта йокларлар, диде...

Әрле-бирле агылган уйларның башы да, азагы да юк иде.

Кеше дигәнең дә балчыктан яратылган яратылуын, шулай да курчак түгел бит. Яшәргә, чәчәк атарга, дөньяга ямь бирергә омтылган җаны бар аның. Шул җанны җепкә тагып уйнарга теләүчеләр күбәйде, хәерле булсын...

Яңа өйдә яңа тормыш башлау язмаган булып чыкты...

Ишек бикләнде. Хәкимулла, авыр көрсенеп, ачкычны үзенең чалбар кесәсенә салып куйды. Нидер әйтеп туктатырга теләгәндәй, энесенең уң як җилкәсенә тотынды да кулын кире алды.

Таң куенына сыенган ихатада тузан сарылырга өлгермәгән сусыл үлән исе, җәй исе аңкый иде. Ул татлы ис, ни хикмәттер, күз-керфекләргә килеп ягыла. Ягыла да ачы бер тәмгә әверелеп, бит очына түгелергә итә.

– Кузгалыйк. Юл кешесенең юлда булуы хәерле. – Газизулланың тавышы карлыккандай иде.

Тамакка да, сулышны кысып, төен тыгылган шикелле шул.

– Килен, юлга дигән ризыкларны Кафия апаң кәрҗингә таслап тутырдым, диде, андагы әйбер-караны үзең хәтергә алырсың инде.

– Мең бәхил без сездән, Хәкимулла абзый, мең бәхил! – Хәнифә, авыз читен юка яулыгы белән каплый төшеп, рәхмәт тулы яшьле күзләрен Хәкимулладан яшерде. Йокылы-уяулы ике кызын җитәкләп, авыз эченнән догасын укый-укый, капка төбендәге ат арбасына таба юнәлде. Яшь хатынның аркасына төшеп торган яшькелт яулыгы, канатлы ак алъяпкычы, ситсы күлмәгенең бала итәге таң җиленең үзәк өзгеч өрфия моңында коена иде. Бу минутта аны берчә нәзек ак каенга, берчә туфрагыннан тамыры белән кубарылган яран гөлгә охшатырга мөмкин иде. Дүртпочмаклы яулыкларга төйнәлеп, юл букчасы кыяфәтенә кергән барлы-юклы йорт малы, көянтә-бауга асылган да хатынның аркасында һәм күкрәк турында, котылгысыз мәңгелек нужа һәм язмыш йөге булып, әкрен генә тирбәлә.

– Казанга имин генә барып җитсәгез, вербовщик үзе табар сезне. Аймыл гына булмагыз инде берүк...

– Ярар, абый, борчылма. Юл йөрмәгән кеше түгел...

– Җир читенә булса да, кайтмас җирләр булмас әле.

– Баш исән булса, белмәссең, кайтып та төшәрбез...

– Дөньясы гел болай тормас, бер рәтләнер...

– Ай-һай... Ул дөнья дигәнең кара козгыннар кулына калгач, белмим инде, абый...

Агалы-энеле Хәкимулла белән Газизулланың ярымпышылдап кына саубуллашуын күршедә уянып аваз салган таң әтәче бүлде.

– Йә, хуш иттек, абый. Син, ни... хәтергә ал инде... Улым да... Әткәй-әнкәй дә... рәнҗеп ятмасыннар...

Сатлык тавыш янә карлыгып чыкты.

– Каберләре караулы булыр, энекәш, борчылма.

– Менә безнең сөякләргә кайда ни язгандыр...

– Юк белән баш катырма. Әле безләргә яшисе дә яшисе. Анавы кызларыңны кияүгә биреп, оныклар сөясе...

– Һай, абый, илкәйләрендә бәндәгә сан булмагач, тумаган оныкларны кызганып еларлык...

Күз күрмәгән якларга менә болай ашык-пошык, кача-поса дигәндәй капыл кузгалу үзе бер җан ярасы булса, хушлашу мизгелләре ул ярага учлап-учлап тоз сибә. Атның хәйран җитез юргалавына ияреп тәгәрәгән тәгәрмәчләр көендә – һәр авазыннан әрнү-әрнү булып түгелгән аерылу сагышы. Ка-ла-лар... Тау-ларым... Чиш-мә-ләр... Ни-ге-зем... А-вы-лым... Шулай дип җырлый арба, әнкәләренең итәгенә баш салып, татлы йокыга изрәргә өлгергән кызларның шушы авылда мәңгелеккә калган балачагы, Хәнифәнең карт атасы белән карт анасын кызганудан телгәләнгән бәгыре, Газизулланың гаҗизлектән ни кылырга белмәгән, ирен читләренә буразна-буразна сыланган җан сызлавы булып җырлый арба. Юк, җырламый, елый: мәңгелек сәфәргә дучар ителгән татар иренең язмышын үзенең тәгәрмәче белән сытарга-изәргә мәҗбүр булуын аңлап елый.

Кузгалырга кирәк иде. Энесенең баш очында кара болытлар куера башлавын, бүген булмаса, иртәгә кара төндә аның артыннан килеп җитәчәкләрен райондагылар аша белеп өлгергән Хәкимулла абыйсы: «Ничек җитезрәк җыена аласыз – шул минутта чыгып китәсез», – диде. Санаулы сәгатьләр эчендә бу юлы да аяк киенделәр.

Шушы көннәрдә генә тирә-як авылларда вербовщик йөреп, бик күпләрне Сахалинга – кемне шахта эшенә, кемне балыкчылыкка китәргә үгетләгән иде. Аның тәкъдимен кара шәлле язмыштан котылу юлы дип санамаса да, абыйсының кисәтүеннән соң әлегә башка чара юк икәнен чамалый иде Газизулла. Заманы – шайтанныкы: кешеләрне берәм-берәм кемдер чүпли тора, моны алып киткәннәр, тегене... Әлләкем төн уртасында бөтенләй юкка чыкан: хатыны да, ата-анасы да берни белми...

Бөҗәк урынына югаласы килми иде! Дөньяга курчак булып түгел, кеше булып туганыңны раслыйсы килә иде! Гади генә бәхеткә тиенеп, Кеше булып яшисе килә иде.

Тик... татар ире өчен моны раслау шактый кыйммәт хак сорый иде. Моны

раслар өчен аңа туган туфрагыннан кат-кат кубарылып, кыйтганың җиде почмагыннан бәхет күләгәсе эзләп йөрергә; аннан, җирсү хисенә чыдый алмыйча, баш орырга дип, нигезенә кайткач, янә, янә, үз яшьтәшләре, үз кавеме, үз авылдашларының хөсетлегеннән зык күреп, ишек-капкаларын, тәрәзә капкачларын бикләргә, билгесезлеккә күз текәп чыгып китәргә; караңгы шахталарда күзләре чепиләнгәнче, күкрәген таш басканчы кемнеңдер убыр авызына тутырыр өчен таш кисәргә, кара урманнарда кул тиреләре суерылганчы, җаны бугазына җиткәнче агач аударырга; бүтәннәргә дан һәм биеклек яулап бирер өчен адәм ышанмаслык кыюлыклар күрсәтергә, утлар-сулар кичәргә, аннан, җаны гарешкә ашкач, тән-күлмәген иңдерер өчен җиде ятның туфрагын үзенеке итәргә кирәк иде шул.

Әлегә Газизуллада бер генә теләк: кызларын, Хәнифәсен Сахалин дигәннәренә исән-сау алып барып җиткерергә насыйп итсен. Әнә бит, вербовщик анда фатир дигәннәрен дә ышандыра, акчасын да хәтәр мул төшәрдән вәгъдә итә; ашау ягы да мондагыларның төшенә дә кермәгән, ди. Татарлар бик күп җыелды, ди, анысы да күңелгә бер тамчы сөенеч. Үзеңнеке кайда да үз булыр әле... Шахта дигәннәрендә дә ике аяклы, ике куллы кешеләр эшлидер, бездән артык җирләре юктыр...

Алыслардан гына күренә микән Агыйделкәйләрнең ак ташы?
Кайда гына йөрмәй,ниләр күрмәй татар иркәенең сау башы...

Һай, бу җыр... Бәгырьнең әллә кай җиренә чәнчеп-чәнчеп, йөрәкнең болай да сулык-сулык килеп торган чи ярасына яңа сызлау өстәп, тел очына килә дә бөяләә... Йөртә шул язмыш, җил тәгәрәткән дүмгәләк булмасаң да, булырга теләмәсәң дә, синең ай-ваеңа карамый... Үз илкәйләреңдә кол кебек яшәргә дип яралмасаң да, кол итеп күрәләр шул. Шулай булмаса, туган туфрактан аерылып, җир читләренә чыгып китәр идеңме?.. Җәсәдеңне шушы туфракка кемнәр алып кайтыр да кемнәр җирләр, дисең... Исән чагыңда кирәксенмәгәнне... Аллаһ колы итеп яралтылганнарны бәндә заты кол итәргә маташсын инде...

Хуш, туган җир! Хуш, кендек каны тамган, үз куенында сөекле әткәй-әнкәсен, газиз улын җылыткан туган туфрак! Газизулла синнән бәхиллек сорап, ерак сәфәргә кузгалды. Ишекләр дә, юллар да вакытлыча гына бикләнерме, әллә гомерлеккәме – фараз кыла торган түгел шул...

Галия, 2019 ел

Райнер мине Дунай буена чакырды. Дөресрәге, ул бик теләп, минем өчен гид роленә алынмакчы: Регенсбургның тарихи урыннарын, Альтштадтны, музейларны күрсәтергә вәгъдә бирде.

Көн дә искиткеч бүген: алманнарның сентябрь кояшы җәй илендә адашып калган, кыздырыпмы-кыздыра. Күктә күгәрчен канаты тиклем дә болыт күрмәссең, баш очына төпсез зәңгәр чиксезлек эленгән.

Тәк... Шәһәр буйлап җәяү атлаганда, аякка иң уңайлысы – менә шушы ак кроссовкам булыр. Зәңгәр джинсы чалбарның беркайчан модадан чыгасы юк; бернинди бизәксез ак футболкамны кисәм – чемоданга сыеп килгән гардеробымнан иң-иң дигәннәре шушылар. Казанда универга йөргәндә,

нәрсә кияргә – итәкнеме, комбинезоннымы, әллә быел модада булган оверсайз күлмәкнеме; ничек бизәнергә дигән сораулар урамга чыгарга җыенган саен чабуга килеп бәйләнсә, монда ул яктан рәхәт! Әйтерсең, шәһәрнең бөтен яшьләре сүз берләшкән: һәммәсендә диярлек джинсы чалбар, гадидән дә гади футболка, кроссовка яки кеды! Иң кызыгы – каш ясаткан, керфек үстергән, иннек сөрткән, маникюр ясаткан беркем юк диярлек! Мюнхен аэропортыннан Регенсбурга килгәндә үк, поездга кергән-чыккан һәр кешене күзәтеп, шундый ачыш ясаган идем. Килгән көннәремдә тавис канатыдай төрле төсләрдә балкыган тырнакларымны кичә бер җәлләми чистартып аттым! Үстерелгән керфекләр белән бер ай йөрисе бар барын, аларны берәмләп йолкып утырып булмас...

Озын толым итеп үргән чәчемә генә кагылмыйм, толым – минем бренд!..

Без кампус янында сәгать икедә очрашырга сөйләшкән идек. Алманнар төгәллеге юк шул миндә – ни ашыгып атласам да, төп-төгәл җиде минутка соңардым! Райнер болай дип сүз катмады катмавын, мин сәлам биреп, кул болгаган мизгелдә айфонына гына күз төшереп алды – сәгатькә каравы дип аңладым.

– Амсорри! – дидем мин инглизчә. Күрәсезме, миндә инде вакчыллык формалаша башлады! Владик белән киногә-мазар барганда, җиде түгел, унҗиде минутка соңаруымны да шулай тиеш дип кабул итә идем, ә монда үземне гаепле хис итү тойгысы баш калкытырга маташа! Менә монысы миңа ошамый! Райнер да егет кеше ләбаса. Кызларның печтеки генә соңга калу гадәте барлыгын белергә тиеш!

– Автобус өч минут элек китте. Алдагысы унике минуттан киләчәк, – диде ул, искиткеч сөенечле хәбәр җиткергәндәй, бөтен йөзенә елмаю таратып. Аркасына аскан әфлисун төсендәге рюкзагы, хаки төсендәге кыска балаклы спорт чалбары һәм кыска җиңле күлмәге, яланаякка кигән яшькелт кроссовкасы аны бераз баласытып күрсәтә иде, походка җыенган яшүсмер кебегрәк тоела. – Теләсәң, Альтштадтка җәяү атлый алабыз...

О, Регенсбург! Нинди гүзәл икән син! Иске үзәктә шулкадәр тар урамнарга килеп юлыккач, хис-тойгыларыма чыдый алмыйча, аһылдап куйдым. Кара-каршы салынган йортларның тәрәзәсеннән бер-берең белән кул сузып исәнләшергә буладыр монда... Аскы каттагы кибетләрнең ялтыр пыяласыннан антиквариат товарлар, алманнарның милли киемнәре, кулдан тукылган келәмнәр күренеп тора.

– Бездә уникенче, ундүртенче гасырдан калган крепостьлар, чиркәүләр бар, аларын Weißgerbergraben урамына чыккач күрсәтермен, – диде Райнер, минем белән зур сабырлык кирәк булачагын шунда ук чамалап.

Чөнки күзләрем курчак театрындагы шикелле төрле төсләрдә, төрле стильдә балкыган иске йортларның кайсына тукталырга белми: кызыл түбәле, кайсы ак, кайсы алсу, кайсы пестә төсендәге таш стеналар буйлап чабыша. Һәрберсе турында төпченә башласам, экскурсия өчен бүгенге көн түгел, айлар да җитмәскә мөмкин. Урамның бер башындагылары готика стилендә булса, икенче якта барокко стилендә төзелгәннәре, ренессанс чорында салынганнары тезелеп киткән. Вау! Бөтен җирдә немецларга хас булган төгәллек, тәртип ярылып ята, ягъни орднунг!

Галәмәт тар урамның берсендә Оскар Шиндлерга куелган истәлек

тактасын күреп, тагын аһ-ваһ килдем. Сугыш вакытында бик күп яһүдләрне коткарып калган бу гуманист немец фабриканты турында өйдәгеләр белән диванга тезелеп, «Список Шиндлера» дигән фильм караган идек – шул исемә төште.

– Бу йортта шушы мемориаль такта гына... Әнә тегендә – бөек Иоганн Кеплер урамы, менә аның музее бар. Борылгач күрсәтермен. Тик кереп тормабыз, искитәрлек экспонатлар юк анда... Кызыгы шунда – Кеплер безнең Регенсбургта соңгы өч аен гына яшәгән, барыбер урамга аның исемен биргәннәр!

Райнер, иңсәсеннән шуып интектергән рюкзак бавын рәтли-рәтли, кулы белән әле уңга, әле сулга төртеп күрсәтә-күрсәтә, канатланып сөйли дә сөйли. Ә мин, аңа сиздермәскә тырышып, тиз генә айфонымнан интернет битен ачарга маташам... Кеплер, Кеплер... Оят инде, тик мин бит аның кем икәнен белмим! Әһә, таптым! Бөек галим, немец математигы, кояш системасындагы планеталар хәрәкәтен беренчеләрдән булып ачучы диелгән...

Эх! Тагын бер тапкыр эх! Былтыр, үзебезнең университетта, татарча шәп белгәнемне сәбәп итеп кенә, мине бер конференциягә кертеп җибәргәннәр иде. Кеше саны булсын өчен. Мин, җүләр, чыннан да, шул «сан» булып кына утырганмын түгелме? Алай дисәң... Әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов сөйләгәндә, уянып киткәндәй, бик кызыксынып, авызымны ачып тыңлап утырган идем. Шунда кайсыдыр төрки шагыйренең Коперник, Галилей, Бруноларга кадәр әллә ничә йөз ел алдан ук «җир кояш тирәли әйләнә» дип язганын мисал итеп китергән иде, шигырьдән өзек тә укыды. Анысын хәтерлим, ә менә кем ул төрки шагыйре? Нинди әсәр язган – оят, хәтеремдә калмаган, мин аны белмим! Кызганыч, миндәйләр бик күп бит. Мәктәптә үзебезнең татар тарихын ничә дәрестә өйрәттеләр икән безгә? Француз геройлары, рим императорлары, патша-кенәзләр турында ел саен, унберенчене бетереп чыкканчы кырык кат укыганбыздыр, тик татар, төрки дөньясының тарихы, шәхесләре турында өч-дүрт дәрес тәтеде микән – истә дә калмаган... Ә менә яшьтәшем, минем кебек үк гап-гади студент, алман егете үз шәһәренең, үз милләтенең һәр тарихи ноктасын, шәхесен белә, аны бөек дип атый...

«Звонок другу» дип, берәрсенә тиз генә аудиотавыш яздырып җибәрсәм? Минем дә мактаныргылыгым булыр иде. Тик җавап килеп ирешкәнче поезд китеп барачак бит... Яшәсен интернет! Сәйф Сараи! Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүен «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәрендә язган. 14 нче гасырда ук! «Кыз әйләнде бу батыр яшь тирәли, Җир әйләнгән кебек Кояш тирәли» ...Рәхмәт, Хатыйп абый! Рәхмәт, интернет! Рәхмәт, Сараи! Бүген үк бүлмәмә кайткач, иркенләп, төпченеп укыйм, вәгъдә!

Бераздан Кеплер урамына борылгач, мин дә әйтеп куйдым:

– Европа галимнәрен беренче дияргә яраталар яратуын, безнең төрки дөньясында алардан күпкә иртәрәк ачыш ясаган шәхесләр бар! – Йөземә акыллы һәм һич кенә дә алдан планлаштырылмаган горурлык хисе чыгарып, Сәйф Сараиның шигырь юлын алманчага тәрҗемә дә иттем.

– Дөнья тарихында иркенләп казынсаң, әллә нинди табышлар күп була! – диде Райнер, артык исе китми генә. – Кампусның китапханәсендә

булдыңмы? Андагы байлык искиткеч! Гомер буе утырсаң да, укып бетерә торган түгел...

Китапханәгә керергә җитешмәгән идем. Беркөн Мириам гына: «Шундый зур китапханә – кеше шыгрым тулган, үземә кием куярга шкаф таба алмадым, чыгып китәргә туры килде. Иртүк барырга кирәк икән», – дип зарланып, ушымны алган иде...

Дунай буена төшкәнче, хан заманыннан калган собор буендагы кечкенә генә кафеда кофе эчеп алырга булдык. Үз уемнан үзем көлеп куйдым: монда ханнар булмагандыр инде булуын, Регенсбург – кельт кабиләләре, рим легионнары, императорлар, бавария герцоглары, епископлар, кенәзләр, бургомистрлар эзен саклаган шәһәр бит. Бавариянең бүгенге провинциясе булып, тыныч кына яшәп ятса да, үз гомерендә нинди генә чорларны кичермәгән.

Чынаяк төбенә салынган куе кофены башта бер генә йоттым, шундый ачы иде. Кешеләр көн саен ничек эчәдер моны? Көн саен дим, чөнки тулай торакта миннән башка чәй эчүче беркем дә юк! Бар белгәннәре – менә шушындый кофе яки салкын су.

Райнер минем чырайдагы канәгатьсезлекне күреп, башын артка ташлый-ташлый көлде:

– Галэ, син үзен суярга җыенганнарын алдан сизгән кроликка охшагансың!

Вәт комплимент бу! Вәт чагыштыру! Барыбер авызым ерылды:

– Сөтле чәй эчкәндә, син дә нәкъ шундый идең!

Күңелле компания булганда, хәтта ачы кофены да тәмләп эчәргә мөмкин икән! – Райнер белән сөйләшүе рәхәт, җиңел, бер карасаң – гаҗәп акыллы, белемле, философ булып күренә дә шул ук мизгелдә миннән дә болайрак, һавада очып йөрүче, бар нәрсәдән тәм табып көлеп җибәрүче уенчак кешегә әйләнә дә кала. Шундый пар килеп торабыз!

Ай, минем болай дип әйтү түгел, уйларга да хакым юк. Мин моны онытырга тиеш түгел! Әти... Әни... Әбием... Германия аркасында язмышлары җимерелгән бабайларым...

Бераз соңрак, җәяүлеләр йөри торган таш күпердән чыгып, Дунай елгасының уң як ярында әкрен генә атлап йөргәндә дә, ялкау гына йөзгән үрдәкләрне кириешки валчыклары белән сыйлаганда да, башымнан бер уй китми йөдәтте: әгәр мин Райнерга яки башка берәр алман егетенә гашыйк булсам? Менә тотам да гашыйк булам да куям. Нишләп ярамасын?! Вәлиднең миңа бер тапкыр да «яратам, гашыйк булдым» дигәне юк, ул, җебегән, дөньяда андый сүзләр барын, гомумән, белә микән әле... Беркемгә дә әйтә алмыйча, башы пеләшләнгәнче шулай кыюсыз булып йөрер, мөгаен...

Миңлегөл әбием сөйләвенә караганда, менә Әхтәм бабай, күп сөйләшмәсә дә, иң кирәген өздереп әйтә белгән, ичмаса! Әбиемне бер күргән дә: «Сине кәләшлеккә алам», – дип әйтеп тә салган. «Ятимә дип кызгангандыр инде», – ди әбием. Күзе төшкән дә тимерне кызуында сугып куйган – чын ир-егет шундый була ул! Әбиемнең: «Егерме ике яшем тулган иде, карт кыз булып килә идем», – диюен ишеткәч, күзләрем маңгайга менгән иде. Егерме икедә – карт кыз?! Әкият! Ул чакта авылда читтән кайтып төшкән, биле

бөрмәләнеп торган кыска жакет, шакмак үкчәле биек сапоги, башына йон берет киеп йөрүче бердәнбер кыз Миңлегөл булгач, Әхтәмнең күзе кемгә төшәргә тиеш иде дип беләсез?..

Миңлегөл, 1945 ел.

– Есть живые? Дайте знать! Есть живые?!

Тирә-ягымдагы кырыкмаса-кырык ишекнең барысы да бикле иде, дөнья тараеп, кысрыкланып калган. Шул ишекләрнең берсен булса да ачарга теләп, кулымны сузмакчы булам – бармакларым тыңламый; кычкырырга итәм – телем аңкауга ябышканмы, һичбер аваз чыгара алмыйм. Үземне урап алган куркыныч аклык тәнемә әле салкын, әле ялкын булып үрмәли: аңым үземә буйсынмый. Кайда, нишләп ятуымны төшенергә теләп, чынбарлыкка кайта гына башлыйм – янә төпсез бушлыкка тәгәрәгәнемне тоям.

Шулай да мизгелнең кайсыдыр бер өлешендә үземнең сәер бер йокыга тала баруымны, бу йокының куркыныч икәнен аңлавымны да сизгән шикелле.

– Есть живые? Дайте знать! Есть живые?!

Баядан бирле колагыма ниндидер тавышлар ишетелә, алар кеше тавышы да кебек, кайчандыр әткәем эшләгән шахта авызына төшеп баручы вагонетка тәгәрмәчләренең тыкылдавы да кебек...

Мин исән... бугай. Мин. Мин! Тик кайда соң мин? Төш күреп ятуыммы? Уяныргга теләп, үз-үземә аваз бирергә тырышам: «Мин! Мин! Монда...»

– Держись, мы тебя спасем! Только не молчи, кричи! Кричи!

Кычкырырга кушалар... кычкырырга... Кемне... нигә... каян коткарырга телиләр?

Тәнем дә, җаным дә кисәк кенә бушлыкка очты.

– Күлмәк белән тугансың икән, Маша! Җиде сәгать кар астында ятып бит!

Керфекләремне әкрен генә күтәргән мәлдә баш очымда тагын аклык пәйда булды. Ак халат, ак башлык кигән берәү, минем өстемә иелеп, әллә кайчы, әллә пычак белән тәнемнең кай җирендер шатыр-шотыр кисә, ботарлый. Тик әллә авыртмый, әллә авыртуны сизмим... Больница түгелме соң бу? Тар гына тәрәзә әллә кая өскә, түшәм янына ук урнашкан. Мин яткан урын карават түгел, агач өстәл, ахры. «Маша» дип дәшкән ир заты хирург дядя Толяга охшаган. Шул ич, дулкын-дулкын чәчләренең көлсу яссылыгында калын кара кашлары ярылып күренә. Ак каплавычы ярты йөзен каплаган, халат өстеннән кара алъяпкыч ябып, аны арттан бәйләп куйган. Аның каршысында – күзләре шешенгәндәй күренгән шәфкать туташы. Алар икесе дә, идәннән күтәрелеп салмак көйгә биегәндәй, минем күзалдымда әкрен генә йөзәләр...

Уйларымның, акылымның аеклыгын тикшерергә теләп, бармакларым белән өстәл читенә тотынырга, калкынырга итмәкче булам – бер генә күзәнәгем дә үземә буйсынмый.

– Чү, чү, кызым, сабыр ит... Слава Богу, аякларыңны саклаган! Кисәргә туры килер дип курыккан идем. Ә болары гына туеңа кадәр төзәлер, хәзер, түз инде, яме... – Дядя Толяның, сабый баланы көйләгәндәй, мине йомшак сүзләр белән юатырга маташуын һич башыма сыйдыра алмыйм: нәрсә булган, ни сәбәпле больницада мин, нишләп ятам?

– Миңа... операция... ясыйсызмы? – Җитмәсә, телем көрмәкләнә, башым да җиңелчә әйләнгәндәй.

– Операция түгел. Менә, эчең киселеп, кан белән штукатурка оешып каткан. Шуны яхшылап чистартып бәйлибез дә палатага күчерәбез. Түз, яме...

Кан? Штукатурка?

Үз-үземә биргән сораулардан тагын каядыр еракка, упкынга очам. Тик шул мизгелдә аңым кисәк кенә тулысынча ачылып китә.

Кайчан иде ул? Әнкәй эштән кайтып керде. «Шахтаның сталавай складында эшләдек, бәрәңге чери башлаган, көн буе шуны чистарттык», – дип арып-талып, караватка сузылып ятты. Мин дә, үзебез яшәгән Октябрьск посёлогын иңләп-буйлап, эшче комсомолларның исемлеген барлап йөргәннән соң, кайтып, примусны кабызырга гына өлгергән идем. Сеңлем Рәйханә дә көнозын Рәшитне карап утырып, тәмам хәлдән тайган, чөнки дүрт яшьлек энебезнең кулы җитмәгән берни юк, орчык урынына бөтерелеп кенә тора, күз-колак булмасаң, бөтен әйбер уенчыкка әйләнә дә куя.

– Галимә апаң кич утырырга чакырган иде, моны ияртеп төшсәм, кеше рәтеннән авыз ачып сүз катарга да җай бирмәс, – диде әнкәй, мендәрдән башын күтәрми генә Рәшиткә кулы белән ымлап. – Миңлегөл, балам, синә калыр инде...

– Әнкәй, ә мин синең белән барам! – диде Рәйханә, әткәйнекен хәтерләткән озынча кара күзләрен тутырып, ялварып дигәндәй. – Бер сүзегезне дә тыңламыйм, дәресләремне генә хәзерләп утырам, чын мәгәр! – Сеңлемнең күзләрендә шаян җемелдәү чагылып үтте, ул оч-очлары сүтелгән ике толымын ялт кына үреп, аркасына чөйде. – Елашмагыз гына! Алайса, әйбәт кенә гөрләшеп утырган җирдән йә җырларга, йә еларга тотыналар да, бөтен кызыкны бетерәләр...

– Ялгыз солдаткалар тагын ни белән юансын... – Бу юлы әнкәйнең күкрәк турысыннан тонык көрсенү авазы гына чыкты. Ул ялт кына урыныннан торды да шүрлекне – сагышы һәм өмете яшеренгән саргылт китапны, әткәйнең «хәбәрсез...» дигән хәбәре сакланган почмакны карашы белән барлап узды. – Йөрмәссең! Апаңа булыш әнә, балык пилмәне бөгеп куярсыз.

– Күрше Медвежкада бер абзый тайфун, смерч килә дип куркытты көндез, ачуланып ташлады, нишләп йөрисең дип... – Мин, ярып пешерим дип, бәрәңге әрчергә тотынган идем, кулымдагы пычак идәнгә төшеп китте. Көн буе шулай әйбер-карамны җыйный алмый тинтерим бүген. Посёлокның Бродяжка, Васькин Ключ, Ерак Медвежка, Поселенок, Совхоз, Кара Елга пунктларының барысын җәяү әйләнеп, үзебезнең Урта Медвежкага кайтып кергәнче, изрәвем җиткәнме... Өстәвенә, көнне дә кисәк җылытып ташлады, көньяктан искән җылы җил Сахалинның инде без күнеккән кырыс холкына бөтенләй ятышмый иде, гәүдәне изә, аякларны камыр итә. Болытлар да, тоташ соры юрганга әверелгәннәр дә тауның түбәсенә тиярлек булып, салынып-салынып тора иде бүген.

– И-и, Ходай язмаган эш булмас әле, – диде әнкәй, артык исе китми генә. – Алай шахтада аны-моны сөйләнмәделәр, күмер чыгаруларын беләләр, фронт өчен дип, көне-төне шунда инде, бахырлар...

Әнкәй үз хәрәкәтен үзе дә абайламаган халәттә муеннан бер дә төшми

торган гәрәбә муенсасын сыйпап куйды. Әйтерсең, шул муенса – әле кайчан гына шахтадан күмер тузанына батып, кап-кара булып кайтып кергән, сугышка чыгып киткәннән соң, суга төшкәндәй хәбәрсез-нисез юкка чыккан әткәебезнең яшьлек бүләге – безнең бөтенлегебез, бер җепкә тезелгән язмышыбыз. Әйтерсең, әнкәйнең авыр эштән тупасланган бармак бите шушы бөтенлекне барлап уза. Бар төймә дә үз урынында. Тик... әткәй генә юк!..

Беләм инде, кичләрен Галимә апага кич утырырга җыелган хатыннарның барысы диярлек бердәй язмышлы... Алар да безнең кебек гаилә белән Сахалинга кайсы нефть, кайсы күмер чыгарам дип, вербовщикка ияреп килгән татарлар. «Мгачи» шахтасында татарлар өчен генә аерым төзелгән барак та бар икән, сугыш башланыр алдыннан әткәй шунда булып, танышларын очратып кайткан иде.

...Гадәттә, утырмага төшеп киткән әнкәй без йоклагач кына, таң алдыннан гына кайта торган иде. Бу юлы иртәләде, урын җәеп маташкан мәлебездә, ут алырга гына барып кайткандай, өйгә менеп җитте. Менеп дим, чөнки безнең Урта Медвежка пункты үзенчәлекле урында ул, бер дә тигез җир юк: уртасында чокыр ясап урнашкан кара-каршы тау битләрендә агач бараклар, өйләр тезелеп киткән. Без яшәгән дүрт фатирлы, ике катлы өй үрдә, Галимә апаныкы – аста. Үрдән зур баскычлар буйлап, ярга төшсәң – анда Тын океан. Җәй көне бала-чага шунда мойва тотып мәш килә, саладушка дибез без ул балыкны.

– Әллә нәрсә эчем поша, йөрәгемә урын табалмыйм. Өйгә менәсе иттем, кеше янында күз көеге булып утырганчы, – диде әнкәй, караватта җәйрәп яткан Рәшиткә күз салып. Энем уенчык сорап биетә башлагач, Рәйханә, бишмәтенең җиңнәрен төйнәп, курчак ясап биргән иде – шуны кочаклап, йокыга талган иде балакай. – Рәйханә әйтмешли, елаша башлагач, җанга тия... – Әнкәй, шулай сөйләнә-сөйләнә, кара сырмасын салды, муеныннан буып бәйләгән мамык шәлен карават башына элде, чәчен артка бәләкәй чүмәлә итеп җыеп торган кәкре таракны алып, толымын туздырды.

Ике катлы агач баракны күмер ягып җылыталар, әллә күбрәк ягып ташлаганнар, әллә көнне сындырганга өйдә тын алмалы түгел – кызуга чыдый алмыйча, мендәр-җәймәмне сөйрәп, идәнгә төшеп яттым. Шуны гына көткәндәй, Рәйханә дә: «Әлләй, кызу! Тәнем ябыша башлады!» – дип, минем янга тәгәрәде.

– Апай, син кияүгә киткәндә, бу сугыш бетәр инде ул, име? – диде Рәйханә, әни ишетмәсен өчен колагыма якын ук килеп.

Аның сулышыннан кытыкланып, читкәрәк тайпылдым:

– Җүләркәй, кем әле кияү турында уйлый монда, 16 яшь кенә бит миңа! – дидем мин, сеңлемнең тел төбен аңлап бетермичә.

– Мин чыкканда бетә дә бетә инде ул сугыш! Безнең балаларның әтисенә анда барасы булмый! – диде Рәйханә, шулкадәр җитди итеп.

Әткәй турында уйлавы икән җанашымның...

Түзмәдем, сеңлемне кочаклап алдым.

– Кочаклама! Болай да кызу! – Бу юлы Рәйханә җәймә читенә үк тайпылды. – Әнкәй, Рәшитнең куеныннан курчакны алып ыргыт әле, пешеп ятмасын!

– Җитәр сезгә, төн кошлары! Уникенче ярты җитеп килә бит. Йоклагыз! – диде әнкәй, каршы як стенадагы герле сәгатькә башын күтәреп текәлеп торганнан соң. Аннан энем кочагындагы бишмәтне әкрен генә шудыртып алды да идәнгә ыргытты. Шуны гына көткәндәй, Рәйханә аны әләктереп тә алды, әле генә «кызу» дип зарланганын онытып, үзенең күкрәгенә кысты да борылып ятты.

Керфекләргә йокы эленә башлаган иде, артык сүз куертмыйча, сеңлем дә, мин дә тынып калдык. Шул мәлдә күк күкрәгән коточкыч каты тавыш колакны ярып үтте, мизгелнең күзем шар булып ачылган кайсыдыр бер өлешендә түшәмнең юкка чыкканын аңларга өлгердем һәм үзем дә яшен тизлеге белән каядыр очтым.

Кайчан иде ул? Нәрсә булды?

Мин, зур төенгә төйнәлгән бихисап сорауларымны бер-бер артлы яудырмакчы булып, ялынып-инәлеп, дядя Толяга текәләм, ул минем карашымны тойса да, шуннан качарга теләгәндәй, ялт кына борыла да шәфкать туташына нидер пышылдый, кулында шприц энәсе ялтырап китә. Мине тагын очы-кырые күренмәгән бушлык чолгап ала.

Аңыма килгәндә, кысан гына палатада япа-ялгыз ята идем. Палата диярлеге дә юк, тимер башлы, сиртмәле тар гына карават, шуның аяк очында тупас кына тумбочка – бөтен сыйган җиһаз шушы. Тумбочка өстендә кырлы стакан, яртылаш су салынган пыяла графин тора. Әнкәй минем кайда икәнемне белми микән әллә, эштән җибәрмәгәннәрме – ул янымда булмагач, күңелемдә ачы бер сулкылдау барлыкка килде, күзләремә кайнар яшь тулды. Торып утырыйм дисәм – эчемне-билемне калын итеп шәл белән ураганнармы – шул тартылганда, кисеп-кисеп авырту пәйда булды, күтәрелгән башым мендәргә кире ауды. Үземә җентекләп карасам, өстемдә – капчыкка охшаган иңе-буе бер олы күлмәк. Ике беләгем күм-күмгәк, уң аякка гер аскан кебек, ул кат-кат бинт белән уралган. Тән авыртуыннан бигрәк, билгесезлек, мондагы ялгызлыгым, әнкәйнең әле дә булса яныма килеп җитмәве җанымны көйдерә иде. Шулар барысы бер йомгак булып урала да, башым эчтән, ике чигә буеннан сулык-сулык килергә тотына. Аңымны җуеп алуыммы, әллә температурам күтәрелеп саташуыммы, уйга гына бирелүемме – халәтемне аңлый алмый тинтерим. Кичә һәм бүген дигән ике арада адашып йөрүдән качып, тизрәк биредән чыгып китәсем, әнкәйне күреп, үзем белән ни булганын төпченәсем килә – юк инде, гәүдәмне тыңлата алмыйм. Гаҗизлектән тагын елыйсым килә башлады... Шул тойгыдан котылыр өчен, «математик» икәнемне искә төшереп, саннар дөньясына чумып юанмакчы булам.

Әткәйнең «циләр күрмәй татар иркәенең сау башы» дигән җырына ияреп авылдан чыгып киткәндә, миңа ун яшь иде. Рәйханәгә сигез дә тулмаган иде. Рәшит энебез бирегә, Сахалинга килгәч, кырык бердә туды, шахтёр әткәбез августта сугышка алынганда, энебез ике атналык булып калды. Биредә яшәвебезгә алты ел булып килә...

Алты ел эчендә әнкәйнең авылны телгә алмаган алты көне дә булмагандыр... Рәйханә дә, мин дә мондагы тормышка тиз ияләштек үзе, чөнки «Сахалинуголь» трестына – төрле шахталарга эшкә килгәннәр арасында татарлар бик күп, аларның балалары белән нәкъ авылдагыча авыз

тутырып сөйләшәбез, бер-беребезгә кунакка йөрешәбез. Әнкәй әйтмешли, бары – бергә, югы – уртак. Руслар, украиннар да күп монда, русча өйрәнергә алар белән аралашу да әйбәт кенә булды. Октябрьский посёлогының Татар бугазы янына урнашуын белгән көнне әткәйнең теленнән көнозын теге җыры төшмәде...

Авылда чагында яңа өйгә күчүне дүрт күз көтеп тә, аның рәхәтен күрә алмаган идек, монда килүгә, барактан ике бүлмәле фатир бирделәр – гел ышана торган түгел инде. Әткәй шахтага урнашты, әнкәй ярдәмче хуҗалыкта эшли – акчаны әйбәт түлиләр! Ашау да авылда чакта төштә дә күрмәгән: көн саен ирисләр, кәнфитләр эләгә үзебезгә. Балыкка бөтенләй кытлык юк, пилмән дә, бәлеш тә, аш та гел шуннан әзерләнә. Сугыш башланган җәйне генә балык ашап, агуланып, бик күпләр чак теге дөньяга китмәде... Чын сүз булдымы, японнар суны агулаган дигән хәбәр таралды. Безнең бәхеткәдер, бәбәй табар вакыты җитеп килгән әнкәй, балыкның үзеннән дә, сүзеннән дә күңелем болгана дигәч, ул чакта өйдә балыкның югалып торган мәле иде...

Әнкәйне күзалдына китергәч, тагын йомшардым. Үпкә хисе дә били башлады. Эштән сораса, җибәрми калмаслар иде... Нәрсә булган минем белән, ни өчен яныма керүче, яхшылап аңлатучы юк – һич кенә дә аңлый алмыйм...

Бар көчемне туплап, әкрен генә торып утырдым. Сулык-сулык килсә дә, аякларыма да баса алам икән бит... Дөресрәге, табан астына берьюлы мең энә кадагандай сызлауны җиңәргә теләп, аларны сөйри алам икән!

Караватк белән ишек арасы бер колач булгандыр, шул араны бер кулым белән стенага тотына-тотына, көч-хәл белән атладым да, ишекне ачып, коридорга чыктым.

Иртән микән бу, әллә кич җитеп килүеме – тәрәзәдән төшкән сүрән яктылыкка карап, һич аера торган түгел. Берәүдә бер кеше кайгысы юкмы, әллә, киресенчә, эшләре күбәйгәнме – ак халатлы апалар-абыйлар әрле-бирле йөренәләр, озынча коридорның бер башында ниндидер ыгы-зыгы шәйләнә.

Мин монда беркемне белмим диярлек. Хирург дядя Толяны таныйм – былтыр безнең Рәшитнең эче авырткач, әнкәй белән икәү энемне шушы врач янына алып килгән идек.

– Миңлегөл! Миңлегөл! – Үз исемемне ишетеп, олы ишек буена борылсам, безнең күрше баракта яшәгән классташым Кыям басып тора.

– Миңлегөл, минем Гайнетдин абый да монда. Тәмәке кирәк дигән икән, кертеп чык әле. Мине кертмиләр. Өченче палатада... – Кыямның йөзе сүрән иде, тавышы да калтырап кына чыга. Колакчынлы бүреген күзенә тиклем төшереп куйган. Кистереп кенә шулай диде дә, кулыма, ерактан гына үрелеп сонган шикелле, бер кап тәмәке тоттырды. Минем хәлне сорашып та тормастан, артка тайпылды, чыгып та китте.

Менә сиңа кирәксә! Чыннан да Кыям идеме соң бу? Аның Гайнетдин абыйсына ни булган?

Сорау өстенә сорау бөялсә дә, янымда җавап кайтарырдай кеше юк – янә стенага тотына-тотына, коридор буйлап киттем. Өченче палата ерак түгел икән – ишеген ачыйм дигәндә, кочагына урын-җир җәймәсе күтәргән санитарка килеп чыкты.

– Девушка, вы куда? – диде ул, кыяфәтемә баштан-аяк күз йөртеп. – Идите в свою палату!

– Мин... Гайнетдин абыйга... менә, тәмәке...

– Иштугановкамы? Үлде бит ул. Яңа гына алып чыктылар.

Абау! Нәрсә булган? Нишләп? Миннән ике яшькә генә олы бит ул, ничек үлсен?

Чытырдап йомылган күзләремне ачканда, санитаркадан җилләр искән иде...

– Ник бирмәдең, ярамыймыни? – Ишек төбенә килеп баскан Кыям минем кулымдагы тәмәкегә күз ташлады, йөзенә аптырау, ризасызлык таралды. Аннан кара җимеш төсле күзләрен тутырып, миңа үпкәләгәндәй карап куйды.

– Гай-нетдин абый... үлгән бит... – Кыям янына килеп җиткәнче, «моны ничегрәк әйтермен» дип, адымнарына тагылып сөйрәлгән хәбәр тотлыгып тәгәрәгән сүзләремә иярде дә төште. – Әле генә.

– И Миңлегөл, син дә берүзең калдың, мин дә... – Кыям, бүреген башыннан йолкып алды да, мөгаен, күз яшьләрен миңа күрсәтергә теләмәве булгандыр – аны йөзенә каплады. Ике иңбашы күзгә күренеп дерелдәргә тотынды. Бер кулы белән бүреген, икенчесе белән эчен тотып, стена буйлап шуыша-шуыша, урталай бөгелде.

– Ничек... берүзем? – Берни аңламаган халәттә мин тораташ кебек катып калдым.

Кыямның тавышсыз үксүе басыла төште. Бүреген йөзеннән алды. Егетнең ике күзе яшьләнеп кызарган, юка гына бер учма чәче юешләнеп маңгаена сыланган иде.

– Ничек берүзем? – Кабатлап соравым шулкадәр зәгыйфь, көчсез чыкты.

– Нигә... – Кыям, башлаган сүзен әйтеп бетермәде, ярдәм өмет иткәндәй, безнең яннан буш чиләк күтәреп узучы күксел халатлы, күксел косынкалы санитаркага борылды. Анысының, торасыз монда юл өстендә эчне пошырып, диюе булды микән – каш астыннан сәер итеп сөзеп кенә карады да ашыга-ашыга,順яныбыздан үтеп китте. – Нигә... сиңа әйтмәделәрмени?.. Хәнифә апай да, ни бит... Рәйханә белән Рәшит тә... ни бит...

Әле дә ярый артымда стена булды. Әле дә ярый егылмаска, аркамны терәргә баз юеше бөркеп торган дивар булды! Йөрәк турысыннан әллә нинди коточкыч бернәрсә шуышып үтте дә минем кисәк авыраеп калган гәүдәм, чайкалып, шул таш стенага сыланды.

– Ни бит? Ни бит? – Мин, җилем белән бер-берсенә ябышкандай иреннәремне аерырга, селкетергә тырышып, Кыямнан үз сүзләренә аңлату таләп итә идем. Тик булган көчем әллә кая китеп югалган, тавышым тамак төбеннән ары китә алмый, болай да ярым-йорты хәрәкәтләнгән гәүдәмнән соңгы тамчы яшәү суты сыпылып чыгарга маташа.– Әнкәй! Әнкәйгә ни булган? Апайларым?

Кыям, минем тавышсыз калып ачыргалануымны аңлапмы, яшь тулы күзләрен читкәрәк алды, уң як беләгемнән кысып тотты. Моңарчы тәнемне авырта, сызлана дип, үз-үземне җәлләп, көчкә атлый идем, юк, тәнем түгел, җаным тәмуг утларында яна түгелме? Тән авыртуына түздем бит, ә менә ишетергә җыенган хәбәрне сиземләүдән үк җаным ялкын-утка чорналды.

– Миңлегөл, син нитмә инде, яме... түз... Мин дә... түзәм бит менә... Нишлисең инде...

И Кыям, Кыям, таш-таулардан авыррак кайгылы хәбәрләрне иңнәрдә күтәреп китерү генә түгел, аны иясенә җилләр канатына салып җибәрү дә мең газап шул...

– Әәәәәйт... – Бәгыремнең кай кылыннан чәчрәп төшкәндер бу сыкрау авазы.

– Рәшит больницага илткәндә, исән булган, диде Галимә апа... Операциягә алып кергәнче үлгән... Хәнифә апай белән Рәйханәне бүген иртән тапканнар... Аларны моргка апкиттеләр... Минем дә... инәй дә, әтәй дә, энем белән сеңлем дә... шунда... Гайнетдин абый булса да... исән дип... юанган идем...

Кыямның тавышы сынды. Баягы бүреге янә йөзенә капланды. Идәнгә чүгәләде дә, тамак төбеннән очкылык тоткандагыдай аваз чыгара-чыгара, иңрәп еларга тотынды.

Мин тораташ кебек стенага береккән идем. Елау урынына, эчемнең болай да авыртып, гәүдәмне аска тартып торган теккән урыны тирәсендә үзе ачы, үзе авыр бернәрсә барлыкка килде. Ул бернәрсә әкрен-әкрен өскә таба шуышып, бөтен күкрәк читлеген, йөрәк турысын каплап алды да мине тынсыз калдырды, сулыйм дисәм – ни борын белән, ни авыз белән тын алырга җаем юк. Яр буена чыгарып ташланган балык шикелле, авызымны зур-зур ачып, һава йотмак булам – юк, тамак төбенә дә элпә сыланган.

Күксел косынкалы санитарка, инде чиләгенә су тутырып, кирегә килгән җиреннән безнең хәлне абайлады, ахры, чиләген идәнгә утыртып, яныма атылды:

– Шакирзянова штоли? – диде ул, әйтерсең, минем фамилиямне ачыклавыннан бер-бер мәгънә табарга өлгерүе.

Тапкан икән шул. Ул бер кулы белән әле һаман үксүдән туктый алмаган Кыямны, икенчесе белән елый алмый тилмергән мине култыклап алды, яулыгы төсендәге күзләрендә әниләрчә бер кайгырту пәйда булды.

– Сиңа бит әйтми торырга кушканнар иде, балакай, үз хәлең хәл, диделәр. Җиде сәгать кар астында яткансың бит, ничек аякларыңны өшетмәгәнсең... Көндез күршегез килгән иде, ул да син яткан палата ишеген ачып кына карады да, әйтергә телем әйләнми дип, ашыга-ашыга китеп барды... Сабыр булыгыз инде, балакайлар, бик күпләр өстенә афәт булып килде бу тайфун! – дип сөйләнә-сөйләнә, икебезне ике яклап сөйрәгәндәй, палатага алып керде, утны кабызды, җәймәсен тибәреп, безне караватка утыртты. – Хәзер медсестраны чакырам, берәр укол ясамасмы икегезгә дә... – дип чыгарга борылды.

– Кирәкми. Укол кирәкми... – Телемнән сүзгә охшаган авазлар тәгәрәде. – Туганнарымны күрәсем килә, шунда барам... – Чарасыз йөз белән тәрәзәгә карадым. Кышкы караңгылык үзенең килбәтсез чырае белән төбәлгән, анда – шом, анда – билгесезлек, анда, кайдадыр, миннән читтә – әнкәем, сеңлем, энем...

– А-а-һ! – Баягы элпә тамак төбеннән кубып төште, мин, өстемдәге капчык-күлмәктән шуып чыгардай булып, тән авыртуларын бөтенләй онытып, иңрәп-иңрәп еларга тотындым. Күз яшьләрем язгы ташудай

актарылып-кайнап ага, Кыям әйткән хәбәрне әле генә акыл белән аңлаудан җаным киселә, тетелә. Тизрәк бу тар, сасы, салкын палатадан чыгып йөгерәсем, яланаяк булса да, кар өстеннән сукмак сала-сала, әнкәем, туганнарым янына юл тотасым килә. Юк, юк, алар үлмәгәндер! Исәндер алар! Туңганнардыр, бәгырьләрем, шуңа гына аваз-тын бирә алмый ятуларыдыр... Яннарында булсам, сулышым белән җылытырмын, җан өрермен үзләренә. Юк, юк, алар берничек тә үлә алмый! Мине ялгызымны калдырып! Әткәйне көтеп алмыйча! А-аһ!

Кыям бертуктамый минем кул аркасын сыпыра икән, ә мин икенче кул тырнакларын аның беләгенә батырганмын...

– Барысын да иртәгә күмәләр. Дүрт көн эчендә табып бетергәннәр. – Кыямның карлыккан тавыш белән шулай диюен тиз генә аңыма сеңдерә алмый тордым. Дүрт көн? Ничек, бүген ничәсе соң?

– Тайфун унысына каршы төндә булды. Бүген унөченче февраль, – диде Кыям, төн күзе белән баккан тәрәзәгә хәсрәтле караш ташлап. – Эх, мин дә... Гайнетдин абыйны алыштырам дип, өченче сменага киткән булдым бит... Ичмаса, барыбыз бергә булыр идек. Хәзер ничек яшәргә? Кем өчен, нигә яшәргә?..

Без, ике яралы җан, бер-беребезне юатырга сүзләр табалмыйча, һәрберебез үзалдыбызга үкси бирдек. Мин әле Кыям әйткәннәргә ахыргача ышана алмыйм, тизрәк берәр кием юнәтеп, бу палатадан чыгып йөгерәсем, әнкәемне, энем белән сеңлемне үз күзләрем белән күрәсем килә.

– Табылганнарны посёлок клубына китергәннәр, түлке анда беркемне дә кертмиләр. – Кыям минем сүзсез сорауларымны йөземә карамаган килеш укый иде булса кирәк. – Йөз җитмешләп кеше үлгән, диделәр.

Йа Раббым! Безнең газизләребез дә шул саннар эчендәме?..

Клуб идәненә гәүдәләрне дүрт рәт итеп тезеп салганнар. Беркемне таный торган түгел: пычрак, катып калганнар. Ике күземнән чишмә урынына аккан кайнар яшь буразнасы да карашымны томалый, кул-аякның авыртуы онытылган, алар үземә сизелерлек булып калтырый. Каядыр якында гына, шушы җансызлар дөньясында минем әнием, сеңлем, энем барлыгын белүдән ул калтырау тәнемнең бөтен күзәнәгенә тарала, мин бизгәк тоткандай дер-дер килеп, иелә-иелә газизләремне эзлим. Икенче рәт уртасында кечкенә юрганга төреп салынган бер мәет ята – энемнең больницага алып килгәндә исән булуын, шунда үлүен, аны юып, төреп шушында төшерүләрен әйткәннәр иде – калтыр-колтыр килеп, юрганны ачам. Рәшит энем! Энекәем! Йөзе сап-сары, ләкин чип-чиста! Хәлсезләнеп, юрган өстенә ауганымны тоям, аны кочаклап үксүем тора-бара такмаклап елауга күчә.

– Елама, түз инде, үскәнкәем! Нык бул! – Галимә апаның көчле куллары мине күтәреп торгыза.

Бикле клубның ишеген ачып, ул кертте мине бирегә. Галимә апа. Әнкәемнең ахирәте. Безнең күрше авылныкы. Минем ялваруларыма чыдый алмыйча, клубта җыештыручы булып эшләгән хатыннан ачкычны сорап, шушы мәхшәр дөньясына алып керде. Кулындагы шахтёр фонареннан төшкән кискән яктылыкка ияреп, икәүләп минекеләрне эзлибез. Теге кичне Галимә апага утырмага төшеп тә тизрәк өйгә – әҗәле каршысына менеп

җиткән әнкәемне. Ә бит тайфун җиле Галимә апаларның түбәндә утырган өенә кагылмаган! Андагы солдаткалар барысы да исән калган! Әнкәемнениләр ашыктырган? Күрәчәгеме?..

Галимә апа, сырмасының соры җиңе белән күз төпләрен сөртә-сөртә, минем биләгемнән култыклап ала, хәлсез гәүдәмне үзенә сыендырып, бөгелә төшеп, ул да таштай катып калган йөзләргә төбәлә.

– Рәйханә! – Кычкырып җибәргәнемне сизми дә калып, учым белән авызымны каплыйм. Курчак итеп төйнәлгән бишмәт сеңлемнең гәүдәсенә ябышып каткан, эчке күлмәгенең бер ягы буйдан-буйга ертылган, сул биләге, өзелеп төшәрдәй булып, җеп шикелле асылынып калган. Аны күргән мәлемдә күкрәгемдәге соңгы тамчы көч аһылдау авазы булып саркып чыкты, һушымнан язып егылмас өчен бу юлы үзем Галимә апаның кулына сөлек кебек ябыштым. Чарасыз калып, бу караңгылыкның, бу мәхшәрнең куркыныч бер төш кенә икәненә ышанырга теләп, артыма борылам һәм... Йа Раббым! Алдагы рәттә, йөзтүбән капланып яткан гәүдә – әнкәем! Әнкәем! Мин аны биленә төшеп торган озын чәченнән таныдым. Елан шикелле боргаланган чәч шыкранлап каткан, чәч арасыннан гәрәбә муенсасы күренеп тора.

Йөрәк ярылмасын өчен, түзәр өчен көчне кайлардан алырга? Әллә башым, әллә идән әйләнә башлады, томан эчендә йөзгән уңайга мин, ачы кычкырып, әнкәем өстенә аудым.

– Балакаем! Кермик дигән идем бит! – Бу сүзләрне ишетеп, күземне ачканда, баш очында клуб түшәме түгел, карасу күк йөзе иде. Галимә апа кар өстенә утырган да, башымны үзенең итәгенә салып, елый-елый битемне чабаклый. – Сабырлыклар сорыйк, балакаем...

Ни өчен? Ни өчен шушындый хак белән түләргә кирәк булды, кем гаепле? Барысын да табигать бәла-казасына сылтаргамы?... Ә бит ул көнне көндез үк, мин комсомол эше белән йөргәндә, күрше пунктта иңбашына торба салып атлаган бер агай: «Тайфун, зилзилә килә, нишләп йөрисең ирәеп?» – дип кисәткән, ачуланып ташлаган иде. Димәк, бәла-каза көтелгәне билгеле булган? Ул чагында ни өчен кешеләргә әйтмәгәннәр? Нигә саклык чаралары күрмәгәннәр? «Сугыш өчен, фронт өчен!» – дип, көн-төн шахтада күмер чыгарганнарны да, аларның сабыйларын да шулкадәр кадерсез, курчак ролендәге затлар дип санауларымы?..

Эх, әткәем, теге чакта, ат арбасының тәгәрмәчләр көенә кушылып елый-җырлый, күрәчәгебезгә карап, юл тотканбыз икән лә... Сабый булганмын, ул чакта аңламаганмын гына... Ә менә хәзер кинәт олыгайдым. Үткәннәргә ишек ачылмаслык булып бикләнгәч, ярты гасыр яшәгән карчык булдым да куйдым. Югыйсә уналты яшь кенә бит әле үземә! Моннан ары елларын саннар белән санаудан туктаргамы миңа?..

Бу вакыйгага аек акыл белән борылып караганчы, бер-берсенә ялганып, байтак соры көннәр үтте. Уянырга, уянганнан соң исә янәшәмдә әнкәемне, сеңлемне, энемне күрергә өметләнеп, шул өмет ялына хыялый бер иләслек белән ябышып, төштәге шикелле шактый йөрдем әле мин.

Кайчан гына биш йөзләп кеше яшәгән, үзенчә гөр килеп торган Урта Медвежка күген күз яшьләреннән корылган пәрдә каплаган иде.

9 февраль көнне кинәт җепшетеп җибәргәне хәтеремдә. Шул төнне,

уникенче ярты җиткәндә, тау түбәсеннән ташкын булып кузгалган кар катламы, юлында очраган һәрнәрсәне вата-җимерә, аска кадәр төшә, алай гына да түгел, куәт белән каршы як тау битендәге торакларны да җимереп, өскә таба юлын дәвам итә, аннан, тагын да котырынган кыяфәт алып, юлын үзгәртә-үзгәртә, янә аска томырыла. Унар метр тирәнлектә кар астында калган кешеләрне берәм-берәм эзләп тапканчы, тәүлек арты тәүлек үтә. Боларның барысы хакында соңыннан шахта парторгы Владимир Дмитриевич Сорокин да, мине үзенең өенә алып кайтып сыендырган Галимә апа да, тау эшчеләре дә вакыйгаларны җепкә тезә-тезә сөйләделәр.

1945 елның 14 феврален мин дә, миндәй башкалар да беркайчан онытa алмас. Ул көнне Октябрьский зиратындагы кан-яшь булып түгелгән авазлар җир һәм күк катына да бөтенләйгә берегеп калгандыр. Җитмәсә, ул авазларга тынлы оркестрның матәм көе кушылып, акылдан язар халәткә җиткерә, моның коточкыч ачы чынбарлык икәнен миеңә тукый; елау тавышлары белән бербөтенгә әверелеп, һавада зеңли, тетри... Йөзләп кешене туганнар каберлегенә җирләделәр. Аларның яртысы кечкенә табут-гробларга салынган, әле мәктәпкә дә кермәгән балалар булып чыкты.

Мин комсомол оешмасында эшләгәнгәме, парторг Владимир Дмитриевич бик якын итә иде үземне. Мондый хәсрәттә кемнең кем икәнен аерып торырлык булмаса да, клуб янында кайгымны уртаклашкан мәлендә:

– Шакирҗанова, каршы килмисеңме? Синекеләрне дә гробка салыйк, – диде ул, әтиләрчә бер кайгырту белән эндәшеп.

Үземнән ерак китмәгән тавыш белән: «Риза», – дип җавап кайтардым. Әнкәем белән Рәйханәне, башлы-аяклы итеп, икесен бер табутка урнаштырдылар. Рәшитне күрше малае белән бергә кечкенә табутка салдылар.

Клуб яныннан шул табутлар салынган атлар кузгалып киткәндә, алар артыннан елый-елый ияргәннәр үзләре дә ярты мәет иде...

...Үлгәннәрнең исемнәрен әйткән саен аяк астымдагы туфрак батып-батып киткәндәй була. Егылып китмәсен диюедер, Галимә апа мине кысып тоткан, мин дертләгән саен гәүдәмне үзенә сыендыра, «сабыр бул» дигән пышылдаулы сүзләре колагыма томан пәрдәсе аша ишетелә.

Рушания... Кәнифә... – минем яшьтәшләрем. Барактагы күршебез Гарәфә апа, аның дүрт баласы – Кыям, Хәмидә, Мөсәвәр, Мәхмүт... Кафия апа, аның өч баласы – Әхәт, Тәскирә, Фәрхәт. Мәхмүдә апа, аның Нурсуфиясе белән Раузасы, Гыйлемханы... Гарифҗан абый, аның хатыны Гаян апа, Гаделҗаннары, Фаиклары, Әмирҗаннары...

Татарлардан җитмешләп кеше үлгән, диделәр. Ул саннар эчендә минем әнкәем, сеңлем, энем дә бар! Аларның гомере, аларның исеме, аларның тән һәм җаны шушы коры саннар эчендә... Кемне гаеплим? Авылдан, яңа өебездә ике кич кенә кунарга өлгергән оябыздан шушы җир читләренә куып алып килгән язмышнымы? Гарасат булып ябырылган табигать казасынмы? Әткәемне, гаилә тоткасын үз эченә – билгесезлеккә алып йоткан сугышнымы? Якташларымны, Идел, Чулман буйларыннан кубарып, шушы Татар бугазы ярларына китереп каккан дулкыннарнымы? Кемне, кемне гаепләргә?

Галия, 2019 ел.

Урам буйлап тезелеп киткән коттеджлар төзелеше белән игезәкләр шикелле: барысы да икешәр катлы, бернинди чуар бизәксез, капка-коймалар шулкадәр гади: үзләре тәбәнәк кенә, кайсы – тактадан, кайсы – тимердән ясалган. Безнең Казан янындагы яки авыллардагы коттеджларны, бизәкле коймаларны, тәрәзә кашагаларын күрсәме болар?!.

– Менә монда без яшибез, – диде Райнер, стенасы ап-ак, түбәсе караңгы зәңгәр төстәге ике катлы йорт янында тукталып. Домофон төймәсенә басып, тимер капканы эчкә таба ачты.

Күзне камаштырырлык яшел келәм кебек җәйрәп яткан газон үләненә тәбикмәк-тәбикмәк таш түшәп, сукмак җәйгәннәр – шул сукмак буйлап ишегалдына үттек. Барысын да тизрәк күз уңына аласы килә, кызыксынуымны яшереп тормыйча, тирә-якны күзәтмәкче булам. Карашымны шунда ук тотып алган Райнер:

– Мин сиңа бакчада соңрак экскурсия ясыйм, ә хәзер безне көтәләр, сәгать 5 тә өстәл янына утырабыз, – диде, гадәтенчә ялт кына сәгатькә карап.

Аһ, нәрсә-нәрсә, үтерәләр болар минут санап! Гомернең һәр мизгелен шулай билгеле бер үлчәмдә тоту өчен минем үземә байтак тырышасы булыр, мөгаен...

Өйнең буйдан-буйга сузылган пыяла ишеге янында болдыр-баскыч ише нәрсә юк иде, эчкә узуга, без тар, озын, икенче башында да зур пыяла ишек шәйләнгән коридорга аяк бастык. Ул да булмады, эчтән, башына спортчыларныкы кебек тар гына тасма бәйләгән, өстенә дә гади генә спорт костюмы кигән, кечкенә җыйнак гәүдәле бер ханым килеп чыкты. Табигый җирән төстәге кыска чәчләренә, кыр чәчәгедәй зәп-зәңгәр күзләренә караганда, ул Райнерның әнисе булса кирәк – коеп куйгандай бер-берсенә охшаганнар иде.

– Галә? Миңа гади генә итеп Элизабет дип дәшә аласыз. Мин – Райнерның әнисе. Ул сезнең хакта шундый матур итеп сөйләде! Сезне үзебездә күрүгә бик шатмын! Сез немецча иркен аралашасызмы? Ничек сезгә безнең Регенсбург? Өйдәгеләр белән скайп аша сөйләшәсездер? Сагынырга өлгермәдегезме? Бәлки, сезгә инглизчә сөйләшү кулай булыр?..

Элизабет, җөмләләре арасында бернинди пауза калдырмыйча, бер-берсенә бәйләнгән-бәйләнмәгән сорауларны тезде дә тезде, мин «әңгәмә» башында нидер әйтергә теләп ачкан авызымны шул халәттә бераз тоттым да, хәтта исәнләшергә дә өлгермәячәгемне яхшы аңлап, телемне тешләдем. Сүз кыстырырга форсат юк иде – ханым, гомер буе теле бәйдә торган да менә шушы минутта гына ычкындырганнар диярсең, сөйли дә сөйли, сөйли дә сөйли... Менә ул, сөртенеп егылгандай, кисәк кенә тuктады, кул хәрәкәте белән эчке ишеккә ымлады. «Райнер, кунак кызына туалет бүлмәсен күрсәт!» – диде дә, минем өчен шуннан да зур бәхет булмаячагына инанган бер кыяфәттә, шулкадәр ачык елмаеп, бездән алда эчкә узды.

– О кей, mama! – Райнер, әлбәттә, әнисенең мондый тел бистәсе булуына күнеккәндер, аның өчен бер дә гайре табигый хәл тоелмыйдыр, әмма мин бераз сәерсенеп, хәтта кыенсынып калдым. Ник, минем кыяфәтем бәдрәфкә барырга кысталган кешенекенә охшаган микәнни? Ужас!

Сумкама Казаннан алып килгән талкыш кәләвәне тыккан идем – кайчан

кулына тоттырыйм инде бу ханымның? Тоттырган шәйгә: «Бу нәрсә? Ничек пешерәләр? Нигә баллы ул? Мин аны ашасам тазармыйммы?» – дип, ноктасыз-өтерсез сораулар тезә башласа... Үч иткәндәй, кәләвәнең алманча атамасын да тапмадым әле мин, күргән-белгән нәрсәләре дә түгелдер. Күчтәнәчне, безнең татарның милли ризыгы дип, башымны горур күтәреп бирермен дигән идем. Ә ул мине бәдрәфкә озата...

Ак сумкамны, иңбашыннан әкрен генә төшереп, ишек төбендәге этажерка өстенә куйдым. Райнер аны, бавыннан тотып, җәһәт кенә әллә мөгезгә, әллә кәкре кадакка охшаган элгечкә асты.

– Син үз өеңдә кебек бул. Монда – юынырга мөмкин, көзге дә шунда. Аннан аш бүлмәсендә көтәбез сине, – диде ул башта сул яктагы тар гына ак ишеккә, аннан уң якка – ачылмалы киң ишеккә кулы белән ымлап.

Ярар, кунак – хуҗаның ишәге, диләр түгелме? Шикәр аклыгы белән балкыган зур бүлмәдә кулымны чайкагандай иткән арада, ике почмактагы ике душ кабинасын, джакузины, рәттән торган берничә кер машинасын, массаж кәнәфиен күзәтергә өлгердем. Владик булса, «ничего себе туалет бүлмәсе!» дияр иде...

Кызыл каптагы кәләвәне тотып, аш бүлмәсенә атлаганда, каршыма, давылның үзе кебек җилләп, Элизабет чыкты. Давыл дисәм дә, күзләренә кояш кереп тулган үзенең.

– Бу – сезгә, Татарстан күчтәнәче, – дидем мин, бу мизгелдә дәшеп өлгермәсәм, тагын тел тибрәтә алмаячагымны инде алдан чамалап, капны ханымның кулына сонып. «Кәләвә» дигәнне татарча әйттем дә, үземчә «баллы мамык» дип алманча тәрҗемә ясап та бирдем.

– Татарстан? – Элизабетның саргылт туры кашлары сораулы җыерылып алды, басымны беренче иҗеккә төшереп, шулай дип, берничә кат кабатлады да, белмим бит дигәндәй, иңсәсен сикертте, балаларча бер кызыксыну белән кәләвәнең капкачын ачты. – Мороженое? Юк? Баллы пирожное? Ах! Бик аппетитный күренә! Ах! Мин аны ашасам тазармаммы? Ә сез, Галә, спорт белән шөгыльләнергә яратасызмы? Теләсәгез, ялларда безнең белән бодибордингка бара аласыз. Үзегез белән гидрокостюм бармы? Булмаса, борчылмагыз, анда прокатка да алырга мөмкин... Райнер, Вернерны алып чык, аңа солы боткасы пешердем. Галә, рәхмәт, кадерлем! Менә бирегә, тәрәзә янына утырыгыз. Сезгә кофе? Латте? Капучино? Риндруладенны сезгә бәрәңге белән бирергәме? Әллә гарнирга маринадланган кызыл кәбестә салыйммы? Кызыл шәраб соусы белән кәбестә яхшырак булыр...

Болай кызу һәм бертуктаусыз сөйләгәннән мин Элизабет әйткәннәрнең барысын да аңлап бетермим, әмма аңлап, үзем өчен тәрҗемә итеп барган кадәресе дә супер иде! Вау дими, нәрсә дим? Минем колак төбемдә бары тик немецча сөйләшәләр! Һәм миңа тылмач кирәкми! Үземнең дә сүзгә кушыласы, телемне чарлыйсы килә дә соң, тик бу ханым өчен әңгәмәдәшнең булу-булмавы мөһим түгел, ахрысы. Бәлки, ул берүзе калганда да шулай үзалдына сөйләнеп йөридер, кем белә... Иң кызыгы – ул пулемёттан сиптергәндәй сөйли-сөйли дә шулкадәр кисәк туктап кала, хәтта үзеңне тигез җирдә абынгандай хис итеп куясың...

Элизабет тәкъдим иткән киң аркалы биек урындыкка менеп кунаклаган мәлемдә, түрдәге бүлмә ишеге ачылды һәм коляскада утырган шәүлә

артында Райнер күренде. Ул бөтен гәүдәсе шакмаклы карасу җәймәгә, пледка төренгән берәүне – берәү дигәнем чыннан да шәүлә, скелет түгелме соң, гел сөяктән генә тора! – аш бүлмәсенә алып чыгып килә иде.

– Вернер, рәхим ит, сиңа ботка салдым. Кунак кызы белән таныш. Галә, Россиядән, бездә университетта укый, алман телен өйрәнә. Бик сөйкемле кыз, шулай бит? Аның белән уртак тел табарсыз дип уйлыйм... Вернер – минем каенатам. Вернер, син колак аппаратын онытмадыңмы? Безнең әтиебез эштән соң гына кайта, «БМВ» заводында эшли ул, бу арада эшләре бик тыгыз. Райнер, кофемашинаны көйлә, зинһар...

Буталчык тоелса да, Элизабетның бу минимонологыннан мин Райнерның бабасы турында да, әтисе турында да мәгълүмат алырга өлгердем. Әлегә шул җиткәндер...

Герр Вернерга да туксан яшь икән! О-о, минем Миңлегөл әбием аның янында кызлар кебек күренә, между прочим! Ишетмим дисә дә, колагына аппарат элгәне дә юк, әйткән идем бит, үзенә кирәген бик тиз ишетеп ала! Ә Вернерның кыяфәте мактанырлык түгел. Ике кулы да өзлексез калтырый – Паркинсон авыруы, диде Райнер. Аяклары да авырта, ди.

– Галә! – Бабайның тонык тавышыннан сискәнеп киттем. Баз астыннан ишетелгәндәй тонык тавыш! – Димәк, сез Россиядән...

Аһа, димәк, бабайның колак аппараты супер!

– Әйе, герр Вернер. Россиядән. Татарстаннан, Казаннан мин. – Ни сәбәпледер мин кинәт кенә дискомфорт сизә башладым.

– Гут, гут... Казан?! Мәскәү янындамы ул?

– Янында ук түгел. – Блиин, Казан белән Мәскәү арасы ничә чакрым? Аны да интернеттан карарга тиешме мин?.. Мең? Әйе, әйе, мең чакрым ла... – Аралары шактый ерак. Мең чакрым, – дидем, искә төшерүемә куанып. Торган саен мин үземнең белемем белән артык мактана алмавымны ачыклыйм! Бу миңа һич кенә дә ошамый бит әле... Инглиз телен шәп беләм, әдәбиятын, тарихын белүемне ярыйсы дип бәяләргә була; алман теле, тарихы, әдәбияты да бөтенләй үк икелелек түгел. Ә менә үзебез турында башка милләт кешеләренә авыз тутырып сөйли алмыйм! Оят дисәм дә була...

Мине бая ук өстәл янына утыртып куйса да, Элизабетның өстәл әзерләргә җыенуы күренми иде. Мин үземне ничек тотарга кирәклегенә төшенеп бетмим әле: «Сезгә булышыйммы?» – дисәм, килешерме? Кайда, нәрсәгә булышырга? Болай кул кушырып утыру да мәзәгрәк... Бездә соң... кунак килеп керүгә өстәле буш торса, әнигә йөрәк өянәге булырга мөмкин. Өстәвенә, шундый мәлдә мин болай гына, тик кенә, менә хәзергедәй җәелеп кенә утырсам... О-о, күз алдына да китерә торган түгел! Иртәгә кунак киләсе билгеле булса, шул минуттан чабыш башлана. Бездә генә түгел, бөтен татар гаиләсендә дә шул гадәт. Башта исемлек төзеп кую: беренчегә аш. Токмачны кул белән басарга! Шулпасы тәмле булсын өчен сыер итен, тавыкныкын, казныкын түбәләмә итеп салырга. Бәлешкә дигән эчлектә дә шундый ук ассорти. Гөбәдия өчен кортны жәлләмәскә, базардан иң тәмлесен, күп итеп алып кайтырга! Кемдер алма пирогын, кемдер баланныкын, кемдер күрәгәнекен ярата – оятка калмас өчен өчесен дә пешерергә. Күчтәнәчкә тыгып җибәрергә дә шәп. Салатны артык күп ясап мәшәкатьләнмәскә,

соңыннан куярга урын табалмый тинтерисең. Хәзер винегретка исе китми халыкның, шуңа да берәр савытлык кына итеп ясарга кирәк. «Кышкы» салат та шул бер савыт булса, бик җиткән. Балыкны кызылын, ысланганын, тозлысын олы тәлинкәгә бергә тезсәң, салатын ясап тормасаң да була. Сельдерей, алма, бананны каймак белән бутасаң, тел йотмалы – анысын кечерәк-кечерәк ике касәгә салып, ике урынга кую яхшырак, күп кирәкми, шул җитә. «Магнит»тан юка ләвәшләр алып кереп, бераз гына рулетлар ясарга... «Бәхетле»нең торты тәмле, берәрне генә булса да алырга. И-и, икенчегә ни әзерлисе хәл ителмәгән! Бәлеш бит ул – бәлеш. Ашның ите янына куелган бөҗра-бөҗра бәрәңге дә – ул бит бәрәңге. «Второй» юк бит әле монда! Казны алма белән тутырып куярбыз – тик ул да «второй» түгел бит... Ярар, пылаудан да җайлысы булмас, йә мантый гына ясап ташларбыз. Ул булмаса, фарш белән тутырылган борыч та бик җайлы... Төн чыкканчы әзерләп бетерербез...

Авызымнан сулар килә язды! Өйдә түгеллегемне аңлар, айнып-айнып китәр өчен әле һаман буп-буш торган өстәлгә карап кую да җитә иде. Уф, нишләп гел ашау турында уйлау соң бу? Әйтерсең, кеше дөньяга ашар өчен генә яралган...

Вернер да Элизабетның «ботка салдым» дигән сүзенең дәвамын көтә, ахры. Алдындагы бушлыкка карап, башын иебрәк уйланып утыра. Райнер кофемашина янында кайнашкан җиреннән, минем якка борыла да «бар да тәртиптә» дигән шикелле, ялт кына күз кысып ала.

Ниһаять! Дүртебез алдында төбенә хуш исле кара кофе салынган дүрт чынаяк пәйда булды. Ап-ак тәлинкәдә пестә һәм кокос валчыклары кушып пешерелгән ипи күренде. Риндруладен дигәннәре ит рулеты икән, кызганыч, нәрсә ите булса да, бик аппетитлы күренсә дә, хәләл түгеллеген чамалыйм – «ит ашамыйм» дип, әдәпле генә баш тартырга туры киләчәк. Фарфор кәстрүл белән уртага менеп кунаклаган, тәмле ис аңкыткан сосискалар да минем өчен түгел...

– Элизабет, мөмкин булса, миңа бәрәңге генә салыгыз, зинһар! – Кыюлыгымны җыеп, үзе кебек елмая-елмая, шулай дидем, чөнки кызыл шәраб белән кәбестә дигән вариант та шикле иде.

Ә бәрәңге – тумышы белән Американыкы булмагае, Африканыкы булсын, анысы күптән татарлашкан, анысы – кайда да бәрәңге!..

Өстәл яныннан кузгалгач, Райнер, ап-ак чүпрәк салфетка белән Вернерның авыз тирәләрен пөхтәләп сөртте дә колясканы этеп, бабасын түрдәге бүлмәгә алып китте.

– Галэ! Әйдәгез безнең белән! – Баягы тоныклык тавыш мине чакыра иде. Бабай өстәл янында бөтенләй сөйләшмәде, калтыранган куллары белән кашыкны төшереп җибәрмәскә тырышып, боткасын ашап бетерде, Элизабет та, үрелеп, озын саплы икенче кашык белән ботка каптыргалады.

– Вернер бик сирәк кешене үз бүлмәсенә кертә! – диде Райнер, бераз аптыраган, әмма елмаюлы караш белән миңа борылып. – Димәк, ул сине ошатты!

Һе, мин шуның өчен сөенергә тиешме?..

Өйдә бөтен почмакта да, бусагаларда да колясканы йөртер өчен уңайлыклар ясалган иде. Икенче катка менүче баскычта пандус та бар.

Вернерның бүлмәсе бакча ягына караган икән – тәрәзәдән тип-тигез итеп киселгән яшел үлән, күтәртмә түтәлләр, артлы эскәмия, түгәрәк өстәл күренеп тора. Тәрәзә читендә – зур рамкага куелган аклы-каралы фотолар. Рөхсәт сорап, якынрак килдем. Сурәтләрнең берсендә шундый сөйкемле ике бала. Артта пианино тора, алда – агач атка атланган, комбинезон итеп бәйләнгән кыска балаклы костюм кигән ерык авызлы малай. Бездә садикка йөргән малайлар шикелле, аксыл калын колготки, кара сандали кигертергә дә онытмаганнар. Янындагы кечкенә ак урындыкта моряклардныкы шикелле буй-буй якалы кара күлмәктән, аякларында шундый матур ботинкаларын ялтыратып, көләч йөзле кызыкай утыра. Кулында – маңгай чәче бөдрәләнеп торган нәни курчак. Идәндә, аяк очында да кечкенә бәбигә охшаган төймә күзле курчак күренә. Икенче фотода да шул ук балалар, тик бераз үсә төшкәннәр. Озын сары чәчен ике толым итеп үреп, колак артына төймә кебек эләктергән, аягына баулы ботинка кигән зур күзле хатын, аның янында – апаш якалы, ике төймәле күк пиджак кигән такыр башлы малай, янәшәләрендә – ак чалбарлы, ак күлмәгенә чуар күбәләк таккан, кара костюм кигән озынча йөзле ир, ул сул кулын ике тез арасына салган, уңы белән биленә таянгандай иткән. Алар артында тар маңгайлы, ябык гәүдәле үсмер егет басып тора. Барысы да шундый бәхетле йөз белән елмайганнар.

– Анда – минем әтием һәм әнием Грета. Сеңлем Эльза белән минем кечкенә чагым, Руди – абыебыз.

Тоныклавыш минем җилкә чокырымны бораулый иде.

– Әтиемне – обер-лейтенант Мартин Вольфны кырык икенче елда Мәскәү янында руслар үтерделәр. Ул вермахт солдаты иде.

Карашым өстәрәк торган фотода – фриц киемендәге обер-лейтенант сурәтендә кадакланды.

– Әниебез ул чакта бик елады, акылдан шашар хәлгә җитте. Бәхетенә, Руди врач булгач, аңа вакытында ярдәм итә алды. Ул гаҗәеп белгеч иде!

Вернер мин сорау бирмәгән килеш тә сөйли, аңлаган кадәресен минем баш мие кыска-кыска җөмләләр итеп, эчтән генә тәрҗемә ясап өлгерә. Райнер ул минутта ни белән мәшгульдер – тавыш-тыны юк. Мин борылырга кыймыйм. Гаепсездән гаепле бер кыяфәт белән һаман фотоларга төбәләм.

– Абыегыз исән түгелдер инде. – Ник шулкадәр сабырсыз минем телем? Кая исән булсын, Вернерга туксан булганны, Руди дигәннәре йөзнең теге ягында аягын салындырып утырырга тиеш бит. Аннан, миңа барыбер түгелме?

– Исән. – Ярый әле күземнең маңгайга менгәнен күрмиләр. – Руди күптәннән интернатта яши. Ул миннән ныграк әле!

– Вернер шаярта. Рудида Альцгеймер авыруы. – Райнер да янәшәмә килеп басты. Бармагы белән астагы фотога – чәче ап-ак булып дулкынланып торган карт кына берәүгә төртеп күрсәтте. – Малае аны бик күп еллар элек интернатка – картлар йортына урнаштырды, без дә хәлен белергә баргалыйбыз. Кызганыч, ул беребезне дә танымый.

– Европада аталар һәм балалар мөнәсәбәте Рәсәйдәгечә түгел шул. Бездә ата-ананы соңгы көненә кадәр балалар үзләре тәрбияли, картлар йортына илтү хурлык, җинаять кебек хәтта... – Минем дә үз карашымны ишеттерергә хакым бардыр?

– Беләм. – Райнерның болай диюенә, әлбәттә, ышанам. Белмим дисә, гаҗәп тоелыр иде. – Бездә яшьләр дә Россия яшьләренә караганда күпкә мөстәкыйль, мәктәпне бетерүгә, үзбаш дөнья көтә башлыйбыз. Мин, мәсәлән, әти-әнидән акча сорамыйм. Үзем өчен үзем табам. Бездә эшкә урнашу өчен берәүне дә эзләп йөрисе юк, белемең бар икән – танышларсыз да рәхәтләнеп урнаша аласың. Ә сездә, студентлар әйтүенчә, танышларсыз укырга керү дә, эшкә урнашу да проблема, диләр...

Дөрес сүзгә җавап юк. Бу мәлдә дәшми торуым урынлырак булыр.

– Галэ, сез нинди профессия буенча укыйсыз? Балалар табибы, дөрес әйттемме?

– Юк, герр Вернер, мин гуманитарий, телләр өйрәнәм... Абыегыз балалар врачымыни? – Ниһаять, фотолар яныннан тайпылып, тәбәнәк кара өстәл янындагы киң аркалы кәнәфигә сыендым. Вернер, коляскасын тәгәрәтеп, минем каршыма килде. Үземне имтихандагы кебек хис итеп куйдым: гүя, алдымда – профессор, ә мин, өйрәнмәгән билет эләккәнгә дә исе китмичә, «барыбер берәр билге куеп чыгарыр әле» дип, авызын ерып утырган студент.

– Рудимы? Юк, ул бик яхшы психотерапевт иде. Сугыш вакытында Моосбург концлагеренда эшли башлаганда, бөтенләй тәҗрибәсез, яшь иде. Лагерь аңа зур мәктәп булды. Соңыннан нинди табиб булып өлгерде! Аны Дахау концлагерена да күчерергә теләгәннәр, белмим, ни сәбәптәндер, Моосбургта калдырганнар.

Мин Райнерның бабасы тарафына борчулы карап куюын сиздем. Үземә дә әллә ничек булып китте: концлагерьда эшләгәч, димәк, ул да гитлерчы дигән сүз бит инде...

– Ә сез шушында, Регенсбургта тудыгызмы? Мөмкин булса, сугыш елларында ничек яшәгәнегезне сөйләсәгез иде, герр Вернер. – Мин янә үземнең әбиемне, аның хәбәрсез югалган әтисе, коточкыч авырлыкта үткән авыл тормышы турында елап-елап сөйләгәнен күз алдымнан үткәрдем. Әйтерсең, җир шарының ике почмагында, кайчандыр кара-каршы торып сугышкан ике дәүләттә, язмышлары бер төенгә төйнәлгән, кемнәрдер кулында курчак булырга мәҗбүр ителгән ике зат миңа һәрберсе аерым-аерым үзенең хаклыгын исбат итәргә тырыша... Әгәр хакыйкать берәү генә булса? Нинди ул? Һәм кайда ул?

– Кечкенә чагым Buchsee авылында үтте. Бик матур җир ул. Яныбызда гына Дунай елгасы. Урманның икенче ягында – Австрия җирләре башлана. Безнең үзебезнең wirtshaus – трактирыбыз бар иде, әни күбрәк шунда эшләде. Бик гүзәл җирләр, гүзәл... Мәктәпкә җәяү йөреп укыдык, күрше авылга урман аша бара идек. Кайчагында өйгә дә килеп укыттылар. Хәтерлим, бер бик кырыс укытучы килә иде өйгә. Стенада Адольф Гитлерның фотографиясе булмаганга, әтине нык итеп орышканы истә. Шуннан соң әти аның портретын түргә элеп куйган иде... Сугыш башлангач, әтине фронтка алдылар. Без аны Мюнхенга кадәр озата бардык, әти бик тиздән әйләнеп кайтачагына шундый ышанган иде... Тик аны үтерделәр! Москоуга барып җитә язгач... Ярый әле дәүләтебез безгә аның өчен зур күләмдә пенсия түләп торды, мохтаҗлык күрмәдек. Тик сугыш безне ятим итте! Әнине акылдан яздыра язды. Илгә кара тап якты. Мине этисез калдырды. Мине дә, сеңлемне дә, абыемны да...

Карт Вернерның төсе уңып беткән күзләре коры булса да, күңеле елый иде. Сәяси уеннар, берәүләрнең гарип акылы, туймас тамагы, минминлеге, нәфесе аркасында кеше язмышларының челпәрәмә килүен аңына сыйдыра алмыйча, нәкъ минем әбием шикелле, кемне гаепләргә белми гаҗиз булуымы?..

Миңлегөл, 1945 ел, көз

Үткәннәргә ишек, чыннан да, бикле иде.

Бөтенләйгә, мәңге ачылмаслык итеп, мең йозакка бикләнде ул.

Бердәнбер өмет нуры – әткәй турында «хәбәрсез югалды» дигән соңгы хәбәр. Үлде димәгәннәр бит, сөякләре җирләнде димәгәннәр, бәлки, исәндер әткәем? Бәлки, яралангандыр да кайдадыр дәваланып ятадыр. Ул – минем өчен, мин – аның өчен бердәнбер булып калганны белмичә, кайтыр сукмакларда адашып кына йөридер... Иртәме-соңмы, аның юлы безнең каберләрне эзләп булса да, шушында алып киләчәк ләбаса! «Безнең», дидем... Чөнки мин үземнең җанымны шушында җирләп калдырам.

Парторгыбыз Сорокин мине китмәскә, авыр булса да чыдарга дип, ни үгетләмәсен, башкаларга ияреп, авылга кайтып китәргә дигән ниятем нык иде.

– Монда калсаң, сиңа бернинди җил-яңгыр тимәячәк, кызым. Кал! Үзебез укытырбыз, югары белем алырсың. Материкта ачлык, сугыш бетсә дә, әле кайчан аякка басылыр – билгесез. – Владимир Дмитриевичның нияте изге икәнен аңлыйм – кайгы-хәсрәттән тилерер хәлгә җиткән бик күпләргә аның әтиләрчә җылы сүзе, кайгыртучанлыгы таяныч булды. Тик мин үземне бирегә – Татар бугазы ярларына бәйләп тотар җепләрне югалттым инде. Кайчандыр әткәем-әнкәем безне – сеңлем Рәйханә һәм мине, меңнәрчә чакрымнар уза-уза, шушы Октябрьский посёлогына бәлки бәхет кошы тотарбыз дигән өмет белән алып килгән булса, хәзер мин җимерелгән-җимерелмәгән шахталарда булган бар бәхетле мизгелләрне, бәхетле көннәрне, бергәлекне, бөтенлекне мәңгегә җирләп, кабат авылга кайтырга җыенам.

Их, җанның сулкылдавын басар бер-бер чара булса кана...

Барак бүлмәсенең тәбәнәк тәрәзәсеннән кояшның саран, соргылт яктысы үрелеп карый иде. Тасма-тасма булып үрелгән ул яктылыктан, көз башы гына димәссең, җанны туңдырырлык салкынлык бөркелә. Бүлмәнең каракучкыл бүрәнәләренә кунаклаган шул салкынлыкта кызыл җәймәле агач өстәлнең дә, идән уртасында капкачы каерылып ачылган килеш торган чемоданның да, агач караватларның да тупаслыгы, килбәтсезлеге ныграк күзгә ташлана. Җанга шом үрләткән бу шыксызлыкка Галимә апайның әле төреп тыгылмаган чигүле мендәр япмалары гына бераз ямь өсти.

– Миңлегөл, үскәнем, юл хәйран ерак, бу балык пирожкиларын иң әүвәл ашап бетерергә булыр, име, җаным? – Әллә ничә ел шахтёрларга ашарга пешереп, теле дә баллы-майлыга әйләнеп беткән Галимә апайның. Элегрәк төп-төз басып, зифа буен уклау кебек йөрткән апай, иренең Смоленск шәһәре тирәсендә һәлак булуы турында хәбәр алганнан соң, күрер күзгә кечерәеп, бөкрәеп калган иде. Кайгысын кеше юкта нинди суларга салып чайкагандыр – йөзенә чыгармады, беркемгә кара коелмады.

Бары тик моңарчы баш очына чөеп бәйләгән яулыгы гына каш астына ук төшеп утырды. Оясыннан егылып төшкән кош баласыдай, берьялгызым үз хәсрәтем белән аунап ятканда, шушы Галимә апай мине аягыма бастырды, бүлмәсенә сыендырды.

Май аенда халык Җиңү көнен бәйрәм иткәндә, без Галимә апа белән икебез ике почмакта үкседек. Берничә татар гаиләсе туган якларга кайтабыз дип җыена башлагач, без дә аларга иярергә булдык. Монда бәйләп тотар җепләр калмаган, өзелгән, яндырылган, юк ителгән иде.

Пәлтәмнең эчке ягында – өч пачка белән илле сумлыклар. Шахта начальнигы Владимир Алексеевич Малючков якыннарын югалтканнарга мең ярым сум акча бирдерткән иде. «Боларның ни куанычы бар?» – дип үкси-үкси елаган мәлемдә, Галимә апа: «Кирәге чыгар, балакаем, ышанычлырак җиреңә тыгып куй», – дип киңәш биргәч, төреп, пәлтәнең эчке түш кесәсенә тегеп куйдым. Авылда ни көткәнен белмим бит әле, үз башымны үзем кайгыртырга калганны гына чамалыйм...

Утлы ядрәләре монда кадәр үк килеп җитмәсә дә, сугыш ялмаган иде авылны. Коргаксыган, тезләнгән, салам түбәләре кайсы кай якка авышкан өйләр; ачлыкның ыржайган авызына кереп йотылган да юк булган күрше-күлән; ягар утын юклыктан кышкы салкын кичләрдә мич куенына озатылган койма-капкалар; ат урынына үзләре җигелеп, колхоз тормышын сөйрәгән апалар каршы алды мине. Үз дисәм – үз түгел, чит дисәм – чит түгел... Менә бу урамнан, әткәемнең ике кулына ике төенчек шикелле асылынып, сеңлем Рәйханә белән атына-атына кайтып килгән идек... Менә бу тыкрыктан, әнкәемнең сабыр адымына түзеп атларга тәкатебез җитмичә, Рәйханә белән, яз җиленә ялын сипкән колынкайлар шикелле, юргалый-юргалый йөгергән идек. Менә бу капка төбендә, «Килендәш, төенчекләрең үзеңнән алда тәгәри бит», – дип, якты елмаеп, көянтәсен иңенә аскан Кафия җиңгәчәй каршы ала торган иде. Тагын шул капка төбенә кайтып төштем. Олы бер дөньяда канаты каерылып ятим калган киек каз булып. Юк, аучы ядрәсеннән яраланган, әмма яшәү көчен җуймаган кыр үрдәге булып. «Кайт! – дип язды бит Хәкимулла абзый. – Үз сөягебез үзебездән артмас, кайт, кызым!» – дип язды әткәемнең бертуган абыйсы, аның каны; аның йөз сызыкларын хәтерләтеп торган бердәнбер таянычым. Алар катына кайтып егылмый, бу башымны кайларга илтеп куйыйм?

Таң алдыннан ат арбасына төялеп, әнкәебезнең җылы куенына сыенып, аның вакыт-вакыт мышкылдап, борын тартуына сәерсенеп, ерак сәфәргә кузгалганда, әллә кайдагы Татар бугазына барып җитәрбез дә шунда җебе өзелгән муенса төймәләредәй, берәм-берәм чәчелеп бетәрбез дип, кайсыбыз гына уена китергәндер? Рәйханә белән мин – әле балалык яшеннән чыкмаган. Сабырлык чишмәсеннән учлап-учлап, сулар эчкән әнкәем – «тәкъдиргә язмаганы булмас әле» дип юаныч таба белә. Әткәебезнең авыл ягына каерылып-каерылып каравын ул чагында таң алсулыгы яшергән иде...

Сугышның кара йөзе миңа иң элек сул кулын фронт кырында калдырып кайткан Хәкимулла абзый кыяфәтендә ачыла башлады.

Буш җиңен бөгәрләп чалбар каешына кыстыра да, сыңар кулы белән утын ярырга тотына. Булышам дисәм, «хатын-кыз эше түгел!» – дип кертеп җибәрә. Элеккечә киерелеп-киерелеп селтәнәсе, икенче кулы белән

каерылып-каерылып маңгай тирен сөртеп аласы килүе сүз белән сөйләп аңлаталмаслык карашына кереп тула. Бу теләкнең нинди моң, нинди сагыш, нинди гаҗизлек, нинди нәфрәт белән сугарылганын аңлау өчен аңа нибары бер күз төшерү дә җитә.

Аннары – әтием турында бер-бер хәбәр булмасмы дип, авыл советы, район комиссариаты ишекләрен кат-кат кагу, Хәкимулла абый белән бергәләп, башкала военкоматларын таптау миңа сугыш кайтавазы булып ишетелә башлады. Әткәем фронтка Сахалиннан – Александровск шәһәреннән китсә дә, туу турындагы таныклыгында шушы авыл, шушы район күрсәтелгән ләбаса; салам эскертеннән, ныклап эзләсәң, иртәме-соңмы, энәне дә табарга мөмкин. Ничек инде әткәем тикле әткәем табылмасын... Кеше бит ул! Сезгә кадерле булмаса, минә миңа, аның исән калган бердәнбер баласына – кызына кадерле! «Хәбәрсез югалган» дип, пенсия бирүдән баш тартасыз икән, мине фронтовик баласы дип танудан куркасыз икән – анысы сезнең намуста. Мин бит сездән акча сорамыйм! Мин сездән әтиемнең исемен табуыгызны сорыйм!..

Җан әрнүем калын-калын диварларга гына килеп бәрелә дә, кайтаваз булып, әрнүле өн булып, кире үземнең аяк астына чәчри дә төшә...

Галия, 2019 ел

Үземнең бүлмәмне шундый яратам мин! Кечкенә генә булса да, вакытлыча гына булса да, ул – үземнең өем, үземнең территориям, үземнең дәүләтем. Шкафта да, тәбәнәк суыткычта бары тик мин теләгән ризыклар гына патшалык итә. Алмадан кала. Чөнки монда алма бик кыйбат! Бакчада яки Казан кибетләрендә бәрәңге урынына күреп ияләнгәч, үземне биш бәясенә сатып алгандай хис итәсе килми әлегә. Хәзинәмдә – «Аркаден»нан күтәреп кайткан брокколи. Черри помидорлары. Балык филесы. Кокос чипсылары. Паста. Паста. Паста.

Итальян дусларым Марко, Джосеф, Клара, Мириам, Линда, Аличе, Франческа мине тәки шушы пастага бәйләргә өлгерде, ахры. Безнеңчә әйтсәк, гадәти макарон, токмач инде югыйсә. Юк, паста дигәч, әллә ничек серлерәк булып китә. Мириам үз бүлмәсендә пастаны уылган помидор һәм песто соусында пешереп ашатты да шуннан гашыйк булып калдым. Өйдә чагында спагеттига, макаронга егылып китә торган кеше идемме? Хәер, әни аның янына сыер итеннән зур-зур кәтлит кыздырып сала иде, минә анысы иң беренче чиратта авызга шуа иде. Монда итне онытып торам әле. Альтштадттта төрекләрнең, гарәпләрнең хәләл кибете бар, диделәр, барып кына җитә алганым юк. Ә менә суыткыч ишегенә магнит белән ябыштырылган зур ак кәгазьдә минем бурычларым гельле кара ручка белән астына сыза-сыза язып куелган:

1. Ит ашамый торырга! (Бөтенләйгә түгел, вакытлыча!)

Анысын үземә хыянәт итмәс өчен махсус өстәдем. Чөнки, иртәме-соңмы, минем ашказаны, яшелчәләр генә ашарга тырыш дигән боерыгымнан туеп, кыздырылган тавык, кәтлит, өчпочмак таләп итәчәген алдан ук беләм.

2. Су спорты белән шөгыльләнергә! Вейкбординг!

3. Көн дә сигез чакрым җәяү йөрергә!

4. Дөньяга карашны тулаем үзгәртергә! (Бәхет дигәнне баш миенә

өйдәгеләр сеңдерергә теләгәнчә кабул итәргә маташма: эчми-тартмый торган әйбәт кешегә кияүгә чык... Балалар тап... Эшкә бар. Эштән кайт. Кулдан токмач басып, аш пешер. Вакыт-вакыт, Леруа-Мерлен яки Мегастрой кибетенә барып, яңа обойлар сатып ал – тормышка яңалык өстәргә телисеңме, рәхим ит, стенадагы обойларны алыштыр!.. Яз җитсә, Васильеводагы дачага барып, карлыганнар өстенә кайнар су кой. Җир ачылуга, кишер утырт. Помидор рассадаларын теплицага күчер. Җәй буе, һәр атна ахырында килеп, кыярларга су сип. Көз җитүгә, кура җиләге куакларын кис. Кыш көне, инде бераздан кар эрер вакыт җитәсен чамалап, бер-ике тапкыр булса да чаңгыда йөреп кайт... Өйдәгеләр фикеренчә, тамак тук, өс бөтен, барыбыз исән-сау – тагын ни кирәк... Шулкадәр бертөрлелектән ничек туймыйлар икән? Һәм шуңа бәхет дип табыналар! Юк, тагын бер тапкыр юк! Мин үзем нәрсә телим – беркемгә бәйле булмыйча, барысын да эшләргә телим! «Яшәү» дигән сүзне мин үземчә аңларга телим! Мин үземчә яшәргә телим! Минем хыялларым чиксезлеккә омтыла. Бар киртәләрне җимерергә тели. Илләр белән илләр, кешеләр белән кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне артка әйләнеп карамыйча гына кабул итәргә тели! Без бүген яшибез. Үткәннәрнең нигә кирәге бар? Алар булган, узган, узганда калсын да. Алга, бары тик алга карап яшәргә кирәк. Әледән-әле артка әйләнеп карау, тарих тузанында актарыну заманнан артта калдыра, аннан куып җитә алмавың да бар.)

5. Пауло Коэльоның «Алхимик» әсәрен алман телендә укырга!

6. Дженни белән Мависны гөбәдия пешерергә өйрәтергә. Корт тапмасак, өчпочмак пешерергә.

Канатларын җәйгән акчарлак-магнитик минем шушы араларда эшләнергә тиешле «бурычларымның» иң җиңелләрен күтәреп тора иде.

Ванна бүлмәсен юеш чүпрәк белән сөртеп чыкканнан соң, кулымны футболка итәгенә генә сөртеп корыттым да, тәрәзә төбендә яткан зәңгәр фломастерны алып, 7 нче пунктны өстәп куйдым:

7. Дахауга барырга.

Үзем дә аптырап калдым: Дахау – Мюнхен янында, ә мин Мюнхен, Нюрнберг, Берлин кебек шәһәрләргә соңрак, көзге суыклар башлангач сәяхәт итәрмен дип планлаштырган идем. Әле урамда 25 градус торганда, су спорты! Су спорты!

Тик сәер бер көч мине үзенә буйсындырырга маташа иде. Кулымдагы фломастер, эчке карышуымны җиңеп, 2 нче һәм 7 нче пунктларның урынын уклар ярдәмендә алыштырып куйды.

...Дахауга барырга мин үзебезнең төркемнән Миро белән Дженнины гына күндерә алдым. Миро – Аргентина егете. Куе кара дулкын чәчле, каратут тәнле, күзләре генә түгел, ап-ак тешләрен күрсәтеп, калын иреннәре дә елмаерга гына тора. Алманчасы минеке чамалы; курсларда, гадәттә, ул, мин, тайвань кызы Дженни гел өчәү бергә утырабыз. Миро кулындагы мате стаканын йоклаганда да үзеннән еракка куймыйдыр шикелле тоела: кая гына барса да, янында шоколад төсендәге, нәни чүлмәккә охшаш стаканы, трубочкасы, мате чәе. Шуңа да аңа Миро дип дәшүдән бигрәк, Матэ диясе килә... Беркөнне бомбильясын – чәй суыра торган таякчыкны Миро үзләренчә бомбижже дип атый – кайдадыр югалтып килгән. «Аны югалтканчы, паспортны югалтсам соң...» – дип, кара кайгыга баткан иде...

Мондагы транспортның секундына кадәр төгәллек белән йөрүенә тәмам күнектек. Ярты минутка соңга калдыңмы – поезд артыннан кул изәп калачагың билгеле. Шуңа да Bahnhof – банхоф-вокзалга иртәрәк кузгалдык. Алдан сөйләшсәк тә, болай ук булмас иде: өчебезнең дә өстебездә эре хәрефләр белән Регенсбург дип һәм вак кына итеп, тулай торак адресы язылган ак футболка, зәңгәр джинсы чалбар һәм ак кроссовкалар. Униформа диярсең! Ярый инде, хет рюкзакларыбыз төрлесе төрле төстә.

– Булган бу! Теләсә кайсы барда егылганчы эчәргә була – туп-туры бүлмәгә кайтарып куячаклар! – дип, авызын ерды Миро, безнең көлешүгә кушылып. – Галә, син дуңгыз ите ашамыйм дидең, ә менә шнапс эчәргә ярыйдыр бит?

– Ни ул? – дип сорадым мин, чыннан да шнапсның нәрсә икәнен аңламыйча.

– Син нәрсә, әллә эчеп караганың юк? Немец аракысы! Грушадан, яки алмадан, чиядән ясалган! Во! – Миро бер күзен кысты да авызын колагына җитәрлек итеп ерып: – Дөрес, минем дә эчкәнем юк әле. Ә кешеләр мактый, шәп диләр! Миңа сыралары ошый, вәт анысы чыннан да шәп! – диде ул, баш бармагын тырпайтып.

– Безнең Тайваньда да иң тәмлесе – биа! Мондагыча, сыра була инде. Яки дөге шәрабы, – диде Дженни, алкоголь буенча белгеч шикелле, шулкадәр җитди итеп.

– Ә мин гранат согы яратам. Алкогольле эчемлекләр кызыктырмый, – дидем мин, үземне балаларча тотканымны аңласам да, һич кыенсынмыйча. Эчеп караганым юк, җыенмыйм да – нәрсә дип кыланып, алдап торыйм? Биредә студентлар моның ише сорауларга җиңел карый, хәтта укытучылар да, төрле кичә оештырганда: «Спиртлы эчемлекләрне үзегез белән күтәреп йөрмәгез, вечеринкада сатуда булачак», – дип, киңәш бирүне гадәти саный.

Сүз җебе болай алкоголь турында бөтерелүнең үзенә күрә сере бар иде.

Тулай торакка урнашып, берничә көн үткәч, почта тартмасының ачкычын сорап, хаусмайстер янына кергән идем. Немецча сөйләшергә әңгәмәдәш кенә булсын – герр Оттоның хәлемне белешеп биргән соравына тәмләп сөйлим. Аның кыска керфекле соргылт күзләрендә вакыт-вакыт аңламау чагылып китә: димәк, кайсыдыр сүзне ялгыш яки урынсыз әйтүем... Аңа ничә яшь икәнен һич кенә дә чамаларлык түгел, гәүдәсенә карасаң, үсмер егет шикелле генә, бик ябык; өстендә – буйдан-буйга ике рәт булып төймәләр тезелеп төшкән яшькелт күлмәк. Башына мәңге төшмәслек булып береккәндәй күренгән эшләпәсенә күз салсаң – ул эшләпәнең бу гасырныкы түгеллеге көн кебек ачык. Илле яшь тирәсе микән аңа? Азрак микән?

– Алтмыш сигез яшь тула миңа, – диде ул, минем авыздан ахыр чиктә барыбер яңгыраган сорауга балкып елмая-елмая. – Күңел генә һаман вечеринкаларда йөри... Ох, Галә, мин бит сезгә футболка бирмәдем түгелме? Вечеринка дигәч искә төште... – Ул, нәзакәтле хәрәкәт белән маңгаена сугып куйды да бүлмә уртасында торган шкафны ачып, кечкенә генә бер төргәк алды, буй-сыныма күз йөгертте. – Сез ничәнче размер киясез?

– Кырык икенче, – дидем мин, бераз аптырый төшеп.

– Яраячак! – Ул, төргәкне сүтеп, түше язулы футболканы ялт кына

минем өстемә куеп карады. – Һәркемгә бирәбез мондый футболкаларны, күрәсезме, түшенә тулай торакның адресы язылган!

– Кызык, – дидем, көтелмәгән бүләккә шатлануымны яшермичә. – Мондыйны күргәнем юк иде әле.

– Вечеринкага бу футболкадан барсагыз, курыкмыйча рәхәтләнеп эчә аласыз! – Оттоның йөзе мыскыллап түгел, минем өчен чын күңелдән сөенүдән балкый иде – әйтерсең, мине биниһая зур бер шатлык көтә!

– Гафу итегез...

Берни аңламавымнан чыраем аңгыра шалканны хәтерләтте, күрәсең. Отто тагын елмайды:

– Вечеринкада күңел ачып, артыграк эчсәгез, таксида кайтканда, үзегезнең кайда яшәгәнне аңлатырлык хәлегез булмаса, бер дә куркасы түгел диюем – футболкадагы адрес буенча таксист сезне ишек төбенә кадәр китереп куячак! Махсус шуның өчен языла!

Прикольно!

– Тик... Мин эчмим бит! – Кызганыч тоелса да, футболканы кире кайтарырга җыенган идем, Отто баш чайкады.

– Футболка сезнеке. Паркка йөгерергә чыкканда да кия аласыз!

Вәт бабай! Нибары бер тапкыр иртә белән күршедәге паркта йөгереп керергә җитештем – шуны да күз уңына эләктереп алганмы?..

Чыннан да, мондый футболкаларны тулай торактагы һәркемгә бирәләр икән. Һәм, чыннан да, таксистлар өчен анда язылган адрес буенча клиентны кайтарып кую күпкә җиңелрәк икән...

Дахау шәһәренә сәяхәтебез әнә шуны искә төшереп шырык-шырык көлешүдән башланды.

Поездга кереп тәрәзә буендагы утыргычларга урнашуга, Миро ашыга-ашыга рюкзагын салып ташлады да:

– Мискузи! Кызлар, мин бәдрәфкә! – дип, вагонның икенче башындагы кабинкага таба атлады.

«Хәзер киләм», – дип, артыгын шәрехләми генә китсә дә, ярар иде дә соң... Хәер, аның мондый тәкәллефсезлегенә беренче кат кына тап булуыбыз түгел, баштагы мәлдә генә сәер тоела иде, хәзер артык аптырау юк. Нәрсәсе бар? – Аның кебек көнозын кулыңнан төшерми мате чәе эчеп йөрсәң, үзең дә почмак саен торып чабарсың.

Дженни наушникларын бүлмәдә онытып калдырган булып чыкты, көрән төстәге кечкенә рюкзагын астын-өскә әйләндереп эзләгәннән соң шул ачыкланды. Ул малайларча кистергән кыска кара чәчен бармаклары белән тарый-тарый, кысык кара күзләрен җемелдәтә-җемелдәтә, ах-ух килде:

– Юлда тыңлармын дип, яңа җырлар яздырган идем. Вокзалда наушник сатыла торган кибет булырмы? Нишлим инде мин наушникларсыз? Кайда калдырдым аларны? Өстәлдәме? Кроссовка кигәндә, ишек төбендәге этажеркадамы?

Ну Дженни!.. Әйтерсең, кайда калдырганын исенә төшерсә, колакчыннары менә шушы минутта безнең янга йөгереп килеп җитәчәк.

– Җыр тыңламыйбыз. Үзем белән Wizard уены алдым, барганда-кайтканда шөгыль бар, – дидем мин, рюкзак кесәсеннән карталарымны чыгарып. Тәрәзә астына беркетелгән өстәлне алдыбызга төшердем.

Мондагы поездлар – искиткеч! Йөзеп бара диярсең, бернинди тавышы ишетелми. Селкетми, дерелдәтми. Өстәлгә сулы чынаяк куйсаң, чайпалып түгелмәсме дип, башка да китерәсе юк. Айфонны зарядкага куярга мөмкинлек бар. Вай-фай эшли. Тагын бер тапкыр супер!

– Галэээ! – Иелеп, зарядникны электрга тоташтырган мәлдә, Дженниның еламсыраулы тавышына башымны күтәрсәм, ике күзе тулы мөлдерәмә яшь! Кай арада диген?! – Кулындагы газлы пепси шешәсен ни рәвешле ачарга өлгергәндер – тирә-якка эфлисун исе тараткан эчемлек ак футболкасының нәкъ күкрәк турысына чәчрәгән, эре-эре хәрефләр арасында тап-тап булып балкып тора.

Дженни чыннан да күз яшьләре белән елый иде. Бакча баласымыни? Башта үз телендә, аннан инглизчә такмаклавыннан үзем дә еларга да, көләргә дә белми аптырап калдым. Чынлап шулай зурга алып борчылуымы, шаяртуы гынамы? Каш ярылып, күз чыкмаган ла...

– Ни өчен мин шундый булдыксыз? Ничек мин шундый кыяфәттә поездда барам? Нигә дип бу пепсины үзем белән алдым?..

– Җебегән! – дидем мин, түзмичә, татарчалап кына, барыбер аңламасын белеп. Аның мондый эмоцияләре үзем өчен сәер тоелды. Футболка пычранды дип, кем инде кычкырып елап торсын? – Юабыз да киләбез, бетә ич ул, бер проблема да юк, – дип өстәдем, инглизчәгә күчеп.

– Галэ, син Дженнины кыйнарга да өлгерденме? Ай-яй-яй! – дип, башын чайкый-чайый, Миро ялт кына аның янына килеп тә утырды, Дженни, тамагына кылчык кадалгандай, шып туктады. Дөресрәге, ул елый да, дәшә дә алмаган халәттә катып калды. Тик озакка түгел.

– Мироо! – дип, тагын авызын җәйде ул, тик бу юлы күзләрендәге юеш тамчыларда салават күпере биеде. Кулы белән утыргычка ымлады.

– Тәк. – Егет, нидер сизенеп, читкәрәк шуышты, шикләнеп кенә чалбарының артын тотып карады, торып басарга ашыкмады. Сораулы итеп әле миңа, әле Дженнига карады.

Кыскасы, кәртләр белән уйный алмадык. Юлыбызның яртысы тынсыз калганчы көлә-көлә туалет бүлмәсендә алмаш-тилмәш әле футболка, әле чалбар юып үтте. Урамга чыкканчы бераз булса да кипсен дип, Мирога вагон буйлап, кулларын артка куеп, әрле-бирле йөренергә, Дженнига, футболкасының юеш күкрәк турысын җилләтә-җилләтә, кондиционер астында басып барырга туры килде. Мин исә, көлү өянәген тыярга теләп, инстаграмда актарынып бардым. Шулай да вакыт-вакыт юлдашларыма күз төшергән саен үземне кулга алалмыйча, шаркылдарга тотына идем.

Шулкадәр рәхәт иде. Ниндидер ашкынулы рәхәт. Хәзер инде юктан да көләсе, шаярасы, күңелдәге шундый җиңеллекне дөньяга таратасы килә. Күрегез, барысы да шундый гади! Беркемгә дә юктан проблема ясап кайгырырга, борчылырга кирәкми! Барысы да «ә» дигәнче үтә дә китә... Кызык, ә үтми торган, онытып булмый торган яралар диләр – бик теләсәң, ничек инде онытып булмасын?! Әлбәттә, күңелдән йолкып атарга, үзеңнән алып ташларга, бары тик онытырга гына кирәк. Оны-тыр-га. Шуның белән шул.

Дахау – Мюнхеннан унҗиде чакрымда урнашкан шәһәрчек. Поездлан төшкәч, 726 нчы номерлы автобуска күчеп утырдык, ул бушлай булып чыкты, санаулы минутлар эчендә Memorial Site тукталышына китереп

тә җиткерде. Без башта тиз генә элек концлагерь булган мемориаль комплексны карап чыгарга, аннан шәһәрчекнең башка тарихи урыннары белән танышырга, сәяхәтебезне кечке Мюнхенда дәвам итәргә килештек. Интернеттан карап, монда 1933 елда беренче зур концентрацион лагерь төзелгәнен, анда башта рейх режимына каршы булганнарны, яһүдләрне, сугыш елларында совет солдатларын әсирлектә тотканнары турында аз-маз гына укып өлгергән идем. Беркөн Вернер әлеге лагерь турында да телгә алгач, кичен ватсаптан әтигә дә язып җибәрдем. Ә безнең Әхтәм бабаебыз кайсы шәһәрдә, нинди лагерьда булды икән? Бәлки, ул да Дахауда әсирлектә яткандыр? Бәлки, аны нәкъ менә герр Вернерның абыйсы Руди дәвалагандыр? Чыннан да шулай икән – менә кызык булыр иде! Ничә елдан соң аларның оныклары бер ноктада очраша! Гел кинодагы кебек! Круто!.. Тик әти әле дә булса соравыма җавап язмады, таба, ачыклый алмавы идеме...

– Ой! Миро, синең джинсың тәмам кипкән. Бер эзе дә юк. Минем футболка да! – Дженнининң сөенече эченә сыймый иде, ул, автобустан төшеп, рюкзагын аркасына кия-кия, Мироның чалбарын тотып карады.

– Галә, ә СССРдан Дахау лагеренда күпләр булганмы, син беләсеңме? – диде Миро, аны бөтенләй ишетмәгәндәй, күзе белән тирә-якны айкап.

– Мин сугыш турында, гомумән, аз беләм. 1941 елның 22 июнендә фашист Германиясе безнең илгә басып керә. 1945 елның 9 Мае – Җиңү көне, совет гаскәрләре аларны җиңә, – дидем мин, бу яктан үземнең шыр наданлыгымны яшермичә, турысын әйтеп. – Тарих фәнен яратмыйм мин, вакыт әрәм итәсе килми, күбрәк телләр, телләр өйрәнергә телим!

– Сәер. – Миро минем җавабымнан аптырап калдымы – йөзенә галәмәт бер сәерсенү таралды. – Тел өйрәнү өчен тарих менә дигән таяныч!.. Икенче Бөтендөнья сугышы турында мәктәптә безгә дә сөйләделәр.

– Безгә дә сөйләделәр. Сугыш турында шигырьләр дә ятлый идек. – Ничәнчедер сыйныфта укыганда, Муса Җәлилнең «Вәхшәт» дигән шигырен сәхнәдән укыган идем – шуны искә төшереп, бер-ике куплетын үземчә инглизчәгә тәрҗемә итеп, дусларыма да сөйләп күрсәттем.

– Җәлил – рус шагыйре, димәк? – Әһә, җыр, шигърият дигәндә, Дженнининң күзләре ут яна инде!

– Юк, ул безнең татар шагыйре! – Кара, миндә бераз борын чөюме – моңарчы бик үк таныш булмаган ят бер хис баш калкытырга маташа түгелме? – Ул да сугышта катнашкан, фашистларга әсирлеккә эләккән. Германиядә Моабит төрмәсендә гильотинада башын кисеп үтергәннәр! Төрмәдә язган шигырьләре илгә кайтып җиткән, – дидем, үземнең бөтенләй үк төшеп калмавыма эчтән генә сөенеп. Җәлил хакында ярыйсы беләм, мин бит садикка татар бакчасына йөрдем, шул чагында ук Нәфисә апа башыбызга бик шәпләп сеңдергән иде.

– Муса Җәлил... Кайту белән, интернеттан аның турында укыячакмын! – дип, Миро телефонына шул хакта искәртү дә язып куйды. – Дахауда да татарлар булгандыр әле.

Сискәнеп киттем. Әхтәм бабам турында уйлап куюымнан тыш, үз-үземә мондый сорау бирмәгән идем.

Без, автобустан төшкән төркемгә ияреп, администрация бинасына үттек. Чөнки яныбыздан атлаган ап-ак чәчле бер ир безгә: «Экскурсиягәдер бит?

Монда кереп, аудиогид алыгыз, уңайлырак булыр», – дип, киңәш бирергә өлгерде. Мемориалга экскурсия бушлай булып чыкты, төрле телләрдә, шул исәптән русча да сөйләүче аудиогидны гына түләп аласы. Мин алман телендәгесен сайладым.

Комплексның капкасына алып бара торган аллеядан атлаганда ук, Дженни төймәләрнең әле берсенә, әле икенчесенә баскалый-баскалый, трубканы колагына терәп, күгәрчен урынына гөрләде:

– Ой, телефон кебек! Ой, шундый аңлаешлы сөйли! Ой, инглизчәсе шәп! Ой, кайсы ноктада нәрсә тыңларга телим – шул кнопкага басарга мөмкин!

Аһ, бу Тайвань кызындагы эмоцияләр! Мизгел эчендә мәлҗерәп, юк өчен дә күз яшьләре белән еларга мөмкин; кызык тапкан мәлендә, бая, футболкасының изүен юганда көлүдән туктый алмый тәгәрәрдәй булып шаркылдады; шаккаткан чагында, әнә, алыштырып куйганнармы – шәрык гүзәлләренә хас озынча тар матур күзләрендә учак теленнән чәчрәгәндәй очкын сирпелә, менә-менә кабынып китәр шикелле.

– Дженни, иркенләп тыңларга бирмисең! Үзең генә, читтәрәк йөр әле! – Миро, колагына куйган трубканы сүндереп, Дженнига шелтәле карап куйды. Егетнең тәкәллефсезлеге турында кисәттем бугай. Аның сүзләренә үпкәләргә, борын салындырырга кирәкми – уйлаганын әйтә дә сала, холкы шулайрак.

Элекке лагерь территориясенә алып керүче капкага алманча «Арбайт махт фрай» – «хезмәт ирекле итә» дип язып куйганнар. Керү белән уң якта – кайчандыр администрация, регистратура ролен үтәгән бина. Аудиогид сөйләвенә ияреп, шул якка атлыйм. Менә бу залда әсирләрне кабул иткәннәр, анкета тутырганнар. Пыяла астына тезелгән сәгать, йөзек, документ ише әйберләр – тоткыннардан җыеп алынган экспонатлар.

Һәр плакат янына тукталып, колагымда яңгыраган сүзләрне ишеткән саен мине коточкыч авырлык басканын тоя барам. Бинаның эче дә шундый авырлык белән сугарылган: гүя бу соры, шыксыз стеналарга әсирләрнең тән һәм җан газаплары мәңгелеккә сеңеп калган да, алар ул газапларны бирегә аяк баскан һәркем белән бүлешергә тели... Тоткыннар арасында яһүдләрдән башлап, кемнәр генә юк?! «Руссе» дигән сүзләрне, исем-фамилияләрне очраткан мәлдә, тәнемнән эсселе-суыклы бер дулкын йөгереп үтә. Рәсәйдән! Совет солдаты... Әсирләргә бирелгән калын табанлы агач башмак, пижамага охшаш, буй-буй сызыклар төшкән күлмәк тагын моңарчы таныш булмаган тойгыга күмә. Тәк, ә бүген безгә, яшьләргә, мода дип, тач менә шушындый буйлы-буйлы күлмәкләр, кофталар, итәкләр тәкъдим ителүне ничек аңларга икән? Кызык. Ә бәлки... кызганычтыр?.. Тик бу хакта артык уйланып торырга җаем юк иде.

– Кинозалга керәбезме? Документаль фильм. Тик хәзер французча булачак. Сәгать ярымнан соң – инглизчә. Ну, нишлибез? – Шулай дип киңәш сорагандай итсә дә, Миро, Дженни белән икебезне ялт кына әләктереп, инде рәт-рәт эскәмияләр тезелгән залга алып керергә дә өлгерде. Фильм әле башланмаган, кешеләр күләгә шикелле йөзеп кенә керәләр дә тавышсыз гына эскәмияләргә чүмәшәләр. Гүя бирелә, янәшәдә кемнәрдер татлы йокыда изрәп ята; бер-бер ым каксаң, аваз салсаң, кыштырдасаң, уятырсың кебек. Әллә бу диварлар арасында чыннан да тоткыннарның

рухлары йоклый микән? Бр-р... шомлы уемнан тәнемә салкын йөгергәнен тойдым. Кинозал дисәм дә, безнең күз күреп күнеккән комфорт юк монда: һәр почмактан салкынлык, шом бөркелеп торган зур зал. Аны тутырган артсыз эскәмияләр. Алда – зур экран. Бетте, сулыш алырга кыймагандай, тын гына көтеп утырган тамашачылардан гайре, беркем, берни юк. Монда беркем дә шешәсен ачып, сыра чөмерми, беркем поп-корн кыштырдатмый, беркем сөйләшми...

Документаль фильм Дахау концлагерендагы әсирләрнең коточкыч тормышы турында иде. Французча барса да, андагы вәхшилекне аңлар өчен тел белү бөтенләй таләп ителми икән. Ә менә аңга кабул итү өчен күп, бик күп кирәк иде. Кеше дигән затның шулкадәр кыргый, мәрхәмәтсез, куркыныч җанвардан да җанваррак икәнен минем баш мие болай гына аңларга, бер-бер нәтиҗә чыгарырга әзер түгел иде.

Экранда – утын әрдәнәсе шикелле бер-берсе өстенә өеп тезелгән, шәрә гәүдәләре кылчыкка, скелетка калган әсирләр. Икенче кадрда – лагерь эчендә алып барылган медицина тәҗрибәләре, аларның корбаннары.

Коточкыч! Әсирләр белән нинди генә тәҗрибәләр уздырылмаган биредә?! Кеше организмының салкынга чыдамлыгын тикшерү өчен – ә мондый тикшерүләр немец очучылары һәм моряклары өчен мөһим булган – әсирләрне бозлы суда катырып ясаган тәҗрибәләре, аларны ялангач көе өсләренә бозлы су коя-коя яки бозлы су салынган чанга батырып газаплаулары, һава температурасын, сәгатьләрне, гомумән, туңып үлү өчен күпме вакыт кирәклеген күңел болгаткыч бер төгәллек белән барлап торулары турында тыңлаганда, ике бит алмам эчтән кызып янарга тотынды.

Гиммлерның махсус боерыгы буенча тоткыннарга малярия йоктырып, аларны, тәҗрибә куяны рәвешендә, тере килеш тунаулары; кешеләрнең бавыр, бөер, ашказаны, йөрәк кебек органнарын кыргыйларча «өйрәнүләре» хакында ишетү дә коточкыч иде.

Кайберәүләрне кислород булмаган бүлмәдә югары басым астында сыныйлар, мондый тәҗрибәгә эләккәннәр күз алдында акылдан язалар, башларын стенага бәрә-бәрә кычкыралар, баш миенә кан савудан үләләр. Аларның гәүдәләрен шунда ук камерадан чыгарып, эчке органнарын алып, тикшерү өчен Мюнхенга җибәрәләр. Мондый тәҗрибәләр Германия авиациясе өчен бик кыйммәтле була.

Әлеге кыргыйлыкның баштагы мәлләрдә бернинди наркозсыз алып барылуы, соңыннан гына, әсирләрнең коточкыч кычкырулары, ыңгырашулары лагерьга ишетелмәсен өчен, аларга укол кадый башлаулары турында сөйләүләреннән чәчләр үрә торырлык.

Яңа гына үлгән мәетләрнең күкрәк һәм арка турысыннан тиреләрен салдырып, аларны эшкәртеп, перчатка, хатын-кыз туфлиләре, сумка, атта йөрү өчен махсус чалбар тегүләре...

Дахау – башка концлагерьлар өчен үрнәк, өлге булып торган лагерь. Биредәге әсирләр белән эшләү тәҗрибәсен килеп-килеп өйрәнгәннәр...

Кинозалдан барыбыз да суырылып, өстебезгә бер чиләк шакшы су койгандай каралып чыктык. Алдагы залларга аяк баскан саен күз алдыбызда аклы-каралы фотолар, коры экспонатлар түгел, әле генә экранда күргән чокыр-чокыр күзләр, әрдәнә-әрдәнә гәүдәләр җанлангандай иде...

Телефон трубкасы кебек күрер күзгә гади генә тоелган аудиогидта моның кадәр күп һәм җентекләп тупланган мәгълүмат бардыр дип башыңа да китермәссең! Дөньяның мин бөтенләй белмәгән, әлегә кадәр кызыксынмаган, дәреслектән укысам да, әкияттә булган вакыйгалардай гына кабул ителгән ягы каршымда коточкыч чынбарлык булып ачыла бара.

Менә монда – кайчандыр бер-бер артлы тезелеп киткән бараклар булган. Хәзер аларның урыны гына сакланган. Алдагы ике баракны исә, элекке рәвешкә китереп, соңыннан гына салганнар. Аның эчендә – өчәр катлы нарлар. Бер башында – әсирләр өчен юыну бүлмәсе.

Баракларның кайберсе мастерской булган, әсирләр шунда эшкә йөргәннәр. Ә кайдадыр... кайдадыр... тоткыннарның гәүдәләрен ботарлый-ботарлый, иң гуманлы һөнәр ияләре киләчәк медицинасының ачышлары өчен тәҗрибәләр уздырганнар.

Кинәт башым әйләнеп киткәндәй булды. Вернер үзенең абыйсы Рудины да лагерьда мәктәп узды диде ләбаса! Менә нинди мәктәп турында сүз барган икән!

Коточкыч иде.

Тәнем эсселе-суыклы булып китте.

– Галэ, ...нчы кнопканы тыңлап кара әле! – Дженни, елардай булып, карашын лагерьның алгы башындагы бушлыкка төбәгән иде. Берәрсе катырак сүз әйтсә, елап җибәрүе дә бар, ышан аңа...

Дженниның кәефен тагын да кырмас өчен, сүзен тыңлап, ул әйткән төймәгә күчәм.

Әлеге почмактагы барак фахешханә – «публичный дом» ролен үтәгән. Әсир хатын-кызларны, төрле мәсхәрәдән, авырулардан таушалып беткәнче, җан тәслим кылганчы, шунда йөрткәннәр. Янәсе, бу – әсирләрнең эш дәртен, «трудоспособность»ны арттыру өчен бик мөһим нәрсә булган...

Күңел болгаткыч, косасыны китергеч, коточкыч иде...

– Галэ, анда япь-яшь кызлар да булса? Бигрәк кызганыч, мескеннәр! – Дженни еларга өлгергән, керфек очларыннан юеш тамчы тәгәри иде.

Миро бездән ике-өч адымга читтәрәк йөри. Күрәсең, сүз катып борчуыбызны теләми. Шулай да, Дженниның халәтенә игътибар иттеме, яныбызга килде.

– Кызлар, сез нәрсә? Бар нәрсәне дә йөрәккә якын алырга кирәкми! Булган – үткән... Тарих дип кабул итегез! Теге вышкаларга карагыз әле, пулемётчылар шунда басып торгандыр бит инде... Күрдегезме, таш койма буенда кечкенә арык агып ята. Чәнечкеле тимерчыбык янында, дим...

– Миро, ә синең елыйсың килмиме? – Бигрәк самими инде бу Дженни, күзләреннән күренеп тора.

– Юк. – Мироның болай да каракучкыл йөзеннән ни дә булса уку мөмкин түгел, ул беребезгә дә туры карамады.

Сүзсез калып, янә трубканы колакка терәп, озын булып сузылган сукмактан атлыйбыз. Сул якта – суы үтә күренмәле, шулкадәр чиста, бик тар инеш, аның аша салынан кечкенә басмадан чыгуга – крематорий бинасы.

Тәннең бер салкынга, бер ялкынга чорналган мәле. Без килгәндә генә, бәллүр тоелган һавага тынны капларлык, сулышны буарлык бер ис таралган кебек. Чынлыкта бер ис тә юк, шул ук һава, шул ук тынлык – яфракларның

лепердәвенә кадәр ишетергә була. Тик... янәшәдә генә күз яшьләреннән торган болыт, ул күз алдын томалый..

Алдыбыздан, безнең кебек үк аудиогидны тыңлый-тыңлый, берничә кеше атлый. Беркем дә сөйләшми. Крематорийның аерым бүлмәләренә үтәбез. Тоткыннарның чишенү бүлмәсе, монда аларга, ялангач калганчы, бөтен киемнәрен салырга кушылган. Алдагы бүлмә – «душ»: түшәмдә чыннан да «душ» рәшәткәләре. Бичара тоткыннар, юынуга өметләнеп, үзләрен нәрсә көткәнне башларына да китермичә, шуның астына килеп тезелгәннәр. Ә теге якта кемдер газ төймәсенә баса: рәшәткә арасыннан әсирләр өстенә исерткеч, сулышны буа торган газ агыла... Алда исә – аларның иссез-җансыз гәүдәләрен утын урынына көтеп торган кып-кызыл мич авызлары...

Мин, үземнең буыла башлавымны тоеп, тиз генә урамга атылдым. Әйтерсең, эчтә басып торган мәлемдә, үземнең янәшәмдә Әхтәм бабамның куркудан зур булып ачылган күзләрен күреп алдым – кинәт кенә әллә нәрсә булды, башым әйләнергә тотынды. Куркыныч иде: әсирлек газабыннан исән кайткан бабам турында, ул күргән мәхшәр турында мин бөтенләй берни дә белмим! Аның улы – әтием дә белми! Бабам чыннан да сөйләмәгәнме, әллә әти дә, минем шикелле, белергә тиешлеләрне дә колак яныннан гына уздырып барганмы?

Тизрәк, мөмкин кадәр тизрәк миңа бабамның кайда булганын белергә кирәк иде! Әгәр ул менә шушы урында, шушы лагерьда булса? Бу минутта мин аның эзләре буйлап атласам?

Алай дисәң, мондагы тәмугка эләккән булса, илгә кайта алыр идеме?..

Ә башка концлагерьлар? Алар да бөтен үрнәкне шушы Дахаудан алган дип, бая гына тыңладым түгелме?..

Кичер, бабам! Мин, яңа буын, яңа гасыр баласы, синең турында да, синдәйләр өлешенә тигән сынаулар хакында да белмим диярлек...

Дахаудан кайтканның икенче көнендә ачышка юлыктым. Интернетка миннән дә күбрәк мактау сүзләре яудырган кеше бар микән?..

Ул төрмәдә безнең татар шагыйре Хәйретдин Мөҗәйне җәзалап үтергәннәр! Чын исеме Мөҗәһит Хәйретдин улы Хәйретдинов икән, Башкортстанның Туймазы районы Төрекмән авылында туган булган.

Их, мин бит бу хакта экскурсиягә юл тотканчы ук белергә тиеш идем!

Харьков шәһәре тирәсендә чолганышта калган. Әсирлеккә эләккәч, Мюнхендагы совет хәрби әсирләре лагерена ябылган. Шунда интернациональ антифашистик яшерен оешма җитәкчеләреннән берсе булган. Әсирләр арасында фашизмга каршы көрәш алып барып, баш күтәрү өчен коралларга тиклем булдырганнар. Тик 1943 елның ахырында гестапо яшерен оешманың эзенә төшкән. Җитәкчеләрен Дахау концлагерена ябып, озак газаплагач, үлем җәзасына хөкем иткәннәр. 1944 елның 4 сентябрендә фашистлар 92 Дахау тоткынын җәзалап үтерә. Аларның берсе – безнең татар шагыйре, полковник Хәйретдин Мөҗәй булган!

Никтер бу хакта мәктәптә сөйләгәннәре истә калмаган иде шул...

Әхтәм бабай рухы

Миндәйләр гомер буе үзебезне гаепледән гаепсез хис итеп яшәргә дучар ителгән иде.

Без – гомер буе әсирләр сафында булдык.

Башта – фашист төрмәсендә.

Аннан – советныкында.

Аннан – кешеләр чолганышында.

Җир йөзендә чагында тәнем иреккә чыккач та, җаным гомер буе богауда яшәде.

Менә хәзер генә җаным чын ирек тәмен татыды. Чиксезлектә – мәңгелектә генә мин ул тәмгә тәмам сусаганымны аңладым: гүя яргаланып, канап беткән иреннәремә бер тамчы су тигерергә тилмереп, атналар, айлар, еллар буе, юк, алай гына да түгел, гомер буе эссе чүлнең кайнар комына аякларымны батыра-батыра, чәнечкеле үләннәренә абына-абына атлап килгәнмен дә тешләрне камаштырырлык саф чишмәгә юлыкканмын. Эчәм-эчәм – сусавымны баса алмыйм. Йотлыга-йотлыга, ирек тәмен эчәм...

Моосбургның Шталаг VII A дип тамгаланган төрмә баракларында мин исемсез зат идем. Буйлы-буйлы әсир күлмәгенең аркасына сугылган номердан кала, миндәйләрнең исеме-аты юк иде. Кырмыска оясына игътибар белән төбәлеп торганыгыз булса, күрми калмагансыздыр: беренче карашка бөтенесе бер иш күренгән кырмыскалар әрле-бирле йөренәләр, кайсы үзеннән ике-өч тапкырга зуррак үлән кисәген йә җилкәсенә салып, йә авызына кабып, ояга таба сөйри. Хәле җитмәсә, ташлап та калдыра. Яки берәр иптәше аның янына йөгереп килеп җитә дә үләнне икесе ике баштан «тотып», парлашып күтәрәләр. Тырышып-тырмашып дөнья көтәргә, яшәргә маташулары. Шунда адәми затның итек үкчәсе пәйда булса, бетте: табан астында калып, бер түгел, ике түгел, йөзләгән, меңләгән кырмыска һәлак була. Иң аянычы – аларның качып котылу мөмкинлеге юк. Хәер, язмыштан качып буламы инде?.. Безнең дә кырмыскадан артык җиребез бар, дисезме?.. Теләсә кайсы мизгелдә исерек фашистның да, айныгының да автомат көпшәсе күпләп юк итәргә әзер тора. Сәбәп тә кирәкми. Күңел ачарга теләсәләр дә, ачулары кабарса да, лагерьда әсирләр күбәеп, баракларга сыйдыра алмасалар да. Болай да, хак булса, бу лагерьны ун мең кешегә исәпләп төзелгән, диләр, кара акыл белән исәпләп карасаң, безнең кебекләр монда илле меңнән дә ким түгелдер. Баракларның һәрберсе тоткыннар белән шыплап тулган, үлә торалар – яңаларны китерә торалар. Корал заводларына, мастерскойларына эшче куллар кирәк – француз, совет гаскәриләрен, базарда ат сайлагандай, авызларын ачтырып, тешләренә тиклем тикшерә-тикшерә, сортларга аералар да эшкә озаталар. Миңа бәхет елмайды, әйе, әйе, ялгыш ишетмәдегез, бәхет елмайды! Туган авылым урамында тәгәри-тәгәри үсеп, җир төсен, җир исен һәр күзәнәгемә сеңдергән булганмындыр, мөгаен; мине зур гәүдәле, кызыл йөзле бер немец алпавыты үзенең утарына эшкә алып китте.

Кара эшләпә-радио авызыннан «Ахтунг! Ахтунг!» дип яңгыраган сүзгә ияреп, барак алдына саф-саф булып тезелгәндә, без беребез дә үзебез белән ни буласын белмибез. Күңелдән генә тормыш белән хушлашкан мизгелләрне төймә итеп тезеп санасаңмы... Беркөнне лагерь коменданты янына килгән немец майорының күн перчаткалары югалган булып чыкты: каракның кем икәнен әйттерергә теләп, бөтенебезне башта тезләндереп тордылар. Аннан рәттәге һәр җиденче кешегә, «айн, цвай, драй...» дип кычкырып санап,

ике солдат берьюлы ике автоматтан ут бөркеде. Минем урыным дүртенче рәттә иде. Менә өченче рәттә нәкъ минем алда утырган, өзелеп чыгардай нечкә муенлы, шуңамы, башы артык зур күренгән яшь егеткә чират җитте; ул, эх дигәндәй аваз чыгарды да, алдымда канлы күлләвек калдырып, бер якка янтаеп төште. Секундларның никадәр озын икәнен беләсең килсә, үтелгән гомереңә әйләнеп кара икән... Шул мәлдә – секундның кайсыдыр бер өлешендә күзалдымнан бөтен гомерем йөгереп узды. Читән коймага асылына-асылына, авыл урамындагы яшь колынны күзәтүем; аның, иреккә чыгуына сөенече эченә сыймыйча, тоякларыннан тузан чыгара-чыгара, бер урында бөтерелүен; кулына камчы тоткан әткәйнең, колынга кай яклап килергә белмичә, аптыраулы кыяфәттә үзе дә юлның әле бер, әле икенче ягына йөгерүен; әнкәйнең, гаҗиз кыяфәткә кереп, кулын күкрәк турысына йомарлап, «ләә илааһә иллалаһ, ләә илааһә иллалаһ» дип өзексез кабатлавын да күрергә-ишетергә өлгердем. Үземнең кибеп корыган иреннәрем дә шул сүзләрне кабатлый икән... Комсомолга керткәч онытылып киткән андый кәлимәләрне сугыш бик тиз искә төшерде...

Дүртенче рәт башында санау кинәт тынды. Каскасы баш артынарак шуышкан немец солдаты майорның кулына перчатка китереп тоттырды. Елмая төшеп, тимер капка янында, эчтә торган бишекле мотоциклга күрсәтә-күрсәтә, үз телендә нидер әйтте дә комендант та, майор да, алар янындагылар да хихылдап көлештеләр. Аннан барыбызга торып басарга куштылар. Алдыбызда җансыз яткан канлы гәүдәләргә карамаска, күрмәскә, укшымаска тырышып, аякка күтәрелдек.

Бу көнне Бавария алпавытлары үзләренә эшчеләр сайларга килгән булып чыкты. Завод хуҗалары кебек үк, болар да иң беренче итеп ияктән тотып, тешләрне ачып карадылар. Беләк мускулларын, уч төпләрен, умыртка сөяген, арт санны тоткалап карадылар. Мондый хурлыклы мәлдә теш арасына ком тулгандай хис итәсең, уртны чәйнәп, шул комны шыгырдатасы, эт булып улыйсы, ат кебек кушаяклап тибеп җибәрәсе килә. Тик үзеңнең кол икәнеңне аңлаудан, ирексез икәнеңне аңлаудан җаныңны учыңа йомарлыйсың да түзәсең. Түзәсең! Ә кая барасың??? Кайберәүләр шикелле, соңгы адымны сайлап, ток җибәрелгән чәнечкеле тимер чыбыкка күкрәк белән ташланыргамы? Ташланырга өлгермәсәң дә, аның янындагы сызыкны атлап чыгуга, күзәтү вышкасындагы солдатның автомат көпшәсе сиңа тормыш белән алыш-бирешне өзәргә ярдәм итәчәк... Ул хакта бер түгел, йөз уйлаганым булды. Бер нәрсә – әнкәйнең кисәтүле карашы, «Ярамый, улым!» дип, әллә каян гына колагыма кат-кат килеп иңгән кисәтүле авазы киртә булды. «Ярамый!» Әнкәй җаным, бала чагымда син сөйләгән әкиятләр, мөнәҗәтләр берсе дә исемдә калмаган кебек иде ләбаса, онытыла, җуела бара иде кебек. Баксаң, әйткән бер сүзең хәтеремнең әллә кай төпкелендә сандык-сандык булып саклана икән бит. Ярамый! Үз-үзеңә кул салу – гөнаһларның иң олысы дип әйткәнең дә менә бу җәһәннәм оясында ничә тапкыр хәтердә яңаргандыр. Ярамый! Мәңгелек җәһәннәм утларында янарсың... Әнкәй җаным, бәлки, сүзләреңне кире алырсың? Болай да җәһәннәмнең үзендә бит без. Синең бер сүзең, хәер-фатихаң, ым кагуың кирәк, әнкәй җаным! Бары синең рөхсәтең кирәк... Ә хатыным, балаларым аңлар мине. Аңлар да, иртәме-соңмы кичерер дә...

Үлемнең дә үз сәгате. Ул да бер минутка алдарак, бер минутка соңрак сукмый – нәкъ тәкъдиреңдә язылган мәлдә бугазыңнан җаныңны аера. Юкса, инде беттем, инде фани дөнья белән хушлашырга миңа да чират җитте дип, керфекләрне чытырдатып кыскан чакларым аз булмады. Әйтәм бит, бәхет елмайды – мине җир эшенә коллыкка алып киттеләр.

Хуҗам – печән күбәседәй алагаем зур гәүдәле немец, герр Бруно минем колбиләүчем генә түгел, коткаручым да булып чыкты. Мине адәм заты дип түгел, ат, ишәк, эт яки башка хайван кебек үк бер җан иясе дип санаса да, һәрхәлдә, ул лагерьдагы шашкан фрицлардан аермалы буларак, үткәндә-сүткәндә хайваннарга аягы белән тибеп китми, вакытында ашата. Теш арасына ризык керү – туя тамакка булмаса да, барыбер ашау ул!.. Минем төп эш урыны – утардагы ат абзары. Тирес исен кемдер сасы дияр – юк, аннан бәхет исе, ирек исе килгәнен аңлар өчен фашист лагереннан китеп, тирес арасына баштанаяк кереп чумсаң да аз булыр... Бәрәңге басуына эшкә йөрим. Атларны карыйм. Тирес чыгарам. Минем ишеләргә хуҗалар белән сөйләшү катгый тыелган. «Мин бүген нәрсә эшләргә тиеш? – Вас золь ихь хойте махен?» дигән җөмләне беренче көнне немецча башка мәңге җуелмаслык итеп сеңдерделәр – шуннан артык сүз катарга ярамый, хуҗабикәләр, хатын-кызлар белән аралашу, сөйләшү бөтенләй рөхсәт ителми. Хәер, рөхсәт булса да, ни рәвешле сөйләшер идек икән? Мин болар телен белмим, русчам да такы-токы. Алпавытның да русчасы ипи-тозлык та юк кебек...

Мин үземнең кол икәнемне аңлыйм. Җанымның кимсенүенә чик-чама юк; туган авылым, тәбәнәк түбәсендә рәт-рәт наратлар үсеп утырган тауларым, аны-моны уйламый, әнкәйнең рәешкә генә бәйли торган яулыгы белән балык сөзеп йөргән Кече елгам, шул елга ярында адашып калган балачагым мине, әнкәй телендәге «пүтсез» малайны шушы хурлык халәтендә күрсә, йөз чөереп, читкә борылмас иде микән? Яратып өйләнгән хатыным, уймак иреннәрен очлайтып елмаерга яраткан кызчыгым, мин сугышка чыгып киткәннең икенче аенда туган, йөзен бер тапкыр да күрергә өлгермәгән улым. Улым, малаем, нәсел дәвамчым! Минем сөягем шушында, чит-ят җирдә череп калса да, канымның, җанымның дәвамчысы бар! Ул – туган илдә, баш очында пулялар сызгырмаган, бомба яумаган, фашист итеге таптамаган төбәктә. Үсәр, әтисенең шул төбәкне, шул туфракны яклар өчен ут эченә китүен дә, чолганышта калып, дошман кулына коллыкка төшүен дә, күптөрле мәсхәрә-хурлыклар күргән җанының, ниһаять, чиксезлектә иреккә ирешүен дә аңлар. Аңлар да үз балаларына сөйләр, оныкларына... Яшәү дәвам итәр. Без күргән фаҗигаләр балалар, оныклар күңеленә кан хәтере белән язылыр. Чөнки без күргәннәрнең онытылырга хакы юк!..

Герман җиреннән исән кайтырыма ышанычым юк иде. Дөрес, утарда эш аты булып гомер кичергәндә, лагерьдагы ише булмады: чөгендер яфрагыннан пешерелсә дә, көн саен кайнар аш эләкте үземә! Көрпәле кап-кара икмәк телеменең энә күзе кадәр генә валчыгы да тәнгә яшәү көче өсти иде. Хуҗабикә кайчак, каз-үрдәккә дип, чип-чиста итеп юып пешерелгән кабыклы бәрәңгене, чирканган йөз белән булса да, минем табакка да бушата иде. Патшалар сые анысы!

Кайда да бер кояш, диләр. Үзеңнең эш аты икәнеңә дә, җаныңның богаулы

икәненә дә, хәтта коллык хисенә дә күнегәсең икән. Яралы бүре шикелле, айга карап улар минутларыңда, кайдадыр еракта, авылның гап-гади салам түбәле йортында сине көтеп тилмергән әткәң-әнкәң, хәләлең, балаларың барын белү, дәвамың калганны белү көч бирә. Әле дә ярый кешегә уйлау сәләте бирелгән дә, әле дә ярый ул уйларны чит-ятлар богаулый алмый: уйга ияреп, ирекле канатларыңны җилпи-җилпи, ирекле дөньяны көнгә ничә гизеп кайтасың... Фәкыйрьлектән башы чыкмаган туган авыл белән нимес крәстияненең утар дигәнен чагыштырасың... Болар да шушы ук җир йөзендә яши инде, көнитешләре генә җир белән күк аермасы. Абзар дигәннәре – ап-ак итеп агартылган озынча таш корылмалар, хан сарае булып тоелырлык. Өйләр бездәге шикелле урам-урам булып янәшә утырмый, берәм-берәм чәчелгәннәр, ике күрше арасы чакрымнарга да сузылырга мөмкин. Шул бер өйлек «авыл» урамына да таш җәйгәннәр. Ярты эшләрен машина эшли, кул хезмәте өчен, әнә, миндәй коллар белән лагерь тулган...

Америка солдатлары азат иткәндә, мин лагерьга кайтарылган идем инде. «Советлар Союзында сезнең кебекләрне ни көткәнен беләсезме?» – дип сөйләүләре кеше ышанмаслык чеп-чи әкият булып тоелды – Ватанга кайтудан баш тартып, чит мәмләкәттә яшәп калыргамы? Үз ирегең беләнме?.. Ашкынып, зарыгып, җанга тулган ирек хисеннән исереп, туган илгә кайтуга, «госпроверка» дип, мине Подольскига – НКВДның тикшерү-фильтрация лагерена озаттылар.

Үземнең һич кенә дә сатлыкҗан түгеллегемне раслар дәлилләр юк иде... Сорау алу, җәзалау вакытларында мин бөтен төрмәләрнең һәм вәхшилекнең йөзе бер үк икәненә инандым...

Сугышның да йөзе нәкъ шундый. Яки, яки... Яки син үзең – үтерүче, яки – сине үтерәләр. Җанында хайвани инстинкт, кыргыйлык, нәфрәт, кабахәтлек баш калкытсын өчен шушы хакыйкатьне аңлау да җитә. Чөнки һәркемнең яшисе килә! Мәңгелек коллыкка дучар ителгән минем дә. Минем кебекләр белән кушылганча эш итә белмәсә, үзенең үк баш очында элмәк асылынып торган совет тикшерүчесенең дә. Гитлер һәм нацист Германия боерыкларыннан баш тартуның яшәүдән баш тарту икәнен аңлаган немец солдатының да. Һәркемнең яшисе килә! Шул бер кыйпылчык гомер бәрабәренә үзеңнең мәңгелек кол икәнеңне аңлау белән дә килешәсең икән...

Галия, 2019 ел

Скайпны уйлап тапкан кешегә – респект!

Өйдәгеләр белән көн саен сөйләшеп торабыз, Казаннан китмәгән дә шикелле. Әти дә, әни дә сорау арты сорау яудыралар. Акчам бармы, бәлки, картага салыргадыр? – Юк, бөтенләй кирәкми! Монда студентларга аена 400-800 евро түлиләр. Супермаркетларда азык-төлек хакы Казанныкыннан әллә ни аерылмый, бәрәңге белән алма гына ат бәясе... Килгән мәлне үк бөтен семестр өчен взнос дип 120 евро түләп куйдык – аңа уку өчен түләү дә, транспортта йөрү дә кергән. Рәхәт! Семестр буе шәһәр эчендә бөтен автобуста бушлай йөрисең!

Йоклап кына ятмыйммы, лекцияләргә йөримме?

Йөрим. Яратып, ашкына-ашкына йөрим! Бер арттырусыз әйтәм. Чөнки барысы да бик ошый үземә.

Кампус та, дәресләр дә шәп! Круто! Кайсы курсларны сайларга телисең – рәхим ит! Иртәнме, әллә кичке яктагы дәресләр кызыксындырамы – анысы да синең эшең. Укытучылар – искиткеч! Студентларны үз тиңнәре күрә генә түгел, аларны хәтта беркадәр олылап, минем өчен гаҗәбрәк тоелган бер хөрмәт белән кабул итәләр. «Сез» дип дәшүләре генә дә ни тора! Берсе дә, аудитория алдына басып, коры лекция сөйләми. Шулкадәр җанлы аралашу, кызыклы темалар – дәресләр гөрләп уза. Сөйләшәбез, кинолар карыйбыз, бәхәсләшәбез. Нинди генә сорау белән кайсы гына ишеккә мөрәҗәгать итмә – монда сине беркем дә «бу минем эшем түгел» дип борып чыгармый, киресенчә, булышырга гына тора.

Төркемдәгеләр белән дуслашып беттек, бер «общага»дагыларны әйтәсе дә юк. Бүген менә кич бәйрәмдә тагын очрашачакбыз.

...О-о-о, юууук!

Клара туган көн мәҗлесенә җыелабыз дигәч, бөтенләй башкача күз алдына китергән идем. Итальян ризыкларыннан торган өстәл: ким дигәндә, панцанелла салаты. Ни өчен ким дигәндә? Чөнки исеме яңгыравык булса да, помидор, кыяр һәм рәйхан яфрагыннан торган, гап-гади соус салынган итальян салаты ул. Кайнар ризыктан, бәлки, каччиаторе: помидор, гөмбә, болгар борычы белән алтын төсенә кертеп кыздырган тавык. Эм-м-м... күз алдына китерүдән авызыма сулар килсә дә, үзалдыма уфтанырлык: тавык дигәннәрен Клара хәләл кибеттән эзләп йөрмәс шул. Ярар, тавык булмаса, фасоль, борчак, помидор салып пешерелгән шулпа да ярап торыр... Яки паста. Аннан – маргарита пиццасы. Яки шоколадлы торт.

Ашказанын, туган көнгә барасы бар дип, төштән бирле юмалап, суыткыч ягына күз салмаска күндереп торган идем. Белгән булса-а-ам... Бездәге кебек, өстәл сыгылып төшәрлек итеп табын әзерләү дигән нәрсә боларда да бөтенләй юк икән! Һәрберсенең алдында зур бокал белән сыра. Шәраб яратканнар – шәраб йоткалап утыра. Зур тәлинкәдә – чипсы. Шарлотка пирогына охшаган юка гына кекс. Шуның белән шул. Ярар, көн саен ниткән ашау инде ул... Үз-үземне шулай тынычландырып, Мириам янына барып утырдым.

Бәйрәмгә бишенче каттагы ял бүлмәсенә җыелган идек. Чып-чын ассорти монда: итальяннардан Клара, Мириам, Марко, Джоссеф. Тайвань кызларыннан Дженни белән Мавис – алар инглизчә үзләрен шул исемнәр белән йөртәләр, тик үзләренчә чын исемнәре Сиң, Чың кебегрәк яңгырый. Татарлардан – мин, Галия! Миро – Аргентинадан. Бүген беренче тапкыр гына күргән егетне бразилияле Дави дип таныштырдылар. Кап-кара чәче бөдрәләнеп, җилкәсенә төшкән, кап-кара күзләре зу-ур ике төймә сыман, муенлы ап-ак юка водолазка кигән бу егетне киноактёр диярсең!

– Кызлар, егетләр! Миндә кәртләр бар, уйныйбызмы? – Клара туган көн дип киенеп-ясануны кирәксенмәгән, гап-гади алсу футболкадан, кыска джинсы шортыдан һәм бүлмәдә аягына элеп йөри торган ак башмактан иде, бер аягын бөкләп, өстәл башындагы кәнәфигә менеп кунаклады. Шундый ачык кыз ул: түп-түгәрәк йөзе, ничә карасаң, кояш шикелле балкып тора, биек ак маңгаеның ике каш турысында кечкенә борчак шикелле миңе дә бар. Озын гына буйлы, саллы гына гәүдәле. Мириам исә аның киресе: тәбәнәк кенә, ябык кына; һәрчак туп-туры текәлеп караучы коңгырт күзләрендә гел җитди караш чагыла.

Марко – вак-вак куе бөдрә чәчле егет. Ул бөдрәләренә ничек тарак кердер... Джоссефның, киресенчә, башы кырып алынган, черки кунса, таеп егылырлык. Итальян студентлары барысы да шундый шат күңелле, юктан да кызык таба беләләр.

– Яшьләр, кайсыгыз пианинода уйный белә? – Миро, ял бүлмәсенең түрендә торган пианиноның капкачын күтәрде дә телләренә болай гына баскалап карады. – Миннән булмый, хәзер үк әйтеп куя!

Эх, музыка мәктәбеннән туеп, ташламаган булсам! Менә хәзер утырыр идем дә уйнап күрсәтер идем... Тик әллә кайчан уйнап онытылган көйләрне кинәт кенә ничек искә төшермәк кирәк?

...Гаҗәп, бармакларым «Фазыл чишмәсе«н онытмаган түгелме соң? Авыз эченнән көйләгән уңайга, үзеннән-үзе миңа иярәләр:

Челтерәп аккан чишмәгә
Суга дип барган идем шул...

Әнинең сүзләрен колакка элеп, сабырлык күрсәтсәм, ак сакаллы карт буласы икәнмен дә... «Рөстәм Яхин, Салих Сәйдәшев көйләрен өйрән, кая барсаң да хур булмассың», – дигәннәре ул чакта бер колактан керде – икенчесеннән чыгып тайды шул. Өйрәндем, зачётны тапшырдым, аннан – оныттым. Алай дисәм...

Германиянең Регенсбург шәһәрендә, кампус янындагы тулай торакның бишенче катында Россиядән – Казаннан, татар иленнән килгән гап-гади бер кыз Сәйдәшнең «Кызыл армия маршы»н яңгырата!

Барысы да комплимент яудыра-яудыра кул чапкач, чын музыкант шикелле вәкарь белән генә баш та игән булдым хәтта!

– Син бик матур уйныйсың! Миннән дә уздырасың!

Артлы урындыкны идәннән шуыштырып кына, елмая-елмая, Дави минем яныма ук килеп утырды. Очкынлы күз карашы пианино клавишаларында иде. – Рөхсәт итсәң, мин дә уйнап карар идем.

Сатып алган малым түгел лә. Менә, уйна рәхәтләнеп...

Кычкырып әйтмәдем инде, мин дә елмаеп, урындыгым белән читкәрәк кенә шуыштым.

Оста уйный икән! Давиның кызларныкыдай сыгымалы озын бармаклары аклы-каралы телләрдән кош канат җилпегәндәй кагынып кына уза да, ул бармак очларыннан әллә нинди сихри моң тамып кала. Музыканың теле дә, милләте дә юк шул, таныш көй булмаса да, минем күз алдыннан кичен күл буенда бер-берсенең күзләренә текәлеп торган егет белән кыз сыны сызылып үтте; колагыма аларның баш очыннан иңрәп очкан кыр казлары тавышы ишетелгәндәй булды. Белмим, Бразилиядә кыр казлары бар микән, юк микән...

– Җырмы бу? Нәрсә турында? – дип сорамый түзмәдем Давидан.

– Сагышлы мәхәббәт. Сагышлы! – диде Дави, читкә карап елмайган килеш.

Мин молодец! Димәк, колагыма аю басмаган!

– Теләсәң, сиңа да өйрәтермен. – Давиның күмердәй күзләре миңа шулкадәр туры текәлгән иде – карашны күтәрә алмыйча, керфекләремне

түбән төшерергә мәҗбүр булдым. Абау ла, матур күзләр! Башымны әйләндереп куймасын тагын...

Болай дип, әнинең әйткәннәренә кушылып кына уйлавым... Ул кат-кат тукып тора дидем бит: йөргән җиреңдә күзеңне ачып йөр, нимесе-французы башыңны әйләндерә күрмәсен, колагыңа киртлә... Киртләвен киртлисең дә, причём монда колак? Йөрәк дерт итеп куя, колак түгел... Шаяртам инде. Сызлану катыш шаяртам. Нишләп безнең татар егетләре шулай кыюсыз икән соң ул? Ни үзләре башлап сүз катарга батырлыклары җитми. Инстаграмнан язышканда да, бар кызыксынганнары – ашарга пешерә беләмме, кияүгә ничә яшьтә чыгарга планлаштырам... Моннан да ахмак сораулар булырга мөмкинме? Кая монда романтика?... Очрашуга чакырсалар, яки бөтен сүз дилбегәсен синең кулыңа тапшыралар. Яки шунда ук сине тотып карарга теләк белдерәләр. Ужас!

Вәлидне генә кара инде. Без бер төркем булып Бауман урамын тутырып йөргәндә, йә җыйнаулап Камал театрына барганда, чәтердәп тора, теле-телгә йокмый, минем белән дә шаярып сөйләшә, җитәкләп тә барырга мөмкин. Икебез генә очрашкан чак булса – бетте, телен йоткандай була да куя. Якынрак килсә, берәр җире кителеп төшәр диярсең – үзалдына бераз тиле кеше кебек елмая да, читкәрәк тайпылырга теләгәндәй, кырыйдан бара да бара... Мин сөйлим дә сөйлим, ә ул елмая да елмая...

Ә монда... Миро да башка – аның белән бөтен темага рәхәтләнеп сөйләшергә була. Райнер да, Дави да үзгә. Аларны әрсез диюем түгел, һич тә юк, аларның дөньяга карашы, ул карашның искиткеч киң булуы ошый миңа. Артык сораулар белән дә бимазаламыйлар. Менә, биредә бер мин ала карга кебек утырам, сыра да, шәраб та эчмим – берсе дә «ник, нигә, ни була» дип башымны катырмый. Минем дөньяма кысылмый. Димәк, миңа шулай ошый, миңа шулай яхшы – төпченүнең кирәге юк. Киресенчә, әгәр мин кызыксынып берәр сорау бирсәм – төбенә тоз коя-коя иркенләп аңлаталар!

Менә, Дави белән танышуыбызга бер сәгать узмагандыр – кәрт уенында җиңелеп, икебез дә «читкә» чыккач, ул миңа Бразилиянең бөтен тарихын сөйләп чыгарга өлгерде. Югыйсә:

– Сездә гел җәй бит, әйме? Кар күргәнең юктыр? – дип кенә сораган идем...

– О, Бразилия! Син аны һичшиксез барып күрергә тиеш!..

Ул сөйләгәннәрдән минем хыялымда кояшлы илнең бөтен матурлыгы күз алдымда яңара. Шушы япь-яшь егетнең, Райнер шикелле үк, үз халкы тарихын су кебек эчүе шаккатыра.

Яңа дусларым белән таңга кадәр чөкердәшеп утырырга булыр иде, тик иртәгә тапшырасы презентациям эшләнмәгән, бүлмәмә төшәргә кирәк иде.

– Клара, мин китәм, тагын бер кат туган көнең белән сине! – дип, хушлашырга җыендым.

– Галэ, рәхмәт сиңа! – Клара, эчкерсез елмаеп, яңагын битемә тигереп алды. – Тик син бик иртә кузгаласың...

– Иртәнге дәрес өчен презентация әзерлисем бар, компка утырырга кирәк.

Үземә ничә әйткәнем булды: дедлайн билгеләп, соңгы минутны көтеп йөрмә, буш вакытта эшлә дә куй! Юк инде, чир китә – гадәт китми, килеп терәлгәнче сузылып йөрүем йөрү.

Бүлмәдәге һәрберсе белән саубуллашып, кул изәдем дә ишеккә юнәлдем.

– Егетләр, кызлар, миңа да китәргә кирәк иде! – Дави да, алга ук сузып утырган озын аякларын җыеп, урыныннан кузгалды, элгечтән кыска кара курткасын алып, беләгенә салды, тәненә сыланып торган аксыл футболкасын рәтли-рәтли, миңа иярде.

Лифт ишеге янына килеп, төймәгә баскач, курткасын кия-кия, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды да:

– Сәгать тугызда свидание иде, соңга каласым килми! – диде, миңа хисап бирергә тиешле кешедәй.

Исем китте... Мондый егетнең кызы булмаса, гаҗәбрәк тоелыр иде. Әйтәм бит, кино артистына охшаган прәме, карап кына тормалы!

– Алман кызымы? Кай арада танышырга өлгердең? – дидем, ачылган лифтка атлаган җиремнән, кызыксынуымны җиңә алмыйча.

– Кыз түгел. – Дави беренче катның төймәсенә басты, тагын елмайды. – Леон, егет ул. Мин – гей.

Шул гына җитмәгән идеее... Күзгә туп-туры караган килеш, бернинди читенсенүсез әйтүен күр әле син аның!

Мин бу минутта үземне ничек тотарга, ни дип әйтергә тиешлегемне белми идем. Сүзсез калмас өчен генә:

– Әти-әниеңнәр ничек кабул итә соң моны? – дияргә мәҗбүр булдым. Юкса, беләм инде, бик күп илләрдә балалар һәм ата-аналар арасындагы мөнәсәбәт һич бездәгечә түгел, аларда, безнең татар халкындагыча, һәр адымың өчен хисап тоту да, артык якынлык та юк. Тик барыбер авызымнан иң беренче булып шул сорау очты да чыкты.

– Нормально. Бу бит минем тормышым, – диде Дави, һич исе китмичә. – Безнең кебекләрне табигать шулай яраткан, мин берни дә эшли алмыйм.

Баш очында сүрән генә лампочка янган тар лифтта мин бу егет белән «зәңгәрләр» темасына да, моның табигать хатасымы, әллә бары тик бозыклыкмы икәнлеге хакында да сөйләшергә җыенмый идем, дөресен әйтсәм, бер дә кызык түгел иде.

Лифт төшеп җитте, ишек ачылды. Мин, үземнең ясалма елмайганымны ап-ачык аңласам да, елмаерга мәҗбүр идем:

– Күрешкәнче, Дави!

Фууу, әллә ничек булып китте. Әйтерсең, янәшәмдә басып торган заттан өстемдәге күлмәгемә бер-бер каралык йогып калды – бүлмәмә атлый-атлый, итәгемне сыпыргаладым.

Бүлмә ишеген ачкан мәлемдә, ватсапка зеңләп хәбәр килде. Һи, кеше дип торам! Вәлид яза икән: «Котлау текстын немесчәгә матур итеп тәрҗемә итеп бир әле пжл))»

Хәл сорашу юк, вакытың бармы дию юк, Казаннан сәлам тапшыру юк... Менә юри тиз генә җавап кайтармыйм әле. Хәбәрен укыганымны күреп өлгерде өлгерүен. Булсын. Барыбер язмыйм. Ворд итеп беркеткән текстын да ачмый торам...

Кемне котларга җыенган икән? Әллә, кыюлыгы җитеп, берәр кызга гашыйк булып куйганмы?

Уф, тәки сабырлыгымны сындырды...

«Син булмагач, Казанда бер кызык та юк. Бушап калган шикелле. Кайчак, урамда берүзем атлаганда, кырыйга борылып карыйм – көлә-көлә нидер сөйләп, син дә шунда, якында гына барасыңдыр кебек... Тавышың да, үзең дә сагындырдың...»

И-их, шушы сүзләрне күземә карап өздереп әйтә алсаң иде син!

Миңлегөл, 1951 ел.

Кафия җиңгәчәйнең башына уй төшкән: минем утырып калуымнан курка, бахыр.

– Оя коралмый тинтерәмәсәң ярар инде. Егет-җиләнне сугыш чүпләде. Кайтканының исән җире юк. Рәтлерәген каптырып бетерделәр...

– И, җиңгәчәй! 22 яшь кенә бит әле миңа, язганы табылыр! – дип, сүз белән аны, бәгырем тетелеп, үземне юатырга маташуым. Язмышларны кыл урталай бүлгән теге гарасатлы төндә сеңлем Рәйханә белән көлешә-көлешә сөйләшеп ятканыбыз җанымны айкап ала... Гомер үтә шул, тик берәүгә дә ни күзем, ни күңелем төшкәне юк. Көзге каеннан берәм-берәм өзелгән яфрак төсле, көн артыннан көн оча, ай үтә, ае елга ялгана. Таңның һәрберсе эткәемнән бер-бер хәбәр булмасмы дигән өмет белән ата. Инеш аръягында кояш батканда, ике күзем офык тарафында: исән кешеләр кайтты, үлгәннәреннән килгән кара пичәтле кәгазьләр бүрәнә ярыкларында саклана. Хәбәрсез дигәннәрнең генә хәбәре юк шуууул... Менә, район хәрби комиссариатыннан соңгы эзләнүләребезгә җавап итеп, 1947 елның 1 июлендә бирелгән кәгазьдә: «Ваш отец, солдат Шакирзянов Газизулла, уроженец... находясь на фронте, пропал без вести 6 января 1942 года», – дип язганнарыннан гайре, бер хәбәр дә юк шул... Җаным елаганда, күзләремне юешләтмәскә күнектем инде. Чөнки өметем исән! Ул өмет, сугыш кырыннан кайтып җитмәгән эткәемнең – бу дөньяда бердәнбер булып калган якын кешемнең әле онытылмаган, өзелмәгән җыры булып, көрәк йөздәй киң сөякчел куллары булып, чәченең уң ягына шуыштырып кияргә яраткан күксел кипкесе булып, җир исе, туфрак исе сеңгән озын җиңле күлмәге булып, минем күңелемдә саклана. Кайчагында, Хәкимулла абый белән Кафия җиңгәчәй күрмәгәндә, шул күлмәкнең изү турысындагы исне исемә төшерәм дә, илерердәй-тилерердәй булып бөтереләм. Еллар үткән саен ул исне тузан томалавыннан, вакыт урлавыннан куркам...

Кәнсәләргә эшкә менешли туры юлым элек үзебезнеке булган өй янынннан уза. Шәрәләнеп, ятимләнеп калган; читән коймаларның да кай ягы бар, кайсы юк... Хәзер анда дүрт бала белән тол калган бер апай яши, авылга кайтып төшкән мәлемдә үз йортыбызны үземә кайтарырмын, сатып алырмын дигән ниятем бар иде – кире кайттым. Чыра кебек ябык, яшь кенә булса да, маңгае буразна-буразна җыерчыктан гына торган апайның сүзсез сораулы карашына, берсеннән-берсе кечкенә сабыйларына бер генә юлыктым – ул өйнең бусагасыннан хуҗа булып атлап керүемне күз алдына китерә алмадым. Болай да бәхетләрен сугыш урлаган бер оя җанны ни дип кузгатыйм...

Бу юлы аякларым иртән иртүк шул яктагы сукмакка алып киткән икән, хәерле булсын. Эшкә, ураурак булса да, күпер тирәсеннән йөри торган идем.

Тыкрыктан уңга борылуга, «үзебезнең» йорт янәшәсендә, күрше йортның

җилкапкасы янында, эскәмиядә каңгырап утырган берәүне, аның кырыенда аунап яткан юл биштәрен күреп, шул мизгелдә йөрәгем әллә нишләп китте.

Әллә соң... әллә соң... әткәем кайтып төшкәнме? Безне Сахалиннан эзләткәндер дә, хәбәрләребезне ишеткәч, авылга юл тоткандыр... Әле кайтып кына килешедер... Иң беренче итеп, үз куллары белән салган, тик бер тамчы да рәхәтен күрергә өлгермәгән өй янына тукталасы иткәндер... Башымнан ә дигәнче әллә ничә төрле уй йөгерергә җитеште. Уйларым, мине узып, җитәкләшеп, абына-сөртенә шул тарафка йөгерә иде.

Юк... юк, әткәем түгел... Аның яшендә микән, бераз яшьрәкме – йөзе таушалган, сакал-мыек урынына каралы-аклы төк бәреп чыккан ач яңаклы, төпсез карашлы берәү, кайсыдыр ноктага төбәлеп, үзалдына уйган чумган иде. Өстендә – кара төстәге искерәк кенә бушлат, аның җиң, итәк очлары сизрәгән, өтек-өтек җепләр асылынып тора. Янына килеп бассам да, ул мине бераздан соң гына абайлап алды, ахры – айнып киткәндәй, кырыендагы биштәрен үз янынарак тартты.

– Ә-ә, – диде ул, әйтерсең, мин аңа сүз катканмын. Юкса, исәнләшергә дә өлгермәгән идем. – Танымадым.

– Газизулла кызы мин. Шушы авылныкы. Миңлегөл булам.

– Ә-ә, шулаймыни? – Ирнең сүрән, тонык карашы бераз җанлангандай тоелды. – Кала кызларына охшагач ни... Күрше кызы, димәк... – Ул, уң кулы белән бишмәтенең кесәсенә тыгылып, нидер эзләргә тотынды. Тапмавы булды – сул кесәсенә тыгылды. Тәмәке дисәң – тәмәке түгел, шуңа охшаш, кәгазьгә төрелгән бернәрсә алып, сәер кәкрәйгән бармаклары белән авызына капты. Ут элдермәде, тәмәкесен учына йомарлады, торып, сул аягына аз гына аксый төшеп, җилкапка янына килеп басты. Тәрәзәләренә аркылы такта кадакланган тәбәнәк иске өйнең бер якка шуышкан, тәмам сыегайган салам түбәсенә, якын килергә курыккандай, капка буеннан гына карап торды. – Ут эчендә йөреп, мине үлем алмаган иде. Ә монда... – Ир каралып, тупасланып беткән кулы белән йөзен каплады. Ул елый иде.

Эх, агай, монда да фронттагыдан ким булмаган шул. Ачлык кырган кешеләрне! Кафия җиңгәчәй сөйләгәннәрне куркыныч бер төш тыңлагандай тыңлаган идем. Язын капка төбендә борын төрткән яшь кычыткан өчен күрше белән күршенең җан талашканын. Бала-чаганың, карт-корының ачтан шешенеп үлгәнен. Шыткан бодай ашап, ярты авылны җирләгәннәрен. Аерым кабер казырга хәлләре булмагач, кешеләрне күпләп-күпләп бер чокырга күмгәннәрен...

Әхтәм агайның да әтисе, әнисе, хатыны, кызы, үзе күрергә дә өлгермәгән малае кырык дүрттә үк ачлыктан гүр иясе булган икән. Менә, кайтуына ни хәсрәт... Сугыш беткәнгә алты ел узды бит инде, ишетмәгәнме, хат язучы булмаганмы үзенә, кайларда шул гомер адашып йөргән?..

– Йөрмәгән җир калмады, Миңлегөлкәй... – Тәки кабызды тәмәкесен, корык-корык ютәлләп, болай да какча яңагын уртына ябыштырырлык итеп суыра-суыра, читкә борылды. – Эх, улымны күргәнем дә булмады бит ичмаса! Анысы мин сугышка киткәндә, әнкәсенең буенда гына калган иде...

– Әхтәм агай, нишлисең, үлгән артыннан үлеп булмый, диләр... – Үзем дә башымны читкә бордым. Кайчандыр Галимә апа юатырга маташып әйткән сүзләрне кабатладым. Файдасыз икәнен бик яхшы аңласам да, шулай

дидем... Үз авылына, бушлыкка, караңгылыкка кайтып төшкән кешене минә болай япа-ялгыз үз кайгысы белән калдырып китәргә кыенсынуым булдымы, аның тоташ сагыштан гына торган карашыннан кызгану, җәлләү тойгысы җанымны биләдеме – эшкә барырга чыккан җиремнән борылып, мин аны Хәкимулла абзый йортына чакырдым.

Ул – минем, мин аның хәлләрен сораштыра-сораштыра, урамнан атлаганда, Әхтәм агайның, карап туймас караш белән, йотлыгып-йотлыгып, тирә-якка күз салганына игътибар иттем. Миңа да карап-карап ала.

– Бер дә авыл кызына охшамагансың дисәм, үпкәләрсең микән? – диде ул, мөгаен, минем өстемдәге бөрмә билле кыска жикетка, шакмаклы үкчәле биек сапогиема, башымдагы йон беретка сәерсенептер. – Әллә мәктәптә-мазар эшлисеңме?

– Юк, колхозда, хисапчы мин, – дип җаваплаедым, Сахалиннан кайтуымны ике-өч сүз белән генә әйтеп. Авылга кайтуга, япь-яшь кыз бала дип тормадылар, мәктәптә бик яхшы укуымны, русча бик әйбәт сөйләшүемне белеп алуга, ай-ваема карамыйча, колхозга хисапчы итеп куйдылар шул үземне. Баштарак, исәп-хисап кәгазьләре белән утырганда, җаваплылыгыннан куркып, шыбыр тиргә бата идем... – Ә син, Әхтәм агай, хәзер нишләргә җыенасың инде?

– Сине кәләшлеккә алып, өр-яңадан тормыш башласам дип торам менә...

Сагышлы елмаеп, шаярып әйткән сүзләреннән йөрәгем дертләп китте. Тоташ ярадан гына торган ике җанның бер түбә астында көн күрүе шул мизгелдә яшен сызыгы шикелле кинәт кенә күз алдымнан сызылып үтте.

– И Әхтәм агай, холкым яман шул минем, ачуымны китерсәләр, кымыз күбеге шикелле, шартлап түгелергә генә торам.

– Уйнап әйтәм инде, Миңлегөл, хәтереӊ калмасын. Җиләк кебек кызлар күзләрлекме минем хәл...

Кызгану хисе идеме миндә? Әллә, үземнән шактый олы шушы агайның сагыш күледәй мөлдерәмә күзләрендә, көзгедәге шикелле, алда көткән язмышымны күреп алдыммы?

Ни булса да булды. Сугыш башлануның беренче аенда ук, ике яшьлек кызын, гөл чәчәге кебек хатынын, туарга өлгермәгән нарасыен калдырып, ут эченә чыгып киткән; аннан фашистлар чолганышында әсирлеккә эләккән; америка солдатлары коткарганнан соң, илгә кайткан, туп-туры совет төрмәсенә озатылган; фронтта бергә сугышкан офицерга тап булып, аның ярдәме – могҗиза белән үлем тырнагыннан котылган; такта кадакланган тәрәзәләре каршында чарасызлыктан җаны өзгәләнгән Әхтәм агайга кияүгә чыктым да куйдым мин. Хәкимулла абзый белән Кафия җиңгәчәйнең, икесе беравыздан: «Кырык кат уйла, Миңлегөл, берегеп китә алырсыңмы?» – диюләренә: «Елганың ике яры берекмәгән килеш тә гомер буе янәшә әле», – дип, дөнья көткән олы апайлар кебек җавап кайтардым...

– Ни бит, Миңлегөл, син миңа «Әхтәм агай» димә инде...

– Ярар, Әхтәм агай, әйтмәм...

Тормышыбыз әнә шулай гади генә башланды да китте. Әхтәм агайның, дөресрәге, Әхтәмнең иске өендә. Хәкимулла абый ярдәме белән, авылдашлар булышлыгы белән шуны сипләп, яңа мич чыгарып, ике яралы җан тоттык та бер түбә астына сыендык.

Күпме генә сораштырсам да, Әхтәм агай... Әхтәм ни сугыш турында, ни әсирлек турында җәелеп сөйләмәде. Берчак, Хәкимулла абзый белән ачы балдан авыз итеп, шактый кызган мәлендә генә:

– Тәмугның үзе бит ул сугыш! Бер елганы кичәргә әзерләнгәндә, нимес бомбага тотты. Күперне дә, үзебезне дә. Кырыпмы-кырды егетләрне. Исән калганнарыбыз ничек тә елганы кичеп чыгарга тиеш идек. Күпер булмагач, мәет булып яткан иптәшләребезнең гәүдәләрен түшәргә приказ бирделәр. Үз кулларыбыз белән аларны елгага ташыдык, шулар өстенә баса-баса чыктык аръякка! – дип, өстәл төя-төя елаганын ишеттем. – Әсирлектә күргәннәрне сорама, Хәкимулла абзый! Барысы да бер иш... Менә бу бармакларны совет төрмәсе ишекләренә кыстыра-кыстыра гарипләттеләр!

Шуннан гайре авызыннан әллә ни артык сүз чыкмады, өтек-төтек кенә әйтеп куя иде. Мин дә, җан ярасын кузгалтмыйм дип, кирәк-кирәкмәгән сораулар белән тинтерәтмәдем. Әткәем турында уйлаганда гына, елгага түшәлгән гәүдәләрне күз алдына китереп, бөтен тәнем эсселе-суыклы булып китә иде. Аларның җан-рухлары да «хәбәрсезләр» исемлегендә микән?.. Кемнәрнең газизләре, кемнәрнең кадерлеләре шулай кадерсез булып аунап калгандыр...

Галия, 2019 ел

Универдагы дәресләргә дә, укытучыларга да, төркемдәшләремә дә көннән-көн ныграк гашыйк була барам. Алар белән аралашу – җан рәхәте. Синең фикерең калган беркемнеке белән туры килмәскә, сәер, хәтта мәгънәсез булырга мөмкин – аны кычкырып әйтсәң, берәү дә чигәне бораулап күрсәтми, борын җыерып көлми; укытучыга да каты-каты, сәяси сораулар бирү монда гадәти хәл. Тагын да гаҗәбрәге – укытучылар андый сораулардан сагаеп калмый, ишек ягына, түшәмгә шикле караш ташламый, җаваптан качып, әйләнеп-тулганып йөрми.

Беркөнне алман теле дәресендә «Сез үз Ватаныгыз белән горурланасызмы?» дигән сорау куелды. Әгәр иң беренче булып җавап кайтарырга авызымны ачсам, мин кызып-кызып, «әйе!» дияр идем, мәктәптә ятлаганымча, үзебезнең елга-күлләр, матур шәһәрләр, спорт корылмалары, тагын әллә ниләрне искә төшереп, шулар белән мактаныр идем. Горурлык булырдай шәхесләрне санар идем.

Тик... немец милләтеннән булган урта яшьләрдәге укытучыбыз, герр Копп: «Без, алманнар, мәсәлән, «Германия – безнең горурлык!» дия алмыйбыз. Чөнки безнең кара тап булып торган үткәнебез бар, ул – фашистик Германиянең, Гитлер сәясәтенең хурлыклы үткәне», – диде дә, кырыгынчы еллар башында яһүдләргә карата булган сәясәт, СССРга каршы башланган сугыш, концлагерьлар турында сөйләп китте.

Әңгәмәгә кушылсам, мин ни әйтергә тиеш идем икән? Ни өчен икәнен аңлата алмам – шул мәлдә минем күзалдыма үземнең Миңлегөл әбием килеп басты. Югыйсә ил, Ватан дигән шулкадәр олы төшенчәләр янында, артык кырыс итеп әйтсәм, тәбәнәкләнеп калган гәүдәле, мин белә-белгәннән бирле ап-ак чәчле әбием (ә бит кайчандыр ул да зифа буйлы, озын чәчле, ап-ак «шома» киң маңгайлы яшь кыз булган!), аның әле һаман да, туксан яшенә җиткәч тә, сабый бала шикелле, хәбәрсез югалган әтисен уйлап,

«әткәем» дип өзгәләнүе, саргаеп беткән фотоны җиһандагы иң кадерле бер ядкарь күреп саклавы, ире – Әхтәм бабамның үзебезнең ил төрмәсендә күргән газапларын «чыкмаган җанын гына калдырганнар иде» дигән бер җөмләгә сыйдыруы – барысы-барысы Ватан дигән олы төшенчә янында артык гади, аерым кешегә генә кагылган, аның шәхси тормышының нәни кыйпылчыгы булып саналган бернәрсә шикелле бит.

Юк! Алай түгел, ахрысы... Минем әбием – шул Ватанның бер заты. Бер кыйпылчыгы. Бер күрсәткече. Шәхесе! Әйе, әйе, шәхесе! Гап-гади бер авыл кызы. Авыл карчыгы. Әмма... шәхес! Кеше! Һич кенә дә курчак түгел... Әгәр шулай икән, нишләп соң әле ул үзенең әтисен – шушы Ватан өчен сугышка киткән һәм... курчак шикелле исемсез-атсыз булып, кайдадыр, кайчандыр, ни өчендер хәбәрсез югалган әтисен шушы Ватаннан эзләтә, таптыра алмый? Газизулла бабай да Кеше бит! Суга төшкән балтадай югалганчы, кайсыдыр шәһәрдә, кайсыдыр фронтта, кайсыдыр ротамы, взводмы – һәрхәлдә, кайдадыр сугышкандыр бит инде ул?..

Мин дәрестә утырмый идем. Өйдәгеләрнең Германия дигәндә, аны бары тик Бөек Ватан сугышы белән бәйләп күзаллаулары минем башыма менә шушы минутта гына килеп җитте түгелме? Ватан, сугыш, илләр һәм кешеләр – моңа кадәр бу сүзләрне бербөтен йомгак итеп йомарлаганым юк иде...

– Галэ, син йоклыйсыңмы? – Янымда дәрес башланганнан бирле ләззәтләнеп, мате чәе йоткалап утырган Миро, стаканын дәфтәр читенә куеп, башын өстәлгә салды да күзләрен кыса төшеп, миңа карады. Шаяртырга маташуы.

– Комачаулама. Мин уйлыйм! – дидем, аның үзе кебек туп-турысын әйтеп.

Әйе, минем башыма уй төшкән иде.

Сукмакларым мине бирегә, Германиягә алып килгән икән – димәк, тикмәгә түгел. Мин монда үземне табарга тиеш.

Әтиемнән ватсапка хәбәр килде. Әхтәм бабам, американнар килеп азат иткәндә, Моосбург шталагында булган.

Уйларымнан арына алмыйча, кампусның баскычыннан төшеп килгәндә, артымнан берәүнең рюкзагымнан тартканына кашымны җыерып, башымны борсам, Райнер икән. Авызы ерык, аягына кып-кызыл төстәге кроссовка кигән. Нәрсә үзгәргән соң дип башымны катырсам, бакенбардын кырган икән, малай гына булган да куйган. Үзе кем беләндер айфоннан сөйләшә. Эшем кешесе диярсең... Ниһаять, колагыннан аерды.

– Райнер, Германиядә концлагерь документлары саклана торган архив бармы?

Минем соравымны аңлап житкермәдеме, сәлам бирергә дә онытып, кырт кына шулай дәшүемә аптырап калдымы – Райнерның якты зәңгәр күзләрендә сорау чагылды.

– Сәлам! Маттер сине кичке ашка чакырды. Вернер да көтә. Бик ошатканнар үзеңне. – Ул, җавап кайтарганымны да көтмичә, айфонын ачып, интернетка язарга әзерләнде. – Нинди архив? Тагын бер кабатлагыз әле...

Райнер гадәтенчә шат күңелле булып, шаяртырга гына торса да, минем күңелемдә давыл кубарга итә иде. Сәбәбенә дә төшенеп бетә алмыйм. Мине нидер ашкындыра, нидер әйдәкли, уйларымның башы-азагы юк, алар әле

тәртипсез йөгерешә, әле йомгак булып чуала. Ни куып таратырга тырышсам да, бәйләнчек чебен урынына киләләр дә йөдәтәләр.

– Сугыш вакытында Моосбург шталагында әсирлектә булганнарның документы кайда да булса сакланмады микән? Син бит юрист, эзләшәсеңме?..

Кулымдагы кечкенә генә яшькелт кәгазь – кыйммәтле документның төсле күчермәсе уч төбемне пешерә. Ике яклап тутырылган анкетада – минем бабамның ярты гомере! Беренче рәткә алманча, аска русчалап язылган анкетада – бабам язмышы! Stalag... дип ике урынга сугылган зәңгәрсу мөһер – аның язмышына сугылган мөһер!

1. Name_Фамилия Ибраһимов
2. Vornamen_Имя Әхтәм
3. Geburtstag_ Дата рождения 17.6.1918
4. Geburtsort_Место рождения Татария
5. Lager_Лагерь Шталаг
5 a. Im Lager eingeliefert_Доставлен в лагерь (число) 25.2.42
6. Dienstgrad_Чин
7. Truppenteil_Воинская часть 15.... пех.
8. Nr. der Erkennungsmarke des deutschen Laders_Номер военнопленного в германском лагере 3588...
9. Vorname des Vaters_Имя отца Мәхмүт
10. Name der Mutter_Имя матери Гайникамал
11. Anschrift_Адрес ближайших родственников Татария
12. Beruf_Профессия колхозник
13. Wann und wo gefangen_Когда и где попал в плен 12.1.42
14.Nr.der Erkennungsmarke des eigenen Truppenteils_Номер в собственной части

Перевел: ст.л. Имза.

Монда язылганнарны, әлбәттә, мин үзем тәрҗемә итеп чыктым. Алманнардагы төгәллеккә, сакчыллыкка, игътибарга ничәнче тапкыр шаккатуым, аптыравым, соклануым!

Бабам турындагы шушы документны табып, аның күчермәсен эшләтү өчен безгә санаулы көннәр җитте! Моңа ышана торган түгел иде...

Ә минем Миңлегөл әбием үзенең этисен – хәбәрсез югалган Газизулла бабамны ярты гасырдан артык эзләгән түгелме?

Син дә кичер мине, әбием! Мин үз буыным исеменнән генә гафу сорамыйм...

Газизулла бабай рухы.

Мин хәтер булып яшим. Хәбәрсез саналсам да, җәсәдемне кабул иткән туфрагым бар. Хәтер булып яшәгән рухым бар.

Үткәннәрне, бүгенгене һәм киләчәкне тоташтырып торучы Хәтер мин. Хәбәрсез хәтер.

Сугыш, кайсы гына гасырда, нинди генә илләр арасында, кайда гына булмасын, кешеләр санын меңләп түгел, миллионлап кыра торган үлем чалгысы. Кемнең – тәнен, кемнең җанын кыра ул.

Гап-гади татар ире мин. Башта – үз илендә үги булып, туган туфрагыннан кубарылган, җир читендәге Татар бугазы ярларына килеп, шахтада күмер

чапкан, аннан шул туфракны саклар өчен сугыш башлануның икенче атнасында ут эченә китеп барган гап-гади татар ирләренең берсе.

Беренче бәрелешкә коралсыз кердек. Рота командиры миңа наган бирде. Өйрәнчек! Учебный... «Нишлим мин моның белән?» – дип аптырап соравыма, «Куркытырга булса да ярап торыр», – диде командир. Якташыма – унсигез яше тулып кына киткән Муллагалигә СВТ винтовкасы эләкте, магазинында 5 патрон бар...

Мин дә, ул да – «хәбәрсезләр» исемлегендә...

Безнең «хәбәрләр», кеше дигән затның никадәр кадерсез бер җан иясе икәненә дәлил булып, бикле шкафларда тузан җыеп ята. Якыннарыбызның соңгы сулышкача яшәгән өмете, җан авазы, үз вакытында дәүләттән алынмаган пенсия акчалары булып; күрсәтелмәгән ярдәм, күрсәтелмәгән игътибар булып, әле дә булса бик астында ята. Ишекләр түгел, күңелләр бикле.

Хәбәр бар! Ваемсызлык, куркаклык, саранлык, хөсетлек, нәфес биге астында гына ята ул.

Ул бикне ачар кешеләр дә бар. Чөнки аларның канында безнең Хәтер яши.

Мин үз канымны – оныгымны күрәм. Мин җиңүче булып барып җитә алмаган Германия җирендә ул Хәтерне эзли. Андыйлар берәү генә түгел.

Казанның Бөек Ватан сугышы музей-мемориалында «Сугышчан дан клубы» эшли. Миндәйләрнең оныклары Татарстан яугирләренең хәбәрсез хәбәрен эзли. Чыннан да, Дан аларга!.. Татар иленнән җиде йөз меңләп кеше Ватан өчен ут эченә китеп, һәр икесенең берсе әйләнеп кайтмаган. Хәбәрсез югалган дип тамгаланганнар күпме, төгәл санын белүче бармы? Ә бит Германиядә дә, Америкада да, Бөекбританиядә дә «хәбәрсез югалганнар» юк!

2006 елдан бирле безнең хактагы документлар сер булудан туктап, аларны ачарга, архивларны кузгалтырга мөмкинлек бирелде. Безне эзләүчеләр генә кирәк. Без бар! Безнең Хәтер әлегә исән! Әлегә...

Буыннар алышынган саен Хәтернең дә гомере кыскара бара, шунысы куркыныч...

Музей-мемориалдагы егетләр тырышлыгы белән дә, без берәм-берәм илгә кайтабыз. Әгәр һәркем кулыннан килгән кадәр аларга теләктәшлек күрсәтсә, бикле ишекләрнең күбесе ачылыр иде. Каршылык белән тулы дөньяда тамчы-тамчы ярдәмнән күл түгел, диңгез җыелырга мөмкин. Татар исем-фамилияләренең документларда карашны каерырлык итеп бозып язылуы гына да никадәр аңлашылмаучылык тудыра!

Озакламый мин дә, якташым Муллагали дә хәтер кайтавазы булып сезнең арага кайтачак. Борын астына рәтләп мыек төртергә дә өлгермәгән яшь яугирнең рухы шигырь булып эндәшәчәк:

Батырларның даны онытылмый,
Бар да истә, диләр, күңелдә.
Бер хәбәрсез югалганнар гына
Тынгы бирми әле бүген дә.
Кемнең улы, кемнең сөйгән яры,
Кемнең газиз ире, атасы

Кай якларда, кайсы туфракларда
Бер билгесез булып ятасың?
Колагымда ерак әбкәемнең
Бер хикәят итеп сөйләгәне:
Аның өлкән улы, кадерлесе,
Бу тормышны өзелеп сөймәгәнме?
Унсигез яшь тулган көннәрендә
Ут эченә киткән, сугышка.
«Кичер, әнкәм, кайта алмадым», дип,
Сызлангандыр соңгы сулышта.
Чит туфракта ятып калган чакта
Кемнәр күргән, кемнәр җирләгән?..
«Бер хәбәрсез югалды ул», диеп,
Белмим, кемнәр хәбәр җибәргән...
Ышанмаган газиз ана җаны,
Еллар буе көткән тилмереп.
Бер кайтмаса улым бер кайтыр дип,
Соң көнгәчә йөргән илереп.
Чәчләренә иртә чал сарылган,
Йөрәгенә яра уелган.
Бар сагышы, җан әрнүе беркөн
Акыл белән бергә җуелган.
Шул хәлдә дә ана хәтерендә
Тик бер яра калган ээ булып.
Җилләр шавы хәтта ишетелгән
«Улым!» дигән татлы сүз булып.
Мин бүген дә ерак әбкәемнең
Ишетәм күк шашкан җан авазын:
«Ана өчен бала мәңге исән!»
Сугышның да исән кайтавазы...
Мин бүген дә күкләр аша ишетәм:
Бер хәбәрсез югалганнар булып,
«Сез безне дә онытмагыз», диеп,
Агыла да килә ап-ак болыт...

Ә мин исә, биктән арынып, кызымның, соңгы сулышынача әтисен йөрәгенә сыендырып яшәгән Миңлегөлемнең үзе исән чагында ишетергә өлгермәячәк Өмете булып, бик тиздән кайтып җитәчәкмен. Әнә ул ак кәгазь, «Сугышчан дан клубы» эзләп тапкан мәңгелек өмет: «Красноармеец 133 танковой бригады... Погиб в декабре 1941 г. в Курской области. Сведения Центрального Архива Министерства обороны РФ. Сайт МО РФ «ОБД Мемориал», опись 8188..., дело 7...»

Ул красноармеец – мин.

Хәбәрсез югалмавыңны исбат итәр өчен үзеңнең курчак түгел, кеше икәнеңне расларга кирәк шул. Кичә дә шулай иде, бүген дә. Иртәгә дә шулай булыр күк.

Яңа буынны җиңел акыллылыкта, үз милләте, аның үткәне, ханнары, шәхесләре белән кызыксынмауда гаеплисез. Ата-бабасының үткәнен белмәгән оныклар ни рәвешле тулы бер халыкның тарихын өйрәнсен?

Алар гаеплеме?

Әллә дөньяны алларына ясалма төсләргә буяп китергән чынбарлыкмы? Кырык кат йозак, бик астында күз уңыннан яшереп сакланган үткәннәрме?

Безнең оныкларга фашизмның канлы шәүләсе турында сөйләү белән

беррәттән, совет илендәге канлы репрессияләр, ГУЛАГлар, кеше кадере турындагы аяусыз хакыйкатьне дә җиткерәсезме?

Кешенең, балчыктан яралса да, курчак һәм адәм колы түгеллеген аңлатасызмы?

Әллә яңа буын да хәбәрсезләр исемлегендәме? Аларның хәтере һәм акылына да бик салынганмы?

Галия, 2019 ел.

Монда әлегә көн саен бәллүр бишектә кояш тирбәлә! Декабрь ае димәссең, урамда җылы, күктә карлыган яфрагы тиклем ник бер болыт кисәге күренсен!

Гаҗәп, ни өчен тора салып карлыган яфрагы исемә төште әле? Әһә, иртән үземә зур бокал белән чәй ясаганда, җәй көне бакчабызда ярфак салып, самавыр чәе белән сыйланганыбызны күз уңыннан үткәргән идем бит, шуның галәмәтедер...

Миндә революция. Башымда. Иртәдән бирле аякларымны салындырып, тәрәзә төбендә утырам. Ноутбук теземә куелса да, күзләрем урамда. Уем бөтенләй әллә кайда адашып йөри.

Урамнарның кайчан карама буш булуына ияләштем инде. Килгән мәлдә генә сәер тоела иде: чыгасың, беркем юк, бернинди машина ыгы-зыгысы юк. Автобусларда да кеше өстенә кеше өелми. Халыкның күбесе велосипед белән үз көенә йөри бирә, кая карама – бихисап велосипедлар чылбырга куелган. Кеше кибеттә киләп салып йөрми, кафеда, барда утырганнар гөр-гөр сөйләшеп сәгатьләр буе сыра эчә. Исерекләр дә юк үзе, анысы да гаҗәп.

Университетта укытучылар дөньяда хәлнең катлауланып килүе турында әйткәли башлады. Авыру тарала, 21 нче гасыр чумасы, диләр. «Кешелеккә каршы игълан ителмәгән сугыш», – диючеләр дә булды. Тагын сугыш! Тагын яңа корбаннармы?!

Юк инде, монысы ышанырлык түгел. Җир шарында кояш астында һәркемгә урын җитә! Тарих сабаклары моны кат-кат аңлаткан лабаса!

Аңлаткан дигәннән... Райнер миңа кичә мәхәббәт аңлатты. Монысын «романтичныйрак» итеп әйтүем инде. «Галә, син миңа бик ошыйсың. Мин сиңа гашыйк булдым. Әгәр син Германиядә бөтенләйгә калсаң, безнең уртак киләчәк булыр иде», – дип, туп-турысын ярды да салды. Менә ичмаса! Нәкъ алманнарча: төгәл, кыска, тәртип белән.

Тик... ярты җанымның Казанда калганын мин аңа шулай төгәл, кыска, тәртип белән аңлата белермен микән? Бер сөйли башласам, көлә-көлә, җәелеп, иркенләп сөйлим шул мин. Андый монологларымны, юл читеннән сүзсез елмая-елмая, Вәлид кенә сабырлык белән тыңлый ала.

Аннан... монда ничек кенә рәхәт, ничек кенә уңайлы, ничек кенә матур булмасын, «кеше кадере» дигән төшенчә яшәмәсен – минем үземә кайтыр сукмакларым бар. Үзем тапкан, үзем ачкан сукмаклар. Әлегә мин аларны беркем белән уртаклашырга ашыкмыйм. Әлегә – алар биктә.



Рәшит
Бәшәр

БОЗЛЫК ЧОРЫН ИСӘН-САУ КИЧӘСЕ БАР...

Төнге юл

Сукрана-сукрана кайтып киләм,
Җил көчәйде. Юлга көрт өя.
Мин ашыгам. Кар күмгән авылда
Әнкәм көтә мине карт өйдә.
Урман авызында хәлсез бүре
Каршы баскан җилгә. Иснәнә.
Мин ашыгам шул бүрегә таба,
Тирләп чыгам. Кашым бәсләнә.
Түш кесәмдә гәзит төргәге бар,
Шырпым да бар. Коры, коп-коры.
Кара төндә учак кабызырмын,
Яктырыплар китәр ил-кыры.
Хәлсез бүре чабар урманына,
Көрткә бата-чума үрмәләр.
Чытырманга аны яшерер дә
Кара урман серле көй көйләр.
Караңгыда урман кичәрмен мин,
Исән кайтып туган өемә,
Черем итәрмен мин җылы мичкә
Аркам терәп баскан көемә.
Миңа рәхәт, бик тә рәхәт булыр
Кулъюгычта битем юганда.
Мич арасында өй чикерткәсе
Берөзлексез сайрап торганда.
Сөтле чәен ясап куяр әнкәй,
Чарт-чорт янар утын учакта.
Калган бәлеш килер өстәлгә һәм
Өй җылысы сеңәр кочакка.

Рәшит БӘШӘР (1949) – *шагыйрь һәм прозаик; «Сандугачлы бишек», «Ачык капка», «Былбыл оясы» һ.б. китаплар авторы. А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Чаллыда яши.*

Исәнме сез?

Киң Рәсәйнең һәр җирендә
Яшәп ята татар.
Иделендә, Иртешендә
Эшләп ята татар.
Каф таулары итәгендә
Җәйләүләрдә җәйләр.
Уралында, Ырынбурда
Мамык шәлен бәйләр.
Сахалинда һәм Читада
Үз илендә татар.
Сөйләшергә ник тайчына
Үз телендә татар?
Хуҗа итеп тотмый үзен
Үз өендә татар.

Әкрен генә сүнеп бара
Үз көенә татар.
Чаларды инде чәчләрем,
Шактый өлкән яшем.
Көчәерсең дип, татарым,
Өмет белән яшим.
– Исәнмесез! – дип елмаеп,
Онык керә өйгә.
Саф татарча сөйләшә ул
Ягымлы бер көйгә.
Көйле тел ул, бик ихлас тел
Туган телем минем!
Кояшлы көн, Айлы төнем,
Изге денем минем!

Бу якларда

Челтер-челтер су тавышы – улакларда,
Җил китергән курай моңы – колакларда.
Җилләре дә иркә икән, назлы икән,
Һәркем монда җырлы икән, сазлы икән.
Һәркем монда дастан сөйли – шагыйрь икән,
Җан тәрәзен сөенечләр шакыр икән.
Тәнгә шифа, җанга бәлзәм гөлләр исе,
Күз камаша – серле балкыш үрләр өсте.
Уйный нурлар аллы-гөлле, дөнья ямьле,
Уйдыкларда җиләк исле һава тәмле.
Җилферди бер ап-ак яулык – еракларда,
Оҗмах, валлаһ, оҗмах икән бу якларда!

Урам

Сөялеп бетон коймага,
Йөрәгем тотып торам.
Ашыга халык каядыр,
Гөж килә иркен урам.
Кояш көлә, нур коела,
Чәчәк аткан юкәләр.
Үткәндә калган елларга
Кайтып булмый... Юк алар.
Сөялеп торам коймага,
Йөрәгем тотып торам.
Көн караңгы... Күз алмамда
Юыла яшел урам.
Карашымда бер мизгелгә
Җуелса да киң урам,
Җан күзем белән һәммәсен
Күреп, ишетеп торам.

Чыелдап чаба машина,
Кай җирдә янгын икән?
«Ашыгыч ярдәм»... Монысында
Йөкле бер ана микән?
Алпан-тилпән бер нәни кыз
Килә минем каршыма.
Ак яулыгын ак әбисе
Тартып куйган кашына.
Өскә сузыла балакай,
Озынрак күренмәкче.
Туктап калган ак болытка,
Кояшка үрелмәкче...
Хәл керде, инде елмаям,
Кәефем ару гына.
Бу әле алга барышлый
Бер туктап алу гына.

Бозлык чоры

Кичке җилләр уйный кубыз
Уйный каен тузында,
Йөзгә бәрә яз салкыны,
Тирә-юнем боз гына.
Бозлык чорын ничек тә бер
Исән-сау кичәсе бар.

Борылып карыйм: артымда
Дусларның ничәсе бар?
Сүнә яна, сүнә яна
Алда нинди ут икән?
Җан җылытыр ут микән ул,
Бер алдавыч ут микән?

Елмаю

Аллеядан атлыйм тын гына,
Яфрак оча, яфрак кыштырдый.
Оеп яткан туфрак пышылдый:
«Яфрак түгел, коштыр, коштыр!» – ди.
Узып китә мине бәндәләр
Башын аска игән көенә.
Көләчлекне алар онытып
Калдырган ла бугай өендә.
Яшь гүзәлләр килә ашыгып,
Их, елмайсын иде берәрсе.
Кызыл сумка аскан чибәрнең
Ак тешләрен килә күрәсе.
Дәшми-нитми узып киттеләр,
Бигрәк җитди иде йөзләре.
...Елмайдым да үзем яктырттым
Кара болыт баскан күзләрне.
Күк капусы кинәт ачылды,
Нур чәчелде урам ташына.
Ләң-ләң өреп, күзләр эченнән
Ап-ак көчек чыкты каршыма.

Матурлык иясе

– А-у-у!
Кем кычкыра миңа, кем дәшә?
Таный алмыйм тавыш иясен.
Болын ияседер, бәлки, ул
Чакырадыр таныш биясен.
Таулар ияседер, бәлки, дим,
Чишмә иясе дер, кем белгән?..
Үзен күрмим. Тавыш иясе
Елга талларына күмелгән.
– А-У-У!
Кош оялы куе таллыктан
Кармак сабы чыкты иң элек.
Балтырганлы нәни бер кул да
Әзгә генә алды күренеп.
Менә үзе... Сул колагында
Яшел үлән тора эленеп.
Ирененең аскы читендә
Яра эзе тора беленеп.
Саргылт шортик. Тәне ялангач.

Тырналган эз аяк йөзендә.
Тайлы болын, кылганлы карт тау
Сыеп беткән малай күзенә.
Чишмәләре сыйган, елгасы,
Ак болытлар сыйган. Гаҗәп бит.
Бу байлыкның чып-чын иясе
Шушы малай ласа. Рәҗәп бит!
– Балык качкан моннан. Әйдәгез,
Балыклырак җирне күрсәтәм! –
Кыю гына атлап килә дә
Тотып ала минем терсәктән.
Икәүләшеп камыш ерабыз.
Көне җиләс. Аяз күк өстә.
Карашларда болын сурәте
Рәшәләнә әллә мең төстә.
– А-у-у!
Инде үзем аңа кычкырам,
– Шәп егет син! – килә диясем.
– А-у-у!
Бу – ул! Әллә каян таныйм
Матурлыкның тере иясен.

Кайтыгыз!

Ишетелә аяк тавышыгыз,
Тау артында кешни атыгыз.
Хәерле юл телим, туганнарым,
Исән-имин илгә кайтыгыз!
Җәяүме сез, очкыч, поездламы,
Суйөзәрдә йә аттамы сез,
Көләчме сез, әллә боекламы,
Сөенечтән өске каттамы сез,
Чуерташлы юлдан кайтасызмы,
Кайтасызмы тузан ерып сез,
Асфальттамы кала эзләрегез –
Минем өйдән әле ерак сез.

Минем илдә ап-ак карлар төшә,
Сездә яздыр, яшел җәйдер йә.
Алтын көздер... Аяк астыгызга
Әзердер ул яфрак җәяргә.
Татарларым минем, якташларым,
Һәммәбездә сәйяр йөрәк бит.
Бер ябалдаш астына безләргә
Җыелырга күптән кирәк бит.
Капкам ачык, өй ишегем ачык,
Түгел бит сез илдә юлаучы.
Туган җирдә алтын булыгызчы,
Чит туфракта бакыр булганчы.

***

Хатыным Люциягә

Бездән соң да гүзәл булыр дөнья,
Кояш чыгар, батар офыкларда.
Сокланырлар һәр көн матурлыкка –
Безнең күзләр кала офыкларда.
Көләч булыр алар, шаян булыр,
Һәм булырлар уйчан, боеклар да.
Үзебез дә шундый идек ләса –
Безнең йөрәк кала офыкларда.
Коена гөл кояш асларында,
Җилферди җил ап-ак болытларда.
Бездән соң да гүзәл булыр дөнья –
Безнең сөю калыр офыкларда.

«Аh, туган каумем газиз!» әдәби конкурсы

Асия
Юнысова

ХАТЫННАР СҮРӘСЕ

БӘЯН*

Һиҗрәттән соң Мәдинәдә иңгән бер сүрәдә хатыннар турында, җәмгыятьтә аларның хаклары, хокуклары, иҗтимагый мәйданда тоткан урыннары хакында сөйләнгәнгә күрә, ул сүрә «Ән-Ниса», ягъни «Хатыннар» дип аталган.
«Коръән»нән

Кереш

«...Асия сеңлем! Фәһимә апа минем укытучым гына түгел, күршем дә иде. Мин аны бик тә хөрмәт итәм. Ул ачык йөзле, бик гади, күркәм холыклы кеше иде. Тормыш авырлыгын авыл халкы белән бергә күтәрде. Яшь кенә көенчә дөнья аны, башкалар белән беррәттән, ирсез калдырды, дөньяның ачысын-төчесен татырга мәҗбүр итте.

Ул безгә, укучыларына, өстәмә дәресләр оештырып, искиткеч матур эчтәлекле китаплар укып, коточкыч авыр тормышыбызны вакытлыча булса да оныттыра иде. Аның үзенең дә ачлы-туклы яшәвен, безнең белән бергә үз өлешенә төшкән авырлыкларны онытып торырга тырышканын мин хәзер генә – үзем яшәгән еллар биеклегеннән карап кына аңлыйм.

Фәһимә апа безнең укытучылар арасында иң чибәре дә иде. Ул безне һәм авыл халкын сәхнәләрдән шаккатыра иде. Җиләк кебек чагында ирсез калса да, аның тәртибе «биш»лелек иде. Телгә кермәде. Кирәк санагач, яңа гаилә корды, намуслы булып яшәде. Менә шуның өчен дә әле без

* Журнал варианты.

Асия ЮНЫСОВА (1947) – *шагыйрә, журналист; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан журналистларының Х.Ямашев, язучыларның С.Сөләйманова исемендәге премияләре лауреаты. «Үскән кыз», «Мин кышны яратам», «Айлы юл» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

аны үзебезгә өлге кебек күрдек. Әниең турында яз әле син. Менә шулай, сеңлем... Авылдашың Мөгътәсим абыең дип белерсең».

Бу хатның минем кулга килеп кергәненә дә егерме ел узып киткән икән. Үзеңнекен язу тыйнаксызлык кебек тоела иде шул. Хәзер менә озаклаганыма үкенәм. Лаек иде әни кызының зурлап язуына. Ә болай район матбугаты аңа карата игътибарлы булды. Дәрәҗәле иде шул.

Әсәремә исем итеп куйган «Хатыннар» сүрәсе»нә әйләнеп кайтсак... Заман, аяусыз заман ул сүрәгә дә төзәтмәләрне, ай-һай, мулдан керткән. Урыны ир ышыгында гына булырга тиешле, фәкать мал-мөлкәт җәһәтеннән генә яклау, аралау, гаделлек күрергә тиешле «нисалар» үзләре ирләренә терәк, балаларына таяныч, иң мөһиме – ил тоткасы булып гомер кичерергә мәҗбүр ителгәннәр ләбаса.

Беренче мәртәбә язасы әйберемнең жанрын аныклый алмый йөдим. Сугыш елларын кичергән хатыннар язмышын бәян итәр өчен гадәти алымнар артык гади булып тоела. Шагыйранә өслүбкә сыеп бетеп булмас кебек. Аллага тапшырдык. Әйдә, әни, Сәгыйтова Фәһимә Хәниф кызы – меңләгән укучысына остаз, гомеренең соңында авылның агәбие булган, туксан яшьлек бабайлар өчен дә зур хәрефтән Апа булып калган ниса, үзең турында үзең сөйлә әле. Кирәк дип тапканда, аның хатирәләренә үзем дә кереп чыккалармын. Берни хәл итәр юк, үзе исән чагында күңел-йөрәк ачкычларын ярата алмадык. Сандыклары бикле калды.

Беренче аять

– Әбием, син бик бәхетле булгансың. Чибәр булганга күрәдер инде, өч егеткә яр булгансың.

– Кызым, бәхетле кеше бер генә бара ул кияүгә, шул яры белән гомер буе бәхетле яши. Син бәхетле бул. Тиң ярыңны насыйп итсен сиңа Ходай![1]

Икенче аять

Мин Ютазы районындагы Каразирек авылы кызы. Бабам Хәбибулла мулла булган. Мулла оныгы булганга күрә, бик йомылып, тарсынып яшәлде. Алай да әнием Камилә – мулла килене, шактый кыю иде. Куркып-нитеп тормады, бабайның гомеренең соңгы көннәрен яшәп яткан землянкасына мине еш җибәрә иде. Кайнар ризык, коймак-мазар илтә барам да бабай янында утырып калам. Аңа кычкырып китаплар укыйм. Беренче дин сабаклары минем күңелемә әнә шулай – бабаемның баш очында утырганда сеңеп калды. Бабай, бик карт булганга күрәдер инде, илдән үк сөрелмәгән. Өеннән генә куып чыгарылган. Ул вакытка минем атам Хәниф Бөгелмә төрмәсендә ачлыктан вафат булган була инде. Калган балалары кайсы кая таралышып беткән. Кем – шахтада, кем – Урал заводларында.

Укытучылык безнең канда иде инде ул. Югыйсә бабайның бер кызын сәнәкчеләр бәкегә салып үтергәннәр дип сөйлиләр иде. «Коммун кызлар үстергәнсең, сәвит хәлфәләре тәрбиялисең. Калган кызларыңны кая качырдың?» – дип, бик каһәрләгәннәр бабамны. Сәнәкчеләрдән аны умарта оясы эченә яшереп кенә саклап калганнар.

Безнең Каразирек кызлары «җиденче» сыйныфны тәмамлауга Бөгелмә

[1] Оныгы Нәфисә белән сөйләшкәнен ишетеп калган идем. – А.Ю.

педучилищесына китә торганнар иде. Мин дә алар артыннан иярдем. Бердән, мулла оныгы икәнлегемне белеп алырлар дип куркам; икенчедән, күзләренә ямьсез күренермен дип уйлыйм.

Ул вакытта училищега матур кызларны гына алалар иде.

Күземә арпа чыккан вакыт. Кимчелегемне күрмәсәләр ярар иде дип, ян беләнрәк кенә торам. Күрмиләрме соң?

– Бу күзеңдә нинди зәгыйфьлек ул? – дип ярып салды бит комиссиядәгеләрнең берсе.

– Арпа гына, бетә ул, – дип акландым. Югыйсә үземчә матур буласым килеп, чиста күлмәктән, яңа чабатадан килгән идем. Их, шушы сыйрат күпереннән узсам, укып китәм инде мин. Бабай янында землянкада алган белемнәрем дә җитәрлек анысы. Тик ул хакта бик әйтергә ярамаганын да беләм. Минем әле тагын нииндидер гаебем бар бугай. Бөгелмә төрмәсенә илтеп япкан җирдән инәй качып кайткач, ниндидер мөһерле кәгазьләрне мичкә якты. (Морзалык ярлыгы булган булырга тиеш – соңыннан белдем монысын.) Инде ул хәтлесе дә беленсә, училищедан чыгып очканыңны сизми дә калырсың. 15 яшьлек кызыйга бүтән җәза, бәлки, булмастыр да. Бу бит башкалар комсомолга кереп йөргәндә, мин дә шулар белән бергә яңа тормыш төзибез дип ашкынып яшәгәндә...

– Укытучы – халык көзгесе. Син, сеңелкәй, шуны онытма. Башка яктан сәләтләрең бармы? Бәлки әле, җырлый беләсеңдер?

– Беләм, беләм. Хәзер үк җырлыйсымы?

– Без сиңа ышанабыз. Җырлашырбыз башка вакытта.

Алдылар бит мине укырга. Укытучы булып чыксам, гел бәхетле булырмын кебек тоела инде. Укып киттек. Җамбыл каласында яшәп ятучы Садершаһит абзам укытучы булачак сеңлесенә посылка белән күлмәк җибәргән. Стипендия дә алабыз. Русчаны белү генә чамалы. Баштарак шул фәннән «өч»ле куеп йөдәттеләр. Ә менә төгәл фәннәр гел минеке инде. Партадашым – Гасыйм атлы егет миннән дә башлырак. Бергә-бергә, чикләвек яргандай, мисал чишәбез, бергә-бергә гәзит укыйбыз. Гасыйм комсомолга керерегә җыена. Ә мин куркам әле. Кирәкмәгән сорау бирерләр. Яшереп йөрим мулла бабамны, комсомолга керәм, дисәм, белерләр. Болай да күңелле генә яшибез бит әле. Концерт куйгалыйбыз бергәләп. Ә авылга кайту – тәпиләп.

Бөгелмәдән безнең авылга 40 чакрым. Борчак басуыннан юл үткәндә, дәррәү генә кузак ярабыз. Аннары шалкан өлгерә. 60 яшькәчә тештән зыян күрмәдем. Борчак белән шалканга рәхмәт анысы өчен. Шул басулар безне ач итмәде. Ачыктылар юкса ил белән. Альбомымны алып актарам да йомры битле кызга аптырыйм. Ярый әле шулай түл җыйганбыз кырык бергә керер алдыннан.

Өченче аять

Партадашым Гасыйм дидем бит, Азнакайдан икән ул егет. Якый дигән якын авылдан. Аның белән тәмам дуслаштык. Күзен алмый миннән – оялам, әллә инде мин дә ошатам.

Тулай торак болай ерак түгел. Гел икәү бергә кайтабыз. Озатышып йөрү түгел әле бу. Янәшәндә шундый егет йөрү кызлар өчен үзе йозак бит.

Бергә шулай кайтып килгән чакта Гасыйм миңа хыялын ачты:

– Мин педтан соң әле вузга барам! Галим булып чыгу – бар уем!

– Ә мин менә читкә китәрмен күк. Хаты саен чакыра абыем.

Ул чагында уйлый белмәгәнмен китәм диеп кенә китеп булмавын. Җитәкләшеп йөргән егет-кызны авыллар көтеп торуын. Карамыйча безнең уй-теләккә, юлладылар ике мәктәпкә!

***

Авыл аралары якын түгел.
Гашыйк җанга ара ни соң ул?
Сандугачын көн дә күрер өчен
Җаен тапкан минем Гасыймым:
Сәпит сатып алган юнь бәягә,
Килә хәзер очып һәр кичен.

Мәхәббәте көчле иде аның,
Аның өчен һәр көн кайгырам.
Төнгә кала, димен, караңгыга.
Йончый да бит әле аннары.
Белдекмени әле ул чагында
Караңгының алда булырын?!

Башлы иде шул ул, яренгәсен
Эш урынын күчертеп куйган.
Икебез дә хәзер Кызылъярда.
Бу авылны шундый яраттык.
Зәңгәр таулар, яшел әрәмәләр,
Тымызык кына аккан ямьле Ык.

Дүртенче аять

Ак шомыртлар шау чәчәктә чакта
Икәү бергә генә туйладык.
Ык буйларын парлап буйладык та
Көлеп-җырлап бер дә туймадык.

Без яшь идек әле – хыялландык!
Алда көткәне дә шау бәхет...
Сөйгән ярың янәшәдә чакта
Хыялланып яшәү бик рәхәт!

Бик күп итеп бала үстерербез,
Үзебез дә бергә үсәрбез.
Гасыйм дигән таянычым барда
Дәрьяларны кыю кичәрбез.

***

Эленеп калды җырларыбыз
Ык буе талларына:
«Дошманнарның күле корсын,
Безнең диңгез шауласын!
Безнең җырлаган җырларга
Сандугачлар кушылсын».

Ул чагында шулай иде: сандугачлы җырларда да дошмансыз булмый иде. Ярыймы бу, әйбәтме? Әллә юрап китердекме ил өстенә афәтне? Афәт әле ерак иде, сугышлар әллә кайда – Хәсән күле буйларында, финнарда, Халхин-Голда!..

* * *

Шуннан ары әни сөйләмәде. Югыйсә ачылгандай булган иде теле, сөйләп киткән иде вәземләп. «Ник нервымда уйный икән шушы бала? Хатирәләр мине юатмый, яраларым гына яңара. Сезгә язган булсын тыныч тормыш, язмасын ла сезгә янарга!» Ярый ла соң, туктап торырмын. Сабыр көтәм тагын бер җаен. Сүз йомгаклап, әни әйтә куя: «Төштә күргән кебек гомерем. Алсу төштән кердем төтенгә, таралмады төтен бүген дә! Сер сыйганга, әнә, сандык бар!»

Аять түгел бусы, хатирә...

Почмаклары тимерле яшел сандык күптән инде тынгы бирми. Ни сере бар икән ул сандыкның, нигә микән шулай кадерле? Мондый уйлар бәләкәйдән бимазалый минем күңелне. Җәйге төндә янгын чыккан иде. Түбән очта. Капка төбенә чыгып бастык. Зур авылның икенче башындагы янгын кара төндә бигрәкләр дә дәһшәтле күренә. Авылның ул башы дөрли-дөрли утка кереп бара сыман. Сугыш шундый буладыр инде ул дип уйлаганым хәтердә. Миңа алты яшьләр тирәсе булгандыр. Шул чагында йөрәгем алынып курыккан идем. Олыларның куркышуы миңа да йоккандыр инде. Алар бит әнә, минем кебек багана кочаклап, канлы ялкын шәүләсен күзәтеп, тик кенә басып тормыйлар, тыз-быз йөгерешәләр. Җил янгын чыккан яктан исә. Олыларны шул җил хафага сала. Тимер кыршаулы сандыкны, баш-башындагы колакларыннан тотып, таш келәткә чыгарып куйгач, алар да сабырлана төште. Димәк, иң кадерле хәзинә сандыкта, һәм ул хәзер ышанычлы урында – саклауда!

Янгын сүрелгәч, сандык янәдән урынына кереп утырды. Өстенә тагын юрган-ястыклар – сандыкның сагы өелде.

Ун-унике яшьләрдә өйдә нәрсәнең кайда торырга тиешлеген олылардан артык белә торган бәләкәй «хуҗәйкә» булып җитешкән идем инде мин. Беркөнне теге сандыкка да чират җитте. Кадерледән-кадерле ни-нәрсә бар икән соң аның эчләрендә? Ачтым мин бу серле сандык капкачын. Иң өстә әниемә әбиемнән калган ядкарь – «Кузнецов» тәлинкәсе ята. Читкә алып куйдым. Бер кырыйда саргайган кәгазь төргәге күреп алдым. Аны сүттем. Чәч толымы. Тылдагы авыр хезмәттән өзлегеп, унсигез яшендә гүр иясе булган Мәрхәбә түткәйнең толымы. «Башларым бик сызлый», – дип, Бәләкәй әбкәйнең төшләренә еш керә башлагач, ул толымны түткәйнең каберенә илтеп күмделәр. Тагын ниләр бар? Әһә, монысы күлмәк! Күлмәк! Әниемнеке! Сөйгән егете белән кавышырга нияте барлыгын әйтеп, хат язгач, Кыргызстан ягына киткән олы абыйсы сеңлесенә шушы түше чигешле ак күлмәкне салган. Димәк, туй күлмәге була инде бу. Күлмәкнең сандыктан чыкканын хәтерләмим. 75 ел ятты ул шунда.

Тагын бер күлмәк. Монысы кияүнең туйда кигән, сугышка киткәндә салып калдырган күлмәге микән әллә? Тән исе саклансын дигәндер инде әни – күлмәкнең якаларына сабын тидермәгән. Бу төргәктә Гасыйм Зәкиевнең сугыштан язган хатлары. Иң кадерле хәзинә шушы хатлар түгел микән әле? Сандык янына чүгәләгән килеш укыдым мин ул «кош телләрен». Апамның этисенең – әнинең Беренче Солдатының хатлары иде болар. Миңа кагылмыйлар да кебек, тик әни бит минеке! Аның гомер юлы минеке. Үзе бу дөньядан киткәннең соңында аның серләре дә минеке. Хәзер шулай

уйлыйм мин. Ул чагында бәләкәй идем. Апамның «күзен ачарга» ашыктым. Хатларның берсендәге «Диләрәгә бәрәңге ашатмагыз. Биле юан булмасын», икенче хаттагы «тегәрҗеп белән буен үлчәп җибәр әле, никадәр үсте икән бәгырь җимешем?» дигән сүзләр апамның да күңел дөньясын чайпалдырып җибәрергә тиеш иде дип уйладым. Алай нык хисләнмәде бугай ул. Әллә ул да әни кебек күңелдәгесен биктә тота белә иде микән соң?

Беренче солдат

Сталинград өчен барган иң дәһшәтле сугышка рота политругы булып кергән ул солдатның да сугыш өермәсендәге гомере нибары 24 сәгать кенә булды микән? Яшь бикәчен, сугыш башланган көндә туган нәни кызын, хыялларын калдырып, броньнан баш тартып, дәһшәтле сугыш авызында йотылган солдатның үзенә дә нибары 24 кенә яшь булган икән шул! Сталинград сугышының беренче көннәрендә үк һәлак була ул. Ржев янындагы канкойгыч иттурагычтан исән чыкканның соңында ул тагын нинди ашыгычлык белән мондагы дәһшәткә дә килеп өлгерде икән? Әй, гомер бетүгә чара табылмый каламы соң? «Хәтәр барда – татар бар» – мәгълүм аксиома лабаса! Исеме Мамай курганындагы Мемориалда. Хәер, кош теледәй хатларны укый башлагач, бу Беренче Солдатның янган утка барып керү тарихы беркадәр ачыкланыр әле.

Әнинең бик тә кыска гомерле булган татлы бәхетенең мизгелләрен, кәрәздән бал суыртып алгандай, азапланып, сөйләтергә тырышып карадым мин алай да.

– Туй булгандыр бит инде? Җәй идеме, яз идеме? Дуслар, туганнар җыелган идеме?

Бүгенге заман аршыны белән үлчәп маташам икән...

– Туй дип, кызым... Кавышу безнең өчен үзе туй иде инде ул. Педучилищедан соң икебезне ике авылга юлладылар. Мин Авыл Ырыссуына киттем, Гасыймны Димтамакка җибәрделәр. Ике авыл арасы ничә чакрым булгандыр, хәзер анык кына әйтә алмыйм. Ул таулар-үрләр аша турыдан гына килә иде. Беренче хезмәт хакына велосипед алган иде. Бер ел шулай турист булып йөрде. Икенче елны икебез дә Кызылъярга күчерелдек. Элек бит шулай иде – укытучыларны гел күчергәләп торалар иде. Имеш, мал-мөлкәткә бәйләнмәсеннәр, өйләр салып, тамыр җибәрмәсеннәр, чын пролетариат сыман яшәсеннәр дип уйланылгандыр инде. Шулай ярымгидай яшәлде дә инде. Өйләр салып, бәрәңге бакчасы тотып яши башлагач, иркенәеп, тамак туеп киткән иде анысы. Әтиең белән кушылгач, кәҗә-сарык та асрадык бит әле.

– Ашыкма, әни, беренче туйдан башлаган идек.

– Туйдан-туйдан. Ике ярлы баласының туе тургайлар белән булды. Икебез дә Кызылъярда бер ел укытып, җиденчеләрне каникулга тараткан көн иде ул. Кызылъярны үлеп яраттык. Андый да матур авыл дөньясында бүтән булмагандыр. Ык буе әрәмәләре, анда үскән татлы җиләк, чия, карлыган, шомырт... Ярлы баласы булуыбызны оныттыра торган сыйлы табын иде ул әрәмә. Көзен таугa чикләвеккә дә йөри авыл халкы. Без анда ук барып җитә алмадык. Ә менә Ыкта су керүләр, көймәдә йөрүләр, балык

сөзүләр әлекте. Әйе, әлекте. Гасыйм бу рәхәтлекләрне нибары бер җәй татып калды.

– Әни, син үзеңне ярлы баласы дип сөйләмә инде. Нәселегез Арысланбәк морзадан килә дип ишеткәнем бар. Каразиреккә мулла йортына килен булып төшкән, Чибәр җиңги дигән даны булган зәңгәр күзле Камилә әбием дә Гыйльфан бай оныгы лабаса. Аның әнисе Хәмидә әбиемә Кәрәкәшле авылы бирнә малы итеп бирелгән дигән хәбәр бар. Әллә болары әкият кенә микән? Алай дисәң, безнең нәсел-нәсәп ни сәбәптән тузгыган? Хәбибулла мулла нилектән гомерен сукыр тычкан сыман землянкада төгәлләгән? Нилектән синең атаң, минем бабам Хәниф Бөгелмә төрмәсендә вафат булган? Ә үткен табигатьле Камилә әбием шул төрмәдән җәяүләп качып кайта алган? Менә кайда ул хикмәтләр! Сандык биктә торсын өчен сәбәпләр күп икән шул!

– Син ачкан сандыкның хасияте мал-хәзинә саклаудан бигрәк, хатирәләр саклаудан гыйбарәт иде шул. Хәбибулла мулла нәселе бөтен Урта Азия балаларына гыйлем бирде. Сөргенгә озатыр алдыннан авыл советы бинасына китереп ябып куйгач, иң олы малай, Мирхатип исемле туганнан туган абзам (ул, Чимкентта бик җитеш тормыш белән яшәгән), совет тәрәзәсен артсыз урындык белән ватып, унике сеңлесен Ютазыдан үтә торган төнге поезд белән Ташкент ягына алып киткән. Кызлар барысы да орденлы укытучылар булдылар. Игезәк әбиләрне онытмадыңмы? Хәтерләсәң, кайткалыйлар иде бит. Шул болганыш дәверендә бертуган абыйларым да читкә китеп, кайсыдыр шахтага барып урнашканнар. Алар язмышы да бер әкият кебек инде. Әйтсәң – сүз, төртсәң – күз дигәндәй, ике яшькә олырак Садершәһит абый шахтага баруга бер марҗага өйләнгән. Назыйф абзый алар янына килгән бит инде. Бүлмә кечкенә икән, карават та берәү генә. Шахтада күмер чабу сменалы. Чиратлап йокларга туры килгән. Хатыны сменалы эштә түгел. Җитмәсә, бер малай да табып куйган. Менә шушы урында башыма гөнаһлы уй кертүдән куркам. Олы абый марҗа хатыны белән бер мәртәбә авылга кайтып киткән иде. Марҗа җиңги бүтән күренмәде.

Абыйлар икесе ике сыйфатлы иде. Олысы бик нечкә күңелле, буйга да бик җыйнак иде. Шахтадан кайтып, Туймазы ягыннан Миңсылу җиңгигә өйләнде дә Кыргызстанга китеп барды. Язучы Чыңгыз Айтматов авылында совхозда эшләде. Сугыш кичте, исән кайтты, намазга утырды. Әүлия кебек кеше иде инде. Төсем белән мин аңа тарткан. Ә ул әтәйгә охшаган булган. Гел хат язышып тордык. Бик тәртипле ике ул, бер кыз үстерделәр, тик гомере генә кыска булды. Әлеге дә баягы, сугыш нәтиҗәсе инде.

Дөнья бәясе иде Назыйф абзыем да. Ул сугышка кадәр сабантуйларда көрәшә, йөгерә торган иде. Гәүдәгә дә бик шәп кеше иде. Инәйгә охшап, зәңгәр күзле иде. Сугышта бер кулын калдырып кайтты. Артиллерист булган икән. Шул сыңар кулы белән печәнен дә чапты, дөньясын да көтте. Сугышка кадәр үк бик булдыклы Гаян җиңгине урлап кайтып, башта яратмыйча, аннары соңлап килгән олы мәхәббәт белән бик матур итеп яшәделәр. Син Назыйф абзыйның өйләнү тарихын язган идең түгелме соң инде? «Кыз урлау» дигән хикәятеңне әйтәм. Сокланып туймаслык Наил абыеңны үстерделәр. Менә шулар миңа гына түгел, сиңа да чын туган, чын абый булдылар. Бу яктан ярлы булмадым мин. Кайвакыт бердәнбер туганың йөз кардәшеңне алыштыра ала. Наил абыең шундый булды.

Дөньяга сибелгән туганнарым күплеген белә идем. Тик күп сөйләшергә ярамады шул. Инәй Бөгелмә төрмәсендә әтәйне калдырып кайткач, бер ялтыравык мөһерле кәгазьне дөрләп янган мичкә ыргытты. Морзалык ярлыгы булгандыр дип фараз итәм.

Безнең кардәш-ырулар Кандра-Күл авылында ишле генә булып яшәп ятарга тиешләр. Әтәйнең сеңлесе Мәхүпҗамал түтәйнең дә унике баласы булган. Ничәү калгандыр хәзер. Зөфәр абзый дигәне бигрәкләр дә Назыйф абзыйга охшаган иде. Мансуровлар анда – Кандрада дип әйтүем. Аралашу җитмәде шул. Тормышлар авыр, эш мәшәкатьле булды. Гомер буе укырга тырышу да туганлык араларын ныгытырга бирмәгәндер дип уйлыйм. Менә сезнең йөрешер-аралашыр туганнарыгыз булмауга хәзер бик борчылам да бит. Үзегез юллап, табышып карасагыз гына инде. Күп без, бик күп! Финляндиядәгеләрен табып кайттың инде. Анысына мең шөкер. Инде югалтма!

– Юк, әни, югалтмаска иде инде. Унөч яшьлек Гәүһәр Туганай бармагында Хельсинкига киткән йөзек минем оныгым Камилә бармагына кереп утырды бит инде. Йөз елдан соң! Менә ул дөньяның балдак сыман түгәрәк булуына бер дәлил! Кызганыч, Гәүһәр Туганай үзе генә бу дөньядан күченгән иде. Әмма мин аның зиратында дога кылып кайта алганыма сөенәм. Камилә әбиемнең кардәшләре ята бит анда. Бәлки, әле оныгым Камилә дә берәр вакыт шул тарафка юл сабар.

Дөньяның сәерлекләре! Кәрәкәшле авылыннан башланган нәсел җебе бер төенләнеп ала да, шул төендә берәр шагыйрь калдырып китә. Шагыйрь Сирингә кадәр дә булдымы икән берәүсе. Аннары Гәүһәр Туганай... Хәзер монда без – Асия Юнысова, Ләйсән Юнысова, хәтта Камилә Юнысова да каләм сүзенә битараф түгелбез. Әле тагын да бардыр.

Их, барлыйсы иде бөтен шәҗәрәбезне! Әни ягыннан да, әти ягыннан да. Беләсе иде кемнәр килеп, кемнәр киткәнен. Һәр язулы сүздән үч алганда, нәсел тарихлары да, гади елъязмалар да халык язмышына дучар ителгән шул, ни аяныч! Кешелек дәрәҗәңне түбәнәйтүнең иң отышлы юлы – нәсел-нәсәбеңне оныттыру. «Коръән»дә дә иң олы гөнаһларның берсе – туганлык бәйләнешләрен өзү диелгән. Бу дөньядан сиңа кардәш тиешле кемнәрнеңдер шаулап, җырлап, җир җимертеп, бәлки, олы уйлар, олы гамьнәр белән үткәнен белә алу Ходай Тәгаләнең гүзәл бер ганимәтедер. Бәлки, алар бу тынгысыз дәвердә биниһая зур михнәтләргә дучар ителгәннәрдер. Аларның бик азына гына үз язмышларын яшәргә мөмкинлек бирелгәндер.

Ир затларының байтагы – солдатлар! Гомерсез солдатлар!

Хатын-кызларның күбесе – толлар! Сүрелмәс сагыштан көйгән толлар!

* * *

Көнбатыштан! Яшен ташлы гарасат килә! Аңа бер ел калган иде. Шул бер елны, һич югы шушы соңгы тыныч җәйне бу икәүдән рәхәт яшәтергә иде бит. Ничек тә!

Беренче Солдат Казан дәүләт университетының физика-математика факультетына укырга кереп кайткан икән. Сандык төбендә кара тышлы зачётка белән студент билеты ята. Беренче курс өчен билгеләрен алып өлгермәгән...

Гасыйм Казаннан баеп кайткан. Беткән баш беткән – яшь бикәч алдында ничек тә хисап тотармын, дигәндер. Фәһимәсенә мәктәпкә кара-каршы кияргә ике күлмәк, бер кием ботинка алган. Үзенә дә чалбар-күлмәк юнәткән. Яраткан Камилә әбисенә (хатынының әнисенә) француз яулык, такта чәй алган. Инде парлап Димтамакка – Гасыймны фатирда тоткан Ямалетдин бабай белән Бибизөлхиҗә әби янына кунакка барып яталар. Аларга да колак сөенчесе тиештер бит инде – укырга керде ләбаса.

Бүләкләрен шул сәбәпне әйтеп тапшырып, өстеннән йөк төшерергә уйлаган иде дә Гасыйм, алай гына булмады.

– Менә, бабай, менә, әби, мине үз улыгыз кебек күреп, тәрбия кылдыгыз. Тормышымның иң рәхәт вакыты сезнең янда үтте. Инде менә югары уку йортына да кереп кайттым. Шул шатлыкны уртаклашуым дип, күчтәнәчләр китердем.

– Их, син, бабаң янында күпме гыйлем җыеп, акыл утыртмаган малай. Кадерле улым минем! Иң зур сөенечең, иң зур бүләгең – яныңда басып торган шушы гүзәл бала. Дипломын да алырсың. Иншалла! Тигез, бәрәкәтле гомер насыйп итсен үзегезгә! Сез, коммун балалары, бик сизеп торам, никах укытмагансыздыр. Әйдә, карчык, мичтәге коймагыңны табын уртасына куй. Киленгә ак яулыгыңны бәйләт. Никахны, тәвәккәлләп, үзем укыйм. Өч сугышны күргән бабагызның догасы да, тыны да дөрес аның. Дөньялары буталып тора, никахсыз сабыйлар дөньяга китерүдән куркыгыз. Бар, карчык, Ярулла кияү белән Зәйтүнәгә дәш – шаһитлык кылырлар. Гасыйм улым, кәләшеңә ни мәһәрең бар? Тарак бирсәң дә ярый. Баегач, олырак мәһәр белән бәхилләтерсең. Киленнең белеме, сылу буй-сыны – үзе бирнә!

– Бар минем мәһәрем. Сер булып торсын дигән идем. Бирәм, мәһәргә бирәм. Дәресенә йоклап калмасын өчен сәгать алып кайткан идем мин аңа. Ну, бабай, серне чиштердең. Әле комсомолдан да кудыртмагаең... Шаһитларга сер сыядыр бит инде... Аннары без бит Фәһимә белән кавышып яши башлаган идек инде. Алай ярыймы соң ул?

– Игелекле эшнең иртә-киче юк аның, улым. Хәзер, тәһарәтемне генә яңартып алам да сезне Ходай каршына хәләл ир белән хатын итеп бастырып куям, Аллаһы боерса!

Менә шул көннән, кеше-мазар ишетмәгәндә, Гасыйм Фәһимәсенә «хәләлем» дип дәшәргә остарып китте.

Димтамакка икесенә бер велосипедны җитәкләп килгәннәр иде бит әле, ат җигеп кайттылар. Велосипедка Ярулла кияүнең кызыгуы хак булган икән. Үзенә сатып калдырдылар. Көзгә кадәр яшисе бар иде бит әле бер кат күлмәк-ыштанлы яшь гаиләнең. Аннары арбага салып кайтырдай нәрсәләр дә шактый җыелды. Ямалетдин бабай ишегалды тутырып, сарык асрый. Йоннарын Чәкән базарына илтеп мәшәкатьләнәселәре килми икән. Юри генә әйтүләредер инде. Бу ике гидай итек бастырып кисеннәр, яшь килен язгы йоннан йомшак оекбашлар бәйләсен, дигәннәрдер. Ике капчык булырдыр, актан, карадан сарык йоны тутырганнар. Бу зур байлык иде. Фәһимә яшьтән кофта-башлык ишене гел үзе бәйләп кия торган иде. Берәр матур буяуга манасың да – бер дигән була. Мәктәптә дә, авыл арасында да ялт итеп йөрисең.

Ике капчык арасына картлар биш литр керешле җиз самавыр салып җибәргәннәр икән – анысын кайткач кына күрделәр. Менә бу байлык

ичмасам! Өстәлеңдә самавырың гөжләп торса, ач булмыйсың инде аны. Өең дә ямьле була.

Өй дигәннәре – укытучылар өчен тәгаенләнгән мәктәп йорты. Бик суык була, диләр аны. Мәктәп укытучы башыннан дүртәр кубометр утын бирә. Шул утынга кызыгып, фатирга өндәүчеләр бар. Уйлашырлар әле.

Мәктәп йортындагы күршеләре бик әйбәт. Алардан ерак китәсе дә килми. Ильяс абзый мәктәп атын карый, хуҗалык эшләре дә аңа йөкләнгән, хатыны Гашыйга апа мәктәп җыештыра. Димәк, бер коллектив кешеләре. Бу яхшы күңелле күршеләр яшьләргә әйберләтәдән бигрәк, киңәшләре белән гел ярдәм итеп торалар.

– Фәһимә кызым, – диде бер көнне Гашыйга апа, – директорның да ялда чагы. Ык буе яланнарының, әрәмәләрнең җимешкә мул вакыты. Кышның авызы зур аның. Карлыган, гөлҗимеш киптереп куй. Җиләк белән баланнан как кой. Белмәсәң, үзем өйрәтермен. Авылда докторы да, даруы да шул – әрәмә җимеше. Алла боерса, ишәеп тә китсәгез, бала-чага чирләүчән була. Шифасына чарасы үзеңдә булсын. Өйрәтә дип үпкәләмә. Үзем, әнә, дүрт бала үстердем. Нарат бөресе дә, имән кайрысы да, кипкән шомырты да, кура җиләге дә үз урынында бик кирәк. Кеше ул синең йомышыңны бер йомышлый. Көн дә керә башласаң, туеп китә. Алуга караганда, бирү күңеллерәк. Үскәнем, миңа кермә, дигән сүзем түгел бу. Яшәргә яшьтән өйрән, диюем генә. Дөньяны аны хатын-кыз тарта. Ирләр кирәктә терәк кенә алар. Әйтергә онытып торам икән әле. Имәнлек урманына еш барасыз. Итәгеңә нарат күркәсе салып кайта торган бул. Кыш буе самавыр күмеренә рәхәтләнерсең... Өйрәтә дип үртәлмә, үскәнем. Безнең шул инде, акыл сату. Янында инәең юк бит әле. Бәбәегез туса, ул да килми түзеп тора алмас. Укытучы мәктәптән артамыни ул? Аның баласы ярым ятим үсә инде. Тәүбә-эстәгъфирулла! Бар уйлаганымны түктем дә бетердем. Акыллы Гашыйга дигән булалар тагын үземне. Ярый, үскәнем, безнең дә абыең белән ике башыннан тотып пычкы тартасыбыз бар. Мәктәп мичләренә утынны хәстәрләү дә безнең өстә бит. Кисәсе дә, ярасы да бар. Әнә ул әрдәнәләрне генә күр син, пычкы иңе түгел, колач җитмәслек. Кәҗә майларыбыз чыга инде. Аны уйлаучы бармы? Утының коры булса, кышын мәктәп мичләрен җылыту бик рәхәт. Ис тә чыкмый. Чөнки коры утын җәһәт яна. Бала-чага җыелгалаганчы мичләрне томалап өлгерәбез. Менә шулай, үскәнем, кырмыска гына түгел, Ильяс абыең белән Гашыйга апаң да җәйдән хәстәрләнә. Син дә шулай өйрән. Шулай иткәндә, тормыш үрчемле була. Әниеңә хат яз: мендәр-юрганнарыңны китергәндә, берәр ала каз кыстыра килсен. Безнең ата каз ала казлар ярата. Бәбкәләре ишле булыр. И-һи-һи!

– Пычкы тартышырга без дә булышырбыз Гасыйм белән! Кичкырын инде... Акыллы киңәшләреңә рәхмәт яусын!

– Менә рәхмәт! Сезгә дә физкультура булыр!

Кичен пычкы тартып арыгач, ялга туктаган арада Гасыйм болай диде:

– Хәләлем, Казаннан кайтканда, вагонда яшьләр бер җыр җырлап кайтканнар иде. Мин шуның сүзләрен отып алдым. Пычкы тартканда, шул көй гел колагымда яңгырап торды. Көен бераз тәртәсенә кертергә тырышып карыйм әле. Бәлки, аны син дә радиодан ишетеп калгансыңдыр. «Иделем» дигән җыр бугай ул.

– Әйдә, көйләп күрсәт әле.

– Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул, шул;
Караңгы төн, болытлы көн –
Без аерылган көн бит ул.

– Беләм мин бу яңа җырны. Аны радиодан Зифа Басыйрова «Су буйлап» дигән җыр дип җырлады.

– Әйдә, син дә кушыл, икәү бергә җырлыйк:

Идел буйларына барсам,
Әйтер идем Иделгә, шул,
Минем кайгыларымны да
Илтеп сал, дип, диңгезгә.

– Әй, әллә нинди моңсу җыр булды ла бу. Аерылу турында җырлар чагыбыз түгел әле, хәләлем, әйеме? Идел елгаларын бер барып күрсәң, ярар иде лә ул...

– Безгә Ык та җиткән. Әйдә, көн сүрелгәнче су кереп кайтыйк. Пычкы кибәген тәннән юдырыйк. Алайса, тирләгән тәнгә гүпчем сыланды. Моңынчы сентябрь башында су коенып йөргән юк иде әле. Ык монда тиз агымлы бит. Суы да салкын. Минем туган авылым Каразирек янында Ыкның суы талгын, ашыкмыйча ага. Укулар башланганчы, инәйне күреп килмәдек инде шунда. Директор апабыз бик кырыс. Ары-бире йөртә торган түгел.

– Яңалыгың барын сизенсә, инәй үзе дә килеп җитәр әле.

– Яңалыкның буласы бар бит әле. Шикләндем генә бит әле. Әллә чын, әллә түгел. Кара әле, дустым, көн туды исә мәктәптән берәр укытучы киткән булып чыга. Кая югалалар соң алар?

– Күпне белмә. Кем хәрби өйрәнүләргә, кем тәртибе начар булганга күрә... дип уйлыйм. Югыйсә тәртипләре дә яхшы кебек. Ил чикләре тынычсыз, хәләлем. Мин китеп югалсам да, аптырамассың. Дөнья сезгә, хатыннарга калырга тора.

– Әллә ниләр сөйлисең, бәгырь. Як-ягыңа каран. Авызыңнан җил алсын. Ир-атларсыз тормыш була, димени? Менә минем ат җигеп караганым да юк. Абзыйларым мине андый эшкә якын китермәделәр. Син дә гел саклап кына торасың.

– Синең эшең – балаларга белем бирү. Хөкүмәтебез сиңа иң зур байлыгын – балаларны ышанып тапшыра. Алда ни язгандыр. Минем җаным тыныч түгел. Теге яңа җыр күңелне кузгатты. Шомландырды. Зират буендагы өйдә үскәнгә күрәме, шомланучан мин. Йә, йә, курыкма. Син бит минем батырым. Минем әбекәй: «Улым, кайгы бездән алда туган ул. Аны куып тотып та, узып китеп тә булмый», – ди торган иде. Без яшәрбез әле. Мондый илдә дә яшәмәгәч!

* * *

1941нең кышына яшь гаилә киләчәккә өмет белән керде. Мәктәп эше гөрли, өлгерешләр әйбәт, дәресләр күп. Уч тутырып, акчасы килеп тора. Икесенә дә Миһмангәрәй абзыйдан итек бастырып алдылар. Фәһимә,

бар осталыгын җигеп, башлык-шарфлар бәйләде. Җебен Мәрвия әбидән генә эрләтеп алды. Үзе дә булдыра. Тик андый эшкә вакыты тар. Ничәшәр параллель сыйныфның дәфтәрен тикшереп өлгерә алмый. Алар тәрәзәсеннән төшкән җиделе лампа яктысы ярты төнгә кадәр урамны яктыртып тора. Аларның өен шул якты тәрәзәгә карап табалар.

Июнь уртасында ук туарга тиешле бала ашыкмады. 22 июнь таңын көтте. Үзенчә иң якты, иң озын көнне сайлаган. Ашыкмыйм дигәч тә, бигрәкләр дә әнисен интектереп туды сабый. Бүтән бала табасың да килмәслек итеп. Акбуада яңа ачылган бала тудыру йорты табиблары бу кызның үзләре белән эшлисен белмиләр иде әле.

Гомумән, дөнья берни белми иде. Чөнки таң атканда, миллионнарның язмыш карталары буталды. Миллионнарның бәхетенә ябалак канатыннан кара күләгә төште. Көнбатыштагы кайберәүләрнең Советлар иленең, һич тә җир йөзеннән югалырга уйламыйча, матур гына яшәргә омтылуы, рәхәт, тыныч тормышы эченә тиде. Йә, беләк кадәр нарасыйның кемгә зыяны тигән инде? Аның өлешенә дигән бәхетне урлау кемгә кирәк булган? Ул бит бу якты, кояшлы иртәдә дөньяга бәхетле булыр өчен туды. Елмаерга, көләргә, сөенергә, иркәләнергә туды. Әнисенә гөл кебек, әткәсенә чук кебек булыр өчен туды. Әнә аңа дигән бәбәй күчтәнәчләрен төяп Каразирек әбкәсе капкадан кереп килә. Тик күрше-күлән генә ашыкмый. Ашыгырлар иде. Алар «кара тәлинкә»дән иртә таңнан яңгырап торган хәбәрдән өнсез катып калганнар.

– И Ходаем, мәдәт бир! И Ходаем, бу нарасыйны ятимлектән арала!

Әбекәйнең иң тәүге догасы шул булды. Күпне күргән, күпне кичергән, 36 яшеннән үзе дә тол калган абыстай иде шул ул!

– И бала, Ходай бәхетеңне күп күрмәсен. Ярабби! Исемең Диләрә булыр. Шул кемәеңне бик ошатам, Фәһимә кызым.

Камилә әбекәй ишектән бөтен төеннәрне чишә керде.

Исемне ошаттылар. Иң мөһиме исем идемени соң әле монда?! Өй түренә ил кайгысы иңгән иде. Ил кайгысы! Мир белән күтәрә торганы. Туган бала үсәр ул. Фәрештәләре генә ташламасын!

Шул көннән Гасыймның өйдә торганы да юк. Фәһимәсенә дә кырыс кына карап алды:

– Әби килде. Бала бишеге янында озак юанмассың. Бөтен халык кырда. Утауга гына булса да чыгарсың. Агитаторлар да кирәк. Кыр станына барып, газеталар укып, яңа хәбәрләрне ирештереп кайту да синең өстә.

Бигрәк кыска булды әле бу иркә тормыш.

* * *

Бер көнне Гасыймым кабаланып кайтып керде:

– Алтыным, кызымның әнкәсе! Бүген радиодан иптәш Сталинның бик мөһим мөрәҗәгатен укыдылар. Иртәгә газеталарда да булыр инде ул. Бу сугыш тиз генә үтеп китәргә охшамаган. Миңа да җыенырга кирәк. Бераз хәстәрен күрә башла. Походка әзерлә мине. Минем ул мәшәкатьләргә вакытым булмас. Татарстанга предприятиеләр эвакуацияләнә икән. Безнең авылда да качаклар кабул итәргә дигән күрсәтмә бар. Ленинград кешеләрен көтәбез. Без яшәп тора торган укытучылар өен бушатасы, диделәр.

– Ярар, әтисе! Мин инде ишеткән идем. Габбас карчыгын белештем. Мәктәп атына аз-маз йөгебезне төяп, бүген үк күченербез. Юлдан йончып килгән кешеләрне тилмертеп булмас. Безнең өчен борчылма. Инәй дә нык кына бит әле. Партия кушканны үтәү юлында йөр инде син, бәгърем. Тик, кара аны, бала бераз исәйгәнче генә булса да, фронтка ашкынма. Йөрәгең дә бик үк сау түгел. Сүземә колак сал. Сугыш барыбызга да җитәргә охшаган.

– И әнисе... Ил хәсрәте белән яшәргә тиешле кешеләр бит без. Илебез безгә ышана. Рәхмәтле булырга тиешбез. Укытты, кеше итте. Җиңеп кайткач, алда тагын ямьле итеп яшәрбез. Планда тагын ничә бәбәй бар әле безнең?

Күчендек Габбас карчыгы өенә. Ике карчык уртак тел таптылар кебек. Бер Диләрәмә ике әби – ярап тора ул. Мин дә уракчылар яныннан кайтып кермим. Мәктәптә дә эш күп. Миңа иптәш кыз табылды әле. Рәисә Хаҗиева исемле кыз килде Казан ягыннан. Үзе чибәр, үзе ипле. Зыялы гаиләдән. Иптәшлеккә менә дигән. Немец теле укытачак. «Дошман телен ничек укытырмын инде?» – дип, бик борчыла. Юкка гына борчылган. Раяның ягымлы, тәмле теле назга өйрәнмәгән авыл баласын сихерләде дә куйды. Кара итәк, ак блуза кигән, чәчен башына таҗ кебек итеп урап куйган бу гүзәл кыз авызыннан алман сүзләре дә ачуны китермәслек булып чыга икән. Өстәвенә ул малайларны үз фикеренә ышандырды: «Дошман телен белү сезнең кесәдәге яшерен ачкыч булачак ул, егеткәйләрем. Сез бит фронт күрәсе бөркетләр. Менә рус телен дә, татар телен дә төшенмәгән дошман, сезне берни аңламый дип уйлап, серен чишә дә ташлый. Бәлки әле, сезне, авыл егетләре елгыр була бит, дошман тылына, йә партизаннарга ярдәмгә самолёттан десант белән ташларлар. Ул чагында сез инде коралланган. Минем бер абыем – очучы. Дошман тылына еш кына оча ул. Менә нинди кыйммәтле белем бирмәкче булам мин сезгә, батыркайларым!»

Менә шундый итеп укыта белә иде ул Рая дустым. Минем өчен үлә язып торган, язуларын да минем шикелле язарга тырыша торган укучыларым да аның янына сырыша башладылар.

* * *

Җәйдән көзгә, көздән кышка кердек. Мәскәү янында канкойгыч сугышлар бара. Авылдан көн дә диярлек олау-олау егетләр китә тора. Безнең елгыларны сыдырып кына алып баралар. Егет-малайлар агач мылтык тотып, кырда өйрәнүләрдә йөриләр, карга ятып шуышалар, граната ыргытырга, төз атарга өйрәнәләр. Газеталардагы хәбәрләргә, радиодан Левитан сөйләгәннәргә караганда, агач мылтык кирәк тә булмас кебек. Аэродромы-ние белән очкычларны сафтан чыгара дошман. Көн саен бер шәһәрне калдырып китәбез. И Ходаем, Иделгә кадәр җитә генә күрмәсеннәр. Мәскәү янында, шөкер, абынды бугай дошман. Халыкка менә шуны күңелләренә шом кермәслек итеп, ничек аңлатсын икән агитатор? Партизан кыз Таня турындагы мәкаләне укыгач, хатыннарым үксеп-үксеп еладылар. Дошманга үч кайнады. Унсигез яшьлек ул кызда һәр ана үз баласын күрде. Кайбер кызлар да шыпырт кына военкомат юлында йөри икән. Бер-икесе китеп тә барды. Зенитчылыкка җыйганнар. Рая дускаемның да уенда бар икән фронтка китү. Ярый әле, военкоматтагы бер абзый үгетләп, уеннан кайтарган.

Шундый чакта Гасыймны тыеп калып буламы соң? Март башында озаттык егетләрне. Еламаска тырыштым. Мин елак түгел дә бит, әле теле дә ачылмаган Диләрәм елый. Югалтуларның ни икәнен белгән инәй елый.

Бераз юанып чыгыйм дип, Гасыймны озатып кайтышлый Рая дустым янына кердем. Аның белән кочаклашып, теге Гасыйм белән соңгы өйрәнгән җырыбызны җырладык.

Төне караңгы түгел иде үзе. Акрын гына кар явып тора иде. Бәлки, яхшыга юраргадыр. Исән кайтыр бәгърем. Кавышырбыз, җырның яңаларын җырларбыз. Рая да мине шулайрак дип юатты. Аның шул сугышка китәсе ире, әтисез үсәсе кызы юк.

Рая мине яңа фатирыма кадәр озата килде. Ярый әле килде. Урамда сандык өстендә бала күтәреп утырган инәйне күргәч, егылып киткән булыр идем.

– Кудылар, кызым.

Җилтерәп, өйгә кереп киттем. Миңа хәзер теләсә кемнән типтерергә ярамый. Ирләр дөньяны безнең кулга калдырып киттеләр.

– Бу ниткән тамаша? Әй? Карчык!

– Ирсез хатын тотар хәлем юк. Сүзе күп була аның. Тынычлыгым кадерле.

– Минем ирем синең тынычлыгың өчен дә сугышка чыгып китте. Әй, Габбас карчыгы! Исемеңне дә белеп өлгермәдем. Ә менә солдат хатынына почмак кызганганың өчен икеләтә налог салдырам әле мин сиңа! Әйтте диярсең. Фатирга кертүче бетмәс. Балам гына түгел, утыным да бар минем.

– Ә ни, теге китергән утыныңны аласыңмыни? Күтәрә алмассың...

– Күтәрүче табылыр...

Минем ярсып сөйләшкәнемне читән аша күршебез Мәрвияттәй ишетеп торган икән. Игелекле күңелле бу хатын мин Габбас карчыгын дуылдатып чыккан арада инәй белән кызымны түренә кертеп утыртып та куйган. Җиденчедә укый торган игезәк малайлары бар иде. Яраткан укытучылары үзләренә фатирдаш буласын белгәч, утынны ташып та, кисеп-ярып та куйдылар. Без бу авылдан күчеп киткәнче туганнарча яшәдек. Ни кызганыч, уңган малайлар бер елдан ут эченә киттеләр. Элек бит мәктәпкә кичегеп керәләр иде. Яшьләре җитте.

Рая дустымны авыл советына эшкә күчерделәр. Аның немец теле – дошман теле миңа калды. Рая-Рәисәнең авыл советына урнашуы миңа да әйбәт булды әле. Тамак бик киселгәндә, ярдәме тиеп кенә тора. Ә тамак киселде. Читтән килгән укытучының ни малы, ни бәрәңге бакчасы, ни кәҗәсе юк. Ни-нәрсә кабып, тамакны хушландырырга белгән юк. Әле дә ярый Рая бар. Эвакуациягә килгәннәр йончу иде. Беркадәресе безнең авыл зиратына кереп ятты. Кайвакыт шулар өлеше безгә тиеп куйгалады. Тиздән Ленинград халкын мәктәптә балаларын русча укытып булырдай урыннарга күчерделәр.

Шөкер, безгә дә, солдат гаиләсе дип, күпмедер паёк бирә башладылар. Атнага бер булса да, көлчә пешереп ашый идек. Аерткан сөт бәрабәренә кыз балаларга кофталар бәйләп бирә торган идем. «Һөнәрле үлми, кызым», – дип, инәй үсендереп торды. Югыйсә һөнәрнең иң изгесен сайлаган идем дә бит. Соңгы вакытта акча ведомостена кул гына куя башладык. Илнең ертыгы зурайганнан зурая бара иде шул. Сугыш ул аждаһа кебек.

* * *

Рая да безнең янга күченде. Ялгыз башы ямансу иде аңа. Хәзер инде Гасыймнан хатларны бергә көтәбез. Диләрәнең уңышларына бергәләп куанабыз. Инәй онытын бик бөртекләп карый. Үзенең матур гына күлмәкләрен бозып, мине дә, Диләрәне дә чуктай киендерә. Ташкент ягындагы абзый әнигә юрган-ястык тышлыгына җибәргәләп торган әдрәс ефәге дә бик затлы күлмәк булып чыга торган иде. Кызым миннән җитмәгән кайгыртуны әбисеннән ала.

Инәйнең миңа дип җыйнап алып килгән өшәнчекләре – киндердән суккан чыбылдык-чаршаулары сәхнә киендерү өчен тотыла. Ай саен диярлек халыкка театр куябыз. Укытучы артист булырга тиеш дип беләләр иде бугай ронодагылар да. Өйгә кайтып та керми кыз бирнәсе. Ярый әле, киндер туза белми – өемне аннары да гел шулар белән бизәдем. Тыныч заманда да, дим. Тамбур белән чиккән тәрәзә кашагалары чыккандыр бит сандыктан?

Минем инәй – Камилә абыстай – авылның мәртәбәле абыстае булып китте. Бик гыйлем иде шул ул. Тиз белеп алдылар остабикә икәнен. Француз яулыгын ябып, түшенә тәңкә хәситәсен киеп, бик дәрәҗәле итеп йөрде. Авылның Хәкимәттәй, адашы Камиләттәй кебек кордашлары аны араларына бик тиз алдылар. Үз дәрәҗәсе ышыгында инәй минем дәрәҗәне дә күтәрде. Ятимә бер кыз түгел икән лә бу Фәһимә, нәселле, затлы кеше баласы икән. Дәрәҗәң булса, сүзең дә тизрәк үтә ул. Инәйне ашка йөртәләр. Фронттан хат килсә дә, матур төш күрсәләр дә, берничә ахирәт әби бер-берсен чәйгә алыша. Күңел юатыша. Сугышның беренче елларында халыкның түле бар иде әле. Аннары гына әрәмә малына, Ык балыгына калдылар. Алай да чормаларда каклаган казлар – нәзер казлары ияләрен көтте. Килергә тиеш иде бит ул якты көн. Инәй күкрәкчә кесәсенә яшереп кенә, онытына сары җимеш алып кайткалый. Кайсы заманнардан калган, кадерләп сакланган тәгам булгандыр инде ул оҗмах җимеше? Инәйгә ямьле мәкам белән китап укыган өчен әҗергә килгән җимеш баламны бик сөендерә торган иде. Диләрәмнең бәхете әбисеннән булды. Миннән наз сирәк эләкте шул аңа. Өйгә кайтып кермәле итмәде шул укытучылар өстенә йөкләнгән вазифалар. Ил үзенең тылдагы сәясәтен безнең аша йөртте. Налог кермәсә дә, укытучы гаепле, заемга язылмыйча йөдәтсәләр дә, сиңа җавап тотасы. Хәләл хезмәтеңә тиясе акчаң да синеке түгел.

Ындыр табагында ашлык җилгәрү дә калмый, баздан бәрәңге аралау да... Кичләрен солдатларга бияләй бәйлибез. Телемләп, бәрәңге киптерәбез. Кетердәп торган ул телемнәрне кабып карарга да базмыйбыз. Мин капкан телем бер солдатка җитми калыр кебек. Әбисе Диләрәгә яшереп кенә бирә инде. Мин күрмәмешкә салышам.

* * *

Авыл һаман бушый бара.

Яшь вакытта хат көтеп алу татлы газап булган икән ул. Менә хәзер... Левитанның Совинформбюро хәбәрләрен тыңлый-тыңлый хат көтүнең никадәр газаплы икәнен белсәгез иде сез?! Өчпочмаклы кош теле килерме сиңа, кара мөһерле конвертмы? Хаты юлда чагында да һәлак булуы ихтимал бит синең газиз солдатыңның. Хат көтүчеләр бер мин генә түгел. Безнең

лампа яктысына җыелган кызлар арасында да бар андыйлар. Бияләй эченә салып җибәрер өченгә кульяулык чигәләр, гөлкәйләрем.

Минем Гасыймым миннән кульяулык түгел, сохари көтә. Бик тансыкладым дигән иде бер хатында. Ипине үзебезнең дә күргән юк. Әлегә Гасыйм сержантлар мәктәбендә генә. Бик чамалап кына, бик кысмыр гына ашаталар бугай аларны. Ач солдат ничек сугыша алсын инде, йә? Тамагы тук булмаса да, ут эчендә түгел әле, дип юанам. Тик ул санаулы көннәр, курсантлык дәвере менә-менә бетеп китәр дә, Гасыймымны ут чәчеп өскә килә торган фашист Дәҗҗал каршына озатырлар. Шул гарасат килер көннән куркам.

Хатларын карандаш белән яза. Язуын бер дә бозмый. Пөхтә дә кеше инде. Минем тилмергәнне белгәнгә күрә микән, үзе сагынгангамы, хатлары еш килеп тора. Мин дә шундук язам, тик аңа минем хатларымның барысы да ирешми. Әллә уйларымны цензурадан яшерә белмичә язам микән? Ул бит әнә бер дә зарланмый. Үзе аңлар әле, ди торгандыр инде. Хатларны гомер буе сакладым. Сезгә укытмый, кемгә укытыйм аларны? Минем белән гүргә китсеннәрмени?! Фотога гына бергәләп төшеп кала алмадык. И, бу мохтаҗлык!

Мин гомерем буе әдәбият укыттым. «Кульязмалар янмый» дигән мәгълүм гыйбарә бар бит әле. Гасыймның хатлары да – кульязмалар. Ул үзе дөрләп янган Сталинград утына кергәндә, минем аңа язган хатларым да аның куен кесәсендә утка кереп киткәндер. Яшь сержантлар төялгән эшелон Ржев янындагы сугыштан соң башта Коломна ягына бара башлаган икән дә, аннан эшелон, кырт борылып, бүтән тарафка киткән. Озатучы лейтенант хәрби серне ачмаган. Мөгаен, Сталинград юнәлеше булгандыр ул. Яшь сержантларны, минем патриотизм дәрте белән янган яшь иремне кем дә аяп тормагандыр.

Сталинград хәл эчендә иде бит! Һәр Совинформбюро хәбәре шуны кисәтеп торды: Сталинградны бирү ярамый. Сталин шәһәре – стратегик объект. Бер карыш та чигенергә, дошманны Иделнең аръягына үткәрергә ярамый. Инде дошман листовкалары солдатларны бирелергә кыстый икән. Уралга кадәр чигенергә тиешбез, имеш. Аның саен халыкта ярсу үч кайный.

Идел үзе дә ирек, хөрлек символына әверелде. Идел китсә, без дә бетәрбез кебек. Соңыннан белдек: анда сугышчылар яр кимереп, тырнакларын биек ярларга батырып сугышкан. Минем Гасыймым да шулар арасында булган бит инде. Төгәлен әйтмәсә дә, хакыйкать җиңү белән бергә кайтты. Комсорг Гасыйм – киләчәктә зур галим буласы кеше Сталинград күмеренә әйләнгән. Кулындагы әләме белән бергә ялкынланып, дөрләп янган.

Ул көннәрдә күз алдымнан бер сурәт һич тә китмәде. «Иделкәем» җырындагы төсле мул сулы, алкын агышлы Идел суы буе белән ялкын булып агып бара, имеш. Яп-якын гына бит. Ул җырны җырлаганда да, «Иделкәем ялкын» дип җырлый башлаганмын икән. Яннарына йөзеп кенә барырдай арада булган бит югыйсә, йөрәк парәм. Безнең бернидән хәбәре юк зәңгәр Ыгыбыз тыныч кына шул тарафка агып яткан лабаса. Ык Чулман аша шул Иделгә барып чыга бит инде. Ык буена төшеп салкын суына кулымны тыккан саен йөрәгемә ялкын үрли сыман иде. Алар анда – Сталинградка август уртасында барып җиттеләр бугай. Барып җитүгә үк утка кергәннәрдер инде... Берәр ай сугышкандыр әле ул. Соңгы хаты үкенеч тулы: «Күрешә алмабыз,

ахры», – дигән... Сохари да барып җитә алмаган. Сугышта югалтуның гомерлеккә кала торган әнә шундый үкенечләре була икән аның.

Нинди асыл затлар көл, юк, очкын булды. Туган ил, Ватан дигән төшенчә – бөек яңгырый торган сүзләр. Ватан хакына гомереңне бирү – изге бурыч! Тик ул гомер миңа да, кызыма да кирәк иде бит! Бер сүнгәч, кайтмый бит ул гомерләр. Таңнар һәр иртәне атса да, ул бит инде яңа таң! Ул таңда минем мәхәббәтем янып беткән була. Тимәсеннәр иде бәхетле парларның таңнарына! Сугышасы килгән бәндәләр үзара гына сугышсыннар иде. Ә безгә сугыш кирәкми иде. Мең кат әйтәм: кирәкми иде! Без яратырга, балалар үстерергә килгән идек җиргә! Тыңлагыз хатыннарны!

Газиземнең хатларын сезнең белән бергә укыйсым килгән иде. Инде мин дә гомеремне очлап киләм. Нинди тансык хатлар иде алар! Никадәр наз, җылылык иде ул хатларда. Авыл кызының бөтен гомеренә җитәрлек иркә сүзләрне каян табып бетерә алган икән ул ярлы авыл малае? Университет тәмамлап кайта алган булса, ниндирәк кеше булган булыр иде икән ул?! Ничә бала үстереп өлгергән булыр идек? Буйларын тегәрҗеп белән үлчәтә-үлчәтә, үскәнен көткән кызының ирешкән дәрәҗәләренә сөенә алмый калганы өчен дә сугышны башлаган фашистларны, нәселләрен каһәрлим. Мәңге рәхәт күрмәсеннәр!

Беренче хат

«Исәнлек хаты.

Якын дустым, миннән сиңа сагынычлы йөрәк сәламе. Шулай ук Диләрә кызыма күп-күп-күп сәлам. Шулай ук әбигә миннән сәлам. Минем хәлне сораучыларга һәрбарчасына сәлам. Мин үзем исән-сау, сәламәт. Сезнең дә һәр кайсыгызга исәнлек теләп калам. Сине сагынып, хат язучы якын дустың Гасыйм. Тагын иртәгә яки берсекөнгә, урынлашкач, хат язармын. Адресымны җибәреп, хат көтәрмен. Дустым, менә шуның белән тәмам. Хат безне китерүче, Ютазы кешесе Малкин дигән карт артыннан җибәрелә. Сәлам, җаным».

Хатның икенче ягында – көндәлек:

«9 март – 1942 ел. Кичкә кадәр Ютазыда поезд көттек. Кич сәгать биштә поезд килде, утырдык. 13 нче вагон. Богданов, мин һәм Ырыссудан син укыткан һәм синең дәфтәрләреңне тикшерешкән бер сары малай – өчәү урта полкада ятабыз. Урын яхшы, вагон олы. Өчәү бергә ашадык, йокладык.

10 март. Иртән ашадык. Шенталага җиттек. Кондуктор № 11, 12, 13 вагоннар Ульяновскида өзелә, ди. 10 нчы вагонга күчтек. Тыгын, һәм өстә, һәм урта полкаларда өчәр кеше урнашкан. Госпитальдән кайталар, армеецлар. Һәркайсының йә бер аягы, йә бер кулы юк. Утырып кына йокларга туры килә. Ульяновскига килеп җиттек.

11 март. Анда аттестат белән, өч км ераклыктан барып, 45 кешегә сохари, ике баш шикәр, коры ботка, 1 кг селёдка – продукт алдык. Поезд озак торды. Кичкә кадәр продуктны команда өчен бүлдем. Поезд китте. 30 км бара да туктый. Ирле-хатынлы Уфадан кайтып килүче яшь кенә бер пар бар. Ире авырый. Менә үлде.

12 март. Пенза якынлаша. Иртән бер стансада поезд туктады. Ырыссуның иптәш Хәсәнов та безнең белән бер поездда Казанга, Суслонгерга бара. Армия сафына.

13 март. Пензага килеп җиттек. Һәм тиз генә 65 кешегә бер товарный вагон алып, бик тыгыз-тыгыз-тыгыз утырып, иртән Уразовкага килеп төштек. Һәм аннан рабочий поезд белән Саранскига иртән сәгать сигездә килеп төштек. Вокзалдан шәһәр буйлап капчык-биштәр күтәреп, хәрби комендатураны эзләп киттек. Аннан безне карантин урынына җибәрделәр. Бик-бик зур чиркәүгә китереп тутырдылар. Тору тәртибен дә, ашау тәртибен дә, уку тәртибен дә әйтүче юк. Үзебез алып килгән ризык белән генә тамак ялгап торабыз. Бүген кич военком килеп кабул итә дә, безне мунчага җибәрәләр икән. Мунчадан соң икенче урынга урнаштыралар. Ризык ише әйберләрне уртак ашауга җыясылар икән. Шуңа күрә малайлар майларын, ипиләрен шәһәргә чыгарып саталар. Алдагы тормышны һич тә әйтеп булмый.

Хәзерге торган урын утын сараеннан да әшәке күренә».

Икенче хат

«1942 ел, 20 март. Сәлам хаты.

Якыным Фәһимә, сиңа чын күңелдән сагынып, йөрәк сәламемне җибәрәм. Шулай ук Диләрә кызыма миннән бик күп-күп сәлам җибәреп калам. Шулай ук әбигә бик күп сәлам җибәреп, исән-сау гына яшәвен теләп калам. Шулай да, әби сәламемне үз күзләре белән укысын дип, татарча (гарәпчә) да яздым.

Дустым-иркәм, үзем исән-сау, сәламәт яшим. Сине дә исән-сау дип беләм. Ничек соң, дустым, тормыш хәлләрең? Бик чыдаша алмаслык авыр түгелме? Гомумән, миңа хат язганда, үзеңнең миннән соңгы тормышыңны бөтен ваклыклары белән таныштырырсың.

Минем тормыш болай. Башта өч көн бик күңелсез чиркәүдә тордык. Мунчадан соң киемнәрне бик каты кыздырдылар да яңа урынга күчерделәр. Ютазыдан килгән 33 егет бер взвод булып урнаштык. Бер бүлмәдә, йортның дүртенче катында торабыз. Шәһәргә чыгып йөрешле түгел. Занятиеләр каты расписание нигезендә 20 марттан башлана. Әле безне өйрәтү өчен команда килмәде. Уку срогы алты ай булып, ике еллык пехота училищесының программасын узачакбыз. Мәктәпне тәмамлагач, мл.лейтенантлар булып чыгарсыз, диләр. Курс ачыла гына әле. Моңарчы булмаган. 2 меңләп кеше бар. Бүген-иртәгә обмундирование бирәбез, диләр. Менә шулай әкренләп, армия тормышына өйрәнәбез.

Ашау ягына килгәндә: көненә 700 гр. икмәк, өч мәртәбә аш, көндез второй да була. Эш тәртипкә салынганчы, ашауның вакыты гына җайсыз.

Монда килгәч, горнизонный комиссия үттем. Һич чир тапмадылар: «годен» дип кенә чыгардылар. Менә тагын тамак авыртып, фельдшер янына кергән идем: «Тиздән белгечләр килә, алар әйбәтләп дәвалар», – дип озатты.

Син дустымны сагынып, хат язучы иң якының Гасыйм.

Диләрәнең үсеш баскычларын аерып яз».

Өченче хат

«Сагынычлы хат башы, миңа да языгыз каршы. 1942 ел, 29 март.

Иң якыным, синең тарафка сагынычлы дуслык сәламнәремне җибәреп, сиңа да исәнлек, сәламәтлек, түземлек теләп калам. Якын күргән әбиемә,

Диләрә кызыма күп сәламнәремне җибәреп калам. Шулай ук Дәүләтбаев Зәкидән күп сәлам. Аның белән бер койкада ятабыз, гел бергә.

Диләрә кызым исәнме, авырмыймы, еламыймы, әле һаман да кич утырамы, эшләрен төнлә дә торып карыймы? Тагын нинди һөнәрләре бар? Хат язганда, дустым, һәммәсен дә аерып яз. Әбинең хәлен дә аерып яз. Бик борчылмыймы?

Дустым, үзеңнең хәлең ничек, авырмыйсыңмы? Эш бик күп түгелме? Кызылъярда мине кызыксындырырдай нәрсә булса, барын да яз.

Үзем сау-сәламәт. Берничә мәртәбә комиссия тордык. Бернинди дә чир тапмыйлар. Занятиеләр көнгә 11–12 сәгать бара. Көннән-көн кырысрак кыланалар.

Ашау ягы яхшырды. 800 гр. арыш икмәге, ике аш һәм обедта второй да була. Көн дә чисталыкны карап торалар, атнага бер кино күрсәтәләр. Яту өчен такта гына. Шулай булса да, өстенә тузан төшерттермиләр. Бүгенге көн начар түгел. Кызыл Армия командирлары булабыз дип торабыз. Алдагы көн караңгы.

Мин, дустым, шуны әйтәм: совет хөкүмәтенең миңа биргән бәхете, белеме өчен ил өстенә килгән куркынычны алып ташлауда илем алдында үземне бурычлы дип беләм.

Ярый, дустым, сиңа күңелле тормыш теләп, сине бик сагынып язучы дустың Гасыйм».

Алтынчы хат

«1942 ел, 10 апрель.

Якын дустым Фәһимәм, сиңа чын дуслыктан йөрәк сәламемне тапшырам. (Гадәттәгечә сәламнәр китә.) Берьюлы ике хатыңны алдым. И, күңелем булды да соң. Чын күңелдән рәхмәт.

Дустым, син рәхәт яшәсәң иде, бар теләгем шул.

Үзең, дустым, монда минем янга килә алмассың. Тик менә почтадан сорап кара, посылка алмыйлармы? Әгәр алсалар, саф арыш сохарие генә хәзерләп салсаң, әйбәт булыр иде. Хәзер арыш ипиеннән бик-бик тәмле тәм килә.

Үземнең хәлне башлыйк. Эшнең башы ашауда. Ашау – ач түгел. Ләкин бик-бик кысан. 700 гр. икмәк, ике аш. Норма норма инде ул. Кай көнне бик сыек та була. Ну шулай да бер өйрәнгәч бара. Чөнки башка җирдән көтәргә урын юк.

12 апрель, ял көне.

Бүген расписание буенча занятие булмый. Шәһәргә һич тә чыгармыйлар. Нәрәт алганым юк. Агитатор булып эшлим. Җавапны яхшы, отличнога бирәм.

Инде хәзер синең сорауга җавап бирәм. Якыным, йөкле калмавың әйбәт булган инде. Пока хәзерге момент өчен диюем. Күз алмабыз, күңел юаткычыбыз Диләрә бар әле күңел күтәрергә.

Аннан соң киләчәк турында сорагансың, дустым. Әйе бу хакта мин үзем дә бер хатымда бик чуалчык язган идем... Бер бик сагынган көнемдә. Халыкара хәл һәм хәрби сер турында сөйләшергә без бик яшь әле, дустым. Аны белү бик авыр. Дөресе, эшнең нәрсә белән бетәсен кем дә белми.

Шулай булса да, сугыш барышына караганда һәм дошманның элекке тарихына кайтып караганда да ул, элекке сугышта нинди чудесалар күрсәтеп, соңыннан тар-мар ителгән булса, аның бу сугышта да тар-мар ителәсен көтәргә тиешбез.

Шуннан чыгып, мин әле безнең дәвергә бик яхшы тормыш өмет итәм.

Карточкага төшеп булмады бугай инде. Чыгармыйлар. Ну дустым, көн ямьле дә, тормыш ямансу инде ул. Бергә түгелбез бит. Безнең белән монда кемнәр генә юк. Бер сүз русча белми торган авыл малайлары белән, институт бетереп, Мәскәү, Горький шәһәрләрендә 12шәр ел укыткан кешеләр, инженерлар бар. Менә аерма!»

* * *

«1942 ел, 30 сентябрь.

Сәлам хаты.

Якын дустым, тормыш юлдашым, акыллым, тормыш чәчәгем, кадерлем, сандугачым, иң-иң якыным. Сине бер генә минутка да исемнән чыгармыйм. Һәм сиңа – иң кадерлемә, исәнлек телим. Булган авырлыкларны җиңеп чыгуыңны телим. Авыр моментлар булганда, сагынып сөйләрлек тормыш сабагы итеп кичер. Илебез авырлыклар кичергәндә, миңа да бер авырлык кына сыя, дип кичер. Әнә шулай итсәң, тормыш сынаулары җиңелрәк уза. Әбиемә, кызыма күп сәламнәр.

Ике айдан бирле синнән хат алганым юк. Әле тиз арада гына хат ала алырмын дип тә ышана алмыйм. Чөнки тормыш кебек, моментка карап, адресы да бик тиз үзгәрә. Мин моңарчыга кадәр булган хәлемне белдереп тордым. Менә тагын бер хатымны иркенләп язам. Минем хәл белән таныш. Һәм бу хатны укыгач, үземне күреп сөйләшкән кебек булырсың.

15 сентябрьдә Коломна госпиталеннән терелеп чыктым. Тагын биш көнлек ял бирделәр. Аннан соң Москва янындагы Кратовка дачасында биш көн формировочный пунктта булып, аннан 43 боецны кабул иттем. Старший вагон булып, аларны фронтка пополнениегә алып килдем. Сәвиткә моның белән файдалы эш эшләдем. Хәзер кеше йөртү бик җаваплы, авыр.

Калинин шәһәрен уздык. Ржев шәһәренә поезд белән якынлаштык.

20-25 кеше генә калдык. Монда килгәч, рота взводларга бүленеп, мин отделение кабул иттем. Менә хәзер зур өйрәнү белән куркынычлы хәл көне-сәгате белән килеп җитте.

26 сентябрьдә иртәнге сәгать 3тә Ржев шәһәренә сул флангтан һөҗүм башладык. Шәһәр янындагы бер военный городокны чистарттык. Гомумән, алга наступать иттек. Нәрсә ул хәзерге техника белән сугыш – аның эчендә булдым. Чудеса икән.

27 көнне иртән 5 сәгатьләрдә ранен булдым. Снаряд кыйпылчыгы муен артыннан чигәгә тиеп китте. Ярам зур түгел. 20 көн лечение бирделәр».

* * *

«1942 ел, 7 октябрь.

Якын күргән дустым Фәһимәм. Барчагызга да миннән күп сәлам.

Дустым, синнән хат алганым булмагач, һәм үземдә дә яңалык булмагач, хатка язар әллә ни сүз юк. Шулай да минем һәр минуттагы исәнлегем синең

өчен сатып алгысыз кыйммәттер дип уйлыйм. Шуңа күрә үз хәлемне мөмкин кадәр ешрак белдертеп торырга телим. Яңа хәбәр шул, дустым – инде яраларым төзәлде. Гомумән, мин авырып, бер көн дә ятмадым. Менә бүген врач, яраң төзәлде, бүтән бәйләтергә килеп йөрмә, диде. Иртәгә частька кайтам. Аннан берсекөнгә тагы передовойга барам, дип өмет итеп торам. Шуның өчен пока өйдә әле дип, сиңа һәм этиләргә хат язам. Исәнлегемне белдерәм.

Тагын бер кат сәлам белән якының Гасыйм».

* * *

Хатлар бүтән булмады.

* * *

Хуш, бәхил бул, йөрәк парәм! Мин – тол, кызыбыз ятим калды. Ләкин без өч ай әле толлыкны, ятимлекне белмичә яшәдек. Һәр көн туган саен хат көттек. Мин үзем дә яза тордым. Җаваплар гына алмадым. Хәтта кара мөһерле җавапны да... Өмет белән яшәдем. Авылга кара мөһерле хатлар күп килмәгән иде бит әле. Бәлки, адреслар үзгәргәндер. Бәлки, почта поездына бомба тигәндер. Бәлки... Сугышлар тәмам кызган, ил язмышы хәл ителгән айлар иде бу.

Кара хәбәрле конвертны дускаем Рая миңа бик озак белдерми йөргән. Эш белән районга еш йөргәч, ул еш кына почтаны да ала кайта иде. Өстәвенә, бер кайтуында юлдаш белән кайтып керде. Отпускага кайтып килүче бер майор икән бу. Үзе безнең авылныкы. Ярты сәгатьлек чана юлында танышып, дуслашып, гашыйк булышып өлгергәннәр болар. Габделхак исемле озын буйлы, чибәр офицер Кызылъярдан өйләнеп китте. Кабат фронтка. Праганы азат иткәнче сугышты, ахирәтем бәхетенә, исән кайтты. Тыныч тормышта да дәрәҗәгә ирешеп яшәде. Дүрт кыз үстерделәр.

Рая дустым минем, ягъни ахирәтенең, фаҗигасен яшь кияве белән уртаклашкан. Бер ярдәмсез, авыр тормышта яшәгәнемне сөйләгән. «Хәбәрсез югалды» дигән кайгылы хәбәрне ирештерә алмавына уфтанганын әйткән.

«Син нәрсә инде, иркәм. Дустыңның тормыш хәле мөшкел күренә бит. Һәлак булган ире өчен аның кызына пенсия чыгарга тиеш. Яшермә хакыйкатьне! Батыр бул, иркәм! Илдә сугыш бара. Фәһимә – кайгысын батырларча күтәрә алырлык хатын. Тик менә «Хәбәрсез югалды...» дигән хат килгән иде» дисең бит әле син. Монысы бик үк әйбәт түгел әле аның. Мин уйлап карармын әле. Ачыкларга тырышырмын. Әлегә ул хәбәрне ирештерми тор».

Мәктәптә куеласы чыршы белән бер чанада кайтты миңа Гасыймымны югалту хәбәре. Яңа ел кичәсендә мин җырларга тиеш идем. Авыл халкы ул кичне яңа җыр ишетте. Ул җырны сугыштан соң гына чыкты, диделәр. Юк, мин аны Гасыймым һәлакәтен ишеткән көнне җырладым. Тол хатыннар йөрәгендә ул алданрак ялган иде инде.

Мин ул көнне чыннан да батыр идем. Нindидер аңлаешсыз батыр идем. Кара хәбәр мине ышандырмады. Күңелем нидер сизенә, нindидер серне миннән яшерәләр кебек тоела иде. Алай да халык алдына чыгып, кулъяулыгымны учыма йомарлап, җыр башлаганчы мин әле болай дидем:

– Ишеттем мин бер хәбәр, хак булса әгәр... – Аннары Зәкинур исемле гармунчы малайга ым кактым. Ул малайның да атасы ут эчендә йөри. Өздереп уйнап җибәрде.

Гөл чәчәкләрен өзәм мин,
Юлларыңа тезәм мин;
Бик сагындым, бәгърем,
Бик сагындым сине,
Әле дә ничек түзәм мин...[2]

Клубка җыелган халык ул көнне минем белән бергә елады. Гасыйм Зәкиевне бик яраталар иде шул. Ә мине кызганып елаганнардыр. 24 яшьтә тол калганнар, сөйгәненнән мәхрүм калганнар мине аңлар! Югалту, парыңны җую ачысы гомер буена бара икән ул.

Гасыймым миңа соңгы хатларының берсендә: «Син рәхәт яшә!» дигән васыятен әйтеп язган иде. Без икәү (икәү!) рәхәт яшәргә тиеш идек. Безнең хыяллар олы иде. Без зур, ямьле тормыш корып яшәүне ният иткән идек. Үзебезнең егәр, үзебезнең белем белән! Беркемнән дә терәү өмет итмичә, үзебез башкаларга терәк булып! Өйләр салып, балалар үстереп, җырлап, балкып – ил нуры булып яшәү иде ниятебез. Мин тол хатыннарның кара шәлен ябынырга тиеш түгел идем. Ике яшьтән атадан ятим калып, тырыша-тырыша якты көнгә күтәрелеп килә идем. Гасыймым белән бергә... Еллар үткәч, Хәсән Туфанның бер шигырен минем хакта икән бу дип, гел кабатлап йөрдем: «Кемгә тидек, кемне рәнҗеттек? Начар түгел ата-ананың начар түгел баласы идек...» Ил белән килде. Ил белән күтәрдек ул кайгыны. Кара кайгыны.

Кара дигәннән, Гасыймга барып ирешмәгән арыш сохарилары, үтәлмәгән нәзер сыман йөрәгемне өзә. Табынымнан арыш икмәген өзмәдем, Гасыйм төсе итеп. Арыш ипиен ярата ул дип, күчтәнәчкә дә һаман кыстырып килә торганнар иде балалар... Арыш ипиен нигә шулай яратканымны белдермәдем. Нигәдер, Гасыйм турында сүзләр сөйләү халәтенә җитә алмадым. Яратуым да, серем дә олы иде шул. Әйдә, үзем белән китсен!

Инде менә 95 яшемдә бакыйлыкка күчеп барам. Онытмадым! Сугышны башлаган илне кичермәдем! Оныгым мине алтын туй белән гаҗәпләндермәкче булган иде бит әле. Алтын, бриллиант туйларны Гасыйм белән бергә кичерә алган булыр идек. Быел менә 75 ел бергә без аның белән. Уйларымда бергә. Йөрәгем түрендә һаман ул гына. Гасыйм васыятен үтәп, сынауларга чыдап яшәдем. Балалар үстердем. Җәмгыятьнең лаеклы кешесе булдым. Ул өлгерә алмаган иде – мин югары белем алдым. Аны алыштырган солдатларым мине, Гасыйм кушканча, «рәхәт яшәтергә» тырыштылар. Алардан да риза-бәхилмен. Сагышлары, үкенечләре белән бергә дөнья миннән калып бара. Өчесе дә хәләл ирләрем булды. Кайсысы мине каршы алыр?

Хроника

Германия Европадагы союздашлары белән бергә СССРга һөҗүм итү өчен 191,5 дивизия туплап куйган иде. Дошманның хәрби көче 5,5 миллион кешедән тора иде. Аның тагын 4,3 мең танкы, 47,2

[2]Муса Җәлил шигыре, Заһид Хәбибуллин музыкасы.

мең штурмлау коралы һәм миномётлары, 5 мең хәрби самолёты, 192 корабле һөҗүмгә әзер тора иде. Германия яулап алган Европа илләренең индустриясе фашистлар өчен корал ясауга җайлашты, ризык һәм бүтән төрле продукция биреп торды. СССРдан куалап алып кителгән яшь көчләр фашистларга хезмәт итәргә мәҗбүр ителде. Германия Советлар Союзына каршы яшен тизлегендәге һөҗүм, ягъни блицкриг әзерләгән иде. Германия тагын унике Европа иленең хәрби индустриясен үз ягына аударды. Шушы куәтле көчкә каршы, хәрәкәттәге хәрби көчләр белән бер сафта булып, илебезнең хатын-кызлары, яшүсмерләре дә калкан сыман басты.

* * *

Сугышның зәмһәрир суыкларына уралган беренче кышын ярыйсы гына имин чыкканнан соң, дәррәү килгән язга сөенеп, алдагы кышның ни вәгъдә итәсеннән бихәбәр булганга күрә, авылның азмы-күпме егәре булган кемсәләре балта-көрәк сапларына, сука башына, дилбегә каешына ике куллап, чытырдатып тотынды. Мәдәт барында, авылда ирләр әле тәмам бетмәгән мәлдә, кем әйтмешли, сабанда сайрашып калырга кирәк. Терсәкне тешләп ыңгырашырга калмасын. Шаять, күктәге тургайлар да, талчыбыкта тирбәлгән сыерчыклар да китек күңелләргә дәрт өстәү ниятеннән сайрыйлар булыр. И, рәхмәт инде аларга – Ходайның канатлы илчеләренә. Мөгаен, алар туган якларына кайдадыр җирне төтенгә батырган сугышларны күрә-күрә очып кайтканнардыр. Шуңа күрә дә аеруча дәртләнеп, күңелләре булып сайрый торганнардыр. Шөкер әле, сез яшәгән илләр тыныч, биредә туплар шартламый, урманнар янмый дип әйтәселәре килә торгандыр.

Умартачы Сәхәү карт та бүрәнә умарталарының авызларын кояшка каратып борып куйган. Коръәндә зурланган җан ияләре язга кинәнсеннәр. Алар җыйнаган татлы нигъмәтнең дә кадере бермә-бер артмагае әле. Хастасы, яраланып кайтканы бар адәм балаларының... Бабайлары янында әбиләре дә бу борынгы кәсепне өйрәнеп, отып калу җаен карый. Дөньянықын белмәссең. Бабайларга чират җитә күрмәсен тагын. Өч улын сугышка озатып кайткан Мирзаһит бабай ишегалдындагы җил тегермәнен кабат җырлатып җибәрү хәстәре белән йөри.

Камилә абыстай оныгы Диләрәгә бәбәй сөенчесе итеп, Каразиректән үк ала килгән Ала казны Гашыйга киленнең ак канатлы ата казы сөекле хатыны итеп сайлады, күрәсең. Бик тә каңгылдашалар, елтыр алсу томшыкларын якын ук терәп серләшәләр. Өлкән каз сабыр икән. Читтән килгән Ала казга бер авыр каң да салып карамады. Тиздән Ык буе талларыннан Ильяс кода үреп куйган, эченә сары салам тутырган ояга Ала каз берәм-берәм озынча-йомры күкәйләр сала башлады. Кар сулары агып беткәндәрәк күкәй баса башламагае. Шаять, күкәйләр тәңкәле булырлар. Камилә абыстай белән Гашыйга килен (икесе дә Каразирекнеке булгач) шулай эндәшешеп киттеләр. Күңелле бит. Ата каз ике оя арасында чуарланып таптаныр, биер инде. Өлкән каз да җанына газиз ләбаса. Казларның әле берсе, әле икенчесе шатлык белән урамга тын алырга чыкканда җыйнаулашып сөенешәләр. Кешеләр дә шулай, бу дөньяда һәр туган сабыйга сөенеп яшәсеннәр иде дә ул. Шул чагында Гасыйм, Мөхлис, Назыйф, Садыршәһит кебек асыл

ирләр, сөлектәй егетләр сугышка китмәсләр, авылны көчәйтү, ишәйтү өчен беләк нығытырлар иде. Шул чагында бернинди алман иле дә муллыкта, сыйфатлы хезмәттә Татар иле белән ярыша алмас иде.

Камилә абыстайның тормыш тәҗрибәсе нык сыналган иде шул. Кешедән күчтәнәчкә кергән бәрәңгене тансыкка гына тотып, кыш чыкканга күрәме, буш яткан җирләрне караштырып йөри башлады. Аның бу кыланышын күргән Мәрвия хуҗабикә түзмәде: «Абыстай, мин тагын туганлашып беттек инде дип торам. Ул алагаем бәрәңге бакчасы быел үземә генә булмас әле дип, алдан ук сөенеп торам тагын. Игезәкләрне дә алып китәргә торалар бит әле менә монда. Уртакка утыртсак та, бакча иркен. Уңса да, уңмаса да, уртактан булыр. Орлык бәрәңгесен кызың табышыр әле. Сәвит Рая белән ахирәтләр ләбаса! Укмашып яшәргә кирәк булыр безгә. Крәчине дә, чырасы да, утыны да, яккан мунчасы да уртактан булыр әле аның. Янда ир-атлар булу белән генә беленми ул дөнья авырлыгы.

– Аны белмимени соң абыстаң? 36 яшемнән тол калып, төрлесен күрде инде башлар. Шуңа күрә, укытучының яртылаш чегән икәнен белә торып, бәрәңге утыртырдай буш урын эзлидер идем шул. Качып китсәң дә, чәчеп кит, ди торган иде безнең бабай. Әле тагын теге мәзәкне син дә белә торгансыңдыр: «Бер карчык белән кызы сөйләшәләр, ди: «Әнкәй, мин быел кияүгә китәрмен инде. Син дә картайдың – үләрсең. Борчак чәчеп тормыйк. Ашар кеше булмас аны», – диешәләр икән. Әби дә үлмәгән, кияү дә ишектән кермәгән. Ә менә ачлык бабай килгән.

Шулай, сугышны берничә рәт өстеннән үткәреп җибәргән, яше корал тотар заманнан узган бабайлар көрәк-балта саплаганда, әби-апалар кышка теш арасына кыстырыр нәрсәләрне алдан хәстәрләү әмәленә керештеләр. Анысы, ачлык барыбер якадан алыр, тик берәр елдан. Анысына да татар халкының ваемсызлыгы сәбәп булмас.

Ил гаме бит! Ил гаме!

Шушындый зур вазифаларга күмелгән килеш тә Фәһимәнең йөрәгенә кадалган арыш кылчыгы кебек, Гасыйм хәсрәте тора. Ул анда ипигә туймый инде анысы. Тик ул сораган арыш сохариларын ничек юнәтәсе. 24 кенә яшьлек тәҗрибәсез укытучының сүзен бик тыңлаучы бармы монда? Килер вакыт – абруе аягына уралып йөрер. Тик бүгенгесе менә. Өйсезлеге, акчасызлыгы, килмешәклеге... Бәлки әле, толлыгы дадыр.

Гасыймнан хатлар юк. Югалды якыным. Илебез, кайсы тарафка карасаң да, ут эчендә. Кайдагы ут эченнән: «Мин – исән!» – дип килеп чыгар икән ул? Фронтның эченнән кайткан берәр солдатны күреп сөйләшсәң икән ул? Бәлки, серләр ачылыр иде. Болай бит, йә бик куркытып сөйлиләр, йә: «Без җиңәрбез!» – дип, лозунг белән генә җавап бирәләр. Агитатор буларак, син күп беләсең дип сораштырган кешеләргә ул үзе дә шулайрак җавап бирә. Кайтучылар күренми әле. Ленинградтан килгәннәр әллә ни сер чишмәделәр. Күбесе якыннарын югалту хәсрәтеннән бик басылганнар иде.

***

1942 елның августы гына иде әле.

– Ахирәтем, типтәр очына бер яралы солдатны кайтарып киткәннәр. Сөйләшерлек түгел, ди, үзе. Баштанаяк бинтка уралган гипс курчак кебек

ята, ди. Йөгерек Шәйхулла малае ул. Иң олысы түгел. Икенчесе! Алардан дүрт егет киткән булган бит сугышка. Иң өлкәне Ленинград блокадасында, ди. Кечеләре синең укучыларың да булган бугай әле.

– Рая, бәгърем, барыйк әле шул солдат янына. Бәлки, авызы ачыладыр аның. Сөйләшә аладыр, диюем. Сугыш нинди була икән? Сораштырыр идек. Сөйләшмәсә, күреп кенә кайтыр идек. Аның хәлен без – колхоз активистлары, агитатор кешеләр бөтен кешедән алда белергә тиешбез. Кешеләр уйдырмалар уйлап чыгара башлаганчы. Без бит партиянең авылдагы чик сакчылары да. Уяулык булырга тиеш безнең тарафтан. Аларда тагын берничә малай үсә әле. Шәйхулла карт Армия өчен нык тырышкан. Олы малайларның әниләре үлгән булган бит инде. Үзләре кара матур, үзләре боек Мөхлис белән Шәйсолтанны, Раякаем, син дә укытып өлгердең әле. И-и, шулар да сугышта йөри диген хәзер. Артык буйчан түгелләр иде бит. Алай да яшьләре тулганчы ук алганнар икән. Бигрәк тә Мөхлисен. Ул бит 1925 елгы гына. Кыю малайлар иде, үзләре теләп киткәннәрдер алар! Үги аналары бик миһербанлы апа кебек күренгән иде. Теге солдатны кеше итә әле ул. Мин әйтте диярсең. Кулы шифалы Хәерҗиһанеттәйнең.

– Кызылъярга килгәнемә бер генә ел, бер гомер яшәгән кебек булдым. Сугышка, ут эченә китәм дип йөргән җирдән килеп эләктем бит мин бу авылга. Блокадникларны озата барырга кушканнар иде. Алай да ярты ел госпитальдә эшләп алдым. Сугышның үзен булмаса да, кайтавазын күрдем.

– Мин үзем дә Кызылъярда өченче елым гына. Ике елым бәхет дәрьясында йөзеп үтте. Бер хәсрәтсез кыз идем. Соңгы елда дөнья йөген тартып йөдәдем, өшәндем. Ләкин сынатырга хакым юк. Кешеләр бездән – укытучылардан таяныч эзли, ныклык үрнәге көтә. Рая дустым, үз йортың булу кирәк икән. Йорты-нигезе булмаган кешегә сан-дәрәҗә юк. Гасыймым гына исән йөреп кайтсын иде. Дүрт саны бөтен булмаса да, кабул итәм мин аны. Исән генә кайтсын. Ул миңа бер хатында: «Безнең нигез Якыйда. Әтиләргә кайтып тор!» – дип язган. Каенатам булган ул Зәки карттан әллә нигә шөллим мин. Малаемны алдың дип, усал итеп караган шикелле. Әнисе менә юаш. Кайтып тор, ди. Тик бит алар миннән дә ярлы торалар кебек тоелды миңа. Әнисе, киленен сыйламакчы булып, сыңар йомырка пешерде. Мин ашасам, Гасыймга юк. Тамагымнан үтмәде. Сугышлар беткәч, кулга акча керә башлагач, ярдәмләшербез, әлбәттә.

– Сердәшем, аны уйлама әле син. Иң мөһиме яратышасыз. Сугышлар бетсен. Барысы да җайланыр. Гасыйм исән кайтачак ул. Менә күр дә тор!

– Син бәхетле булырсың. Яхшы туганнарың бар. Очучы абыең гына да ни тора. Исән генә әйләнеп кайта күрсен. Мин алай-болай ялгыз кала күрсәм, сине ташламабыз дип, сүз бир, яме. Күңелем тыныч түгел. Ярый әле, әни бар. Ярый әле, кызыбыз бар.

– Ярый әле сезнең янга күчеп яши башладым! Эзләсәң, шатлыклар табыла ул.

– Мин дә сине бик бәхетле булырсың дип уйлыйм. Сиңа насыйп берәү ут эченнән сине эзләп кайтыр дип уйлыйм. Ә син ярата беләсең. Әлегә сине күрмәгән теге берәүне дә мәхәббәте яшәтер. Хыялы, якты өмете булган кеше тормышка чат ябыша ул. Ә менә Гасыйм соңгы хатында бәхилләшкән кебек тоелды. «Рәхәт яшәргә тырыш», – дигән. «Яшәрбез»,

– димәгән. Эчем поша... Ярый әле син янымда! Дустым, «Татар халкының татар сугышчыларына хаты» уңаеннан әңгәмәләр үткәреп аласы бар. Ашыгырга кирәк. «Правда» газетасында да, фронт газеталарында басылып чыккан икән инде. Мыштырдасак, иманыбызны укытырлар. Сабирова апаны беләсең... Гасыймнан хат килмәве дә җанымны өзгәли... Фронттагы хәлләрне ачыктан-ачык язмыйлар бит. Анда ниләр булып торадыр?

Икенче солдат

Хроника

Сугышның беренче көннәрендә үк хәрби көчләрнең 2 миллион 335 мең солдаты (сугышта югалтуларның 52,2 проценты) әсирлеккә эләкте. Армия корпуслары күпләп чолганышка төште. Чик буенда тупланган совет гаскәрләренең бик аз өлеше генә, чолганыштан чыгып, безнең гаскәрләргә кушыла алды. Исәннәрнең күбесе каты яралы иде. Чолганыштан чыга алу үзе үк каһарманлык иде.

Фронттагы хәлләрне һәр күзәнәге белән кичергән берәү араталары каерылган вагонның как идәнендә тирбәлә. Тирбәлгәне бишек түгел. Тик тирбәлә инде. Канына сеңгән тирбәлү бу. Инәе бәбәйдән вафат булганда, аңа унбер яшь иде. Шәйхразый тирбәтеп үстергән ике малай янында Мәрхәбә исемле сеңлесе дә бар иде әле. Бәләкәй сеңлесен бик кызгана торган иде ул. Сагына микән абыкаен? Бусы – инәенең үлеменә сәбәпче булганы – үзе дә яшәмәскә охшап тора. Үлмәсә тагын! Болай да малайның дөнья йөзе күргәне юк. Әтәе яңа хатын алып кайтып, яңа малайлар тумый торса, Шәйхразый да Ык буена төшәр, тал чыбыгы кисәр, матур-матур каз оялары ясар, аларны Күрткәү базарына илтеп сатып кайтыр. Акча җыяр. Аннары шул акчаны җыеп, читкә китәр. Еракка-еракка. Бәлли-бәлли-бәү, Габдулла! Нигә бу туганда ук үләсе мәгълүм сабыйларга Габдулла дип исем кушалар икән? Аның исеме – Шәйхразый. Әйбәт исем. Шәехләр аннан разый дигән сүз була торгандыр инде бу.

Шәйхразыйның үзен тирбәтәләр. Тик бик тә каты итеп. Кагын-сугын китереп. Бишегеннән чыгып оча бит инде. Кинәт төш өзелә:

– Воздух! Воздух! – дигән ачы тавыш өзә төшне. Сискәнеп уянган солдатның зиһене ачылып китә. Аны каядыр алып китеп баралар лабаса!

– Воздух! – дип, аның саен сөрән салалар. Немец телендә түгел бу оран. Димәк, Шәйхразый әсир төшмәгән. Төшерә алмаганнар! Әмма тәнен иләгәннәр. Иләүчеләре снаряд ярчыклары булырга тиеш. Как идәннең тактасы аркага сытылып керә. Астына җәелгән плащ-палатка манма кан. Аның каны. Үзенә калдымы икән соң? Үтереп баш чүмече сызлый. Анда да нәрсәдер кадала. Баш миен бораулап керә дә югалтмаска тырышкан аңны суырып ала. Солдат янәдән упкынга оча.

– Воздух!

Зәһәр тавыш аны тәмам өненә кайтара. Йоклап ятарга ярамый. Атып алырга кирәк ул тилгәнне! Төбәп килә бугай...

Һавадагы ямьсез гөрелдәү якынайганнан якыная бара. Кайда соң аның винтовкасы? Сугыш алдыннан гына гвардияче полк исеме бирелгән вакытта

алынган винтовкасы кайда? Солдат җан-фәрманга талпынып куя һәм шул мизгелдә янәдән упкынга оча.

– Воздух!

Состав туктап кала. Шыбырдашып, яралылар җиргә коела. Сикерә алганы сикерә, сикерә алмаганы тәгәри-тәгәри түбәнгә мәтәлә. Солдат янәдән талпынып карый. Вагон идәнендә ятып калырга ярамый. Я-ра-мый! Бомбалар иң беренче нәүбәттә вагоннарны мишень итә.

– Воздух! Тревога!

Юк! Бу тавышка айнымау мөмкин түгел. Аңсыз яту – үлем белән бер. Вагоннан төшеп, әрәмәгә качарга кирәк. Шәйхразый ятып калды. Аны кузгатырга ярамый. Кузгатырга омтылучы да булмады. Үз җанын саклаганда, кем аның плащ-палаткасына килеп ябышсын инде. Составны бомбага тоталар. Йә кала инде, йә юк! Үзен язмыш иркенә тапшыруы беренче мәртәбә генә түгел. Солдат зәп-зәңгәр күзләрен төпсез зәңгәрлеккә төбәде. Соң кабат күрүе булса, күзләре биек күкләр яктысын туя күреп калсын!

Гөрс-гөрс бомбаларын ташлап, үлем арбасы кайтыр юлга борылды кебек. Яралылар, санитарлар янәдән вагонга үрмәләде. Бер миһербанлысы ятып калган солдатны онытмаган. Үзләре сыенып, тән саклаган басу читендәге чүмәләдән бер күбә сары салам күтәреп менгән. Канлы плащ-палатка өстенә ипи исе килеп торган салам түшәделәр. Данлы украин икмәге буласы салам инде бу. Башаклы салам.

22 июнь таңында иген басулары сөтле башакларын җиләс җилдә тирбәлдереп кенә утыралар иде. Полк мәктәбен тәмамлап, Украина чигенә килеп баскан гвардия кече сержанты Шәйхразый Галиуллин офицер буласы тәңгәлгә санаулы көннәр генә калганына сөенеп, иртәнге постта тора иде.

Таң йокысы иң татлы чак. Иртәнге дүртләр булыр. Тиздән алмаш килер. Ил сакчысы уяу. Туган авылын, Ык буйларын сагынып, хозурланып торган мәле. Ык үзәнлегенә дә иртәнге томан әнә шундый әкияти ефәк пәрдә булып төшә. Үзе җылы, үзе йомшак була шул чагында һавалар. Егетләрнең сөйгән ярлары белән төне буе өянке ышыгында серләшкәннән соң кызлар озатып кайта торган сәгатьләр бит ул. Апалар-җиңгиләр абзар-курада сыерларын савып, малкайларын көтүгә куарга каударланып йөри торган вакыт. Томан серле дә, хәтәр дә була белә ул. Шулай бервакыт вербовка белән Карелиягә китәсе елны Чүмеч урамы кызын озатып кайтып, болдыр баскычы урынына салынган алагаем чуер ташка басам дип, аягын күтәргән генә иде, ташта йомылып утырган соры бүрене абайлап алды. Җәй көне бит инде. Бүрегә авылда ни калган? Шәйхразыйның кызлар озатып кайтып килгәнен көтеп утырмаса, ни калган авылда ул соры угрыга? Бүре кешенең дошманы шул ул. Дошманы булмаса, иң бәхетле мизгелләрендә каршыларына чыгып утырмас иде. Алабай баскыч астына шуышкан булган икән. Хуҗасы кайтып килүен сизеп алгач, ул да поскан җиреннән чыкты. Икәүләп куркыттылар Ык аръягыннан килгән юлбасарны. Юкка гына уянмады инде солдат күңелендә бу хатирә. Нindидер ым бар бу бүренең кинәт кенә исенә килеп төшүендә. Әллә йокы баса башлады инде? Чик сакчысына төнге соры күктән соры бүре балалары яуган кебек күренеп китте. Күзен киеребрәк караса, күршедәге аэродромга берәм-берәм бәләкләр ява түгелме соң?

Апалар Ыкта кер бәләкли торган ише... Ниткән бәләкләр? Бу гайре табигый күренеш авыл егетен сискәндереп җибәрде. Ул да булмады, колакка чикнең теге ягыннан савылып кына агылган матур музыка аһәңен ниндидер чыелдау бозып, аэродромнан ут көлтәләре күтәрелде. Ниндидер шом бар һавада, ниндидер хәтәр үрмәләгән кебек. Урманда печәнчеләрнең куышына елан шуышып керә башлаганын йокыдагы кеше искәрмәстән сизеп ала бит әле. Хәзер дә табигатьне шундый бер киеренкелек биләп алды. Курку түгел бу, сагаю. Адәм балаларының кан тамырына борын-борыннан сеңеп калган хәтәрдән саклану тойгысы.

Шәйхразыйның, тамак киереп: «Бүре бар!» – дип кычкырып җибәрәсе килде:

– Б-б-б... Боевая тревога!

Кошлар кебек тезелешеп йокыга талган хәрби очкычлар берәм-берәм көлгә әйләнә түгелме соң? Күз ачып йомганчы аларның гарнизоны авиациясез калды дигән сүз бит бу!

– Боевая тревога!

Мизгел эчендә гарнизон тревога белән кузгалды. Батальоннар, полклар дәррәү аякка басты.

– Чикне боздылар! Дошман басып керде!

– Под ружье!

Ул арада чик сызыгын барга да санамыйча, кара киемле, тимер каскалы ташкын – дошманның мотопехотасы үтә башлады. Алар тизлекләрен киметмичә генә Смоленск тарафына узалар иде.

Блиц-криг!

Германия коралллы көчләренең «Барбаросса» планы хәрәкәткә килде. Дошман киң фронт белән хыянәтчел һөҗүмгә күчте.

Шәйхразый Галиуллин чик буенда торган Көнбатыш фронт тимер ташкын юлында иде. Һөҗүмнең үзәктәге ук сызыгы аның йөрәге аша уза. Аның полкы, армиясе, фронты аша... Көнбатыш фронтның Карелия, Бессарабия операцияләрендә чирканчык алган тәҗрибәле солдатларына бирешергә ярамый иде бу сәгатьтә. Алар Бөек Ватан сугышының беренче ядрәләрен күкрәкләренә алдылар.

Яңа корал килгән генә иде әле. Яшьләрдә осталык җитеп бетми. Каушау да бар. Тик Шәйхразый югалып калырга тиеш түгел. Аңа ярамый. Яңа команда аны тиз куып җитте.

– Старшина Галиуллин (бер секундта старшина булып та куйды)! Ротаны кабул ит! Чигенәбез! Иң зур тизлектәге марш белән! Дошманның алдына чыгып, оборонага урнашырга!

Кисәрсең дошманның юлын алай ансат кына!

Аксыл томан пәрдәсе аларны куркып, каушап калудан саклаган икән. Чик сакчылары томан пәрдәсе артына яшеренеп, үрдән шуышып төшеп килүче фашист танкларын күрмәделәр. Күрмәүләре үзенә күрә бер бәхет булды. Тегеләр дә күрмәгәннәр, ахрысы. Марш белән чигенү юлына баскан солдатлар, томан таралгач кына, үзләренең могҗиза белән генә исән калганнарын аңладылар.

Бу юлы исән калганнар!

Иген басуы өсләтеп, сырлы юллар – танк эзләре сузылган иде. Танк

эзләре, биек сабаклы, сары чәчәкле көнбагыш кырын ярып үтеп, Смоленск тарафына китә торган юлга чыкканнар. Көнбагыш басуы артында зәңгәрләнеп, урман күренә. Һөҗүм итеп баручы дошман явының икенче ташкыны үр артыннан шуышып чыкканчы, шул урманга чумып өлгерергә иде бит.

Өлгерергә! Өлгерергә!

Аннары позициягә урнашу турында уйлый башласаң да була. Гел генә чигенмәсләр бит инде бер атна элек кенә гвардияче исеменә лаек булган чик сакчылары.

Сары чәчәкле көнбагыш басуында эзләп кара син сыену урыны! Өскә килгән яудан поскын табып кара! Әйе шул – өстән дә киләләр! Һичшиксез, киләчәкләр. Авиациясез калганны белгәч кыюландылар инде алар. Их, ачык авызлар. Очкычларны каз бәбкәләрен чүпләткән кебек чүпләттеләр тилгәннәрдән.

Томан таралганчы чумып өлгерәсе иде бит теге шәфкатьле урманга! Анда аларны тилгән тиз генә чүпли алмас иде.

Инде кояш та күтәрелеп килә. Биш сәгать буе марш-бросокта атлаган солдат йончыды, ачыкты, сусады. Кемдер сары чәчәк таҗларын суырып, сусынын баса, кемдер көнбагышның йомшак төшен чәйнәп ризыклана.

Һавада гөрелте көчәя. Дошман зурлаган боларның гарнизонын, мотопехотага өстәп, бомба төягән очкычларын да җибәргән. Юк бугай. Бер теземгә тезелгән «юнкерслар» кыеклап китеп баралар. Мөгаен, Днепр кичүен бомбага тотар өчен барышларыдыр. Мәскәүне яшен тизлегендә яулап алу өчен, һичшиксез, Днепрны кичәсе! Смоленск янында кыйналасылары да бар әле аларның. Их, шул дәһшәтле Сабантуйга кадәр киң далага таралышкан гаскәрләрне кабаттан чуен йодрыкка тупларга кирәген уйлыйлар микән генераллар!

Дошман белән безнең юл көнбагыш басуы өстендә үк кисешмәгәе әле! Менә хәзер үк – көнбагыш басуында ук сугышып алмагаек. Чөнки «юнкерс»ларның өчесе, теземнән аерылып, сары чәчәкләр арасында таралышып яткан чик сакчылары өстенә килә башлады. Күреп алганнар диген! Их, зениткалар булса?! Көнбагыш басуы уртасына зенитчылар каян килсен инде, җә?!

Бомба ташлап кына канәгатьләнмиләр, нәгълә т суккырлары. Аппетитлары әйбәт. Иртәнге ашка яшел погонлы яшьләрне чүпләп алмакчылар. Түбән үк төшеп, күзеңә карап, берәм-берәм чүкеп йөриләр.

Чүкетермен менә мин сезгә!

Шәйхразый, җиргә чалкан ятып, винтовка түтәсен тезенә терәде дә, «юнкерс»ның бензин багына төбәп атып җибәрде. Фашист очучысының күзләрендә шаян очкыннар уйный иде. Имеш, яле, яле, руссиш зольдатен! Мин – югары, син – түбән! Кем-кемне – бергә-бер! Сугышның беренче генә көне иде шул әле. Немец очучысы комарлы уенчы иде булса кирәк. Койрыгын каерып өскә менеп китү ягын сайламады.

Шаярма абзаң белән. Ачуымны китерсәң, рогатка белән дә тишәм мин синең бензин багыңны. Керосин түгел, бензин ягалар болар. Бензин ул гөлтләп кабынып китә. Булды бу! Беренчесе кадалды. Теге икесе дә өйләренә кайтып китә алмады. Килгән якларына таба борылганнар иде инде югыйсә.

Бара-бара янтайдылар. Алары да шушы көнбагыш басуына кадалдылар. Теге – көләч ыржайган очучы өчен сюрприз булды инде бу. Гомерендәге соңгы сюрприз! Шушы дуэль чигенеп баручы солдатларның рухын күтәреп җибәрде. Болар да әллә кем түгел икән ләбаса. Сугышабыз әле, боерган булса!

– Окружили! – Монысы өр-яңа команда. Командирлар табылган! – С боями выйти из окружения!

Тәүлегенә туксанышар чакрым чигенә-чигенә җитезләнеп бетәчәк солдатлар бу чолганышны ерып чыктылар. Тик барысы да түгел. Яралыларны санаучы да, җыючы да, бәйләүче дә юк.

Нindidер карусель бу: «Окружили!» «Выйти из окружения!»

* * *

Яралы солдат әле аңына килеп, әле аңын җуеп, сугышның беренче аенда сугышып узган көннәр исәбен яралар саны белән ялгарга, чагыштырырга тырышып азаплана. 1941 елның 22 июненнән алып, 1942 елның уртасына тиклем күкрәккә дә, баш чүмеченә дә тигән кыйпылчыклар, ядрәләр, сугышлар санының исәбе бутала. Хәтер төпкеленнән әле бер орыш, әле икенчесе күтәрелеп чыга. Контузияне канлы җәрәхәт басып китә. Кайсы көн, кайсы сугыш, кайсы кичү, кайсы лазарет? Шәйхразыйның контузияле башында арифметика гамәлләре бутала. Сугышларның урыннары алышына. Тик, барыбер, сумма бер үк чыга – ул каты яралы, аны каядыр илтәләр.

Карусель! Җәһәннәм каруселе...

Уенчык карусель күреп үсмәгән малай, солдат булгач, сугыш каруселенең уртасында мәтәлчек ата. Исән чыгарга иде бит! Илгә исән кайтырга. Илгә кайтып барадыр бит инде?! Өйләнергә! Балалар үстерер...

Тагын чоңгыл йотты.

Фашистлар төнгә сугышны туктаталар – ял итәләр. Җәйге якты төндә дозорга чыккан ай гына кыр-дала буйлап сибелгән солдатларны барлап йөри. Монысы нindidер «томанлы» кинодан бугай. Аз калганнар. Байтагы мәңгегә җылы җирне кочаклап ятып калган. Яшь кенә гомерләр. Аналары, сөйгән ярлары көтәдер инде. «Хәбәрсез югалды» дип, гомер буе көтүчеләр дә булыр. Югыйсә хәбәрсез югалырга тиеш түгелләр иде алар. Бик тә аяусыз сугыштылар чик буен сакларга баскан яшь солдатлар. Аларны еллар үткәч, орден-медальләр эзләп йөрмәс инде. Чигенгән солдатка нинди медаль инде аңа? Югыйсә аларга дошманга әсир төшмәгән өчен генә дә орден тиеш иде. Илгә яңа малайлар тудыру өчен кирәкле нәсел орлыгын исән алып кайтып җиткерә алган өчен генә дә тиеш иде. Кайтып җитә алсалар...

Һич югы медаль!

Яралы айнып китте. Кая алып бара икән аны составның бусы? Инде ничәнчесе... Шушы вагоннан төшмичә генә авылга ук кайтып җитсәң иде ул! Җиңелгән солдат булыпмы? Һич юк! Сугыша әле ул! Германны инде бер җиңеп кайткан Шәйхулла солдат улы лабаса ул! Әллә инде сугыш тәмам булды микән? Алай дисәң, нигә һаман, «Воздух!» дип сөрән салалар. Тилгән килгән өчен генә түгелдер бит инде... Әй, йокласын әле...

...Теге ерактан ымсындырып торган урман авызына җиттеләр. Немец урман эченә кермәскә тиеш. Старшина үз ротасыннан исән калган, ротадан гынамы, полктан калган бер уч солдат белән үзебезнекеләргә

кушылу өчен урман ерып бара. Арыган, яралы солдатларны берәр ышык урынга урнаштыра да үзе, компасын тотып, дөрес юнәлеш эзләп китә. Алай-болай әсир төшү ихтималы була калса дип, погоннарын йолкып алды, партбилетын эчкәрәк яшереп куйды. Җәнлек адымнары белән бара торгач, аланда учак тирәли утырган кешеләрне күреп сөенеп китте. Кемнәр икән болар? Урманчылармы, эвакуациягә барырга чыккан берәр оешма кешеләреме? Әллә үзләре ише адашып-буталып йөрүчеләрме?

Ашамаганнарына атна бардыр инде. Учак тирәсендәгеләр бик шаулашып сөйләшәләр. Немецчә! Каһәр икән. Алар да сак куйганнар.

Абайладылар!

Бу хәлдә ни эшләп була? Бары бер генә чара: билдәге гранатаның чекасын яшен тизлегендә тартып алып, гранатаны учак уртасына ыргыту!

Аланны утлы күмер очкыннары белән үкерү авазлары күмде. Кошлар тынып калды. Старшина үзенекеләрне калдырган урынны бик тиз тапты.

– Ычкындык. Бик тиз!

Шартлау тавышын ишеткән булганнар инде. Сорау биреп торучы булмады. Тагын урман аша марш-бросок. Бәхетләренә, бер капчык шикәр комы табып алдылар. Ниткән трофей булгандыр инде: тыл тарафына китеп баручыларныкымы, белмәссең. Суга болгатып, ун көн җан асрарга җитте бу табылдык сый. Төп гаскәрләргә килеп кушылганчы тамаклары киселмәде. Ә аңынчы әле Днепрны кичәсе бар иде.

Бессарабиягә поход вакытында зур-зур елгалар кичелде. Тәҗрибә бар. Шуңа күрә старшина Галиуллин солдатларына зур елганы йөзеп чыкканда, ниләр эшләсен, елга кичү алымнарын бераз төшендерергә тырышты. Әмма Днепрны кичү сират күперен кичүгә бәрабәр булыр дип уйламаган иде.

Алай да кичкәннәр икән. Без – балаларына ул кичүдәге бер генә җөмләне алып кайткан: «Днепрның суы кып-кызыл булып акты...»

Хатирә

Контурлы карта буяп мавыккан ул-кызлары янына килеп утырып, кызыл елга булып аккан Днепрны кичү хәлләрен сөйләгәндә, ник әтидән сугышта күргәннәрен тагын-тагын да сөйләтә белмәдек икән? Гомеренең бик кыска буласы башыбызга да килмәгән шул. Бик сирәк кенә, әле бер эпизодны, әле икенчесен сөйләп куя иде. Анда да саран җөмләләр белән генә: «Бервакыт бричкага төялеп, чолганыш чылбырын өзеп барганда, атыбыз дошман пулемётына килеп бәрелде. Күзе чәчрәп чыкты малкайның». «Авыр яралылар яу кырында: атып китегез безне дип тилмерешеп ялвара торганнар иде». Калдырмый идек. Менә бит мине дә калдырмаганнар. Бар курыкканым әсир төшү иде. Төшмәдем бит! Өйгә дә кайтып җитә алдым. Минем полкташлар инде егерме ел җир куенында ята».

Хатирәләр аз. Әгәр тагын ике генә ел яшәсә дә, Җиңүче солдат данын татып каласы иде дә бит... Насыйп булмады! 1963 елны ук, 47 яшендә бакыйлыкка күчте. Юбилей медальләре өләшүләр 1965 елдан – Бөек Җиңүнең 20 еллыгын бәйрәм иткәндә генә башланды. Батырларның да исемнәре кайта башлады...

***

Әйе. Старшина Галиуллинның бар курыкканы – әсир төшү иде. Төшмәгән икән.

Тагын баш чоңгылга чумды. Тагын бер бомбёжканы үткәреп җибәреп, аны тагын бер тапкыр вагонда ялгызын калдырып, кабат төялешеп, кузгалып киттеләр. Инде тагын сабый кебек бишектә тирбәлә. Сабыйлык рәхәтен татыдымыни соң ул? Бүгенгә калган икән. Бу көнгә кадәр аны ана догасы коткарадыр дип уйлар иде, анадан да яшьли ятим калды. Инәенә дигән назны бишекләр үргәндә, матур бизәкләр итеп төшерде. Ык таллары бик күндәм ул бишек үрер өчен. Үз балалары өчен бишекләр үрү язган микән аңа? Алар – дүрт малай, һөнәрле булып үстеләр. Инде абыйсы Шәрифулла күптән офицер, Шәйхразый да хәрби кеше булырга кызыкты. Бу сугыш ике энесенә дә эләкмәгәе әле. Фашист ажгырып килә. Җиңүен дә җиңәрбез. Корбаннар күп булыр. Анысы, Татар илендә батыр малайлар тагын да туар. Алар өендә дә үги ана ике малай табып куйды лабаса. Алар сабый әле. Сугыш алар өлешенә калмас.

Зиһене дөресләнә түгелме соң? Инде тән ярасын түгел, ил хәсрәтен кайгырта. Бу бик әйбәт фал.

Аталары Шәйхулла – атаклы балта остасы. Йөгерек дигән даны да бар. Менә шушы ике сыйфат аны чолганышлардан һаман саен исән-сау алып чыгып барадыр да. Ә теге санитар егетләрне кая куясың? Ташлап калдырмаганнар бит. Югыйсә: «Үзегезне саклагыз. Минем ярам эчемдә, терелмәм. Атып кына китегез. Дошманга әсир итеп калдырмагыз!» – дип, ул да инәлгән иде. Ташламаганнар. Үзләре исәннәр микән? Погоннарны яшереп, дөрес эшләде. Яу кырында ни булмас! Фашист погондагы йолдызларга төбәп ата. Ихтимал баш чүмеченә ядрә кадалгандыр. Арыган ядрә! Йолдыз чүкеп алам дип ашыккан ядрә! Баш миенә кереп урнашырга хәле калмаганы. Их! Бу чигенгәндә кадалган – ни эчкә кереп китмәгән, ни тартып алып булмый торган ядрә белән ничек яшәрсең, оятын кая куярсың? Сугыш эчендә йөрмәгән кеше беләмени ул? И җүләр, шулай исән калып, авылыңа кайтып җит әле син!

Тагын чоңгылга чумды. Их, Ык суының чоңгылы булсын иде ул! Рәхәтләнеп, колкынганчы көмеш суын эчәр иде. Ыкның мул сулы, ташыган вакытыдыр хәзер. Ык талларына көмеш маймычлар сарылгандыр. Гомеренең бер елын сугыш урлады булып чыгамыни соң? Санитар егет: «Хәзер 1942 елның җәе бетеп бара, – диде. – Солдат, сине бу вагоннар ил гиздереп күп йөртте инде. Хәзер менә Кировобад госпиталеннән чыктың. Алга таба – Идел буена. Тимер юл кичүе ябылу куркынычы бар. Фашист Сталинградка үрмәли. Менә бу санитар поездын исән-сау гына Иделнең аръягына чыгарып өлгерәбезме инде, юкмы? Әллә нинди урау юллар белән айдан артык кайтабыз да кайтабыз. Мондагылар барыгыз да Идел буе мәҗрухлары. Бәхетең, сине өеңә кадәр озатырга дигән фәрман бар. Ташламам. Тик син дә мине ташлама. Кайтып җитәбез дигәндә генә үлеп китә күрмә. Хатының көтәме, балаларың бармы?»

Әллә шатлыктан, әллә йончудан Шәйхразый кабат аңын җуйды. Әмма санитарның соравына берни дә уйламастан: «Хатыным көтә, балаларым бар», – дип әйтеп өлгерде. Гаҗәбенә ниләр диярсең? Хәер, ил тулы тол

хатыннар, ятим балалар. Алар янына тагын бер әти кайтып килә икән, аннан кемгә зыян? Юлда үлеп калмаса...

Укыйсы килгән иде Шәйхразыйның. Авылдагы җидееллык мәктәптән соң Баулы мәктәбенә барган иде. 8 нче сыйныфтан соң, 16 яшендә вербовка белән Карелиягә китте. Агач эшен яратканга күрә китте. Сугышка якташлары белән алынган булыр иде. Бәлки әле, чик буена – немец коралы белән шыплап тулган җиргә эләкмәгән дә булыр иде.

...Ә теге хәерсез ядрә! Смоленск өчен барган аяусыз сугышларның нәгъләт төшкән ядкаре ул!

Хроника

Смоленск янындагы сугыш алдыннан көчләр әле һаман да фашистлар файдасына иде. Бу юнәлештә дошман юлында Көнбатыш фронт гаскәрләре торды. Дошман исә Смоленск өчен сугышны хәлиткеч бәрелеш буларак бәяләп, «Үзәк» төркеменә кергән армияләрен куйган, 16 нчы армиянең бер өлешен китергән иде. Дошманның беренче һөҗүмендә 29 дивизиясе сугышка кертелде. Шул исәптән 9 танк дивизиясе һәм 7 мотопехота дивизиясе катнашты. Икенче эшелонда һөҗүм итү өчен дошман тагын 34 дивизия китертте. Дошманның кешеләр составы да ике тапкырга, самолётлар саны дүрт тапкырга, минамётлар саны 2,4 тапкырга күбрәк булып, безнең якта танклар гына артыграк иде. Сугыш әле бер якның, әле икенче якның өстен чыгуы белән чиратлашып барды. Әмма дошман, яу кырында 130 танкын, 100 автомашинасын, күпсанлы корал складларын калдырып, чигенергә мәҗбүр булды. Смоленск бәрелешендә Мәскәү саклап калынды. Маршаллар бу сугышка бер сүз белән йомгак ясап: «Смоленск янында җиңүне совет солдатларының чиксез батырлыгы, фидакарьлеге, сугышчан осталыгы, кыюлыгы тәэмин итте, – дип бәяләделәр. – Гади солдат дошманның Мәскәүгә юлын күкрәге белән каплады».

Шәйхразый Галиуллин шул сугыштан кайтып килә.

* * *

– Илаһым!

Арата капканы киереп ачып, кабык колашага салынган мәет алып кереп килүләрен күреп алган Бәләкәй әбкәй, авызын алъяпкыч итәге белән каплап, шундый гына өн чыгара алды. Колашада кем ятканын белми иде әле ул. Шәйхулла оста нигезеннән дүрт солдат сугышка киткән иде. Бу кайсысы икән? Алдан хәбәр-мазар килмәде.

– Илаһым!

Аталары да өйдә юк чак бит әле. Кулдашы белән такта ярырга киткәннәр иде. Мокшы авылына. Бүген-иртәгә генә кайтмас. Чуваш, мокшы авылларында ипи бар. Сугышка хәтле башлап куйган бураларын түбә астына кертеп калдырырга йөрәге җиткән хуҗалар шулай Шәйхулла останы килеп алгалыйлар. Тирә-юнь авылларда ул салган өйләрнең чуты юк инде. Үзенеке генә менә. Ни сәмән юк, ни бүрәнәнең икенче башыннан тотарлык кул юк. Улларының кавырсыны ныгыган берен сәвит үз хезмәтенә ала

бара. Менә яшь хатыны тагын өч малай табып, тезеп куйды. Шулар сугыш күрми үсеп, Шәйхулла картка терәк булырга язсын иде дә бит. Карты бу вак малайларны бүгеннән үк Алтын Баганаларым дип йөртә. Ни язганын белмәссең. Әле үзе капкасын ачып, бәла кергәнен белми. Бәла дигәнең шатлык-сөенечкә әйләнсен иде ул, бер могҗиза булып.

– Илаһым!

Ниһаять, Хәерҗиһанеттәй мышкылдап елап җибәрде. Эче тулы миһербан булган бу әбекәй үз кайгысыннан гына түгел, кеше шатлыгыннан да елап җибәрә торган нечкә күңелле бер фәрештә мисалындагы кеше иде.

– Илаһым! Тере зат ята бит бу кабыкта! – Бәләкәй әбекәйнең яшьле күзләре ак бинтка уралган гәүдәнең баш очына иелеп карауга, аның соры күзләре зәп-зәңгәр күзләр белән очрашты. – Шәйхразый улым! Синең күзләрең бит бу! Шәрифулланың күзләре – кара. Мөхлисулланыкы – шәмәхә, Шәйсолтанныкы – яшел. Балакаем, нишләттеләр сине? Нигә болай итеп кайтардылар? Лаеклы булып чыгып киткән идең бит өйдән!

– Апа! Вашего сына мы долго везли домой. Он сильно ранен. Ещё не скоро поправится. Если поправится... Получайте. Вот его вещи. Котелок... ложка. Больше ничего и нет. Не обессудьте. Война идёт. Ему ещё повезло. Многие лежать остались, многих не довезли.

– Рәхмәт, улым! Чәем дә юк, ичмасам.

– Чай говорите, бабушка. Неплохо бы. Но мы торопимся. Колодезной воды найдется?

Бәләкәй әбкәй белән санитарлар шулай аңлаштылар.

Китәр алдыннан солдатны сәкегә кертеп салырга башлары җитте тагын.

– Эй, живут же люди. Как этот солдат выздровеет в такой убогости?

Бәләкәй әбкәй аларның бөтен сүзен аңлады. Карты гел халык арасында йөргәч, төрле милләт сүзен өйгә ияртеп кайта торган иде. Үзеннән шактый яшь, ушлы карчыгы сүзләрнең берсен дә әрәм итми, зиһененә җыя бара.

– Терелтмәм мин сезгә! – дип, йодрыгын күрсәтеп калды ул бер гаепсез санитарлар артыннан. Шифалы куллы Хәерҗиһан, диләр аны. Дөрес, нимеч кыйнап кайтарган мәҗрухларны имләгәне булмады моңарчы. Барыбер табар чарасын, юнәтер дәвасын, сыйпар, сылар, өшкерер, дарулар, әмма улын үлемгә бирмәс. Ятимнәрне иркәләргә вакыты булмаса да, какмый-сукмый үстерде бит ул аларны.

Биш ятим өстенә килеп, Кызылъяр халкын шаккатырган иде ул унбиш ел элек. Шәйхулланың үзенә кызыгып килде. Элек гашыйк булып дип сөйләү юк иде бит. Йә кызганып, йә кызыгып. Бәбәйдән хатыны үлгән кара түбәтәйле, ап-ак түгәрәк сакаллы матур бабайны чыбылдык «күзеннән» генә күзләп өлгерде дә шундук ризалыгын бирде: «Чыгам!»

Бер атнадан авылга бу олы сугышның беренче яралысын кайтарганны ишеткән халык хәл белергә килә башлады. Инде Шәйхулла оста такта ярып йөргән җиреннән кайткан, улының хәлен күргән. Өйалдына – ышык, тын почмакка сәке әмәлләп куйган иде. Чебен борчымасын өчен сәке тирәли чебен куначасы дигән үлән тезелгән, өйалды почмакларына әрем себеркеләр куелган иде. Шулардан ниндидер тәмле ис тарала. Әрем тәме – туган ил тәме. Ачы, әмма татлы! Шәйхразый үзен шулай кайгыртуларына сөенеп, бер рәхәтлек кичереп ята.

Аның хәлен белергә килгән һәр кеше иң әүвәле сугышта йөргән үз иренең, баласының язмышын уйлап сыктап ала. Сораштырып карый. Әмма солдатның хәле әкият сатарлык түгеллеген күреп чыгып китә дә иртәгәсен, аны тизрәк терелтү өчен дигән булып, берәр чебешен чалып китерә. Хәерҗиһанеттәй ул чебештән башларың әйләнеп китәрлек хуш исле шулпа пешерә. Мәрхәбә сеңлесе абыйсының авызына чәйнек борыныннан гына шифалы шулпаны агыза. Дәвалау үз җае белән генә бара. Бригадир Әнисә Бәләкәй әбине уракка чыгудан бушатып торды. Яшь баласы өстенә, яралы солдаты бар. Авылдашлар сүз әйтмәс.

Уракчылар янына барыр алдыннан Фәһимә, Рая, яңа килгән укытучы Роза солдат күрергә килделәр. Розаның ут эчендә йөргән кешесе юк. Шуңа күрә ул аеруча сүзчән. Аңа сугышның үзе кызык. Нindirәк театр икән ул сугыш дигәннәре? Әле бит моңынчы аннан кайтып күренгән кеше юк иде. Абау! Куркыныч икән. Уенда бер тәвәккәл хыял йөртә иде. Комсомолка Гөлсара кебек, җырларда җырланырдай яу кызы булып, әллә бер йөреп кайтырга микән дигәнрәк уй иде ул. Яралы солдатның хәлен күргәч, ул уеннан бик тиз сүрелде. Комсомол аппаратында эшләргә ризалыгын белешкәннәр иде, бик тиз ризалашты. Дөрес эшләде. Аның чәчәк кебек гүзәллеге яу кыры өчен түгел иде. Гомумән, сугыш хатын-кыз гайрәт чәчә торган урын түгел. Коръәндә дә хатыннар сугышып йөрсен диелмәгән.

Рая да әле тыныч. Аңа кияү буласы егет әле кайтып күренмәгән. Ә менә Фәһимәнең эче тулы ут. Ни хәлдә йөри икән аның Гасыймы? Өммия әбидән фал китабы ачтырып караргае, белеп әйтәме икән. Әбигә барып йөргәнен ишетсә, Сабирова эштән кумас микән? Дөнья явызы шул хатын. Кайгы күргәне юк, шуңа күрә аяусыз. Ул да күрер әле. Ятимнәрнең яше төшә ул. Атадан ике яшьтә калган Фәһимә рәнҗешенең бик тиз төшә икәнен үзе дә абайлаган иде инде. Кешегә генә сиздерми...

Кызлар солдат янында бераз утырдылар да: «Эштән бушаган арада тагын килербез. Ә син терелә тор. Без аннары сине уракчылар станына алып барырбыз. Сугышны үз күзләре белән күреп кайткан кешенең мисалы бик кирәк. Без дошман белән шулай да көрәшәбез», – дип китеп бардылар. Шәйхразыйга үзләре белән алып килгән газеталарын калдырып киттеләр. Радио ноктасы авылда берәү генә – идарә каршында гына иде. Ә яралы солдатның фронт хәлләрен бик тә нык беләсе килә. Дошман Сталинградка үтә алды микән? Шул борчый аны. Сталинград менә генә бит инде ул. Идел буенда гына. Аны алып кайткан состав, итәгенә ут капкандай диярлек, ут-төтен ерып кайтты. Казан янындагы тимер юл күперенә дә бер бомба ташлап киткәннәр икән дип сөйләнделәр кызлар. Горький шәһәрен бомбага тоталар икән, диделәр. Анысы да ерак түгел бит инде аның. Агитатор булгач, алар беләдер инде. Тизрәк аякка басарга, эшкә ярый башларга иде бит. Сакалын сәлперәйткән атаң сыртын кимереп ятар чакмы соң?! Өй тулы вак бала-чага.

Шомырт мае салынган көмешкә, зәңгәр балчык, солидол, чыршын мае яшь тәндәге яраларны әкренләп ялмап барды. Ютәл дигәне генә һаман интектерә. Днепрны кичкәндә, тәнгә үткән суык галәмәтеме, окоплар салкынымы, яраларның үпкәгә үк юл ярып керүеме – нәрсәдер ютәлләтә. Айга якын лазарет-госпитальләрдә аунаудан гына түгелдер инде. Карелиядә

урман төягәндә, полк мәктәбендә сугыш уеннары уйнаганда, тәмам чыбыркы сыман үрелеп беткән мускуллар шәлперәйгән. Шәйхразый үзенең саусызлыгын бик авыр кичерә.

Салкынайткач, урын-җирен мич башына күчергәннәр иде. Шуннан карап ятты. Атасы намазында сәҗдәгә киткән чакларында, намазлыгына ятып елый икән. Бер күрде, ике күрде. Аннары әтәен янына дәшеп китерде:

– Әтәй, син үзең дә герман белән сугышкан кеше. Сугыш хәлен беләсең. Бусы бигрәкләр дә әшәке сугыш. Түзик инде. Тереләм әле мин.

– И улым, – диде Шәйхулла абзый, – ул чагында мин үзем генә йөрдем сугышта. Хәзер бит минем дүрт улым утка кереп китте. Мин сезнең һәркайсыгыз белән сугыш эчендә йөрим. Анагызның бәхете булды. Үлеп котылды. Мин көн дә иртәгә ни хәбәр килер икән дип, урынга ятам.

– Бүгенге елавыңның сәбәбе минме?

– Түгел, улым, Шәйсолтаным хәбәрсез югалды. Ваянкаматка чакырып әйттеләр. «Дезертир түгелме икән ул?» – диләр. Шундый җирдә дә ахмак кешеләр утырыр икән. Галиулла нәселендә гомергә куркаклар булмады. Мөхлисулла да бит хатында: «Мин лазаретка кергәнмен, шул көнне Шәйсолтан чыгып киткән. Ярты сәгать арада күрешә алмый калганбыз», – дип язган иде. Шул бала, яралар ала-ала сугышкан бала, дезертир була микәнни? Кем әйтер икән моның чынын, дөресен? Ичмасам, син дә аякланып йөри алмыйсың. Барыр идең ваянкаматына, сораштырыр идең. Сугышта ятып калганнарга акча чыга, диләр бит. Әллә шуны бирмәс өчен генә мине мәсхәрә итүләре микән? Йа Раббым! Бер өйдән дүрт солдат озаткан атага сәвитнең бер җылы сүзе юк. Хатәбе, синең сөягең кайтты. Анысына да шөкер итәм бит әле. Инәңә рәхмәт. Яшь баласыннан артык күреп карый сине. Күршеләргә рәхмәт. Сугышта йөргәннәрнең аналары, хатыннары тәрбияләшә бит сине. Бөтен сый алардан килә. Яралы солдатлар кайткалый башлады. Кара хатлар да ешлады. Авылдан өч йөзләп кеше киткән иде, диләр. Ничәсе исән әйләнеп кайтыр менә? Исән дигәне дә бөтен түгел бит аның. Улым, сүзләремне авырга алма. Синең җылы тыныңны ишеткәнемә дә сөенеп ятам.

Күзгә кергәч, канлы бавыр шулпасы Шәйхразыйның авызына көн дә керә башлады. Укшый-укшый эчте – терeләсе килә бит. Бигрәк тә хәл белергә кызлар килеп киткәннән соң көчәеп китә ул терeләсе килү теләге. Арада иң чибәре – Фәһимә. Аның ире Сталинград янында сугыша икән. Бер яшь чамалы кечкенә кызы бар икән. Рая белән Роза әле кияүдә түгелләр икән. Әмма Шәйхразый төннәрен сызланып ятканда, Фәһимәне аерып уйлый. Бигрәк моңлы, сагышлы күренә. Ирен сагына торгандыр инде.

Үзе дә инде бигрәк... Шәйхразыйның хәле кызлар уйларлыкмыни соң? Менә яралары төзәлгәч, чын егеткә әйләнер әле. Кызларның хәлен белергә дә баргалар. Бәлки, ир-ат ярдәме кирәккән чаклары буладыр. Раясы – шәһәр кызы. Авыл тормышының рәтен дә белми торгандыр.

Начар малай түгел иде лә ул. Сугышта чыныккан, полк мәктәбен тәмамлаган, гвардияче старшина! Сугыш башланып китмәгән булса, Армия сафларында хезмәткә калып, абыйсы кебек офицер буласы иде.

Әтәй елый. Ул әле олы улының хәленнән хәбәрдар түгел. Абый, абый! Ул да җәһәннәмгә эләккән икән ләбаса – Ленинград блокадасында – ачлыкта,

чолганышта көрәшә! Күрешүләр язгандырмы-юкмы?.. Мөхлисулла белән Шәйсолтаннан ишетелгән хәбәрләр канга тоз сала торган. Шәйсолтаны алай. Ә соң малай гына килеш сугышка алынган Мөхлисулла ут эчендә нишләп йөри икән? Яшь малайларны баштагы мәлдә курсларда өйрәтеп алырга тиешләр ләбаса. Күрәсең, дошман бик куыра! Нинди нык холыклы ата йөрәге сызлана. Шәйхулла картның гына түгел, Шәйхразыйның да өйалды почмагында аның котелогы янында һич югы тагын ике котелок тәгәрәп яткан көннәрне күрәсе килә. Хәер, котелок гел эштә. Еш кына бөрлегәнгә барып кайта. Солдат флягасын вак малайлар яратты. Үгәй инәйгә кадәр ничекләр ут йота! Мәрхәбә сеңелнең яшьрәк булуы әйбәт әле. Окоп казырга җыялар тазарак кызларны.

***

– Сугышка дүрт егет биргән, үзе балта тоткан, колхоз төзешеп йөргән Шәйхулла абзый йортын күрдегезме, кызлар! Йорт димәсәң, хәтере калыр, алачыкның алачыгы! Өй эченә кермәдек әле. Ишек ачылганда күрдем – ике терәүле.

Роза кыю шул. Уендагысын әйтте дә салды. Кыю булмаска, аның әнкәсенең абзасы генерал Булатов шул. Шуңа күрә үзен батыр тота. Яклаучысы бар.

Фәһимәнең менә инде булды дигән яклаучысы да әллә исән, әллә юк. Хатлары килми башлады. Яшь хатынның эче тулы ялкын. Әллә аның нарасыен да, үзе кебек, ятимлек язмышы көтә микән? Авыр синең хәлең, Фәһимә! Кызылъяр туган авылың түгел. Яклап, сүз катар кешең юк. Иң мөһиме – үземнеке дияр ояң юк! Розаның өй турындагы мыскыллы сүзләре яшь хатынның тәмам кәефен җибәрде. Балта остасының өе шундый булгач, сиңа – бер таянычсыз укытучыга өй салып керүләр бөтенләй дә буш хыял булырга охшап тора. Ярый ла, быел көз кайтарып аударган утыныңны игезәкләр ярып бирделәр дә үзләре сугышка киттеләр. Сугыш тиз генә бетмәсә, алга таба ничекләр көн күрәсе булыр? Һаман саен заёмга язылыгыз, налог түләгез дип кыстап йөргән укытучыга авыл кешеләрендә җылы хисләр уяныр микән? Алар аңа ярдәмгә ашкынып торырлар микән? Ул заёмнарга укытучыларның да барлы-юклы хезмәт хаклары уелып кына кереп китә шул. Кая монда өй салырлык акча җыю турында уйлау!

Бер кичне җиделе лампа яктысында дәфтәрләрен тикшереп бетереп, бер читкә этеп куйгач, ул башын беләгенә салып, бик озак уйланды. Бер анык фикергә килде. Аның бөтен таянычы – үзе. Ул беркайчан да елап, егәрен әрәм итмәс. Җебемәс, сынатмас. Кызы бәхетле булсын өчен таш тауларын ярып үтәр. Гасыйм аңа соңгы хатларының берсендә: «Рәхәт яшә», – дигән. «Рәхәт яшәрбез», – димәгән, нәкъ менә «Рәхәт яшә!» – дигән. Васыять кебек итеп әйткән. Иреннән килгән хатның шул өлеше күңеленә шом үрләтте... Әлвидагъмы әллә бу? Гасыйм уйламыйча сүз әйтә торган кеше түгел. Аның эче нидер сизенәдер. «Куркыныч җитте», – дигән җөмлә дә бар иде бит әле ул хатта.

Фәһимәнең күңеленә кереп оялаган шом, төнге ябалак кебек, канатларын җәя бара. Тиккә түгел бу, тиккә түгел!

Төнлә төшендә аның янына Гасыйм килде: «Ник борчыласың, якыным?

Мин бит нибары арыш сохарие гына сорадым. Хәзер кирәкми дә инде. Болай да яшәп була», – диде дә югалды. Нигә алай диде икән? Җибәрде бит инде, җибәрде. Инде барып җиткән дә булырга тиеш күчтәнәче. Һай, дускаеның ризыгы киселде микән әллә?

Иртән төшен инәенә сөйләде. Камиләттәй: «Хәерлегә юра, кызым. Кайгы дигәне дә адәм башыннан йөри. Ил белән бит, ил белән. Көтеп карыйк әле хатын. Шуның матур итеп сәлам сырлауларын сагындым. Мин догада, балам», – диде. Тик хатлар килү тукталды шул, тукталды.

Агитатор һәр көн саен радиодан Совинформбюро хәбәрләрен язып ала. Юаныч булырдай бер хәбәр юк: «Иделгә ут капкан. Безнекеләр шәһәр эчендәге һәр йорт өчен сугыша. Шәһәр эчендәге трактор заводы танклар эшләп чыгаруын дәвам итә. Һәр әзер танк шунда ук сугышка кереп китә». Бер көн килеп: «Дошман армиясе боҗрага алынды. Маршал Паулюс әсир ителде!» – дигән хәбәрне тантаналы тавыш белән Левитан илгә ирештергәнче йөрәкләр, кайнар табага төшкән майдай, сызыкка әйләнеп бетте.

Сталинград азат! Азат диярлек...

Хат кына килмәде...

Фәһимә дөньядагы иң сагышлы хатынга әйләнде. Аның ире җиңү канатында кайтырга тиеш иде. Хәзер ул аны, теге Шәйхразый хәлендә кайтса да, шатланып каршы алыр иде. Аларның бит бер-берсенә биргән вәгъдәләрен үтиселәре – бәхетле илдә бәхетле балалар үстерәселәре бар. Дошманга үч итеп! Күп итеп...

Мәхәббәтнең өметсезләргә дә канат куя торган тылсымы бар. Әлегә ул Шәйхразый кулына шөшле генә тоттырды. Шәйхулла абзыйның чабата үрергә дип хәстәрләп куйган юкә кайрылары байтак икән. Һич югы кулым эш тотсын дип, шуларга тотынды. Мичкә көн дә ягыла. Көн дә юкә кайрылары пешәләнә. Алардан өйгә татлы-баллы ис тарала. Юкә кайрысын нечкә телемнәргә телеп тезеп куя да, Шәйхразый көн яктысында бер рәхәтләнеп, чабата үреп ала. Шәйхулла абзый малайларының агач эшенә кулы ятып тора. Көнгә ике кием чабата үреп өлгерә ул. Үзләренә дә кирәк. Сатып кайтырга да була. Хәерҗиһанеттәй Баулыдагы сеңлесе янына йөреп кенә тора. Анда да балалар ишле. Шәйхразый Фәһимә өчен дип тә, бик матур күтәртмәле чабата ясап куйды. Шуны илтә барган иде, шаккатты: Камилә абыстай үзе чабата үреп утыра. Бетә торган нәсел түгел икән болар! Ярар, язга чыккач, Ык талыннан тырыслар үреп күрсәтермен әле мин сезгә. Юк, Диләрәне ишегалдында тартып йөрү өчен бишекле арба ясармын. Үсә бит инде. Арба кирәкмәс инде аңа. Нишләп бу бала һаман тәпи йөреп китми икән? Ашау җитми бу балага, ашау җитми. Шәйхразый шушы бәләкәй кыз өчен үзенең ихластан борчылуына сәерсенеп куйды. Ата буласы килү теләге уянган, ахры, аңарда.

* * *

1943 елга да кереп барулары. Мәктәптә чыршы куярга йөриләр. Ильяс абзый урманнан хуш исле бер нарат кызын алып кайткан. Кичкырын чыршы уенчыклары ясаштырып утырганда, ишектән кунак килеп керде. Менә сюрприз, ичмасам. Колашада мәет хәлендә яткан адәм үз аягында!

– Кызлар, менә мин дә кеше булып киләм. Инде укырга өйрәнәсем килә. Сездә мин дә укый ала торган китаплар бардыр дип өметләнеп килдем әле, гаеп итмәсәгез.

– Ой, Шәйхразый абый, минем немец теле дәреслекләрем генә бар шул. Фәһимәдә инде ул әкиятләр. Бала-чаганың ач тамагын әкият укып алдалый ул.

– Мин алай ук ач түгел. Авылдашлар әйбәт тәрбияләделәр мине. Менә бәләкәй кызга да инәй күчтәнәч җибәргәние әле. Бездә моны кырыккат, диләр. Төйгән киндер орлыгы ягып пешергән урама көлчә бу. Бик тәмле! Бәләкәй балага ярый торгандыр бит?

– Тәмлегә ияләшкән бала түгел. Яратыр, – диде чаршау эченнән кузгалып чыккан Камиләттәй.

– Менә монысы уенчык. Чыршы уенчыгы. Кыш бабай бүләге.

– Ой, нинди матур арба. Нәни курчагы да бар. Пассажир! – Рая Диләрәдән алдарак сөенеп, уенчыкны идәндә тәгәрәтеп җибәрде.

Бала куанычтан кулларын чәбәкләп алды да, тиз-тиз генә мүкәләп килеп, кунак абыйның итекләрен кочаклап алды. Фәһимәнең үзәге өзелеп китте: «Әтисе дип уйлады бала». Нишләп алай булсын инде? Гасыйм киткәндә, тугыз айлык кына булып калган бала әтисен хәтерли алырмы? Уенчыкка сөенүе генәдер...

Шәйхразыйның күзе өстәлдә яткан «Үсү юлы» журналына төште.

– Менә бит! Бу журнал нәкъ минем өчен икән. Үсәсе бар минем. Бер кичкә генә алып торсам ярыймы? Иртәгә сезнең чыршыгызны күрергә килгәндә бирермен. Мин чын урманчы бит. Дөрес урнаштыра алдыларммы икән чыршыгызны, килгән-килгән аны да карап китәрмен. Агач исе сагындырды.

– Син урманчымыни, егет?

– Вербовка белән китеп, Карелия башкаласы Петрозаводскида урман эшендә эшләдем мин. Бик кирәкле һөнәрләргә өйрәндем. Балта эшен кечкенәдән яратам. Әтәй тәрбиясе. Кайсыгызга өй салып бирәсе? Бераз ныгыйм да...

Фәһимә егеткә кызыксынып карап куйды. Аның уена кергән нәрсәне бу егет ничек сизеп алды икән? Сәер, бик сәер бу.

– Бик кызыклы тәкъдим. Менә фашистларны җиңгәннең икенче көнендә үк. Юк, Гасыймым кайтып күренүгә үк тотынырбыз, яме. Сүзеңне онытма!

* * *

«Үсү юлы» журналы эчендә Гасыймның хаты киткән икән. Фәһимәгә күңеле төшкән Шәйхразый хатны укымый булдыра алмады. Угрылык инде бу! Тик йөрәк бар бит әле монда. Хат кыска гына икән. Әмма сугышларны ерып кайткан солдат бу хатның хәвефле икәнен тойды. Фәһимә кебек ул да: «Рәхәт яшә!» – дигән җөмләгә игътибар итте. Бәхилләшә бит бу солдат. Сугышка керер алдыннан солдатларның күбесе өйләренә хатлар язып сала. Командирлар да моны куша. Кыр почтасын йөртүчеләр кулыңнан ук алып китә. Әлбәттә, хәрәкәттәге армиядә йөргән чагың булса, шулай инде ул.

Бу хат Шәйхразыйның тынычлыгын алды. Фәһимә кул астында гына торган хатны алып китеп, гаепле булган бит ул. Бик начар иткән! Иртәгәсен төш вакытында ук илтеп бирим дип, мәктәпкә китте. Ә анда ...

– Шәйхразый абый, иплəп сөйләш, – диде Роза. – Фәһимәгә кайгылы хәбәр килде. Ире һәлак булган. Без белгәннәрдән беренче кеше хакында кара хат! Ничекләр чыдар инде дускаем! Яңа ел кичәсендә җырлыйсы да бар бит әле аның.

Алар яшь укытучының үз-үзенә беркайчан да сыгылып төшмәскә, дошман тегермәненә су коеп, күз яшен күрсәтмәскә сүз биргәнен белмиләр иде әле. Әнисе Камилә абыстай күрмәгәнме андый хәсрәтләрне? Сынатканы булдымы соң инәенең? Фәһимә дә сынатмас! Ышанмый да әле ул бу шомлы хәбәргә. Аның кыр үрдәге кебек җитез Гасыймы дошманга тоттырмагандыр.

– Розакаем, Рая дустым, килегез әле яныма. Булыгыз әле ике канатым! Гасыйм исән бит ул, әйеме? Исән бит ул! Кайта бит ул! Мин ансыз яши алмам, аһ дусларым! Мин елыйм, мин елыйм! Инәй белми бит әле. Диләрәм белми...

– Еламыйсың, Фәһимәкәй! Син җырлыйсың! Чык сәхнәгә! Халык укытучысының чыдамлык үрнәген күрсәт кешеләргә. Кайгы урман өсләтеп түгел, кеше башыннан йөри. Бүген – сиңа, иртәгә миңа килә ул. Җырла, Фәһимә! Җырла! Гасыймың ишетсен...

Бәйрәмдә юанып китик әле дип, клубка җыелган хатын-кызлар Фәһимә Сәгыйтова башкаруындагы «Юксыну» җырын үкси-үкси тыңладылар. Кайгылы хәбәр ни арададыр таралып өлгергән иде инде. Бу хәбәрне Камилә абыстайга кичтән әйтеп тормадылар. Менә кайчан Фәһимә чыдамлык үрнәге күрсәтте. Инәе дә ишетмәгәнгә-белмәгәнгә сабышты.

* * *

Баулыга медкомиссия үтәргә барган Шәйхразый Галиуллинны Кызылъяр мәктәбендә военрук булып эшләргә күндереп кайтардылар. Инвалидлык төркемен ачыклау өчен генә барган иде югыйсә. РОНО мөдире янына кергәч: «Командир булган кеше мәктәп укучылары янына җиткән чәч белән кермәстер бит инде», – дип, тәрбияләп маташканнар иде дә, «командир» сүзне кыска тотты: «Минем чәчемне фәкать бер генә кеше ала. Ул минем полкташым. Аның белән очрашкан көнне алдырырмын!» – диде. Минем баш чүмеченә хыянәтчел кереп оялаган ядрә бар. Ул каһәрнең тимер арты күренеп тора, дип, аңлатма биреп торасы килмәде. Дошман үкчәңә басып килгәндә, чигенүнең нәрсә икәнен үзе татымаган кеше сине ничек аңласын! «Чигенгән икән ул!» – дигән сүзне күтәрә алмый ул. Әсир төшмәс өчен чигенү иде бит ул! Хәрби приказга буйсынып...

Менә хәзер бер коллективта эшли башладылар инде. Ара-тирә мәктәп кызларына ярдәм итү өчен дә уңайрак хәзер. Беркөн Мәрвияттәйләргә чүкеч-балтасын кыстыра барып, калыккан идәннәрен, калҗайган ишекләрен көйләп чыкты. Мәрвия карчык эшләрне тагын да табасы иде әле. Кәҗә абзарының түбәсе ышанычсыз икән. Бүре-фәлән килмәсен дип курка. Кыш көне боз өстеннән авылга килгәләп йөрергә ярата алар. Солдатның яралары ачылырга гына тора. Түбәгә үрмәләп йөрерлек түгел. Мәктәптә дә эш күп. Фронтта хәлләр кискенләште әле анда. Безнекеләр нindидер хәлиткеч һөҗүм әзерлиләр булыр. Ел башында Сталинград янындагы кан коеш йомгаклангач, фашистлар күпләп әсирлеккә алынгач, безнең маршаллар кыю-кыю планнар коруга күчте. Немецларны килгән

юлларына таба борып куйдылар. Дошман да сагайды – уйлабрак кылана. Партизаннар хәрәкәте көчәйде. Эх, сугыш башында ук партизан отрядлары оешкан булса, чигенүләр ул тиклем ачы булмас иде. Шунда ук укмашып алып, контрһөҗүмгә күчү җаен табарлар иде. Күпме солдат гомерләре зерәгә кырылды.

Шәйхразый военрукны бик кырыс кылана, диләр. Шук малайлар бик тиз тәртәгә керде. Башың белән карга чумасың килмәсә, хәрби команданы ялтыратып үтисе. Агач мылтык тотып та чаптылар, граната ыргытырга да остардылар. Балалар ач, физик күнегүләр йончыта инде үзләрен. Ләкин Суворов әйткәнчә инде: «Трудно в учении – легко в бою!» Әй, сугыш күрмәсеннәр иде инде бу балалар!

Мәшәкатьләр, өйрәнүләр белән кыш үтеп бара. Мәктәптә ир-ат укытучылар азайганнан-азая. Район үзәге Ютазыга кышкы юлга чыгарга хатын-кыз курка. Ә барасы чыгып кына тора – кирәк-ярак юллап та, һәр айның 20 нче көнендә коллективка тиешле хезмәт хакын алу өчен дә. Юк, булмый ир-атсыз. Бүреләр дә, угрылар да очрый.

Кулы эш белгән егетне Сабирова бик оста файдалана. Директор ханым үзен яшәргән коллективның анасы кебек тоя. Ялгыз, ягъни сугышка кадәр башлы-күзле булырга өлгермәгән кыз балалар аның киңәшләренә бик мохтаҗ дип белә ул. Бәлки, дөресе дә шулайдыр. Әнә бит беркөн укытучылар тулай торагына барып керсә, өч кыз өч якта елашып утыралар. Мичләре ишелеп төшкән. Урыс кызы Екатерина Дмитриевнаның бу авылга килгәнче, гомумән дә, мичкә ягып караганы булмаган. Башлангычлар укытучысы Фәүзия: «Кайтам да китәм үз авылыма. Әниләр янында торып эшлим», – дип, план корып утыра. Математика укытучысы Рәсимә генә кайдандыр кызыл балчык табарга иде бит инде дигән дөрес нияттә. Директор аларга ярдәмгә Ильяс абзыйны җибәреп, мәсьәләне хәл итү җаен тапты. Үзеннән бик канәгать калды ул. Менә бит ничек оста җитәкчелек итә. Юк, ир-атлар бөтенләй бетеп киткәнче бу кызларны берәм-берәм башлы-күзле итәргә кирәк. Хәзер үк түгел инде. Җәйгә табарак. Бәлки, аңынчы солдатлар да кайта башларлар. Алай дисәң, җиденчене тәмамлаган берсен военкомат чакыртып кына тора. Малайлар Мәккә орлыгы мисалында калып бара. Юка гәүдәле Сабирова кинәт куырылып куйды. Үзе дә ялгыз лабаса ул!

* * *

Теге дәһшәтле булырга чамаланган һөҗүм август башына тәгаенләнгән икән. Чыннан да, хәтәр яу булган икән ул. Танкка танк бәрелгәндәге тимер шыкырдавы бөтен ил буйлап яңгырап ишетелеп торган кебек иде. Бөтен ил киеренке бер хәлдә, ялгыш тын алудан да сагаеп, шомланып, Дуга сугышының ни белән тәмамланасын көтте.

Курск дугасындагы танклар сөзешеннән соң Совинформбюро күңел күтәрердәй хәбәрләрне ешрак әйтә башлады, әмма кара конвертлы хатлар килү отыры ешаеп китте. Халык боекты. Өстәвенә сугышка чаклы тупланган маялар бетте. Өйләргә ачлык дәһшәте үтеп керде. Ипигә генә түгел, бәрәңгегә тилмерә халык. Чит авылда баласына сыңар чынаяк сөт таба алмый йөдәгән Фәһимә, әллә туган авылым Каразиреккә кайтып урнашыйм микән дип тә уйлана башлады. Кызылъярда Гасыймны көтеп

утырудан мәгънә булмас кебек. Исән кайтса, ул хатыны белән кызын Каразиректән дә эзләп таба ала бит инде.

Өстәвенә, мәктәп директоры Сабирова да, берәр сәбәп табып, һаман каныга. Холкы шундый инде аның. Беркөн Ильяс абыйга каныгып маташкан, ахрысы. Ни ипле кеше инде югыйсә, ул да кызып киткән: «Монда беркем күрми. Башыңны ике күзең атылып чыкканчы кысам бит», – дип куркыткан Сабированы. Шуннан соң беразга басылып торган иде. Берничә фронтовик егет җыелып килеп, укытучы кызларның утыннарын ярып биргәнен ишеткәч, кабат тузынды. Теге егетләрне кабинетына чакырып, мәсьәләне кабыргасы белән куйган: «Йә өйләнегез бу матур кызларга, йә ялгыз укытучылар янында буталып, аларның данын чыгарып йөрмәгез!» – дигән. Егетләр – Шәйхразый да, Гомәр дә – икесе бер тавыштан: «Без риза! Бүген үк өйләнәбез», – дигәннәр. Сабирова аптырап калган: «Бүген үк түгел. Әле Розасы Бөгелмәдән кайтсын. Берегез бит аның егете», – дип әйтә, ди. Каян белеп тора, диген, бөтенесен. Зәһәрен басар өчен, приказ язып элгән: «Сәгыйтова Фәһимә, югары белеме булмау сәбәпле, башлангыч сыйныфлар укытучысы итеп күчерелә». Приказны элүен элгән, ә үзе, ни әйтерләр икән дигәндәй, елмаеп карап тора икән. Шунда Ютазыга киткән Шәйхразый Шәйхуллович кайтып кергән: «Менә булдырдым, Фәһимә Хәниповна! Анда сезнең белән санлашалар икән. Ике йөз дәфтәр биреп җибәрделәр. Минем, остазым ул, завуч хатын. Педагогика хикмәтләрен аңардан өйрәнәм. Дәрес планнарын да ул төзешә, дидем. Алай әйтергә ярагандыр бит? Иптәш Бикташов сәлам әйтте. Саклагыз аны. Кайгылы вакыты. Сакламасагыз, үзебезгә – РОНОга алабыз, дип тора. Сабирова апа ни за что җибәрми аны, дидем. Ә бу ниткән фәрман? Ә шаяртып торасыз икән. Ертып атыйк без моны. Минем завучыма дәгъвам юк. Фронтовиклар сүзе идәндә ятмый торгандыр бит!»

– Галиуллин! Остармагыз! Дәфтәрләр алып кайтып, бик яхшы иткәнсез. Сез санарга да оста, диләр. Һәр сыйныфка тигезләп бүләрсез инде. Укытучылар бүлмәсендәге өстәлнең аягы сынык икәнен абайламавыгыз начар менә. Приказны болай гына, яшь кызларны сагайту өчен генә элгән идек. Башлангычта укытучылар җитәрлек безнең, шулай бит, Фәһимә Хәниповна?

Кара син бу Шәйхразыйны! Фәһимәне ничек оста гына яклый алды. Көтмәгән иде. Сабировага каршы торырлык канаты юк иде әле аның. Әкренләп, үзенә дә теш чыгаргалый башлыйсы булыр. Тешсез ярамас!

* * *

Бу көннәрдә Шәйхулла абзыйлар өендә тагын кайгы бар. Яңасы. Унҗиде яшеннән сугышка алынган Мөхлисулла унсигез яше тулган көнне аягын өздереп, агач аякта өенә кайтып кергән. Кара чәчле, куе зәңгәр күзле чибәр егет – кызлар озатып карамаган егет аяксыз калсын әле. Шәйхразый өчен өйалдына җәелгән саламга хәзер инде ул капланып яткан. Юатыр сүз таба торган түгел. Нишләтә бу сугыш адәм балаларын?! Шәйхулла абзый хәзер Шәрифулласы өчен генә догада. Хәерҗиһанеттәй алъяпкыч итәгенә һич тыя алмаган күз яшьләрен сөртә-сөртә:

– Менә тиле карт! Мине алып кайтканда, ике генә улым бар дип, юрап

кына китерден инде бу хәсрәтләрне. Илаһым! Ярый ла мин тагын өчне таптым. Юрамышың Мәрхәбә кызыма да төшә күрмәсен тагын. Аны да юкка санаганыең бит. Тиле карт! – дип, картын орышты.

– Телеңә салынма, Чәүкә!

– Һы, нимеч синең балаларыңны харап иткәнгә мин гаеплемени әле? Кичә генә Күгәрчен ием, бүген Чәүкәмени әле? Мөхлисулла улым, ятма болай. Боекма! Бар, энеләреңне ияртеп, Ык буена балыкка төш! Нурфаяз, бар абыең белән! Балык куырырбыз. Ач тамакка ярап куя ул. Аннары соң... Су агышлары җанга дару була ул. Син гел дә исән кайттың лабаса. Ике аяксыз кайтты Мирхаҗиан абзыең. Идрис сукыр кайткан. Апуш та агач аякта. Бик матур кызлар егетсез тилмерә. Сиңа әле патша кызы бара торган. Ятма болай. Тор! Әле син бит бер дигән эш табып, эшкә урнаша аласың. Амбарга мылтыктан ата белә торган кеше – каравылчы кирәк, дип ишеттем.

Мөхлисулла елап ятса да, үги инәенең сүзләрен ишетеп ята. Дөрес әйтә бит дип уйлап куя. Ну яшьлек гарьлеге йөрәген әрнетә. Унсигез яшь кенә бит әле аңа. Унсигез генә! Ник бу дөньяларга туды икән, гомер буе аяксыз титакларлык булгач?

– Аяксыз кеше әйбәт йөзә икән ул. Беркөн Мирхаҗианны карап тордым. Аръякка балык кебек кенә йөзеп чыгып китте. Акча эшләгәч, сәпит алырсың. Баерак егетләрдә шул бар хәзер. Амбарга керсәң, башта тамагың туяр. Аннан өйләнеп җибәрерсең. Хатының терәк, балаларың аяк булырлар...

– Җиттеме, инәй! Мыскыл итмә мине.

Шул амбар эше Мөхлисулланы тагын бер харап итте. Ярты пот арыш чыкмады. Фронтовикка тимәсләр дип, Мөхлисуллага сыладылар. Тиделәр. Төрмәгә илтеп яптылар. Шәйхразый абыйсы йөри-йөри көч-хәл белән коткарды. Әмма егетнең каурые каерылды. Үртәлү әчесен әче су белән юарга өйрәнеп китте. «Баулынефть» конторасына сварщик булып урнашкач, анда да күңеле яралы дуслары табылды. Акча кулга кергән саен эчә торгач, бу гадәтен гомер буе ташламады. Аны яр итеп сайлаган Шәрык кызлары кебек гүзәл, озын пар толымлы Рәхилә «Хатыннар» сүрәсендә язылмаган бу хәсрәтне касә төбе күренгәнче эчте. Уллары да әтисе эзеннән китте. Нәсел бетте. Бусы да сугыш нәтиҗәсе иде. Шәйхразый моны бик авыр кичерде. Ә нинди саф күңелле кеше иде Мөхлисулла. Металлдан челтәр үрә торган оста иде.

Инәй көннәр буена мөнәҗәт җырлап йөри торганга әйләнде. Әллә мине юатуы, әллә үзенең җан ярсуын тыярга тырышуы. Уллары сугышта йөри, кияве ннән кара хәбәр килде. Ана бит ул – ничек түзәдер. Ярый ла минем көнем мәктәптә үтә. Мәктәп эше өйгә дә ияреп кайта. Агитаторлыктан бушамыйм. Завуч буларак та вазифаларым күп. Җидееллык мәктәп бик зур бит безнең. Һәр сыйныф икешәр. Һәр сыйныфта утызар бала. Ярый әле дәфтәрләргә кытлык. Дәфтәр тикшерәсе аз диюем. Һәр сыйныфта икешәр такта куйдырдым. Оста егетләр бар бит. Язма эшләрне мәктәптә үк кабатлатам, өйгә кушмыйм. Кушудан ни файда? Кәгазь-фәлән юнәтү бик кыен. Фронтка хат язасы булганда, кәгазьгә аптырыйлар. Әдәбият фәнен дә күбрәк мәктәптә үзләштерергә көйләдем. Ач балаларым әсәрләр тыңлый-тыңлый оеп китәләр. Хыял диңгезендә йөзәләр. Бөтенләй оеп

китсәләр, табышмак таптырам, такмак чыгартам. Җанланып китәләр. Бик талантлы балалар бар.

Кара тактага акбур белән язудан тыймыйм. Язулары һич югы шулай шомарсын. Минем язуга охшатып язмакчы булып тырышалар. Мине яратуларын шулай белдерәләр. Ә мин мәктәптәге һәр баланы язуыннан таныйм. Үземнең дә исем китә. Бу сыйфатым гомер буена да югалмаячак.

Безнең төрле биналарга таралып утырган мәктәпнең бер бинасы клуб итеп көйләнгән. Залы да, сәхнәсе дә бар. Бик еш кына театр уйныйбыз. Габдулла Тукайның «Шүрәле»сен куйдык. Мин, әлбәттә, Шүрәле. «Үги кыз» әкияте бик матур килеп чыкты. Җырчы кызларыбызның, җырчы малайларның таланты шулай ачыла. Илдә тынычлык урнашса, әллә нинди артистлар килеп чыгар әле безнекеләрдән. Мине шушы балалар арасында кайнашу кайгымнан аралый. Әни (безнең авылда «инәй» диләр, Кызылъярлар инәкәй дип әйтә, мин әдәби телдә сөйләшергә тиешмен дип, «әни» дип эндәшергә күнегеп киләм. Әни генә ияләшә алмый тора әле) Каразирек әрәмәләрен юксына. Монда да аръяктагы әрәмә бик шәп. Тик олы кешене Ык аръягына ничек алып чыгарга белмим.

Шәйхразый да әнине кызганып йөргән икән.

– Ык буенда балыкчыларның көймәләре бар бит. Алып чыгам мин абыстайны да, Диләрәне дә. Анда җәннәт!

Әни куркырмы әллә дип уйлаган идем, исе дә китмәде:

– Инәеңне белмисең әле син, кызым. Мин Кәрәкәшледән Каразиреккә чанага баскан килеш ат юыртып килеп керә торган идем. Камчымны селти-селти! Менә шулай йөрдек без! Әйдә, чыгыйк әрәмәгә. Шәйхразый бик ютәлли, андыз тамыры бу әрәмәдә дә бардыр. Безнең Каразиректә – Ачы ягында күп үсә ул. Монда тапмасам, шунда кайтып килербез әле бер.

– И абыстай, ул ютәлдән үзем дә йөдәдем. Фашист бүләге булды бугай инде ул миңа. Комиссия үткәндә күрделәр – снаряд ярчыгы утыра, ди. Бәләкәй генә, ди.

– И балакаем. Күрде инде сезнең башлар. Минем улларым ни хәлдә кайтырлар икән инде? Күңелем сизә – кайталар үзләре!

Көймә белән Ыкны гизеп чыгу күңелле булды. Су бик тирән, бик чиста. Тирән урында агымы да талгын гына. Әни байтак дару үләннәре юнәтте. Мунча пиннеге дә бәйләп алдык. Көймәгә йөк булмаслык итеп кенә инде. Сәхрәдә йөрү күңелне күтәрде, әмма мин тагын моңайдым. Әй, Гасыйм! Гасыйм! Югалган асылташым! Бу әрәмәдә икәү йөргән чаклар кичә генә кебек иде бит әле...

Укытучы кызларга өйләнергә тиешле дип, Сабирова тәгаенләп куйган егетләрнең берсе Казанга гына барып кайтам дип китте дә югалды. Шәп егет иде. Бәдәне бөтен, буе-сыны зыянсыз. Әллә шул барган җиреннән фронтка ук алып киттеләр инде? Кияүгә чыгу уемда юк. Диләрәне үстерәсем бар. Әни дә минем карауда. Тик менә Шәйхразый тәмам гашыйк булып йөри. Ярдәмен гел күреп торгач, куып та җибәрә алмыйм. Бөтен эшне булдыра торган егет шул. Аның белән өй салып кереп тә була торгандыр. Балта остасы улы лабаса. Хәер... Үзләренең өйләренә карасаң...

1944 елга да чыктык. Безнекеләр бик ышанычлы рәвештә Көнбатышка таба баралар. Ленинград бөҗрасы өзелү зур шатлык булды. Шәйхразыйның

Шәриф абыйсы блокада эчендә калып сугышкан икән. Бер заман ул кайтып төште. Татар-башкорт егетләреннән яңа полк тупларга кайтуы. Офицер. Бик белемле, кызыклы кеше. Мин дә аңа бик ошадым бугай. Тик менә Шәйхразый: «Фәһимә минеке!» – дип кистереп куйган бугай. Шәриф абый да шаян: «Сеңлем, алай да син ашыкмый тор әле», – дигән була. Хатлар язып торачагын әйтте. Мин сүзне озынга җибәрмәдем. Гомумән, бик үзгәрдем әле мин. Җемелдәп торган тигез тешләрем сер саклар өчен генә тезелгән кебек. Артыгын сөйләшмим. Хәтта җырламыйм да икән инде. Нишләттең син мине, Гасыйм?

Каразиректә урнашырга теләгем барлыгын белдереп кайттым РОНОда. Укытучыларны урыннан урынга чөеп йөртергә яраталар анда. Форсат та чыгып тора. Каразиректә ятимнәр йорты ачканнар. Миңа шунда август аеннан күчеп эшләргә мөмкин, диделәр. Директор урынбасары булачакмын икән. Әни дә бик сөенде. Гәрчә Кызылъярдагы ахирәтләрен бик яраткан иде. Фатыйма апа, Рабига апа, Камиләттәй, Хәерҗиһанеттәй бу хәбәргә борчылыштылар. Туган авылыңа әйләнеп кайту борчу түгел инде ул. Төяп китәр нәрсәбез мәктәп аты җигелгән тарантаслык кына җыелды. Казны Шәйхразыйларда калдырдык. Аның Мәрхәбә исемле сеңлесе безгә бик ияләшкән иде. Менә ала каз безнең төсебез кебек булыр. Җиде бәбкәсен дә калдырып тордык. Үстеләр инде. Ияләнгән күлләрендә йөзә торсыннар.

Август башыннан кузгалырга булдык. Ничә җәй Кызылъяр басуларында янып-пешеп урак урган идем, солы утаган идем. Быел шәплегемне күрсәтә алмый китәм инде. Китәм инде... Гасыймым хатирәсен калдырып китәм. Аның белән Каразирек яланнарында йөрергә өлгерми калган идек. Димәк, сагынуларым анда кайткач басыла төшәр.

Кызылъяр белән Каразирек арасы алтмыш чакрым. Иртәдән кичкә кадәр кайттык. Кузла башында кем дисез? Шәйхразый инде. Ат тотуның да җаен белә. Тарантас түренә әни белән икәүләп, байбичәләр кебек менеп утырдык. Бәрәңгә генә ашата торган йомшак печәнгә сеңдек. Әни миңа бирнә малы итеп алып килгән шакмаклы чаршауны җәеп куйгач, күңелле генә оя булды. Диләрә безнең арага сыенды. Юл буендагы авылларда чәй эчәргә туктарлык чыбык очы тумачаларны әни искәртеп барды. Ул яктан да җайлы булды. Безнең бәхеткә Ык күперен дә ташу алып китмәгән булып чыкты. Рәхәт кайттык. Нindидер бер тәвәккәл адым ясый алуыбызга сөендем.

Сөенечнең зуры Каразиректә көтеп торган. Бигрәк тә әнине. Назыйф абыем кайткан сугыштан. Исән кайткан. Бер кулын гына Миргород янында калдырган. Әмма исән бит! Гаян җиңгинең бәхетен күрсәгез иде сез. Көнләштем. Минеке кайтмаячак... Назыйф абыем бар бит әле минем. Зәңгәр күзле, шаян сүзле, Сабантуйларда батыр кала торган, йөгерешләрдә алдан килә торган абыем! Хәзер көрәшә алмас шул инде. Әмма йөгерер. Сыңар кулы белән дә ат арбасын әйләндереп сала ала иде әле ул.

Шәйхразый моңаеп кына кайтып китте:

– Киләм әле мин! Монда эшкә киләм.

Килде дә. Яңа ел алдыннан җиде бәбкәне эшкәртеп, каз түшкәләре китерде. Үзе исә Каразирек мәктәбенә военрук булып билгеләнгән. Үҗәт егет булып чыкты бу. Егет димәктән, июнь аенда ук кушылган идек инде без. Коллективта сиздереп кенә тормадык. Илдә сугыш барганда, тормыш

кайгыртып йөрү килешмәс кебек тоелган иде. Дөресрәге, Гасыймнан соң миңа ирем кем булса да – барыбер кебек иде. Янымда безне кайгыртып йөрүче берәү булу начар түгел дип уйлаганмындыр инде. Яшь идем бит әле. Ятим үсү дә үзенекен иткәндер инде. Ә Шәйхразый бик кешелекле, ярдәмчел егет иде.

Әни дә, Назыйф абый да ризалык бирделәр безнең никахка. Бигрәк тә Гаян җиңги хуплады. Бергә торырга туры килмәгәе дип хафаланган булса кирәк. Бергә начар булмас иде лә ул. Сыер янында бит. Сыйлы җирдә. Әмма таланган мулла нигезе бик кысан иде шул. Үзләренә дә бик тар иде анда.

Җиңги берәүләрнең төзелеп бетми калган мунчасын белеште. Шәйхразыйның алтын куллары аны яшәрлек хәлгә китерде. Ләүкә карават булды. Миче бар. Җылы... дияр идем. Каразиректә утын урынына тирестән суккан кирпеч ягышлы. Монысы тагын бер бәла.

Менә шулай. Безнең заман Коръәне «Хатыннар сүрәсе»н яңа баштан язган, күрәсең. Безнең – нисаларның өлешен мал бүлүдә гаделлек җәһәтеннән генә кайгыртасы урынга, ул хатыннар өлешенә өеп-өеп – бик тә мулдан хәсрәтен, кайгысын, мәшәкатен әзерләгән. Безнең янга барымтадан мөлкәт туплап, баеп кайткан яугирләр түгел, яралардан туралган саусыз ирләр әйләнеп кайткан. Кайтсалар әле. Нисаларга дөнья йөген тартасы, бала табасы һәм иксез-чиксез сабырлар итәсе дигән өлеш тәгаенләп куелган икән.

Ә мин Шәйхразый кебек зәңгәр күзле, тупырдап торган улымны мунчада таптым. Мунча салкын иде. Туганда ук салкын тиде бугай улыма. Чуан чыгып җәфалады үзен. Альберт улым Җиңү алып килде. Илшат дип исем кушасы идек. Авыл советындагы кызый, Шәйхразыйны көндереп, Альберт дигән исем кушып җибәргән. Улым үз исемен ярата бугай. Шәриф абыйсы һәлак булган көнне туганын белә микән?

Җиңү көненә ике ай кала Шәриф Шәйхуллин (Галиуллин) Германия җирендә һәлак булган. Шәйхразый Җиңү таңында тәрәзәдән яшел уҗым күтәрелгән басуларга карап елады да елады. Көне буе яңгыр пыскаклады. Икебезнең дә күңелләр елагандыр инде. Мин сабый баламны кочаклап юандым. «Балалар үстерербез!» – дигән вәгъдәбезне үтим бит әле дип уйладым.

Диләрә кызым – юанычым, минем детдом эшләремне тәмамлап кайтканымны тәрәзә төбенә басып көтәр иде. Аңа бит мәми кайта – бармак буе тәмле кишер. Детдомнан барыбер күпмедер ризык тама иде. Гаян җиңги каен сеңлесен аерткан сөт биреп тә «азындырмады» – мөстәкыйльлеккә өйрәтте. Кая барасың, өйрәндек. Детдом балаларыннан сабырлыкка өйрәндек. Сугышның иң рәхимсез ягы – сабыйлар ятимлеге.

1945нең көзенә Каразирек балалар йорты ябылды. Кайбер сабыйларның йә атасы, йә анасы табылды. Урыс балаларын үз телләрендә эшли торган йортларга җыйдылар. Менә шулай итеп, мин директор урынбасары дигән урыннан коры калдым. Яңа уку елын башлангыч сыйныфлар укытучысы сыйфатында башладым. Үрдән түбән төшүнең башы инде бу. Миңа шулай тоелды. РОНОда урын табылуга башка мәктәпкә күчерергә вәгъдә иттеләр: «Фәһимә сеңлем, – диде Рахманкулов абый, – белемеңне күтәрү турында уйлан әле син. Алайса башлангычта утырып калырсың. Фронтовиклар кайта башлады. Сугыш барган дәвердә унынчыны бетергән кызлар мәктәпләргә

күпләп урнашып калганнар. Алар, әнә, дәррәү барып, учительский институтка кереп кайттылар. Читтән торып укыйлар. Шул турыда уйлан әле син. Менә Бәйрәкәтамак мәктәбенә математика укытучысы кирәк. Булдыра алырсыңмы? Аттестатыңда ул фәннән билгеләрең әйбәт икән синең».

Ризалаштым. Шәйхразый да военрук булып, шул мәктәпкә күченде. Минем солдатларым велосипед ярата торган булып чыктылар. Шәйхразый да берәүдән трофей велосипед алган. Юк кына бәягә. Аның Ютазы үрләреннән, шул велосипедны иярләп, очып кына йөргәнен һаман да сөйли торганнар иде. Мең яралы солдат булмаса, исең дә китмәс иде. Бичаракаем, үзендә комарлык көчле иде. Бервакыт Кызылъяр Сабантуенда атаклы көрәшче Әсгат Абдуллинга каршы чыккан бу. Биленә сөлге ураган. Әсгатнең колагына нидер пышылдаганын күреп калдым. Көрәштеләр болар. Шәйхразый үз өлешенә тигән чи күкәйне эчеп куйды да минем янга килде.

– Яраларың ачылып китсә шунда...

– Мин Әсгатнең колагына пышылдап кына әйтеп куйдым: «Мине селтәп салганда, җиргә ипләп кенә куй! » – дидем. Күкәй эчеп килдем менә.

Шәйхразыйның иң матур сыйфаты – Диләрәне ятимлектән аяп калуда булды дип уйлыйм. Какмады, сукмады, ризыктан мәхрүм итмәде. Гомумән, аудан кайткан сыерчык сыман, һәр валчык ризыкны кеше санынча бүлү гадәте үлгәнче калды. Гаиләбез интекмәсен өчен бөтенесен эшләргә тырышты. Икебез дә кул эшен белә идек. Мин бәйләдем, ул итекләргә олтан салды. Куллар гел эштә булды. Кич утырулар күңелле була торган иде. Мин, җылы мичкә аркамны терәп, оекбаш-бияләйләр бәйлим. Шәйхразый песиле талларны бөгеп, тавык-каз оялары үрә. Күршеләр кереп утыра. Элек кеше кешегә кич утырырга йөри торган иде. Гөрләшеп утырганда, йөрәккә кара кан булып оешкан кайгылар таралгандай була. Күршеләрдән бик уңдык без. Ярдәмчел булдылар.

Ул арада укытучы буларак та макталдык. Хәтта Шәйхразый да спектакльләрдә уйнап йөрде. Ә мин үзем Асиям белән авырлы килеш сәхнәдә Мәйсәрәне җырлаган кеше – «Зәңгәр шәл»дә.

Бәйрәкәтамакта Нурдидә апаларда тордык. Күршебез Советлар Союзы Герое Фатих Шәриповның энисе иде. Бу сугыш каһарманы белән, туганым белән горурланган кебек горурлана идем. Бер кайтуында мәктәптә очрашу үткәрдек. Алтын йолдыз кавалеры Фатих Шәрипов озак еллар «Аврора» крейсерының коменданты булып та торды әле.

Бәйрәкәтамакта безнең янда Шәйхразыйның сеңлесе Мәрхәбә дә яшәде. «Апа, синең кебек булам», – дип, Бөгелмә педучилищесына укырга кергән иде. Асияне бик карашты. Бик яратты. Бигрәк матур иде шул балам бәбәй чагында. «Кайчан шуны җитәкләп йөри башлармын микән?» – дип хыяллана иде Мәрхәбә. Сеңлесенең тәпи атлап киткәнен күрә алмады каенсеңлем. Диплом алган елның көзендә гомере өзелде. Бигрәкләр дә ачлык еллар иде ул сугыштан соңгы 1946-47нче еллар.

Асиягә йөкле чагымда өзелепләр ипи ашыйсым килде. Әллә миңа Гасыймның арыш ипиен тансыклавы сеңеп калган иде микән? Шәйхразый, кемгәдер өмәгә барып, үз өлешенә тигән ипиен алып кайтты. Туйганчы ашарлык булды иремнең көне буе эшләгәненә тигән хезмәт хакы. Шуңа күрәдер баламның бөтен саны җитеш булып туды. Асия дә ипи ярата.

Ә менә Мәрхәбәбез шул ачлык корбаны булды. Бөгелмәдән кайтып килгәндә, баткак юлда машина бик каты сикертеп алган. Мәрхәбә: «Абый, эчем!» – дигән дә бөгелеп төшкән. Буш эчәгеләре элмәкләнеп төенләнгән каенсеңлемнең. Җитмәсә, рульдә Шәйхразый үзе булган икән. Мәктәпнең металлоломга алыштырып алган полуторка машинасын аңардан башка кеше йөртә белми иде. Хәсрәтне Шәйхразый да күп күрде инде. Балаларның уңышына сөенергә генә өлгермәде. Насыйп булмады. Бик горурланыр иде.

Мәрхәбәдә тифтыр дип уйлап, тиешле чара күрелмәде. Чын сәбәп үлгәч кенә беленде. Ул сылу кыз да сугыш корбаны инде. Мәрхәбәне Кызылъяр зиратына алып кайтып күмдек. Шул кайтудан бу авылдан китәсебез килмәде. Югыйсә минем өчен ул мәктәптә ямь калмаган иде инде. Чөнки гөрләшеп бергә эшләгән дусларым таралышып беткәннәр. Роза – Ютазыда Фазыл исемле чибәр егеттә кияүдә. Ырыссу мәктәбендә ул малай минем укучым булган иде. Рая-Рәисәне офицеры кайтып алып киткән. Габделхак Кадыйровичка әйләнгән егет бер районда җитәкче эштә икән. Миңнурны Рахманкулов абый үз яры иткән. Мәгъзия Миргалим исемле чибәр егет белән кавышкан. Аларның да Асия исемле кызлары үсеп килә. Шулай итеп, мине Кызылъяр мәктәбе яңарган сагышларым белән каршылады.

Мин инде өченче балама йөкле килеш Укытучылар институтына кереп кайттым. Беркадәр ашыкканмын. Мәктәптә дә Сабирова апа мине генә көтеп торган диярсең, эшкә күмеп ташлады. «Яшь балам бар», – дип әйтеп кара син аңа.

– Сәгыйтова, баланы байлык дип беләсеңме әллә син аны? Җәмгыять өчен файдалы кеше булам, дисәң, көн-төн эшлә. Фронттан кайтмый калганнар өчен дә эшлә!

Монысы минем төзәлмәс ярама тоз сибеп кую өчен әйтелде булса кирәк.

Мин дә усалланып киләм:

– Минме эшләмим? Беренче сентябрьдә баладан котылдым. Унбишенче сентябрьдә эшкә чыктым. Әнә бала салган бишектә тагын ике балам атынчык атына. Шуны белеп торган ана кеше ни йөрәге җитеп, дәрес бирә алсын?! Әнине алып килер идем: «Кызылъяр авылында мин кермәгән бәдрәф калмады», – дип, чат каршы тора. Сез бит бик дәрәҗәле директор. Миңа йорт-җир җиткерергә булышыгыз. Кәҗә булса да асрарга рөхсәт юллап бирегез. Минем бит бу авылда бер кашык сөт сорап алыр туган-тумачам юк. Ярдәм итегез.

– Эшлим мин моны! – Үзе белән санлашканны ярата иде ул. Ярдәм итү чарасына керешкән бит. Бу сөйләшү онытылды дип йөргәндә, кабинетына чакырып кертте: «Гариза яз! Йорт таптым мин сезгә. Тик бушка булмас. Килешү төзербез авыл советы белән».

Төзедек. Менә ул килешү:

«Без, түбәндә имза итүчеләр: Кызылъяр авыл советы председателе Фәттахова С. – бер яктан; Кызылъяр җидееллык мәктәбе укытучысы Сәгыйтова Ф. – икенче яктан, төзибез шушы килешүне түбәндәге хакта:

1) Кызылъяр авыл советы «Алга» колхозы территориясендә булган ятим калган Гыйлаҗева Ф., Гыйлаҗев Зәкәрия, Гыйлаҗев Римнәрнең йортларын якындагы кечкенә таш келәте белән, кузгатмаган килеш, Сәгыйтова Фәһимәгә 1500 сумга сатып бирә һәм акчаны бүгенге көннән кулга алырга.

2) Сәгыйтова Фәһимә югарыда әйтелгән йортны усадьбада булган таш келәте һәм калдык ихатасы белән авыл советы күрсәткән бәягә сатып ала. Һәм 1500 (мең биш йөз) сум акчаны 15 майдан да калмыйча авыл советына тапшырырга өстенә ала.

Килешү төзелде һәр ике якның имзасы белән.

Авыл советы председателе Фәттахов.

Кызылъяр 7 еллык мәктәбе укытучысы Сәгыйтова.

14 май, 1949 ел».

Әҗәткә баттык. Аның каравы, күңелләр үсеп китте. Йорт яшәмәслек түгел икән. Галиуллиннарның алтын кулы белән соң! Таш келәт үзе бер хәзинә. Җәйге эссе көннәрдә шунда ятак хәстәрләп куябыз. Кунак өе кебек була. Утары зур түгел. Мал-туарсыз кешегә җитәрлек. Утарның бәләкәй булуына үзләре бәрәңге утарлык яшькә җиткәч, балалар бик шатлана иделәр инде. Өй янында бакча ясадык. Агач, чәчәк бакчасы. Алмагач, крыжовник, карлыган утырттык. Яшелчә үстерә белмәдек. Анысын Өченче солдатым булдырды.

Кем ни белән алдыра бит!

Әүвәл заманда Сәхәү байныкы булган, диләр, ул йортны. Байныкы булмаса, таш келәтләр салынмас иде, дип уйлыйм үзем дә. Яңа йортка дип, нигез кузгаткач, яшереп куелган ядрәләр байтак чыкты. Кемнеке булгандыр ул «хәзинә»?

Бу йортта рәхәт кенә яшәп алдык. Иркен генә иде ул. Чаршау эче – мич алды ягы бигрәк тә уңайлы иде. Тар сәке, өстәл куешлы. Олы якны юка фанера белән бүлеп, йокы бүлмәсе ясадык. Мөхлисулла металлдан бизәкләп ясап биргән караватка салам матрас түшәдек. Шәйхразый урын-җирне, үзе әйтмешли, шартына туры китереп тигезләп, тиешенчә итеп җыештырып куяр иде. Без җыйганны ошатмый. Аңа матур кирәк.

Олы як уртасында зур өстәл тора. Өстәл тирәли утырышып, мин дәфтәр тикшерәм, Диләрә дәрес әзерли, Асия Сталинга хат яза. Безнең тәрәзәдән төшкән лампа яктысы авыл урамын маяк кебек яктырта. Түшәмгә җиделе лампа элеп куйган идек. (Электр уты да безгә бик иртә – нефть белән бергә килде.) Өебезгә радио керде. Аннан замана җырлары агыла. Балаларга кадәр: «Фирдәвескәй, кара күзкәй... Таш астыннан ике күзе энҗе кебек елтырый» дип җырлап йөриләр. Кем ничек булдыра ала инде. Асиягә «каш асты» дигәннәре Ык буендагы вак таш асты булып ишетелә икән. «Айли, Баулылар, һәр эштә мактаулылар» Асия телендә «һәреш тамак таулыларга» әйләнә. Альбертына кадәр: «Мин барас Минзәгә, син барас Минзәгә» дип, яңа җыр өйрәнеп йөри. Гүпчи күңелле яшибез. Менә нишләтә тормышны радио – олы дөнья белән ялгый.

Безнең хәзер мур кыргыры кәҗәбез дә бар. Берәү генә түгел, икәү. Он тутырган агач сандык торган бүлмә ишеге ачык калганны сагалап кына тора олы кәҗә. Угры булгач угры инде. Әмма сөтне мул бирә. Инәй аның сөтен җыеп, сепаратка да барып кайта. Кәҗә сөтеннән катыгын да оетабыз. Минем бу солдатым тормышны көйләү рәтен белә.

Әмма бер ягы бар – Шәйхразый бөтен нәрсә балкып торганны ярата. Аңа мич акшарланган, идән кырып юылган булсын. Хәтта атна саен минем фетр итегемне, өстәлгә ак кәгазь җәеп, каяндыр юнәткән махсус таш белән

ап-ак булганчы кыргычлап куяр иде. Баскыч ташлары капкага кадәр алып барсын, һәм алары да ялтырап торсын, ишегалды үләнен мал таптамасын, тавык пычратмасын. Агач эшен инде ул авылда гына түгел, районда бер булырлык итеп башкарып куяр иде.

Өй салып кергәннең соңында атлылар, безнең турда туктап, тәрәзә яңакларын, гәрничләрне каерылып-каерылып карый торганнар иде. Ә инде мәктәп утынына килгән агачларның ярарлыгын сайлап, мунча салып куйгач, килгән-киткән, ягъни мунчаның эчен күреп, юынып киткән кешеләр аны «фестиваль мунчасы» дип бәяләгәннәр иде. Чөнки мунча 1956 елны өлгерде. Агачтан, тал чыбыгыннан челтәр генә үрми иде инде. Карелиядә вербовка буенча китеп эшләгәндә, агачның бөтен хасиятен өйрәнеп өлгергән. Янгынчылар командасында дежур торганда, Асия кызына челтәр урындык үреп алып кайткан иде. Андыйны берәүдә дә күргәнем булмады. Ә ул ясаган комод, этажерка, кытай бильярды, гомумән, сәнгать әсәре иде. Каян, кемнән күреп ясагандыр ул аны? Кунак-мазар килгәндә, сый да кирәкми, шул бильярд янына сырышалар да, китә комарлы уен. Чәнчә бармактай баганачыкларга идеаль итеп кырылган шарлар тезеп куела. Җебеннән хәйләсен белеп тартып җибәрүгә, бөтерчек уйнап китә, шарларны берәм-берәм кыерлый башлый. Почмаклардагы ояларда да шарлар посып утыра. Очко туплау тәртибе ничек булгандыр, әмма уен гаҗәп кызык иде. Хәтта карап тору өчен дә кызык иде. Бүтән кешедә андый бильярд күргәнем булмады. Безнекен Өченче солдатым мунча ишек төбенә басма итеп каплап куйды. Башта үзенең исе киткән иде: «Булса да булган икән бер оста кеше. Ник сакламадың син бу кешене, Фәһимә?» – дип, тел шартлатып йөргән иде. Ник ул бильярдны Альберт алып китмәде икән? Әтисенең төсе итеп...

Хәзер менә торып-торып исем китә. Альберт белән шахмат уйный торганнар иде. Өйгә бу уенны улы алып кайтты. Гомумән, Альберт улыбыз мавыгучан, әтисе кебек һөнәрле булып үсте. Аның лобзик белән кисеп ясаган әйберләре белән ата кеше горурлана иде. Ә менә улына шахматта оттырасы бер дә килми иде. Оттырган чакларында башындагы контузиясе уяна иде дә шахмат фигуралары төрле якка оча торган иде.

Бик мәшәкатьле еллар кичердек. Мин укырга кереп кайтуга Шәйхразый хисапчылар курсына китте. Ничек тә укыйсы килә, миннән дә калышасы килми иде аның. Югыйсә икенче дәрәҗә инвалидлыгы азмы-күпме акчалата ярдәм бирә иде. Әмма аның матди якны да тәмам үзенә йөклисе килә иде шул. Бөгелмәгә йөреп укыды. Февраль буراннарында шинельдән сүтеп теккән пальтодан туңа торган булгандыр инде. Юк, ул җәяү кайта. Юл акчасын янга калдырып, куенына күчтәнәч тыгып кайта. Күчтәнәчнең төрлесен табарга була, акчаң гына булсын. Авыл башында нефтьчеләр өчен магазин ачып куйдылар. Анда гел без татып карамаган тәмле ризыклар саталар иде бугай. Сыр тәгәрмәче күргәч, бәләкәй кызым шаккаткан иде: «Аны ашыйлармы?» «Юк, – дидем. – Матурлык өчен генә ул». Ә Шәйхразый, үзеннән җәлләсә дә, шул кибеттән миңа әстерхан йә бәдам чикләвеге алып кайта. Мине шат күңелле, сәламәт, бәхетле хатын итеп күрәсе килә иде аның. Берьюлы күчтәнәч урынына кап-кара көчек кыстырып кайткан. Эт яратты микәнни? Мин: «Өйгә кертмә!» – дигәч боекты. Мин шул чагында ятим үскән малай күңелен аңлый белмәгәнмен.

Хисапчы таныклыгы алгач, Икенче солдатым Баулы бораулау конторасына барып урнашты. Кая инде аңа авыр торбалар сөйрәргә! Үзем чарасына керешеп, Кызылъяр клубына мөдир итү җаен таптым. Бу эш безнең гаилә өчен мәдәни яктан отышлы булды. Һәр яңалык белән кызыксынучан Шәйхразый патефон алып кайтты. Өйгә «Огонёк» журналы килә башлады. Балалар шуны карап үскәннәр икән. Балачакта кергән мәгълүматны кара син! Бәләкәй Асия Рерихны белә!

1952 елда Октябрьск шәһәрендәге шофёрлар курсына урнашып кайтты бу. Ничек тә булса, үзенә нефтьчеләр тирәсендә – акчалы җирдә эш табасы килгәннән инде бу. 4 нче СМУга алдылар үзен. Әмма еш авырып торган яралы солдат анда озак эшли алмады. Кайда да озак эшләрлек түгел иде аның хәле. Үзе тәвәккәл, үзе чамасыз батыр. Ни булырын уйлап тормастан, куркынычның күзенә керә торган холык. Баулы янгын сүндерү командасында эшләгәндә, аның түбәгә үрләгән утны сүндерергә менгән җирдән, түбә белән бергә өй эченә ишелеп төшкәнен сөйләп, йөрәгемне алдылар. Үзе көлә генә: «Коммунист бит мин. Кайда хәтәр – шунда булырга тиешмен», – ди. Бер курку белмәс адәм булса да булыр икән. Аръякта бүленеп калган укучыларны алып чыгарга көймә белән ташуга – бозлар арасына кереп киткәнен үзем күрдем. Югыйсә ул балаларга, борылып, авылларына кайтып китсәләр дә, сүз әйтми идек бит инде... Җыйнак кына гәүдәдә, яргаланып беткән бәдәндә каян шулкадәр егәр булгандыр?

Бервакыт авылга ниндидер сәер кеше килеп йөри башлады. Өязы ягыннан килә, диләр. Олы гәүдәле бер дивана адәм икән бу. Әҗелгәрәй исемле икән. Бер төнне иңбашыма кул тигәнгә сискәнеп уянып китсәм, якында гына олы күләгә басып тора. «Шәйхразый!» – дип кычкырып җибәрдем, ахрысы. Шәйхразыем сикереп тә торды бу әзмәверне өйалды баскычыннан түбәнгә томырды да. Шуңа күрә безнең ишеккә килә кирәкми иде: Шәйхразый йорты бу!

Ә үзе нечкә хисле, кырыс холыклы, әмма бик гадел иде. Мин кышкы каникул вакытында дүрт ел рәттән кышкы сессиягә йөрдем. Икенче солдатым балаларның каникул көннәре ямьле үтсен өчен өйгә чыршы куя иде. Ике бала өчен! Кич утыруларына ямь кертү өчен кабак төше куырып бирә икән. Аны өчәүләшеп, берәмтекләп саный-саный тигез итеп бүләләр. Һәркемгә үз өлеше. Монысы гаделлек әлифбасы! Кабак төше – тәмле нәрсә. Шуңа күрә ул өйдә юк кеше өлешенә дә тияргә тиеш. Бөгелмәдәге Диләрә белән Казандагы минем өлешкә дә...

* * *

Шәйхразый хәленнән килгән кадәр мине кайгыртып яшәде. Күрәсең, ул озак-озак мине сагынып яшәгәндә, Гасыймнан килгән хатларны укыгандыр. Чөнки нәкъ аныңча итеп, хатларында яшерен сер инде бу дип уйлаган урыннарны гарәпчәләп яза торган иде. Гарәпчә язуы бик матур иде. Бераз гына мәдрәсә эләгеп калган иде аңа. Аннары Шәйхулла әтәй дә кадимчә белем алган кеше, намазлы карт иде.

Шәйхразый мине саклыйм дигәндә, чамадан уздырып та җибәрә торган иде. Ул аркылы пычкы белән утын кисәргә туры килгәндә дә, миңа пычкы башы тоттырмады. Авыр әйбер күтәртмәде. Минем Казаннан кайтыр

вакытымны көтеп, урман җиләген кар базына төшереп саклый торган иде. Ә аның мин кайтуга, ак ыштаннан калып, идән юулары үзе бер хикмәт булган инде. Акча муллыгы булмагач, хезмәте белән сөендерергә тырыша иде. Мине олы кызы урынына күреп көйләде. Ә менә мин аны тәрбияләп җиткерә алмадым бугай. Гөл кебек итеп өйләр салып куйганның соңында ул өйнең рәхәтен аз күреп калды шул. Мин диплом алганнан соң ике җәй яшәп калдык аның белән. Ул җәйләрне Ырыссу хастаханәсенә йөреп үткәрдем. Язга чыгуга сөяк-санаклары өзелеп сызларга керешә иде аның. Бер дәва да килешмәде. Барасың янына хастаханәгә утыз километр юл үтеп. Ә ул урынында юк. «Абый гараждадыр ул, – диләр яшьләр. – Аңа машина җене кагылган бугай». Шулайрак иде шул. Техника аныкы иде. Хыялында машиналы булу уе булгандыр да бит. Сәгате иртә сукты.

Мәктәптә физкультура һәм хезмәт укытучысы булып эшләде. Соңгы берничә елда гына инде. Юк иде шул саулыгы, юк иде. Шуның өстенә хезмәт дәресе вакытында уң кулының ике бармагын өздерде. Кайсыдыр шук малай укытучы станокка такта урнаштырып торган вакытта рубильникка баскан. Шунда да югалып калмаган бит ул. Бармакларын алып, кулын ак җәймәгә төреп, район хастаханәсенә үзе киткән. Югыйсә юлда күпме каны аккан инде аның. Бер зарланып карамады. Аяклары шешенеп, чыдамаслык сызланулар өстенә бит бу. Сугышларны кичкән адәмне сугышта күргән газаплары куып тотты. Бик йончыды.

Әйе. Бу зәхмәтләр минем пединститутны тәмамлап кайтканны гына көткән, диярсең. Миңа гел аркылы килеп торды. Күп газаплар күрә-күрә алган Укытучылар институты дипломы, имеш, югары белем саналмый башлады. Вокзал идәннәрендә куна-куна, күкрәк баласын тилмертә-тилмертә укып йөрүләрем җәл.

Минем тагын арбадан төшеп калу ихтималым бар иде. Безнең мәктәпнекеләр барысы дәррәү кузгалгач калышмыйм, дидем. Кайбер имтиханнарны Бөгелмәдә генә тапшырып булу мөмкинлеге дә кызыктырды. Мине үзебезнең төбәктә татар телен укыту җәһәтеннән методист итеп тә билгеләгәннәр иде. Күңелемнән генә Гасыйм өчен дә укыйм дип уйладым. Имеш, аның бүленеп калган хыялын дәвам итәм.

Минем Икенче солдатым бу сынауны да сабырлык белән үткәрде. Балаларга күз-колак булды, йортны тотты. Мине мәктәп директоры итеп билгеләгәч һәм алдыма яңа мәктәп салып керү бурычы куелгач, аның урман гыйлеме миңа әйтеп бетергесез ярдәм булды. Җитмәсә, минем эшем тиешенчә үтәлсен өчен төзүчеләр бригадасын да үзе күзәтеп эшләтте. «Шәйхразый абый бүрәнәнең авыр башын ялгыз күтәрә. Булса да булыр икән көчле адәм», – ди торганнар иде. Болары бармакларын өздерү тарихына кадәр булган иде.

Әйткәнемчә, бармаклары белән бергә сәламәтлеге дә ишелеп китте. Ул миңа юнәтергә хыялланган санаторий путёвкасын тапкан идек Шәйхразыйга. Кырымга. Евпаториягә. Ул анда да барып җитүгә миңа фатир белешеп, өч укытучы белән бергә килергә чакыру җибәрде. Диңгез күреп кайтыйк әле дип сөенә-сөенә бардык. Бу минем Шәйхразыйны алырга баруым булып чыкты. Без килүгә бик ябыккан, ашаудан калган иде. Шул хәлендә дә безгә искиткеч фатир табып куйган, курсовка белешкән.

Мин кайтып китәрмен, ә син калып, ял итәрсең дип уйлаган. Кырымның башкалар өчен шифалы һавасы аның әҗәлен тизләтте. Тәмәкене күп тарта иде шул. Сугыштан ияреп кайткан гадәт. Бары «Прибой» папиросларын – иң катысын гына тартты. Үпкәсендә яман шеш, ахрысы, диделәр. Әмма табиблар кистереп әйтә алмадылар. Ни булса да, процесс бик тиз бара иде.

Үзен генә юлга чыгарырлык түгел. Дусларым калдылар. Без киттек. Юлда кайтканда, бер станциядә кефир алып меним дип төшүем генә булды, состав кузгала башлады. Арттагы вагонга утырып өлгердем. Шәйхразый бичаракаем, бик хәлсез иде. Фәһимә калды, дип уйлап, ятагыннан торган, киенгән, ике кулына ике чемоданны тоткан, киләсе тукталышта төшәргә җыенган. Мине имин күргәч, күзләреннән яшьләре бәреп чыкты.

Шәйхразыйны өйгә исән алып кайтып җиткерә алмадым. Баулы хастаханәсендә калдырдым. Диләрә кызыбыз шунда эшләгән чак иде. Ярый әле барганмын Кырымга. Үзе генә кайта алмаган булыр иде. Шул хәлендә дә балаларга бүләкләр алган...

30 нчы июньдә кайтып җиттек Баулыга. Районда Сабантуйлары гөрли. Яшәү белән үлем янәшә.

Үләсе көнне минем килеп җиткәнне ничек көтеп алганын сөйләделәр. Үч иткәндәй, автобус кеше җыя-җыя, озаклап барды. Газраилнең кулын тотып торгандай, секундларны санап, ихтыярын җыеп түзде, диләр. Ул Әҗәлнең ничек килгәнен күп күргән кеше иде бит. Мин килеп җитеп, янына утыргач кына өзелде. Соңгы тапкыр мәхәббәт тулы күзләрен миңа төбәде. Яратуы хак иде инде. Хак иде...

12 нче июльдә Шәйхразыйны җир куенына иңдердек. Нибары 47 яшь иде аңа. Өч көннән туган көне буласы иде. Мин егерме елдан соң – 44 яшемдә икенче мәртәбә тол калдым!

Аны җирләп кайткач, ялт итеп торган ихатага чыктым. Бөтен нәрсә аны хәтерләтә. Көрәкләр ул куйганча тора – тәртип ярата иде: «Алган җирегезгә куегыз!» Бакча коймасына таяндым. Йорт урыны тапканнан соң, нибары җиде елда ул мине өйле-нигезле итте. Кешенекеннән матур өем булыр дип уйлаган идеммени мин, яу кырыннан кыерланып кайткан солдатны үземә иптәш иткәндә? Ул да бит мине – йортсыз-җирсез, яшь балалы хатынны иш иткән иде. Әле үкенеп йөргән чакларым булды. Имеш, дусларым шәп кешеләргә кияүгә чыга белделәр. Ә бит аларның ирләреннән берсенең дә акчасыз, мөлкәтсез килеш, юктан бар итеп дигәндәй, өй салып керә алганы булмады. Һәммәсе дә казна фатирларында гомер кичереп, безнекедәй, бөтен урамны балкытып торган өйгә кызыгып яшәделәр. Өч баланы кимсенү галәмәте күрсәтмичә үстердек. Мин ике дипломга ия була алдым. Бәхетле иткән икән бит ул мине. Бергә яшәп калган 19 елда ирешкәннәрнең рәхәтен, рәхмәтен калган гомеремдә дә күрдем. Шәйхразыйдан соң тагын 50 ел гомерем булды бит әле. Калган яшәвем мәхрүмлекләр, кимлекләр, ачлыклар кичермичә үтте. Чөнки өем бар иде, белемем-дәрәҗәм бар иде, балаларым тәрбияле иде. Шәйхразый вафатыннан соң олы хәсрәтләр күрмәдем. Ул мине мәшәкатьсез тормышта калдырып китте.

Бакча коймасына таянган килеш Шәйхразый белән узган гомер юлын барлап, бик озак тордым. Хәзер миңа бакча коймасына таянырга гына калдымыни соң инде? Диләрә кияүдә, бәби көтә. Альберт бер елдан армиягә

алыныр. Асиясе дә укырга китәм дияр әле аның. Мин тагын ялгыз калам икән. Бу авылда туган-тумачам юк. Йөрәгемә тирән сагыш үтеп керде. Бичаракаем, яратканмын икән мин сине. Мин бу сүзләрне чәчәк түтәленнән миңа үрелеп карап торган зәңгәр чәчәк күзләренә карап әйттем. Шәйхразый күзләре! Хәзер миңа ирләрчә ныклык белән яшәп китәсе. Балаларны укытыр – аларга терәк була алыр өчен дип, үзем укыган идем бит. Димәк, минем күңелдә Шәйхразый гомерле булмас дигән яшерен фикер яшәгән. Сугыштан калган кыйпылчык кына иде ләбаса. Хәзер инде мәктәп утынын эш агачы итеп сакламабыз. Утын көе генә ягарбыз. Җылынып кына булмас.

Балаларны Шәйхразый белән үстердек. Ул аларга тәрбия бирә белде. Куркак булмаска өйрәтте. Үзе дә кулы тигән һәр эшне башкарып чыга белде. Мин җитешмәгәндә, оекбашларга ямау салып куярга да иренми иде. Улыбызга ир-ат эшен өйрәтте, кызларга энә тоту җаен күрсәтте. Диләрәне ару кешегә кияүгә бирәсе килеп, аның өчен гел борчылды. Ул исән чагында Диләрә яклаулы булды. Төпчек кызыбыз авырганда да, хастаханәгә аның белән гел ул йөри торган иде. Чөнки үзе сырхау кеше, баланың хәлен миннән алдарак сизеп ала торган иде. Аны хәтта минем дусларым, балаларның дуслары да бик хөрмәт итәләр иде. Алар чишә алмаган мәсьәләләрне чикләвек кебек кенә ярып ташлый иде. Табигый зиһен бик көчле иде аңарда. Һәр гамәлнең әмәлен белә иде. Бик тә, бик тә укыйсы килгән аның. Их, бу сугыш чыкмаган булса иде ул.

Мин педсовет утырышларыннан кичегеп кайтсам да, аш янына ялгыз утырмас, балаларны да: «Әниегез кайтсын», – дип тыеп тора торган иде. Иртән уянып чыгуга каршы йорттагы Хәкимәттәй тәрәзәсен кереп ачар иде. Янәсе, карчык төнне исән-сау гына чыкканмы? Күршелек кагыйдәләрен шулай үтәтте ул. Гомумән, язылмаган кагыйдәләрне үтәтү аның тормыш рәвеше иде. Шул Хакимәттәйнең армиядәге улына хатлар язып торды. Яшьтән атасыз калган егеткә әти тәрбиясе бирү турында кайгыртты. Югыйсә башка берәүнең күрше малаенда бер гаме булмас иде. Бервакыт Асия төш күргән. Имеш, әтисе теге дөньядан әйләнеп кайткан икән. «Хәйләсен таптым мин аның. Юлы бар аның», – дип әйтә икән. Бу төш ышандырды. Валлаһи, юлы булса, таба торган кеше иде ул!

Шәйхразый бер эшне генә эшләми иде – сугым суймады. «Сугышта канны күп күрдем. Булдыра алмыйм», – диде. Аның эше төзү иде. Хәтта аның кебек кырыс табигатьле кеше күңелендә дә сугышка каршы әнә шундый зур каршылык яши иде. Югыйсә бит хәрби кеше булырга җыенган. Өченче солдатым да тавык та чалмады. Чәчәкләр үстерде. Матурлык тансыклау кадәресе икесенең уртак сыйфаты булган икән. Әле тагын җан кыюга, кан коюга нәфрәт тә берләштерә иде бу икәүне. Беренче солдатым нинди булып чыккан булыр иде икән сугыштан? Сугышларны туктатам дип кереп киткән җиреннән...

Әйе. Нибары 19 ел бергә яшәп калдык. Әмма шушы 19 елда кеше гомере буе башкарырга тиешле вазифаларыбызны үтәп өлгергәнбез икән. Өченче солдатыма Шәйхразый салган өй бүрәнәләренә кадак каккалап йөрергә генә калган иде. Мәшәкатьсез яши белгән кешегә ияреп, Гасыйм хыялланган «Син рәхәт яшә!» гомере килде. Шәйхразый белән дөнья көткәндә күргән михнәтләрнең әҗерен күрү Мөбарәккә – Өченче солдатыма язган булып чыкты. Аның белән 29 ел бергә гомер кичердек. Муллыкта яшәдек.

Өченче солдат

Кавказда барган сугышларда катнашып, орден-медальләр генә түгел, бәлки, яралар да алган батыр танкист Мөбарәк Нигъмәтов, ниндидер могҗиза белән генә Курск дугасындагы канкоештан котылып калган, сугыш тәмам булгачтын да әсир төшкән фашистларга конвоир сыйфатында унике ел гомерен исраф иткән кеше иде. Тик, ни гаҗәп, бу кешене сугыш бер дә кырысландырмаган иде. Танышканнан соң бер еллап кияүләп йөрде әле ул. Икебез дә укытучылар бит. Безнең шәхси расписаниеләребез мәктәпнекенә бәйле. Очрашулар бик еш була алмый. Ике мәктәп арасы, һич югы, 40 чакрымлап бардыр... Шулай да ул килә. Һәр юлы бүләк-күчтәнәч белән килә. Күпереп торган мамык шәл япты бер килүендә. Ә бер килүендә бармагыма алтын йөзек үк кидерде. Заманага хас кыланыш иде инде бу – алтын йөзек кидерү. Мин моңа кадәр андый затлы нәрсәләр күргәнмени! Беренче солдатым да, Икенчесе дә мине заманына күрә ярата белделәр.

Мөбарәк яңаны төзеп азапланмады. Булганының кадерен белеп, мул, иркен яшәүне алга куйды. Шәйхразыйга рәхмәт укый-укый, мунча керде. Шәйхразый утырткан бакчага умарталар тезеп куйды. Яшел чирәм утравына помидор, кыяр утыртты. Аның ул беренче балын суыртыр алдыннан серле генә бер кыяфәт чыгарып йөрүләре, аннары: «Кая әле, бер матур савыт бир әле», – дип, шул савытка гәрәбәдәй сары бал тутырып кертүләре! Ә помидор соң, помидор! Сабагында бер саргая башлаган помидор да күренмәс. Ә бабаегыз, бер олы эш майтарган кеше сыман идән уртасына кереп басар да, шаровар балагына сөрткәләп, минем кулыма, бала башы зурлыгында булыр, кып-кызыл помидор тоттырыр: «Менә – талалихин!» Ул помидорларын шулай сорты белән генә атап йөртә иде. Аннары кара көзгәчә өстәлдән «талалихин», «бычье сердце» өзелмәс.

«Гәрәбәдәй сары бал» сүзтезмәсе Мөбарәкнең үзен сагынып әйтелә торган бер матур гыйбарә булып калды. Балын бал. Балның бит әле балавызы, кәрәзе, алардан койган ачы балы бар. Ачы бал түр яктагы мич ышыгында җырлап утыра. Ә монда чисталык дип ушлары киткән кызлар-оныклар идән юып «азаплана». Шулар янынннан идән таптап үтүләре... Бабай юри генә сукранган була: «Көн дә юмасагыз соң...» Ә бабай сусый. Аның су түгел, ачы бал эчеп куясы килә. Бала-чага шуны белми шул. Бала-чаганы ярата бабай. Ат җигеп кайтып, юри урам әйләндерә. Өч баладан туган оныклар рәхәтләнделәр бабай тәрбиясе күреп. Үзе булса, «Бәли! Шулай булмыйни соң? Шулар шатланып яшәсен өчен сугыштык бит», – дияр иде.

Мөбарәк диварда эленеп торган мандолинага җан кертте. Үзе белән алып килгән тальянын еш кулына алды. Аның белән бергә өйгә тормыш яме кайтты. Яз көне ул мине җилтерәтеп, каен суы эчәргә алып китә иде. Романтик иде ул күңеле белән.

Олыгаеп кына, тыныч тормышка кайткач, озак еллар педагог булып эшләде. Химия-биология укытты. Кызылъярга күчеп килгәндә, пенсиягә чыгарына бер елы бар иде әле. Кечке мәктәптә укытты, безгә килгәч... Авыл – аны, ул авылны үз итте. Фронтташ дуслары да табылды. Чемоданындагы түшенә орден-медальләре тагылган пинҗәге дә якты көнгә чыккалый башлады. Бигрәк матур табигатьле, күркәм холыклы, тыйнак бер кеше иде инде ул.

Кайда яшәсә, шунда алма-чия үстерде. Чәчәкләр утыртты. Безнең балаларның балаларын, чын йөрәктән оныклары күреп, яратты. Гасыйм белән уртак хыялны өченче Солдатым ярдәме белән үтәп бетердек. Шунысы кызык: шушы өченчесен – Мөбарәкне оныклар «безнең бабай» дип йөртәләр.

Урыннары җәннәттә булсын солдатларның!

* * *

Өч солдатым белән яшәлгән еллар санын кушсаң, нәкъ илле ел – Алтын туй килеп чыгар иде. Ике плюс унтугыз плюс егерме тугыз!

* * *

Бу әсәрем 95 яшендә бакыйлыкка күченгән, гомерен мәктәптә балаларга ана телен укытуга багышлаган, Татарстанның атказанган укытучысы Сәгыйтова Фәһимә Хәниф кызы, аның өч хәләл ире – Бөек Ватан сугышы солдатлары – Сталинград фронтында һәлак булган Зәкиев Гасыйм Зәки улы, сугышны Көнбатыш Украина фронт чигендә күкрәгенә алган Галиуллин Шәйхразый Шәйхулла улы, Кавказда (Кече Җирдә) сугышкан Нигъмәтов Мөбарәк Нигъмәт улы рухына багышланды. Истәлекләре күңелләрдән җуелмасын!

Әсәрем чын булган вакыйгаларга нигезләнеп язылды. Нокта куям дигәндә генә, Альберт абыем Волгоград өлкәсенең Городище авылы янындагы Самофаловка зиратындагы мемориалдан төшереп кайткан фотодагы датага игътибар иттем. Анда: «Зәкиев Гасыйм Зәки улы 1942 елның 22 сентябрендә вафат» дип язылган. Зәкиев Гасыйм әнигә 30 сентябрьдә дә, хәтта 7 октябрьдә дә хатлар язган. Хатларны укыганда, бәлки, игътибар иткәнсездер, аларда Коломна, Ржев тирәсендәрәк сугышка керү турында хәбәр бар. Сталинград версиясе яшәде безнең өйдә. Чынлыкта кайда һәлак булган икән соң ул? Хәрби көчләрне хәзер булса, бик тиз илтеп җиткерә алырлар иде. Ә менә 1942 елда?! Вафат булганнан соң язылган хатлар...

Тагын бер фаразым бар әле минем. Хатларны кат-кат актарып та, мин кара конвертлы хатка юлыкмадым. Диләрә апамның: «Мин әтигә пенсия алмадым», – дип, әнигә үпкә белдергәне булды. «Сиңа чыккан пенсияне Зәки бабаң алып китте», – дигән җавап булды бугай. Анысын бәхәс уртасына салмыйм. Алай булырга да мөмкин. Ә менә Рая апа алып кайткан хат «хәбәрсез югалу» хәбәре түгел иде микән? Дустының газапларын күреп торган Рая апа моны, әлбәттә, белдермәгән. Офицер кияве белән бер-бер чарасын күрә алдылар микән әллә, дип тә гөнаһландым. Хәбәрсез югалган солдат гаиләсенә пенсия билгеләнмәгән бугай ул. Югыйсә меңләгән солдатлар танк асларында «хәбәрсез югалганнар». «Ржев» дигән фильмны күреп калган кешеләр минем бу фаразымны расларлар.

Тагын бер үтә кыю фаразым бар әле минем. Минем әти – хатынына Мәҗнүндәй гашыйк Шәйхразый – берара клуб мөдире булып эшләп ала. Актив кеше иде ул. Авылга курчак театры килгәч, мине – бәләкәй кызын да мәшһүр артист Фуат Таһиров белән таныштырып, хәтта театрның бер бәләкәй курчагын бүләк иттерү хәйләсенә төшеп караган иде. Менә шул әти, ничектер форсат чыгарып, әнинең тавышын радиода яңгырату әмәлен уйлап

йөргән. Ни үкенеч, яздыру аппаратларын күтәреп килгән радио кешеләре әнине күндерә алмадылар. Аны мин дә хәтерлим. Матур җырлый иде шул әни. Аның бу сәләте беребезгә дә йокмады. Язма да калмады.

Җырлатып карадылар. Тавыш яңгырашыннан бик разый булдылар: «Сез, ханым, Җәвһирә Сәләхова кебек җырлыйсыз икән. Хәтта артыграк та түгел микән әле». Әмма тискәрелеген җиңә алмадылар. Шунда берсе: «Ә сезнең менә бу яңа җырны җырлап карыйсыгыз килмиме?» – дип, «Тормыш җыры» дигән җыр язылган язманы тыңлатты. – Сезнең исемегез Фәһимә, ә җырда Фатыймага мөрәҗәгать итәләр. Һәлак булган беренче иремезнең исеме Гасыйм иде диделәр. Җырда – Басыйр. Бәлки, ирегез Болгария партизаннары янына барып эләккәндер. Әсир төшмәгән иде микән ул?»

Әни сер бирмәде:

– Минем ирем Сталинград фронтында һәлак булды. Әсир төшә торган кеше түгел иде ул! Ә бу җырны мин өйрәнермен. Бүтән Фатыймалар, Басыйрлар өчен җырлармын. Исеме дә бик мәгънәле икән: «Тормыш җыры»!

Әнинең бу җырны сәхнәдән җырлаганын хәтерләмим. «Юксыну»ны җырлады. Сәхнәдәге соңгы җыры «Умырзая» булды. Аны ул җырлап бетермичә сәхнәдән чыгып китте. Ә менә «Тормыш җыры»н[3] өйдә, бигрәк тә ялгыз калган чакларында гел җырлый иде. Без аны «әни җыры» дип йөри идек. Нindидер сер бар кебек бу җырда. «Йөрәгем» дигән сүзенә кадәр Гасыймныкы бит.

...Шашкын сагыну баса кайчак, гүзәлем!
Сине сагынам, Фатыймам, йөрәгем.
Сагыну көч бирә, җиңелмәм.
Көт, югалтма мине, теләгем.

Мин исән, мин үлмәм,
Мәхәббәт көчле салкын үлемнән.

Әгәренки бу җыр 1944 елда ук безнең авылга килеп җиткән булса, ихтимал, әни минем әтигә кияүгә чыкмаган булыр иде. Мин дә, абый да тумый калган булыр идек. Бик ихтимал... Чөнки гомере бик аз калган әни көтмәгәндә әйтеп куйды: «Шәйхразыйга кияүгә чыкканыма үкенәм. Югыйсә тату яшәдек... Әтиең исән булса, синең белән бик горурланыр иде».

Бәлки, сер менә-менә ачылырга торган мизгел булгандыр бу. Ә әнинең әйтелмәгән сере бар иде. Үзе белән китте. Яшьлек дусты Роза апа да ниндидер сергә ишарә ясаган иде. Аның белән сөйләшергә дә өлгермәдем. Ул да китте. Ачылмый калды сер! Ачылмый калды... Ни үкенеч! Сер сөйләргә яратмый иде шул безнең әни. Беренче солдаты белән бәйле сер булмады микән ул? Үләр вакыты җиткән иде инде. Әни озаклап, апаның кулын сыпырып-сыйпап утырды: «Иң кадерле, иң яраткан балам син булдың, Диләрә кызым!» – диде.

Мине күрмәде дә...

Унбиш яшьтән туксан биш яшькә кадәр йөрәгендә йөрткән мәхәббәтенең тышка бәреп чыгуы иде бу.

[3] Мирсәй Әмир сүзләре, Җәүдәт Фәйзи музыкасы.



Фирдәвес
Зариф

КИЛӘЧӘККӘ КЕМ СОҢ ЮЛ САЛЫР?!.

Уйланырга иде

Кайда соң син, бөек Татар Иле,
Тарлыккамы калды татарлык?
Оныкларганиләр мирас булыр,
Нефть, газлардан соң сатарлык?

Чишмәләре, елгалары корый,
Аянычы – хәтер саеккан.
Теле, моңы сакланса да әле,
Кояш түгел, ае калыккан.

Төнгә кереп барган юлчы кебек
Күң(е)ле боек – алда юл чаты.
Чиксез далаларны иңләп чапкан
Атын соң ул кайда югалтты?!

Ычкындырган мөмкинлекләр чоры
Булып калды узган гасыр да.
Төштән соңгы акыл: терсәк якын –
Тешләп кенә булмый, асылда...

Иелгәннең башын кылыч кисми –
Горурлыгы аның тезләнгән.
Кайтып булса иде үткәннәргә
Тарихтагы шанлы эзләрдән.

Татар йоклый... Әллә үлгән үкме? –
Битарафлык кая карама.
Тел язмышы ятлар кулында дип,
Ник сибәләр тозны ярага?!

Фирдәвес ЗАРИФ (1961) – *шагыйрь, прозаик, журналист; «Пар дулкын», «Чишмә», «Татлы җәй» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Милләтеңне малга, данга саткач,
Киләчәккә кем соң юл салыр?!
Мал да калыр, алган дәрәҗәң дә,
Кавемең дә җирдән югалыр.

Кайда соң син, бөек Татар Иле?
Ник дәүләтең бирми бер аваз?
Кем соң искә алыр туар таңда?
Уйланырга иде – уянгач!..

Инкыйраз

«Ахырзаман», – дияр иде бабай,
Әгәр бүгенгегә күз салса.
Телен сатып, байлык туплаучының
Исе китмәс, милләт югалса.

«Монафикълар», – дияр иде Тукай,
Муллаларны күреп муллыкта.
Урыс телендәге вәгазьләрдән
Мәчетләрдә, имеш, сан арта.

Сыкрап ята булыр Җәлил рухы,
Тоеп, илнең кад(е)ре киткәнен.
Киләчәге булырмы соң аның,
Пычратылган чакта үткәне?

Нәрсә әйтер иде икән Гаяз? –
Чынга аша бара инкыйраз.
Давыл кочагында милли кораб,
Коткарырга вакыт калды аз.

«Халкың өчен нәрсә эшләдең?» – дип,
Сорау куйса һәркем үзенә,
Бәлки, туры карый алыр идек
Языла барган тарих күзенә.

Күңел күзе

Тау астында терәк таллар корый –
Язгы ташу ерганаклар яра.
Кеше игелек кылмый табигатькә,
Күңел күзен пәрдә каплап бара.

Күңел күзе күргән ак бабайлар
Юк карарга хәзер чишмәләрне,
Һәркемдә дә бары үз кайгысы,
Тутырырга кирәк киштәләрне.

Хәтта руханилар мал бүлешә,
Качып киткән күңелләрдән иман:
Хак Тәгалә күреп тора бит, дип,
Нәфесен соң әле кем бар тыйган?!

Күңел күзе үксез-ятимнәрнең
Рәнҗеш тулы карашыннан бага.
Илгә хәзер алар кирәкме соң? –
Кадерләре юк белән бер чама...

Күңел күзе... Юкса күп кирәкми
Ахыргача аңа ачылырга:
Хак Тәгалә әмеренә буйсын,
Тәүбәгә кил – калма ачынырга!

Рәхмәт яусын сиңа, кадерлем

Хатыным Рәмзиягә

«Уйламыйча бер сүз әйтмисең», – дип,
Гел искәртә идең яшьлектә.
Хисләргә дә урын бирелгәндер,
Шуңа да ул тиле яшьлек лә.

Ялгышлар да урап узмагандыр,
Гашыйк булсам – шашып яраттым.
Ә шулай да, ничек, аңлаталмыйм,
Син үзеңә һәрчак караттың.

Кызып киткән чакта, рәнҗеткәндә,
Дәшми кала белдең, яшь йотып.
Авыр чакта терәк була килдең,
Күңелеңне һәрчак киң тотып.

Игътибарга вакыт гел тар инде,
Кая ашыгабыз шул тикле?
Җылы сүзгә, назлы карашларга
Урын һаман кала бик чикле?!

Соң булса да – уң булсын, ди халык,
Рәхмәт яусын сиңа, кадерлем.
Үткәннәргә кайтып кичер мине,
Белмәгәнгә синең кадереӊ.

Язлар, язлар...

Язлар, язлар, кабатланмас язлар
Үткәннәргә алып китә тагын.
Урап кайтам төсле балачагым,
Каршы ала анда туган ягым.
Язлар аша күчәм яшьлегемә –
Татыр өчен тәүге сөю тәмен.
Тоймый калган идем мәхәббәтнең
Язларга тиң гүзәллеген, ямен.

Туган җирнең каеннары һаман
Картаймыйлар, яшәрәләр язда.
Сөенәләр һәрбер туар таңга,
Җилләр бүләк итә иркә-наз да.
Язлар, язлар, сиңа кергән чакта,
Туктап кала сыман ел агышы.
Гомер, юкса, кышка кереп бара.
Йөрәккә тик тансык үз ялгышы...

Саклыймын йөрәктә

Хисләрнең олысын саклыймын йөрәктә,
Рәнҗетмә тик саксыз кагылып.
Ялгышлар язмышка әйләнгән чагында
Булмый шул үткәнне сагынып.

Ялгызлык халәтен белә тик кичергән:
Көннәрең узса да, төн озын.
Чарасыз калганда өметләр ялгана,
Көтә ул бәхете йолдызын.

Тиңең дип йөргәнең – ятларны күзләгән,
Читтән ул җылылык эзләгән.
Үз насыйп ярына хыянәт иткәндә,
Вәгъдәсен бозуын сизмәгән.

Хисләрнең олысын саклыймын йөрәктә,
Бәхеткә һәркемнең хакы бар.
Бер гыйбрәт алганнар каңгырап йөридер,
Эзлидер гомерлек тугры яр.

***

Туган якка беркайчан да бармый – кайта гына кеше,
Тик кайтулар никтер сирәк була – һаман бетми эше.
Үзен яратканга күз дә салмый – чит-ятларны күзли.
Үкенүләр генә соңлап килә – яшьлек ярын эзли.

И туган як

И туган як, – кендек каным тамган,
Җанга газиз туып-үскән җирем!
Телем ачкан нигезем җылысы һәм
Хезмәт белән чыккан маңгай тирем.

И туган як, төшкә керәсеңне
Белгән булсам, китәр идеммени;
Телем, милләтемне җәберсеткән
Бу ил – минем туган илеммени?!

Бабамнарның горурлыгы булса,
Чыкмас идеммени мәйданнарга;
Раббым насыйп иткән хөрлегемне
Ирек бирмәс идем богауларга.

И туган як, бары синдә генә
Киңрәк алам төсле сулышымны.
Иң зур сугыш үзең белән, диләр,
Кабул әйлә шушы булмышымны.

Чиксезлектән килдем, шунда барам,
Кайтып сыеныр сиңа җисми тәнем.
Бәя алыр бары бакыйлыкта –
Җиргә иңгәч, җирдә үткәргәнем.

Тәүбә капкалары ябылганда...

Тәүбә капкалары ябылганда
Кабул булмый, диләр, теләкләр;
Иман гына булыр таянырга –
Ярдәм итмәс һичбер терәкләр.

Тәүбә капкалары ябылганда,
Үкенечтән аһ-зар агылыр:
«Үтте гомер нигә догасыз?» – дип,
Күңел үткән көнне сагыныр.

Кабул булмас кылган игелекләр,
Һәркем савап эзләп тилмерер;
Онытылыр байлык, дәрәҗәләр,
Җан тынычлык тапмый илерер.

Тәүбә капкалары ябылганда,
Вакытка бу дөнья тар булыр:
Чиксезлектән килгән кире кайтыр –
Яралтучыга ул тартылыр.

Дулкын ярга какмас, кош сайрамас –
Тынлык кына чыңлар һавада;
Галәм туктап калыр, һәлакәткә
Тик санаулы мизгел калганда.

Тәүбә капкалары ябылганда,
Фәрештәләр булыр сәҗдәдә.
Ялварырлар Хакка: «Тулы иман
Бирче, – диеп, – һәрбер бәндәңә!»

Редакциядән:

Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез!

Шәмсия
Җиһангирова

КЫШКЫ БЕР ТӨН

хикәя

Әниләр кат-кат колагыбызга киртләп җибәргән йомышларны йомышлап, кибет саен кереп алырга кушылган әйберләрне җыеп бетергәч, район үзәгеннән авылыбызга кайтырга дип, җәяүле юлчылар машина көтә торган урынга киттек. Кояш инде кичкә авышып бара, караңгы төшкәнче, өйгә кайтып җитәргә кирәк...

Без килеп җиткәндә, машина көтә торган җирдә берсе дә безнең авыл кешесенә охшамаган биш-алты кеше җыелып тора, араларында ыспай гына бер солдат та бар иде. Без дә әкрен генә килеп, шулар янына елыштык.

Торабыз шулай. Машиналар бөтенләй диярлек узмый. Узганнары туктамый. Шактый туңдыра башлады. Сикергәләп тә карыйбыз, тик файдасы гына юк – эчеңә бер салкын төшкәч, җылыну кыен икән. Теге солдат безне күзәтеп торган, күрәсең, яныбызга килеп:

– Безнең авыл кызлары түгелме соң сез? – диде. Миңа борылып: – Ялгышмасам, син Мөгаллимәттәйнеке бугай... – дип куйды.

Бөтенләй таныш булмаган абыйның безне шулай әти-әниләребезгә охшатып тануына хәйран калдык. Соравына җавап бирергә дә онытып, гаҗәпләнеп торуыбызны күргәч, ул:

– Сез мине танымыйсыздыр шул. Мин солдатка киткәндә, сез бәләкәйрәк идегез бит әле. Өч ел вакыт эчендә мин дә үзгәргәнмендер... Әхмәтша Таимҗаны мин... Карга Абдулласы... – диде.

Шуннан соң гына ят абыйны бераз төсмерләп:

– Ә-ә, әйе шул, менә хәзер белдек... – диештек.

Таимҗан абый баскан урынында таптангалап, ыспай итекләре белән кар шыгырдатып, әрле-бирле йөренгәләп-әйләнгәләп килде дә сүзсез генә безгә карап торды. Ниндидер катгый карарга килгән тәвәккәл тавыш белән:

– Беләсезме, кызлар, әйдәгез, җәяү кайтабыз... Көн яхшы. Буран юк.

Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА (1951) – *шагыйрә, прозаик; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, «Төсле моң», «Якты сагыш», «Илаһият» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Машиналар да йөрми. Кичкә каршы, йөргәннәре дә туктар хәзер. Сез дә шактый гына суык өшеттегез, борыннарыгыз кызарган әнә... Әйберләрегез өчен кайгырмагыз, үзем күтәрешермен. Бергә-бергә күңеллерәк тә булыр... – диде.

Инде көн караңгыланып килүенә карамастан, безне бер күрүдә үз итеп, хәлебезгә кереп сөйләшеп-киңәшеп торучы ышанычлы юлдаш булгач, шатланыша-шатланыша риза булдык. Кайтмый калсак, әти-әниләр дә хафага төшәр. Үзебезнең дә «чит җирдә» кунып каласыбыз килеп тормый, тизрәк өйгә кайтасы килә...

Булган әйберләребезне бүлешеп күтәрдек тә, тәвәккәлләп, кайтыр юлга кузгалдык. Шактый ара сүзсез бардык. Без – районнан ары китә алмаган бала-чагаларга, әллә нинди ерак калалар күреп, «әрмис» булып йөргән Таимҗан абыйга башлап сүз кушу килешми. Таимҗан абый үзе сүз башламый, ниндидер без белмәгән уйларга чумып, дәшми-тынмый атлый бирә. Мин аның елтыр итекләренең кар шыгырдатуын тыңлап барам. Туган якка кайтканда гына туа торган ниндидер дәртле-шатлыклы көй көйли иде аның солдат итекләре...

«Юл кешесенең юлда булуы яхшы» дип белми генә әйтмиләр икән. Әле яңа гына кузгалып киткән кебек идек машина көтә торган җирдән, инде – Мәлкән тавына җиткәнбез икән. Юлның яртысы шунда дип сөйлиләр. Димәк, алты чакрым араны узганбыз да...

Кыш көне караңгы тиз төшә бит: тирә-юньдә төн хакимлек итә. Күк йөзе чалт аяз. Ай яктысы яп-якты булганга, кайтыр юлыбыз төшкән энәне табарлык булып ярылып ята. Тизрәк туган авылыбызга, борчылып, зар-интизар булып көтеп торучы әти-әниләр янына, җылы өебезгә кайтып җитәсебез килгәнгәдер, күрәсең, һаман әллә ни артык сөйләшмибез. Безнең сөйләшү-аралашу сорау-җавап төсендәрәк, өзек-төтек җөмләләрдән генә тора. Күбрәк Таимҗан абый теге-бу сораулар бирә, безнең җаваплар исә «әйе-юк»тан узмый. Шулай атлый бирәбез.

...Менә Таимҗан абый тын гына атлаган җиреннән кинәт туктап, әйберләрен җиргә куйды. Ике кулын югары күтәреп, тирән-татлы итеп сулыш алды... һәм бөтенләй ят, куаныч-шатлыклы тавыш белән:

– Ии-и-их! Кызлар! Җанкисәккәйләрем! Сизәсезме сез, юкмы?! Туган як исе килә бит, туган як исе килә! Сагындым, шундый сагындым! Белсәгез иде! Сөйләгез әле, сөйләгез... тартынмагыз әле... Авыл нишли анда? Нинди яңалыклар бар?! – диде.

Без, бер-беребезне уздырып, кар төшкәнче җыеп бетерә алмыйча, әле күпме чөгендернең кар астында калуы, Чупай Мирзаһит абзыйны үгез сөзүен, Сарык Нәсименең язгы ташуда суга батып үлүен, бөтен кешенең калай да шифер белән түбә ябуын, салам түбәнең Мәгъсүмәттәй белән Мәхтүрәттәйдә генә калуын, узган ел бетон труба утыртып, Югары Оч чишмәсен корытуларын, Чыпчык Әсәдулласы малаеның «әрмислеккә» каралуын, ел саен язгы ташу алып китеп тилмертә торган агач күпер урынына әллә нинди тимер-бетон күпер салуларын, тагын әллә ниләр, әллә ниләр сөйләп бетердек.

Таимҗан абый безнең сүзләрнең кайберләренә гаҗәпләнеп, башын чайкый, кайберләреннән сызгырып куя, эче катып, рәхәтләнеп көлә...

Аны шулай бер җилкендереп, бер уйландырып, бер дәртләндереп җибәрә алырлык «акыллы» сүзләр генә сөйләп баруыбызны тою безнең үзебезгә әйтеп бетергесез ләззәт-рәхәтлек бирә иде...

– Ярар, алтынкайларым, башка яңалыкларны, Мирхаҗиан, Әҗәр абзыйларны, Хаффаза апаларны сөйләп тормагыз инде... Әйтегез әле, минем Гөлзифам нишли анда, Гөл-зи-фа-а-ам! Күптәннән хат алмадым үзеннән!..

Кинәт кенә айнып-уянып киткәндәй булдык. Зур сөенеч, шатлыкны әйтми торабыз икән ләбаса! Бер айлар элек кенә Гөлзифа апа бәби тапты бит! Кыз бәби!

Кайда ничектер, ә менә безнең авылда бәби дөньяга килү әйтеп бетергесез зур шатлык-сөенеч, бәхет исәпләнә. Бәби дөньяга аваз салган минутта урамда нинди бала-чага туры килә, шуны тотып, эти кешедән сөенче алырга йөгертәләр. Сөенче алу бөтен кешегә дә тәтеми торган бәхет инде ул! Беренче булып сөенче алучыга эти булган кеше йә берәр бүләк, йә булмаса акча бирә. Бүләк эләксә, аны көне буе очраган һәрбер кешегә күрсәтеп йөрисең. Акча бирсәләр, кайта-кайтышлый ук кибеткә кереп, күлмәк итәгенә генә прәннек-кәнфит үлчәтеп аласың да кызыктыра-кызыктыра урам уртасыннан ашап кайтасың. Нәрсә дә нәрсә ул дип, бик кызыксынганнарга бөреп тоткан күлмәк итәгенең бер почмагын чак кына ачып, бәби күчтәнәчен күрсәтәсең. «Миңа да бир әле...» – дип ялынсалар, жәлләмичә бер-ике кәнфит бирәсең.

Дөрес, бәби сөенече алуның уңышсыз беткәннәре дә булгалый...

Бервакыт мин шулай өебез янында кызып-кызып «кибетле» уйнап ята идем, авылыбызның «кендек әбисе» Хупҗамал әби Хәкимҗан абыйлардан йөгереп чыкты. Тынына кабып:

– Кызым, бар, тизрәк бул, Хәкимҗан абыеңнан сөенче ал... Ул Савытлы буасы буенда печән чаба... Кызың бар, диген... – диде.

Мин очтым гына! Чакрымнан артык араны юл буе йөгереп бардым. Хәкимҗан абый, күлмәген башына урап, зур-зур селтәнеп, печән чабып ята иде. Минем йөгереп килгәнне ерактан ук күргән, ни эш белән йөрүемне сизенгән, күрәсең, чалгысы-ние белән каршыма йөгереп килде.

– Йә! Кеме бар?!

– Кыз... – дидем мин, сулышымны көч-хәл җыеп. – Кызыгыз бар!

Минем сүзләремнән Хәкимҗан абыйның йөзе кинәт болытлап китте. Бар хәленә кизәнеп, чалгысын читкә томырды, лачт итеп төкерде дә янында бала – кыз бала барлыгын да онытып, аты-юлы белән сүгенеп җибәрде:

– Тф-фү, чёрт! Авызыңны... корт чаккыры... бишенче кыз бит! Би-шен-че! Каян чыгалар диген...

Көрәктәй куллары белән башын кыршаулап, иелә-сыгыла янәшәдәге куаклар арасына кереп чумды. Кая ди ул бәби күчтәнәче?! Рәхмәт тә әйтмәде. Мин бөтен юл буе мышык-мышык елап кайттым...

Шушы хәлдән соң бер-ике көн үткәч, ул мине урамда очратып, сүзсез генә чәчемнән сыйпады. Кесәсеннән матур чәчәкле яулык чыгарып, башыма бәйләтте. Шул сөенечтән башым күккә тия язды хәтта!

Ә берсендә... Кич җитеп килә иде инде.

– Әнкәй, мин чирләп киттем бит әле... – дип, безгә түбән урамда яшәүче Зур апабыз килеп керде. Әни башта ничектер югалып киткәндәй булды,

ләкин үзен бик тиз кулга алды. Беренче эш итеп, безне ай-вайлатып, урамга куып чыгарды:

– Ишетсен колагыгыз, өйгә керә күрмәгез! Барыгыз, йөгереп кенә Хупҗамал әбине алып килегез... Бик ашыгыч, диегез.

Ник ярамый, ник бик ашыгыч икәнен уйлап торырга вакыт юк, ялт, өйдән чыгып йөгердек...

Күпмедер вакыттан, кичке тын һаваны яңгыратып, бәби елап җибәрде. Ул ара да булмады, шатланган-дулкынланган әни ишектән атылып чыкты:

– Төпчегем (миңа дәшүе!), бар тиз бул, Ислам юлына чап! Җизнәң шунда утынга киткән. Тизрәк сөенче ал! «Улың бар!» диген... Ә син, кызым, мунчага су ташый башларсың...

Апама йомышланган сүзнең азагын да ишетмәдем – очтым гына!

Мин эзләп тапканда, җизни арбага утын төяп маташа иде.

– Җизни! – дип кычкырып җибәрдем мин килә-килешли. – Җизни! Сөенче! Сөенче! Чибәр апа малай тапты!

Җизни, ялт кына бер якка арбаны янтайтып, төйи башлаган утынын җиргә аударды. Күз ачып-йомганчы арбага сикереп менде. Дилбегәсен селтәп, атка сызгырып җибәрде. Җан-фәрман чаптырып китеп тә барды. Ә мин, сөенчегә бәби бүләге тиеш кеше, каккан казык кебек, баскан урынымда тораташ катып калдым гына түгел, ерак урманнан җәяүләп тәпиләдем.

Бу – җизнәмнең беренче бала, беренче малай туу шатлыгы иде. Ләкин... тора-бара, малай арты малай туып, аларның саны дүрткә җиткәч, җизнинең тәмам пошаманга төшкәнен хәтерлим.

...Көннәрдән бер көнне безгә нәүмизләнеп-дулкынланып, җизни килеп керде. Әнигә хәер биреп:

– Әби, зинһарлар өчен дип әйтәм, бик каты теләп тор инде... Чибәркәемне роддомга илттем... Бу юлы кыз булсын инде, әби!

Әнигә: «Ярар-ярар, кияү, теләрмен!»нән башка чара калмады.

Кичләтеп безгә сөмсере коелган, йөзе качкан җизни килеп керде. Аның кыяфәтен күреп пошаманга төшкән әни:

– Йә, Ходаем, кияү, ни булды? Әллә табалмадымы? – дип сорады.

– Тапты...

– Соң... тапкач... ник куанмыйсың?! Кеме бар соң?

– Тагын малай... – диде җизни, тәмам беткән тавыш белән...

Менә шундый елата да, көлдерә дә, тилертә дә торган гаҗәеп хәл инде ул дөньяга җан иясе туу! Таимҗан абыйны да шундый бәхет көтә иде. Ә без аны бөтенләй онытып, әйтми барабыз икән. Аның: «Гөлзифамны сөйләгез инде...» – дигән сүзләреннән айнып китеп, бер-беребезне бүлдереп, дәррәү кычкырып җибәрдек:

– Сезнең кызыгыз бар! Гөлүсә!

Бу куанычлы хәбәрдән Таимҗан абый әллә ниләр эшләргә тиеш иде кебек. Монда, кышкы юлда ни эшләп булганын белмим. Тик... ул әллә ниләр эшләргә тиешлеген генә беләм. Мәсәлән, әйтик, безне берәм-берәм һавага чөяргә... Чемодан-төенчекләрен ташлап, чабып-йөгереп китәргә... Болай да санаулы солдат күчтәнәчләреннән әз генә булса да, безгә өлеш чыгарырга... Тагын әллә ниләр, әллә ниләр эшләргә тиеш кебек иде. Ләкин бик тә гаҗәпләнүебезгә каршы, боларның берсе дә булмады.

...Таимҗан абый дәртләнеп барган җиреннән кинәт шып туктады. Сөрмәле кара күзләре зуррак ачылды. Кулыннан чемоданы төшеп китте хәтта. Аптырау катыш ниндидер ят тавыш белән, көч-хәл:

– Нич-чек... ничек инде... кыз бар... мин бит өч ел... – диде дә, ике кулы белән битен каплап, чемоданы өстенә сыгылып төште. Ниндидер бик тә ярамаган ялгышлык эшләгәнебезне сизенеп, аптырап, аңа карап тора бирдек...

Бераздан ул үзен кулга алды бугай (әллә безгә генә сиздермәдеме?), ниндидер катгый карарга килгән кебек, башын күтәреп, тирән сулыш алды. Һавада ат пошкыргандагы кебек пар хасил булды хәтта. Аннары сүзсез генә кесәсеннән папирос алып, авызына капты. Калтыранган куллары белән озаклап сыза-сыза, шырпы кабыза алмый җәфаланды. Ниһаять, кабызгач, тәмәке төтенен тирән итеп, эчкә суырып куйды. Болай да эчкә батып торучы ач яңаклары, ике яктан чокыраеп, авыз куышлыгына кереп китте...

Сүзсез генә кузгалдык. Мин янә Таимҗан абыйның елтыр итекләре астында баскан саен шыгырдаган кар авазларын тыңлап барам. Юк, хәзер инде баягыча туган якка кайту шатлыгыннан дәртләнгән шыгырдау авазлары чыкмый. Киресенчә, сулкылдый, елый иде...

Без ниндидер ярамаган сүз әйткәнебезне чамаласак та, нигә ярамаганын төшенер-аңларлык яшьтә түгел идек шул әле. Дөрес, мин инде күптән әнинең: «Мин сине Сарашлыга кер чайкарга төшкәч, бәкедән табып кайттым. Февральнең әче суыгы иде... Чайкый торган керемә ябышып бәкедән чыктың. Өшегән-туңган идең, кып-кызыл иде тәнең. Керемне ташлап, сине башымдагы шәлемә төреп, өйгә йөгердем...» – дигән, үзем турында мең дә бер мәртәбә ишеткән-тыңлаган, кызганыч та, елагыч та хикәятенә ышанмый башлаган, бәбиләрне кайдан алуларын чамалый башлаган яшьтә идем. Тик менә Таимҗан абыйга: «Сезнең кызыгыз бар!» – дип шатлана-сөенә кычкырганда, аның өч ел буе отпускасыз армия хезмәтендә булуын белмәвем дә ихтимал. Баланың әни карынында тугыз ай гына ятуы да башыма килмәгән... Ул гына да түгел, олылар арасында була торган тагын әллә нәрсәләрне, әллә ниләрне белмәгәнмен шул...

Авылыбызга кергәндә, Сарашлы аша салынган күперне чыгып, тау менүгә, сул якка бер урам кереп китә. Анда йортлар гел бер якка гына салынган. Шунлыктан, ягъни «бер генә күзле» булганга, авыл халкы аңа «Сукыр урам» дигән атаманы таккан да куйган. Армиягә китәр алдыннан гына шул урамга өй салып, безнеңчә әйтсәк, «башка чыгып», әле унсигезе дә тулмаган Гөлзифа апаны яңа йортка алып кайткан иде Таимҗан абый...

Аларның көчле мәхәббәте, Таимҗан абыйның, яшь кенә булса да, дөнья куарга һәвәслеге; курыкмыйча, яшь кәләшен ялгызын өйдә калдырып, солдатка китүе; ул киткәч, Гөлфиза апаның Чулак Сәлим абый белән «шаяргалавы» турында кеше сүзләре зурлар сөйләгәндә, безнең сабый колакларга да уйдык-уйдык ишетелгәләп тора иде. Бәби тапкан бер генә хатынны да калдырмыйча «бәби ашы» илтүче әниемнең бу юлы ни өчен Гөлзифа апага бәби коймагы илтмәвен дә, сабыйлыгым белән уйлап карамаганмын икән шул...

...Без авылга кайтып җиткәндә, сәгать кичке уннар булгандыр. Сукыр урамдагы өйләрнең берсендә генә ут яна. Бу – Таимҗан абый салып калдырган өйнең тәрәзәләре иде. Капка буендагы кар ике якка көрәп өелгән.

...Таимҗан абый, шул сукмакка борылуга туктап калды. Керергәме-кермәскәме икәнен белми торган аптырау белән бергә, без әйткән хәбәрнең дөрес булып чыкмаска мөмкинлегенә ышаныч өмете дә чагыла иде бугай аның моңсу күзләрендә...

Кинәт өй ишеге ачылып китте. Ишек ярыгыннан саркылган ут көлтәсендә хатын-кыз гәүдәсе чагылды. Хатын үрелеп, су-мазар түкте бугай, ишек шундук кире ябылды. Ишек ачылып-ябылган кыска гына мизгелдә, кышкы төн карасына сабый бала елаган тавыш саркып чыкты. Яшь хатынның гәүдәсенә елышып чыккан җылы өй һавасының өрфиясе аксыл-моңсу томан булып төн карасына эленеп калды...

Сүзсез генә без дә кузгалдык. Бераз киткәч, команда булгандай, дәррәү икебез дә артыбызга борылып карадык. Таимҗан абый, без яныннан кузгалып киткәндәге хәлендә, һаман да башын түбән иеп, нәүмиз басып тора иде.

...Иртәгәсен, таң атар-атмас, авылга яңа хәбәр таралды. Төнлә белән Әхмәтша Таимҗаны солдаттан кайткан булган. Әти-әнисе янына кереп күрешкән, хәл-әхвәл сорашкан, чәй эчкән дә, энесе төнлә ат җигеп, аны кире районга илтеп куйган. Таимҗан абый кире үзе хезмәт иткән якларга китеп барган, имеш...

Халык телендә йөри-йөри чүбеккә әйләнеп, тәмам кызыгы бетеп, янә көннәрдән бер көнне бөтенләй онытылган авылдагы башка бик күп гайбәт, гыйбрәтле хәлләр кебек монысы да – Таимҗан абый, Гөлзифа апа, Чулак Сәлим турындагысы да – бер телдән бер телгә, бер урамнан икенчесенә күчә-күчә, тәмам төссезләнеп-уңып, бөтенләй төшеп калды. Баштарак гайбәт сөйләүдән үзенә ямь-тәм табучы яман теллеләр: «Алай булмаган икән ул, болай булган икән...» – дип сөйләгән саен һаман күпертә-куерта барып, тәмам кеше ышанмас хәлгә җиткерсәләр, тора-бара икенчеләре: «Кит аннан, булмас ла, кеше ышанмаслык хәлне чын булса да сөйләмә...» – дия-дия, күпертелгәннәрне тәмам кечерәйтеп, йомшартып бетерделәр. Хәзер инде, сүз иярә сүз чыгып, кемдер ул хәлләрне искә төшерсә, элекке кебек «ә» дигәнче эләктереп алмыйча, бөтенләй кызыгы булмаган нәрсә турында сүз барган кебек, «ә-ә-ә, әйе шул, булган иде бугай шул андый хәл...» дип, сабыр көлемсерәп куялар да: «Ишеттеңме соң әле?..» – дип, икенчесенә, яңарагына, мавыктыргыч-кызыктыргычрагына күчәләр...

Минем күңелемдә генә бу төн ап-ак кар өстенә сызылган тирән кара буразна-җәрәхәт булып уелып калды...

Таркалучы гаиләләр, ятим калган нарасыйлар турында сүз чыкса, ятимнәр белән шыгрым тулы балалар йортлары, интернатлар турында ишетсәм-укысам, ирексездән хәтеремдә кышкы төн, ай яктысында капка төбендә нишләргә белмичә, нәүмиз аптырап басып торучы Таимҗан абый гәүдәсе пәйда була. Бер гөнаһсыз нарасый-ятимәнең ишек ярыгыннан саркып чыккан елау тавышын ишеткәндәй булам. Шул сабый тавышы минем җанымны кисә, телгәли. Үксеп-үксеп елыйсым килә... Кемнәрнедер тиргим, кемнәргәдер рәнҗим, кемнәрнедер гафу итәм...

Ул төнне минем мәңге онытасым юк! Юк! Юк!!!

Гөлзадә
Әхтәмова

ӨМЕТ УТЫ БАЛКЫП ТОРСЫН ҖАНДА

Алабуга корылмасы

Тау битендә җилләр нидер сөйли,
Уйный төнлә кемнең шәүләсе?
Дәверләрне бутап баскан мәллә
Алыпларның көчле гәүдәсе?

Юк, аларның җыры тынган инде,
Буыннарда бары сагышы.
Тик бер миңа ишетелә кебек
Калканнарның чыңлы тавышы.

Чәчелгән дә шушы калкулыкка,
Әйләнгән күк ташка бәгырьләр.
Җан өрәсем килә һәр ташына,
Кулларыма алам кадерләп.

Могҗизадай калган Ак мәчеткә
Сарылса да сагыш, моң-зарлар,
Буйсынса да җил-давылга вакыт,
Онытылмый данлы узганнар.

Чулман дулкыннарын таш хәрабә
Тирән уйга калып күзәтә.
Алыпларның көч-куәтле чагы
Төшләренә кереп йөдәтә.

Гөлзадә ӘХТӘМОВА (1941) – *шагыйрә. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Алабугам минем», «Йөрәгемдә яшен», «Күңел ашкынуы», «Шөкер итәм» һ.б. китаплар авторы. Алабугада яши.*

Заман

Кызыл галстуклы дәртле җырлар
Алга дәшеп тора кебек һаман.
Пионер да идек, комсомол да –
Ансыз булалмады безнең заман.
Балачакның кайнар учаклары
Белән ямьле иде безнең заман.
Кулга-кул тотынып, җитәкләшеп
Яши алдык – шунсы истә калган.
Барын бүлеп, югын уртаклашып,
Ярдәмләшеп авыр еллар узган.
Ачык йөзле юмарт күршеләре
Белән якты иде безнең заман.
Тормышның бар кайгы-хәсрәтләрен,
Ахры, алар оныттыра алган.
Батырлары белән мактался да,
Гади кешеләрдән тора заман.
Сайлап алу һич тә мөмкин түгел,
Кайчан тусаң – шул ул синең заман.
Зурлар аны мең сынаулар үтеп,
Сыгылса да сынмый кала алган.
Тик бер тапкыр яшәп китә кеше –
Кем яңадан туып кабатлаган?!
Гомер кыска – барлык хаталарны
Төзәтергә җитешалмый заман.
Җәмгыятьнең кануннары белән
Буйсындыра һәммәбезне һаман.
Белеп, сизеп, аңлап яшәү лязем:
Ни тели ул синнән, ә син – аннан?
Кем килешә. Ә кем һәрчак уйлый:
Язмышына нигә шулай язган?
Җырларында үзәк өзгеч моңнар,
Җиңел генә узмый һичбер заман...

Калфак

Чиккән калфагымны бик яратып,
Бәйрәмнәрдә киям сак кына.
Бикле сандык төпләреннән чыгып,
Ул әйләнеп кайтты халкыма.

Торган саен кадерләре арта,
Менә шуңа бүген сөенәм:
Безгә кадәр яшәп киткәннәр дә
Ничек белеп, матур киенгән!

Калфагымның нәфис бизәлешен
Үрнәк итеп алдым үткәннән –
Зур осталык белән, таң калдыргыч,
Сокландыргыч итеп чиккәннәр.

Калфак кисәм, башым күтәрелә,
Бер горурлык күрәм йөземдә.
Гүзәллекнең биек үрләрендә
Йөргән хисләр тоям үземдә!

Калфак бит ул – борынгыдан килгән
Камиллекнең нәфис өлгесе,
Иң кадерле якты ядкарьләрне,
Миллилекне саклау билгесе.

Чагыла ул халкым җырларында,
Чал тарихлы моңлы көендә.
Калфакларга багышланган юллар
Бер юаныч, бер куаныч булып,
Туып тора туган телемдә.

Бар да яхшы булыр

«Бар да начар!» – диеп әйтмә әле,
Юраган юш килә күрмәсен.
Булганына шөкер кылып яшә,
Мескенләнеп, шыңшып йөрмә син.

«Бар да яхшы булыр, барсы да!» – дип,
Ышанычның янсын күзеңдә.
Бөек омтылышлар ташып торсын,
«Чигенмәскә!» – дигән сүзеңдә.

Өмет уты балкып торсын җанда,
«Сүрелмәскә!» – дигән көч белән.
Безгә кадәр җирдә яшәгәннәр
Сынауларны азмы кичергән?!

«Бирешмәскә!» – диеп, күтәренке
Рух тудырган алар эш белән.
«Бар да яхшы булыр!» – дигән өмет
Саклап килгән күңел төшүдән.

«Бар да яхшы булыр!» – дип ышану
Маяк бит ул кара көннәрдә.
Кешеләрнең бөек казанышы –
Канат кую хыял-гөлләргә.

Гомер көзләре

Гомер көзләренә һич сүзем юк –
Матур бит ул сары яфрак та.
Алтын төсле, кайнар ялкын төсле,
Йөрәкләрдә янган учактай.

Гомер көзләренең үз яме бар –
Соңлап кына аткан гөлләре.
Үз назы бар, күңелләргә үтеп,
Әкрен генә искән җилләрнең.

Гомер көзләренең үз җае бар –
Сабырлыгы сизгер юлының.
Ләззәте бар гүзәл мизгелләрен
Бик кадерләп җанга җыюның.

Гомер көзләренең үз баскычы,
Үз чамасы атлап менүнең.
Үз сере бар – сызланулар аша
Яшәү ямен тоя белүнең.

Ялгышлыкмы?

Кайбер галимнәр фикеренчә,
аңлы кеше радиоактив фон
йогынтысыннан килеп чыккан.

Акыл ияләре, диләр,
Табигатьнең ялгышы.
Яңа сыйфатлы үзгәреш –
Мутация ачышы.

Ми зурлыгы кискен арту –
Радиоактив фон бәласе.
Җир-Ана тик үзе белә
Акыллы җан бәһасен.

Ни теләсә, шуны эшли –
Кеше хуҗа бу Җиргә.
Кадерен белеп җиткерми,
Төзегәнен җимерә.

Гөл итәрме, көл итәрме –
Кая бара дөньялар?
Ә бит матур яшәр өчен
Табигатьтә бар да бар.

Сулар өчен һавасы бар,
Эчәр өчен – сулары.
Бер-береңнең башын кыймый
Яшәү кирәк нибары!

Бүген кеше кулларында
Радиоактив матдәләр.
Корал белән хәтәрләндек,
Юктыр алда киртәләр.

Кнопкага басып кына
Мөмкин дөнья бетәргә –
Ялгыш биргән боерыкны
Мөмкин кемдер үтәргә...

Кешелекне саклар микән
Дөнья аксакаллары?
Килгән сыман китәчәкбез –
Җитмәсә акыллары...

ЯКТЫРАК ЯНА «КАЗАН УТЛАРЫ»

Авылыбыз мәктәбендә укыган елларда минем иң яраткан урыным китапханә иде. Һәр яңа килгән китапны, журналны көтеп алабыз, чиратлашып укыйбыз. Иң зур чират «Совет әдәбияты» журналына, ә ул безнең ише бала-чага кулына сирәк эләгә иде.

Авылыбызда «әдәбият җене», «иҗат чире» кагылган Мөслах абый бар. Аның шигырьләре район газетасында даими басыла, исем-фамилиясе дә, чын шагыйрьләрчә, «Мөслах Таҗи» дип языла иде. Безнең Югары оч урамында «Совет әдәбияты» журналын өенә алдыручы бердәнбер кеше дә – ул. Үзем дә мәктәптәге, авылдагы хәлләр турында мәкаләләр язгалыйм, кайберләре сирәк-мирәк район газетасында басыла. Шуңа күрәдер Мөслах абый очраган саен мине туктатып, журналның яңа санында чыккан роман, повесть, шигырь-поэмалар турында озаклап сөйли, һәрберсенең эчтәлеген тәфсилләп аңлата, аларга бәя дә бирә. Мөслах абый белән очрашып, аның «дәресләрен» тыңлаган саен, мин әдәбият дөньясына ныграк тартылам, әдәби әсәрләрнең тирән серләренә төшенә башлагандай булам. Аннан сорап алып, көннәр буе «Совет әдәбияты»н укыйм. Шулай итеп, мин әкренләп иҗат дөньясына керә баруымны, моның төп сәбәпчеләре «Совет әдәбияты» журналында дөнья күргән әсәрләр һәм шулар аша әдәбиятка мәхәббәт уятучы авылыбыз шагыйре Мөслах Таҗи атлы игелекле зат булуын сизми дә калдым. Ә 1965 елда Казан Дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый башлагач, почтага барып, иң беренче стипендия акчама журналга язылып кайттым. Ул чакта инде аның исеме дә үзгәреп, «Казан утлары» дип атала башлаган иде.

Лекцияләрдән кайткач, тулай торакның пружиналы караватына сузылып ятып, кичләр буе рәхәтләнеп, журнал укыйм. Бүлмәдәшләрем яшь шагыйрь Зөлфәт (Дөлфәт Маликов) һәм яшь прозаик Фәрит Гыйльметдинов белән анда басылган әсәрләрне сүтеп җыябыз, күбесенең тетмәсен тетәбез. Үзебезнең яңа гына табадан төшкән «гениаль әсәрләребез» дә басылса, журнал бер башка үсеп китәр иде дип хыялланабыз. Ул елларда әле яшьләр өчен әдәби журнал юк, бар карап торганыбыз әлеге дә баягы «Казан утлары» гына. Редакция бүлмәләренә иркенләп кереп йөри алмасак та, аның коридорында, ишек төпләрендә еш була идек.

Икенче курста чакта менә шулай «яшь генийлар» белән бергәләп, «Казан утлары» коридорында киләп сарып йөргәндә, мине Язучылар берлеге бүлмәсенә чакырып керттеләр. Чакыручы кеше – барыбызга да мәгълүм шагыйрь, берлекнең яшьләр белән эшләү буенча рәис урынбасары Илдар Юзеев иде. Ул сүзен Мәскәүдәге Әдәбият институты турында сөйләүдән башлады. Заманында безнең күренекле язучыбыз Габдрахман Әпсәләмовның әлеге институтта белем алуын да әйтеп узды. «Татарстан Язучылар Союзы быел көз шунда укырга керү өчен берничә яшь язучыга юллама бирергә әзер», – диде. «Әле күптән түгел «Татарстан яшьләре» газетасында чыккан шигырьләреңне укыган идем. Шуңа сүзне синнән башларга булдым», – дип тә өстәде. Мин инде Түбән Кама мәктәбендә укыган вакытта ук бу институт турында, анда Чыңгыз Айтматов, Рәсүл Гамзатов, Евгений Евтушенко, Белла Әхмәдуллина, Роберт Рождественский кебек атаклы әдипләрнең сабак алуы хакында ишетеп белә, эчтән генә анда укысам иде дип хыялланып йөри идем. Әмма гади авыл малае өчен Мәскәү каласы буй җитмәстәй булып тоела иде. Илдар абыйның бу тәкъдимен ишеткәч,

йөрәгем урыныннан купты, кинәт кенә иңнәремә канат үскәндәй булды. Мин барырга ризалык биреп, гаризалар язып, документлар тутырып, шигырьләремне русчага тәрҗемә иттереп, Мәскәүгә җибәрергә әзерли дә башладым. Ялгышмасам, Язучылар Союзы ул чакта унбер яшь язучыга юллама әзерләп, Әдәбият институтына җибәрергә җыенган иде. Хыялыйлар! Анда тулы бер татар төркеме булачак, имеш...

Шул көннән башлап, мин «Әдәбият институты» дип аталган хыял дәрьясына кереп чумдым.

Мәскәүгә китү өчен университеттан документларымны алганда, доцент Гази ага Кашшаф белән шундый әңгәмә булып алган иде... «Хәтерлисеңме, абитуриент чагыңда мин синнән: «Ни өчен бу уку йортына керергә уйладың?» – дип сораган идем. Син ул чакта: «Чөнки монда Толстой укыган, Ленин укыган», – дип җавап биргән идең. Ә хәзер нигә китәсең?» Мин, озак уйлап тормыйча, беркатлылык белән: «Чөнки Толстой да, Ленин да киткән!» – дип ычкындырганымны сизми дә калдым.

Әгәр дә иҗат конкурсыннан уза алмасам, имтиханнарны уңышлы тапшырмасам, үземнең Мәскәү урамында япа-ялгыз каласымны ул чакта башыма да китермәгәнмен. Иҗат конкурсына бер урынга ике йөзгә якын яшь язучыдан әсәрләр килгән, ә көндезге бүлеккә нибары егерме биш студентны гына алачаклар, дип әйттеләр. Институтка кабул итмәсәләр, Казан университетына кире кайту юлы да ябылачак, ә авылда мине «университеттан куылуым турында» хурлык тамгасы, гайбәт сүзләре көтәчәк иде.

Сүзем «Казан утлары» журналы турында иде бит әле... Журнал редакциясе белән Язучылар берлеге Бауман урамындагы Матбугат йортының икенче катында, бер үк коридорда, ишекләре дә кара-каршы гына. Ул елларда журналның җаваплы мөхәррире – атаклы язучы, әдәби тәнкыйтьче, Муса Җәлил иҗаты буенча иң зур белгеч Рафаэль Мостафин. Йөзендә һәрчак елмаю йөртүче, ыспай кыяфәтле, гаҗәеп итагатьле Рафаэль ага без яшьләрне күргән саен: «Сәлам, егетләр, шедеврлар язасызмы?!» – дип сәлам биреп китә иде. Әдәбият институтына барырга җыенуыбызны белгәч, ул безне үз бүлмәсенә чакырып, кылларыбызны тарткалап карарга булды, ахрысы. Башта киләсе саннарда журналда басылачак әсәрләр турында сөйләде, аннары ниләр язуыбыз белән кызыксынды. Каникулыбыз башлангач, тиражны арттыру максаты белән подписка чорында районнарга чыгарга, журнал оештырган укучылар конференцияләрендә катнашырга да чакырды. «Ә минем каникул башланды инде. Университеттан документларымны алдым», – дигәч, иртәгә иртән редакциягә килергә кушты.

Әдәбият институтына имтиханнар августта гына башлана, димәк, аңа кадәр минем әле өч айлап вакытым бар. Югыйсә иҗат конкурсына җибәргән шигырьләремә әле җавап та килмәгән. Конкурсны узмасам, имтиханга да кертмәячәкләр бит... Ә мин хыял диңгезендә йөзә торгач, үземне чынлап торып Әдәбият институты студенты итеп хис итә башлаган идем инде... Арадан иң хыялые, иң беркатлысы мин булганмындыр, ахрысы... Чөнки университеттан документларны бер мин генә алганмын, ә калган иптәшләрем конкурс нәтиҗәләрен белмичә ашыкмаска булган. Нәтиҗәдә, арадан иң бәхетлесе дә мин булып чыктым: көтә торгач, бер миңа гына конкурстан узуымны әйтеп, имтиханга чакырып, Мәскәүдән хат килеп төште.

Сүзем «Казан утлары» турында иде бит әле...

Сөйләшенгәнчә, мин икенче көнне иртән иртүк килеп, баш мөхәррир ишеген шакыдым. Рафаэль ага Мостафин коридор түрендәге кырый бүлмәгә алып кереп, редакция хезмәткәрләре белән таныштырды да: «Мәскәүгә киткәнче, менә шушында бүлек мөдире Малик Хәмитов янәшәсендә утырып эшләрсең. Төп эшең подписка, журналга яздыру булыр. Калганын Малик абыең өйрәтер», – диде дә, күңелдә елмаю җылысын калдырып, чыгып китте. Һәм мин, бөтен дөньямны онытып, эшкә кереп чумдым. Университеттагы каләм чарлаучы яшьләр белән редакциядән командировка кәгазьләре һәм тамак ялгарлык сәмән алдык та берәм-берәм юлга кузгалдык. Татар факультетындагы җитәкчеләр, үзләре дә журнал авторлары булгангадыр инде,

студентларны лекциядән җибәрергә каршы килмәделәр. Без өч ай эчендә республиканы аркылыга-буйга йөреп чыктык. Журналга язылуның мөһимлеге һәм кирәклеге турында рәсми бланкка язылган, баш мөхәррир кул куеп, герблы мөһер сугылган хат белән йөзләгән колхоз-совхоз һәм тагын әллә нинди оешма җитәкчеләре янына кердек. Әле яңа гына мыек чыга башлаган студентларны башта артык исләре китмичә генә каршыласалар да, Муса Җәлил даны белән бергә үзе дә бөтен илгә танылган Рафаэль Мостафин язган хатның тәэсире шактый көчле булды. Аннары Малик ага Хәмитовның: «Җитәкчеләр белән сөйләшкәндә: «Без обком кушуы буенча йөрибез. Журналга язылуны партия өлкә комитеты контрольдә тота», – дип әйтергә өйрәтеп чыгаруы да нәтиҗәсез калмагандыр.

Ул елларда «Казан утлары»ның халык арасындагы популярлыгы бик тә югары кимәлгә җиткән иде. Язучыларыбызның моңа кадәр күрелмәгәнчә кыю фикерле мәкаләләрен, талантлы әсәрләрен бастыру белән бергә, баш мөхәррир Рафаэль Мостафин республика җитәкчелеге алдында журналның дәрәҗәсен күтәрү, тиражын арттыру өчен кулдан килгәннең барысын да эшләде. Редакция хезмәткәрләре һәм язучылар авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә йөреп, төрле әдәби очрашулар, укучылар конференцияләре оештырды, һәр мәктәптә, һәр китапханәдә, кыскасы, һәр җирдә аларны көтеп алалар иде. Р.Мостафин баш мөхәррир булып эшләгән өч ел эчендә журналның тиражы бермә-бер диярлек артты. (1966 елда – 34300 данә булса, 1968 елда ул 65346га җитте.) Редакция белән саубуллашып, Мәскәүгә киткәндә, Рафаэль ага миңа рәхмәт әйтеп, журнал исеменнән ике рәтле хромка гармуны бүләк итте.

«Казан утлары» журналы белән бүгенге көнгә кадәр дәвам иткән иҗади бәйләнешләрем нәкъ менә шул елларда башланып китте. Казан каласында бер ялгызым язмышымның юл чатында басып торганда, журналга чакырып, үз куенына сыендырган, үгет-нәсихәтләре, төпле киңәшләре белән тормыш дәресләре биргән Рафаэль аганы мин бүген дә рәхмәт хисләре белән искә алам. Шунысы кызганыч, тормыш аңа үзе шикелле гел якты йөз күрсәтеп, һәрдаим елмаеп тормады. 1968 елгы Язучылар корылтаенда аның өстенә кинәт ишелеп төшкән кара болытлар әле бүген дә күз алдымда. Кайчакта мин ул болытларның куеруына без, яшь язучылар, өлешчә сәбәпче булмадык микән, дип тә уйлап куям... Бу корылтайга мине, Әдәбият институты студентын да, яшь шагыйрь буларак чакырганнар иде. Язучылар союзының җаваплы сәркатибе Зәки ага Нури баштарак, вакыт җитсә, корылтайда яшьләр исеменнән сиңа сүз бирербез, дип тә әйткән иде. Әмма, гадәттәгечә, вакыт җитмәде... Мәскәүдән һәм башка республикалардан дәрәҗәле җитәкчеләр һәм мәшһүр әдипләр күп килү сәбәпле, сиңа сүз бирә алмыйбыз дип, бер көн алдан кисәтеп куйдылар. Бәлки, соңгы арада Мәскәү даирәләрендә еш яңгырый башлаган хөр фикерләрне бу малай-шалай трибунадан мондагы халыкка җиткерер, дип шикләнгәннәрдер. Мәскәүдә диссидент язучылар активлашкан, тыелган журналлар, китаплар актив тарала башлаган еллар иде бит... Югыйсә минем ниятем бик гади – яшь язучылар өчен махсус әдәби журнал кирәклеген республика җитәкчеләренә, төрле республикалардан килгән олпат әдипләргә һәм дәрәҗәле Мәскәү кунакларына җиткерү иде. Сүз бирмәселәрен белгәч, без, бер төркем студент яшьләр, җыелышып киңәштек тә мин әйтәсе таләпләрне кәгазьгә язып, ишәйтеп, корылтайда катнашучыларга таратырга булдык. Төне буе кулдан күчереп язып, аны берничә йөз данәгә җиткердек.

Икенче көнне иртән, шул мөрәҗәгатебезне букчаларыбызга салып, без өчәү: Зөлфәт, Мирза һәм мин М.Горький урамындагы Г.Камал театрының икенче каттагы балконнарына менеп утырдык. Менә сүзне «Казан утлары»ның баш мөхәррире Рафаэль Мостафинга бирделәр. Ул саллы дәлилләр китерә-китерә, татар матбугатының элекке һәм бүгенге хәле турында бик тәфсилләп сөйли башлады. Революциягә кадәр татарның утыздан артык журналы нәшер ителеп тә, бүгенге көндә аларның берничәгә генә калуын әйткәч, президиумда утыручы партия җитәкчеләре бер-берсенә шомлы

итеп карашып куйдылар. Һәм нәкъ шул вакытта без, иң кулай вакыт җиткәнен сизеп, яшьләр журналы сорап язган мөрәҗәгать кәгазьләрен өчебез өч яктан залга сибеп җибәрдек. Рафаэль ага бу ниятебез турында белми иде, шуңа күрә ул да гаҗәпләнеп безнең якка, өстәге балконга, карап куйды. Ә җитәкчеләр, билгеле инде, аның чыгышы белән бу өндәмәләр арасында бәйләнеш бар, дип уйлаганнардыр. Нәтиҗәдә, татар матбугаты язмышын ихлас кайгыртып чыгыш ясаган мөхәררирне берничә көннән эшеннән алдылар. Аны алыштырырлык кеше эзләп, ул урында әле Әхсән Баянны, әле Ләбибә Ихсанованы эшләтеп торып, ниһаять, ярты елдан соң гына Зәки Нурины баш мөхәррир итеп билгеләп куйдылар. Ә алдагы 1969 елда журналның тиражы кинәт кенә кимеп, 36 мең данәгә төште...

Корылтайдан соң мине дә тыныч кына калдырмадылар, тиешле чара күрүне сорап, Казаннан Әдәбият институты ректоры исеменә хат юлладылар. Ректор В.Ф. Пименов мине чакырып, тавышын артык күтәрмичә генә, әйтәсе сүзләрен күңелгә сеңәрлек итеп әйтте. Аның «Дорогой мой студент Валеев, запомни навсегда, в нашем институте занимаются не политикой, а поэтикой», дигән сүзләре әле дә колагымда яңгырап торган кебек. Кемнәрдер өметләнгәнчә, мине институттан кумадылар, өч айга стипендиядән мәхрүм итү белән чикләнделәр.

Сүзем журнал турында иде бит әле...

Билгеле инде, татар язучысы өчен иң истәлекле вакыйгалар «Казан утлары» журналында үз әсәрләрең һәм иҗатың турында төпле, акыллы мәкаләләр басылу белән бәйле. Редколлегия әгъзасы, аксакал шагыйребез Хәсән ага Туфан хуплавы белән журналда дөнья күргән шигырьләр тупламым зур әдәбиятка таба атлаган беренче адымым булгандыр. Хәсән ага кырыйларына яшел кара белән теләк-тәкъдимнәрен язган шигырьләремне әле дә кадерле ядкарь итеп саклыйм. Поэзия бүлеге мөдире Нури ага Арслан һәм аның дәвамчысы Рәдиф Гаташ та без яшьләргә һәрдаим хәерхаһ булдылар...

«Казан утлары» журналы белән бәйле тагын бер вакыйганы язып үтим әле... 1982 ел, Чаллы Язучылар оешмасында җитәкче булган чорым. «Энергетик» мәдәният сарае директоры Шамил Закиров көннәрдән бер көнне миңа бер тәкъдим белән мөрәҗәгать итте. «Быел – «Казан утлары» журналының олы юбилее. Әйдә, журналга багышлап җыр языйк та, Казанга барып, юбилей тантанасында сәхнәгә чыгып зурлап котлыйк! – диде ул. – Музыкасын талантлы композиторыбыз Илгиз Закиров язар, ә сүзләре – синнән...»

Билгеле инде, мин моңа бик теләп риза булдым. Тиз арада аны язып та өлгерттек. Г.Камал театры сәхнәсендә җырчы Азат Тимершәех белән Илгиз Закиров (баян) башкарган «Казан утлары» җырын тамашачылар алкышларга күмеп каршы алды. Һәм ул әле хәзер, кырык ел узгач та, төрле җырчылар репертуарында һәм радио-телевидение тапшыруларында яшәвен дәвам итә.

Мин бүген дә «Казан утлары» журналының һәр яңа санын кадерле кунак көткән сыман көтеп алам. Журналны кулга алганда, үзем дә сизмичә, әлеге җырыбыздагы сүзләрне авыз эченнән генә көйли башлыйм...

Яктырак яна «Казан утлары»,
Чакыра безне үзенә һаман.
Киләбез сиңа, кайтабыз сиңа
Учак янына җыелган сыман.

Разил ВӘЛИЕВ,
Татарстанның халык шагыйре

ГОМЕРЛЕК ЮЛДАШЫМ



Мин инде тугызынчы дистәне ваклап баручы шактый өлкән яшьтәге кеше. Үз-үземне белә-белгәннән, уку-язу таныганнан бирле ул вакытларда «Совет әдәбияты» исемен йөртүче бу журнал миңа теге яки бу дәрәҗәдә таныш. Безнең гаиләдә ул бераз бәхәс, тавыш та чыгаргалап ала иде. Аның яңа саны килүгә абый белән апа журналны әүвәл уку өчен тарткалашып та алуларын хәтерлим. Миңа, сеңелкәшкә алардан соң гына эләгә. Әмма әнкәй еш кына кычкырып укырга куша иде. Сукыр лампа янына тезелеп утырабыз: беребез укый, калганнарыбыз тыңлап тора. (Г.Әпсәләмовның сугыш турындагы әсәрләрен хәтта әле икешәр мәртәбә дә кычкырып укыдык бугай). Бераз танышкач, тәэсирләр белән уртаклашып алабыз. Әнкәй үзе дә андый әңгәмәләргә еш кына катнашып китә иде. «Совет әдәбияты»н китапханәдән, күршекүләннән алып укуны да хәтерлим. Бу журналны уку безнең гаилә өчен, ничектер, ашау, йоклау кебек зарури бер гамәлгә әйләнде. Ул вакытта әле радио-телевидение безнең өчен юк. Дөнья, яшәеш-тормыш турындагы мәгълүматларның шактыен без «Совет әдәбияты» аркылы алдык. Татар әдәбиятындагы күп кенә әсәрләр безгә журнал вариантында кереп калды. Үскән саен журнал белән кызыксыну артканнан-арта барды. VII сыйныфлардан бу мәҗмуганы башыннан азагына кадәр уку, аның белән танышып чыгу гадәти бер күренешкә әйләнде. Студент елларында инде без фәкыйрегез үзенә күрә бер тәнкыйтьчегә дә әйләнеп китте. Хәтта бераз төрттеребрәк «Безнең Белинский» дип әйтүләр дә ишетелгәләде. Мәкалә рецензияләр язам, гәҗит-журналларга илтәм. Әмма аларның күбесе басылмады. 60 нчы елларда Рафаил Төхфәтуллинның «Йолдызым» повесте бик популяр иде. Аның хакында без университетта китап укучылар конференциясе дә уздырдык. Авторның үзен дә чакырдык. Мин төп докладны ясадым. Бу чыгышны рецензия рәвешендә хәтта «Совет әдәбияты» да бастырып чыгарды (1962 ел, –№7.– 143-146 б.). Журналда бу минем тәүге публикациям иде. Алга таба бик саранланып кына булса да, мәҗмуга миңа ишекләрен ача башлады. Бераздан, мәсәлән, Ч.Айтматов әсәрләренең татарча басмасы чыгу уңае белән язылган «Гади кешене олы итеп» дигән мәкаләм дөнья күрде (1966 ел, № 6). Ә инде журнал исемен алыштыргач, төгәлрәге 70 еллардан башлап, мин мәҗмуганың даими авторларының берсенә әвереелдем. Ике дистә елдан артык «Казан утлары»ның редколлегия әгъзасы да булып тордым. Журнал хакында аерым мәкаләләр язарга, чыгышлар ясарга да туры килде. Аларның шактые гәҗит-журналларда, төрле җыентыкларда басылып та чыкты. Минем ярты гасырдан артыкка сузылган педагогик, уку-укыту эшчәнлегем, фәнни тикшеренүләрем дә бу журнал белән тыгыз бәйләнештә барды.

Андагы материалларны мин шәкерт-студентларыма, хезмәттәшләремә дә җиткереп барырга тырыштым.

Бер гасырлык яшәү дәверендә төрле исем-атамалар белән йөртелгән хәзерге «Казан утлары» меңьеллык сүз сәнгатебезнең, милләтебез яшәешенең төп, магистраль елында туган күренеш. Аның тууында, яшәешендә Г.Ибраһимов, Һ.Такташ, М.Җәлил, Г.Бәширов, Х.Туфан, С.Хәким һәм башка бик күп каләм әһелләребезнең өлеше бар. Бу журнал соңгы дәвер татар әдәбиятының үзенә күрә бер мәркәзе, штабы кебек тә булды. Күпчелек әдипләребез укучыларга журнал аркылы танылды. Соңгы гасырдагы милли- рухи, мәдәни тормышыбызны без, гомумән, бу мәҗмугадан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Хәзер бездә татар телендә дистәләгән журнал чыгып килә. Әмма, шуңа да карамастан, «Казан утлары» беренчелеген, лидерлык вазифасын, сүз сәнгатебезнең үсеш дәрәҗәсен билгеләүче бер барометрлык функциясен хәзер дә саклый. Ул, иң беренче чиратта, әдәби журнал. Әмма бу мәҗмуга билгеле бер дәрәҗәдә гомуммилли вазифаларны да үтәп килә. Анда, әдәбият-сәнгать материаллары белән бергә, тарихи, сәяси, мәгърифәти мәсьәләләр дә яктыртыла, милләтара бәйләнешләр дә игътибардан читтә калмый. Кыскасы, «Казан утлары» рухи-мәдәни, иҗтимагый-милли тереклегебезнең үзенә күрә бер елъязмасы да булып тора.

Миңа Төркиядә, элеккеге СССР составындагы милли республикаларда, аеруча Казакъстанда, Үзбәкстан, Төрекмәнстан җөмһүриятләрендә еш булырга туры килә. Шунысы мөһим: бу мәмләкәтләрнең шактый гына зыялылары «Казан утлары»н белә, аның эшчәнлеген уңай бәяли. 2018 елның апрелендә, мәсәлән, мин Дүшәнбе каласында халыкара конференциядә катнаштым. Очрашу-әңгәмәләр вакытында дистәләгән таҗик әдип-галименең безнең мәҗмуга хакында белеп сөйләүләре без фәкыйрегезне бик тә сөендерде. Биредәге Милли университетның кафедра мөдире Мортаза Зәйнетдинов, мәсәлән, татар-таҗик әдәби бәйләнешләре, «Казан утлары» турында махсус мәкалә-хезмәтләр дә язган.

«Кадрлар барысын да хәл итә», – дип, юкка гына әйтмиләрдер. Журналның озак еллар буе абруйлы басма булып килүендә анда эшләгән һәм хәзер дә хезмәт куючы баш мөхәррирләренең, хезмәткәрләренең роле искиткеч зур. Болар арасында Г.Кашшаф, Р.Мостафин, Н.Арслан, Р.Фәйзуллин, Т.Әйди, К.Кәримов һәм башка бик күп билгеле затларны атап китәргә була. 40 елга якын журналның поэзия бүлеген җитәкләгән күренекле шагыйрь Рәдиф Гаташ эшчәнлеге үзе генә дә махсус бер мәкалә-язмага соралып тора. Бу истәлекле юбилей алды көннәрендә аларның һәммәсенә дә, шулай ук күпләгән авторларга рәхмәт әйтәсе килә. Киләчәк көннәрдә дә «Казан утлары» үзенең остазлык, беренчелек позициясен саклап, туган тел, милләтебез мәнфәгатьләре өчен көрәштә фидакарьлекнең бер өлгесе, үрнәге булып калсын иде.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ

Тәрҗемәче, мөхәррир-журналист Абдулла Гомәр (Габдулла Закир улы Гомәров). 1958-1963 елларда «Совет әдәбияты» журналының баш мөхәррире.

«Совет әдәбияты» журналының редколлегия әгъзалары һәм хезмәткәрләре. Алгы рәттә утыралар (сулдан уңга): Нил Юзиев, Фатих Хөсни, Абдулла Гомәр, Габдрахман Әпсәләмов; арттагы рәттә: Малик Хәмитов, Яхья Халитов, Вил Ганиев. 1958 ел.





Газиз Мөхәммәтшин «Совет әдәбияты» журналының 1963-1965 еллардагы баш мөхәррире.



Бөек композитор Нәҗип Гаяз улы Җиһанов (1911-1988). СССРның халык артисты. СССРның Дәүләт (1948,1950,1970), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт (1958) премияләре лауреаты. Социалистик Хезмәт Герое (1981). 1980 елда төшерелгән фото.

Драматург Юныс Әминов (1921-1982) – «Язылмаган законнар», «Тамырлар», «Гөлҗәннәтнең җәннәте» һ.б. пьесалар авторы. Бу айда аның тууына 100 ел.

Фирдәвес Гариф кызы Гарипова (1941-2014) – филология фәннәре докторы. Дистә еллар буе «Казан утлары» журналының даими авторы булды. Галимәнең төп хезмәтләре Татарстанның җир, су, торак атамалары тарихына багышланган.

Туфан Миңнуллинга 60 яшь тулган көннәрдә аның туган ягында. Сулдан уңга: Рабит Батулла, партия өлкә комитеты секретаре Рәис Беляев, Әсхәт Хисмәт, (...), Туфан Миңнуллин, Фәиз Зөлкарнәй, Гариф Ахунов. 1995 ел.

Татарстанның ПЭН-клуб әгъзалары (сулдан уңга): Марсель Галиев, Миркасыйм Госманов, Нур Әхмәдиев Словения, Любляна шәһәрендә. 2005 ел.

Сәхифәне **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

Мөдәррис Әгъләмовның тууына – 75 ел

ЕРАККА КИТҮЛӘР... САГЫНДЫРА

Мөдәррис Әгъләмовның шигъри таланты Ходайдан бирелгән. Аның шәхси язмышы, бу очракта без аның бала чактан әти-әнисен югалтып, апасы Рәсимә тәрбиясендә сугыштан соңгы ачлы-туклы тормыш һәм хезмәт авырлыкларын үз җилкәсендә татып үсүен дә, Казан университетына шагыйрь-әдәбиятчы булам дип укырга килгәч, атнасына бер тапкыр көне буе автомат сүттереп, устав ятлатып, кырда булмаган дошман белән сугыштырып... синең җилегеңә үткән хәрби кафедралар белән уртак тел таба алмавын да, матди һәм рухи-психологик каршылыклары кирәгеннән артык күп булып (ул елларда Казанда нибарысы өч татар мәктәбе калуын искәртеп үтик), ятим яшүсмерләргә хас булганча, гади халык һәм милләт фаҗигасен үз тәкъдиредәй кабул итүендә, гомумән, алдагы бөтен иҗат-яшәеш рәвешенең шушы фидакарь дәрвишлек фәлсәфәсенә барып тоташуын истә тотабыз.

Ике курсны тәмамлагач, укуын өзәргә мәҗбүр булган егет 1968-1973 елларда Тукай районының Яңа Гәрдәле урта мәктәбендә тарих укытучысы, аннары Чаллы шәһәрендәге Халык театрында режиссёр ярдәмчесе булып эшли. 1974 елдан кабат Казанга килә һәм, газета-журнал редакцияләрендә вакытлыча эшләп алуларын исәпләмәгәндә, профессионал язучы сыйфатында фәкать иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Дөньяга мондый әрнүле, җаваплы һәм үзенчәлекле карашның нәтиҗәсе, табигый ки, шагыйрьнең бөтен иҗат эволюциясендә дә ачык чагылыш тапмый калмый.

* * *

Әнисен юксынып, иң беренче язган һәм басылып чыккан «Истәлекләр» (1958) шигыреннән башлап, 1965 елда Казанга килгәнчегә кадәрге мәктәп чоры шигырьләрен без авторның беренче өйрәнчек шигырьләре итеп карый алабыз. Аларның күбесе Зәй район газетасында, шул исәптән Татарстан һәм Башкортстанның балалар матбугатында даими басылып килгән яшь каләм иясе әсәрләре буларак тәкъдим ителә.

Авторның шулай ук җиде елга сузылган икенче иҗат чоры Казан дәүләт университетында укыган көннәреннән башланып, актив рәвештә күмәк җыентыкларда («Беренче карлыгачлар», 1969; «Шигырь бәйрәме», 1969, 1970; «Идел» альманахы) һәм үзенең ике мөстәкыйль китабын («Кыңгырау», 1970, «Учак урыннары», 1973) бастырып чыгарган елларын үз эченә ала. Шул ук 1973 елда ул СССР Язучылар берлегенә кабул ителә. Бу чорны, һич икеләнмичә, шагыйрь иҗатының иң югары күтәрелгән «классик чоры» дип атарга була. Аның иң яхшы егермеләп шигыре дә нәкъ әнә шушы вакыт аралыгында иҗат ителгән.

Шагыйрь иҗатының өченче чоры итеп, без авторның 1974 елда кабат Казанга килеп, соңгы көннәренәчә (2006) яшәп иҗат иткән утыз биш еллык гомерен күзаллыйбыз. Бу чор авторның нигездә сюжетлы шигырьләр, балладалар һәм публицистик яңгырашлы әсәрләрен, монолог-поэмалар язуы белән характерлы («Акмулла арбасы» (1981), «Тукайдан хатлар» (1972-1985), «Киләчәккә кайту» (1987), «Мин әйттем...» (1992), «Иман тәрәз шакый» (1996), «Кан тамырын кистем» (2001) шигъри китаплары).

* * *

Соңыннан калын-калын сайланмалары басылса да, авторның икенче иҗат чорына караган иң әүвәл чыккан «Кыңгырау» (1970) һәм «Учак урыннары» (1973) дип исемләнгән ике китабы шагыйрь иҗатының үзәгендә ята. Аларга махсус тукталып үтми торып, безгә калса, шагыйрь иҗатының төп үзенчәлеген дә, аның әдәбиятыбыздагы объектив урынын да аңлау һәм аңлату һич мөмкин түгел. Әлеге китаплар безгә шагыйрьнең табигый талантын бик ачык күрсәтеп-дәлилләп торучы конкрет мисалларны үз эченә ала.

«Кыңгырау» китабына кергән шигырьләрнең композицион ягы әле тиешле камиллектә дип әйтеп булмаса да, авторның поэтик фикерләү куәсе аларда ярылып ята. Бу яктан караганда, әлеге җыентык шагыйрь иҗатының чын мәгънәсендә өлгерү лабораториясен чагылдыручы китап булып тора. Киләчәктә классик камиллектә үсеп чыгасы шигърияттнең ул чишмә башы.

Инде сүзне шигъри фикерләүнең үзенә бирик: *Ак патшаның кара хатларын да / Китергән ул почта атлары... / Авыр яраларны ачкан сыман, / Ачкан хатны илнең картлары.* («Уфа юлы»).

Шигырьне, тулаем алганда, сайланмаларга кертергә лаек дип әйтә алмасак та, биредә инде укучы, һичшиксез, авторның колачлы поэтик җегәрен тоймый калмый.

Ә менә «Туган якларыңнан киткән чакта...» шигыренең төп сайланма мираска кертелмәве инде безнең күңелдә шактый гына ризасызлык та тудыра: *Туган якларыңнан киткән чакта / Җырсыз китәрмен дип уйлама: / Җырсыз чыгулары мөмкин түгел / Мәшәкатьләр тулы дөньяга.*

Монда нәкъ менә Мөдәррис шигъриятенә хас кыю, ярсу-дуамал, кодрәтле поэтик көч ташып тора. «Мичкә керсәң, койрыгыңнан таныйм...» дигән шикелле, әлеге шигъри хис ташкынын башка шагыйрьләрнең шигъри язмасы белән бутау һич мөмкин түгел. *Адашмаган кеше юл эзләми, / Юл табылмый әле тиз генә... / Ялгышларым белән җирдән китсәм, / Үз ялгышым калсын үземә.* («Балам, бәгърем, диеп»)

Әлеге юлларда инде шигъри фикерләү генә түгел, безнең алга кыю чыгып баскан фидакарь шагыйрь шәхесе дә күренми калмый.

Беренче китапка кергән бу шигырьләрдә шагыйрьнең катлаулы социаль төркемнәр психологиясен олы рәссамнарча гаҗәеп төгәл ачып салган шедеврлары белән дә очрашабыз. Аларга укучы буларак сокланырга гына кала. Биредә шагыйрьнең нечкә психологик күзәтү сәләтенә ия булуын гына түгел, фәлсәфи диалектика законнарын тирән үзләштерүенә дә һич шигебез калмый: *...Кемнәр көлеп, кемнәр белеп йөри, / Кемнәр эзли, таба, бутала... / Буталганнар кайчак юл табалар, / Көлеп йөргәннәре туктала.*

Никадәр төгәл фикер, нечкә тоемлау һәм реаль картина!

Соңгы строфада шагыйрьнең идея-фикерен гомумиләштереп белдерү таланты, әсәрне композицион яктан да гаҗәп төгәл йомгаклап кую осталыгына ирешүе бик ачык күзгә ташлана: *Тормыш үзе дә бит кешеләр кук, / Аңарда да никтер мең гадәт... / Ул да кайчак аягүрә бара, / Кайчагында бара үрмәләп.*

Бу шигырьне сайланма җыентыкларга кертергә күзләре җитмәгән төзүчеләр белән инде монда бәхәсләшеп торырга да урын юк кебек, бары уфтанырга гына кала.

Шагыйрьнең «Кош» шигыре дә безне шәхесләр психологиясен ачу тирәнлеге белән сокландырмый калмый. Шигырь «кошларын төшлеккә йоклаткан» – тынып калган урманга багышланган: *Бары бер кош кына йокламый нигәдер, / Берүзем – ни ямь бар, ни шатлык, ни кадер? / Күрәсең, аңарда бик нечкә бәгырьдер... / Ул кошлар илендә, мөгаен, шагыйрьдер.*

Ниһаять, шагыйрь әлеге беренче китабында үз буынының киләчәк еллар каршында әле көчсез-зәгыйфь тә, өметле һәм кодрәтле дә булган тарихи урынын ачыклап күрсәтеп бирүгә ирешә: *Безнең әле килер язлар алда, / Вәгъдә бирсәк – ялган сүз түгел. / Без әлегә сукбай малай гына, / Без хәзергә әле без түгел.* («Без – курпылар».)

Соңгы – 2016 елда басылып чыккан иң тулы басмаларның берсе «Еракка китеп кара» китабында (479 бит) шагыйрь иҗатының үзәгендә торган әлеге шигырьнең дә урын алмавы бик аяныч, әлбәттә.

Алда китерелгән шигъри өзекләрдән чыгып, без ныклы бер фикергә киләбез: 31 генә шигырьдән торуына да карамастан, әлеге беренче китап авторга үзенең шигъри фикерләү үзенчәлеген дә, тормышта шигъри сүзен әйтү кодрәтен дә күрсәтүгә мөмкинлек биргән.

89 шигырен үз эченә алган икенче китабы – «Учак урыннары» (1973) исә шагыйрьнең дистәләгән иң яхшы классик шигырьләрен тәкъдим итүе белән әһәмиятле. Менә бу урында әдәбиятыбызның шушы чордагы гомуми үсеше, ягъни М.Әгъләмовның нинди объектив шартлар эчендә татар шигъриятенә килеп керүе турында да берничә сүз әйтеп үтик.

50 нче еллар – татар шигърияте үсешенең шактый авырлык кичергән еллары. Тематиканың шактый чикләнгәнлеге, идеядәге шаблон ура-патриотизм, эстетик тасвирның коры сөйләп чыгу, шома такмак коруга кайтып калуы һ.б. сыйфатлар – аның бу еллардагы иң характерлы үзенчәлекләре. Классик шагыйрьләребезнең киң катлам укучыларыбызга 20-40 нчы еллардан соң шактый урау юллар белән әйләнеп кайтуын да биредә аерым ассызыклап әйтеп үтәргә кирәк: (Муса Җәлил. Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр (1953), Габдулла Тукай. Әсәрләр, дүрт томда (1955-1956), Шәехзадә Бабич. Сайланма әсәрләр. (1958), Хәсән Туфан. Җырлар, шигырьләр. (1958), Дәрдемәнд. Сайланма әсәрләр. (1959) һ.б.).

Ниһаять, шушы бушлыкны тутырырга теләгәндәй, шигъриятебездә Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов шигырьләре калкып чыкты, 60 нчы еллар уртасыннан яңа бер шау-шулы вакыйга буларак Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим исемнәре килеп керде, алар эзенә үк басып, Рәшит Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәтнең поэтик сулышы төсмерләнде, дулкын-дулкын булып аларга тагын берничә төркем шагыйрьләре килеп кушылды. Монда, һичшиксез, төп казаныш – шигъриятебезне бу чорда күрелмәгән биеклекләргә күтәргән яңа шигъри фикерләү ташкыны иде. Мөдәррис Әгъләмовның беренче китабында укучы барыннан да элек әнә шушы поэтик яңарышны күрде. Аны әлеге яңа заман шагыйре буларак кабул итте.

Инде икенче китабында бер-бер артлы тезелеп киткән камил шигырьләре киң катлам укучыны гына түгел, поэзиябезнең тәҗрибәле аксакаллары Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәр күңелен дә чын мәгънәсендә тетрәтеп-илһамландырып җибәрде. Бу җыентыкка язган керештә Сибгат Хәкимнең яшь шагыйрь иҗатына карата әйткән сокланулы сүзе-бәясе шул хакта сөйли.

* * *

Бу икенче китапка кергән иң зур поэтик табышларның да нигезендә, һичшиксез, авторның шигъри фикерләү хасияте ята. Алар барыннан да элек халыкның үз күңеленнән чыккан әрнүле-сызланулы йөрәк авазы булып кабул ителә. Алар гади-аңлаешлы да, бер үк вакытта югары поэтик югарылыктагы эстетик кыйммәткә дә ия. Алар Акмулла, Тукай, Бабич рухы белән сугарылган. Сөрсегән торгынлык елларындагы мәдәни-сәяси атмосфераны кинәт сискәндереп-айнытып җибәрә торган шәхес иреге, милләт азатлыгы кебек мәңгелек идеяләрне яңа заманда шигъри телдә яңгырата алуы белән дә М.Әгъләмов үзенең югары профессионал шагыйрь исеменә лаек булуын тагын бер кат раслый алды.

Иң әһәмиятлесе шунда, нинди генә темага килеп кагылмасын, шагыйрьнең табигатьтән бирелгән шигъри фикерләү сәләте һәрвакыт үзеннән аерылгысыз. Кайчакта ул логик фикерләү каршылыгы буларак барлыкка килә: *Әмма кояш күтәрелгән саен, / Кечерәя бара күләгә.*

Әсәрдәге моннан соңгы фикер-хис үстерелеше дә шушы логик каршылык

тудырган шартлы хикмәтнең дәвамы буларак үстерелә: *Күтәрелде кояш. Сезгә инде / Конвойларсыз кайтыр чак җиткән.* («Кайтасылар», 1966.)

Шигъри күрү сәләте тасвирда сиземле табигать рәсеме яисә халәт картинасы буларак та гәүдәләнә: *Кайчак күлдә йолдыз бәргәләнә.* («Төнге тынлык», 1970.)

Бу сиземле сурәтләр, табигый ки, авторның фикер-идеясен югары очышка күтәргән армас-талмас канатлары алар. *Буй җитеп, яуларга китеп / Кире кайтмаса бала, / Аналар өйдә, бишекләр / Чормада ятим кала, чормада...* («Матчага элгән силә», 1971.)

Әсәрдә шигърият еш кына сиземле картина һәм логик фикерләүнең синтезы – метафоралы микросурәт буларак калкып чыга: *Тасма-тасма булып юллар кала, / Казан сөлгеседәй җилфердәп.* («Кайтып барам», 1970.)

Шагыйрь үзенең шигырьләре композициясен поэтик шартлылыкның гомумиләштерү хасиятенә корырга ярата. Бу хакта сүз барганда, укучы өчен иң әүвәл аның «бер каптырмалы» гомумиләштерүләрен – шигъри параллельләргә нигезләнгән кыска, җыйнак шигъри этюдларына тукталып үтү кызыклы булыр дип уйлыйбыз.

«Сабантуй» (1966) шигыре, әйтик, ике композицион өлештән оеша. Аның беренчесе гап-гади бер Сабантуй күренешен тасвирлаудан тора: *Мәйдан күк кысыла йөрәкләр:/ Бирмә биленңне! / Бирмә - ә - ә...*

Икенче өлештә бу халәт киңәйтеп, гомумиләштерелеп – инде халыкның дошманы белән көрәшү ситуациясенә күчерелеп яңгырый: *Мәйдан күк кысыла бар халык: / Бирмә илеңне! / Бирмә - ә - ә...*

«Кайтулар» (1966) шигыренең поэтик табышы да әнә шундый параллель психологик ике эпизод аерымлыгын янәшә куюга нигезләнгән: балачакта уйнап-үскән таулар дөнья гизеп кайткан егеткә үр генә булып тоелса, аның картлык көннәрендә алар кабат биек тауга әверелә.

«Учак урыннары» (1969) шигырендә исә поэтик гомумиләштерүләрнең нигезенә лирик геройның ассоциатив кичерешләре алына: атларын эзләп йөргәндә килеп очраган көйгән һәм курпы тишелмәгән учак урыннары аңа «ләхете иңеп төшкән кабер»не хәтерләтә, әлеге көтелмәгән – «яшь йөрәкне урыныннан куптарырлык» күңел шомлануы, көчәеп, шигырь үсешен масштаблы поэтик тасвир-белдерү юнәлешенә борып җибәрә: *Җир шарына тәңгәл / Болын шундый чуар... / Монда синең Болгар, / Монда синең Суар,–/ Болын шундый чуар, болын шундый чуар.*

Шагыйрнең иң тәэсирле шигырьләреннән берсе «Еракка китеп кара» (1967) шигыре дә шушы реаль тормыштагы бер ситуацияне, гомумиләштереп, аны яңа фәлсәфи идея белдергән шигъри яңгырашлы поэтик орбитага чыгару үрнәге булып тора.

Лирик герой Пионерлар йортында рәсемнәр карап йөргәндә, «Абый, әйдә, син монысын еракка китеп кара!» дип тәкъдим ясалуы абыйлары аңында фәлсәфи-шигъри яңа үлчәмнәр тууга сәбәпче була: *...Үз халкыңның киләчәген, / Үткәнен, бүгенгесен; / Кайгысының, шатлыгының / Зурлыгын белер өчен / Еракка китеп кара син, / Еракка китеп кара!*

Шагыйрьнең масштаблы шигъри фикерләве, әнә шул рәвешчә, үткәннәрне дә, киләчәкне дә, бүгенгене дә концентрацияләнгән бер психологик берәмлеккә төйнәп кую көченә ия. Шагыйрь кулында мондый кодрәт булу – аның үз заманы каршылыкларын гәүдәләндерүдә алыштыргысыз бер чара. «Җил дә җил» (1965) шигыренең поэтик гомумиләштерүе беренче һәм соңгы строфалар аерымлыгыннан үсеп чыга: *...Тынгысыз җилләр йөрәккә / Иртә дә, кич тә керә... / Җил дә җил... / Чаганнар түгел, / Заманнар аягүрә.*

* * *

Икенче китабында шагыйрь шулай ук психологик рәсемнәр ясау осталыгын үстерүгә дә зур игътибар бирә.

Остазы Хәсән Туфанга багышланган «Төн буе утырсаң...» (1969) шигырендә автор бу реальлеккә метафора аша ирешә: *Әйтсеннәр: «Тынмаган / Ул нинди җан икән?» / Шигырьләр сыктым мин, / Кан икән, кан икән.*

Каләмдәше Рәшит Әхмәтҗановның җәмәгате Луиза ханымга багышланган «Карага – кара җеп...» шигырендә геройның эчке портреты берничә баскычлы штрих белән җанландырыла. Беренче строфада автор башлыча аның тышкы рәсеме, шөгыле һәм лирик геройга мөнәсәбәтен ача: *Пушкинның нянясы шикелле / Син безгә тынычлык саклыйсың... / Карага – кара җеп... / Тырышып, / Энәгә кара җеп саплыйсың.*

Моннан соңгы строфаларда автор укучыны үзенең яраткан алымы – шигъри гомумиләштерүләр аша олы тормышка алып чыга: *Безне дә кешелек бу көндә / Яктыга җибәреп күзәтә... / Карага – кара җеп, / Акка – ак, / Бутасаң барыбер төзәтә...*

Ул гына да түгел, шушы ук реаль тормыштан тотып алган шигъри деталь ярдәмендә шагыйрь әсәренә салынган төп фәлсәфи фикерен – әсәрнең идеясен яңгыратуга ирешә: *Табигать салган бер орлык бар, / Җыр сөйгән йөрәктә кара юк... / Җырда да шулай ук... җырда да / Акка – ак, карага – кара җеп.*

* * *

Шигъри тасвирланган портретлар белән эш итү шагыйрьнең алдагы җыентыкларында да урын ала. Аның әнисенә багышланган «Бердәнбер» шигырендә якты, фаҗигале поэтик гомумиләштерү ярымсюжетлы баллада жанры аша әсәрнең исеменә үк чыгарылып, төрле тарихи тормыш ситуацияләрендә үзгәрмәс бәя рәвешендә кабатланып килгән күпкырлы психологик халәт деталенең символлашуы ярдәмендә тормышка ашырыла.

«Акмулла арбасы» һәм «Тукайдан хатлар» поэмаларында автор геройлары портретын ачуда поэтик тезмә-шигырь, цикллар рәвешен сайлап ала. Безгә калса, әсәрләргә бу билгеле бер күләмдә таркаулык бирә, аның бербөтен яну-мөнәсәбәт ялкынын беркадәр сүрелдерә төшә.

Шагыйрь исә фәлсәфи ачкычлы нечкә лирик кичерешләрендә: *Ничә төшмим – төнге сулар / Ярга тиеп авыр сулар... / Моңы барның йөрәгеннән / Һәрвакытта җылы чыгар. / Соңга кадәр үзе туңар.* («Төнге сулар».)

Яисә чичәннәрдәй логик контрастлы фикер һәм хикмәтле белдерүгә корган шигырьләрендә һәрвакыт үз стихиясендә, аның көче шунда: *Киләчәккә барасы бар, / Саубуллашыйк, йәгез. / Ачыгыз тәрәзәләрне, /Булса тәрәзәгез.* («Тәрәзәгез булса...»)

Шагыйрьнең бер генә зур шигырь кичәсендә дә укымый калдырмаган, замандашларыбыз һәрчак әсәрләнеп кабул иткән «Китә алмыйм...» шигыренә дә тукталып үтик.

Ул ике төп үсеш этабыннан гыйбарәт. Беренчесе – каршылыклы, гөнаһлы реаль тормыш – мәхәббәт эпизоды: *Без йөзәбез... Дөнья ап-ак күбек. / Без йөзәбез менә шашкан кебек, / Безгә тәкъдир язган бөтен ләззәт / Бергә килеп, баштан ашкан кебек. / Мин китәргә тиеш таңга чаклы, / Ә бу кичә кабатланачакмы? / Кабатланачакмы бу кичә – / Китә алмыйм шуны белмичә.*

Монысы лирик герой күңелендә купкан беренче башлангыч шомлы уй. Алга таба ул, тагын һәм тагын кабатланып, көчәя, тирәнәя, социальләшә барып, киләчәк буыннар, милләт язмышы, җәмгыять, кешелек масштабына җиткерелеп яңгыраган фаҗигале бер заман соравына әверелә: *...Киләчәккә бара алмый кеше, / Бара алмый шуны белмичә.*

Шигырьнең төп көче әнә шушы киң яңгырашлы заман проблемаларын, уч төбедәй бер экспрессив ноктага төйнәп, укучы аңына җиткерә алуында түгелмени?! Әлеге сыйфат исә авторның талант кодрәте турында сөйли. Шунысын да өстәп әйтергә кирәк: ярты гасыр элек язылган бу шигырь бүгенге көндә тагын да актуальрәк булып яңгырый. Яшерен-батырын түгел, ераккарак киткән саен... бүгенге әдәбиятыбызда һәм бүгенге тормышыбызда бу юлларның авторы да безне күбрәк сагындыра бара!

Равил РАХМАНИ

Сибгат Хәкимнең тууына – 110 ел

СИБГАТ ХӘКИМ УРАМЫНДА



Без сиксәненче елларда яшәгән Театр урамындагы йортыбызның тәрәзәсеннән Казансуның каршы ягындагы сазлыклы яры ачык күренеп тора иде. Анда биек булып үлән үсә, җикән камыш чәчәк ата. Җәен мин еш кына Казансуда су керәм. Ишегалдыннан туп-туры Фукс бакчасына чыгам да озын агач баскыч буйлап, зур булмаган пляжга төшәм. Анда беркем дә булмый диярлек. Пляж дип тә мин аны үзем генә атыйм. Әйләнә-тирәсендә чүп-чар, буш шешәләр ауный, куаклык, америка өрәңгесе баскан. Анда кояшта кызынырга да җай юк. Яр буенча шактый ук көчле агым, су салкын, озаграк коенсаң, аякны көзән җыерырга да мөмкин. Көзән җыера калса дип, үзем белән булавка йөртәм, кирәге чыкканда, аны туп-туры балтырга кадыйм, көзән җыеру шунда ук бетә.

Гадәттә, мин каршы як ярга таба йөзеп китәм, анда су сай, кояшта җылынган була, сәгатьләр буе судан чыкмыйча ятарга мөмкин. Елганың ул ягында арыш йә бодай басуы дулкынлана. Хәзер бу урыннарда биек йортлары белән торак квартал үсеп чыкты, стадионнар, кунакханәләр, ресторан, кибет, аттракционнар гөрли, әйтерсең лә, бөтенләй ят шәһәр. Матур, чыннан да, монда бөтенләй башка тормыш кайный.

Сибгат Хәким урамы минем катнаштан башка гына барлыкка килмәде. Татарстан Министрлар Кабинетының этиемнең исемен мәңгеләштерү турындагы карарында мэриягә Казанның бер урамын аның исеме белән атау бурычы йөкләнгән иде. Мэриядән тәҗрибәле бер иптәш миңа исемне әле төзелмәгән урамга кушарга кирәклеге турында киңәш бирде. Чөнки инде нинди дер исем йөрткән урамның исемен алмаштыру бик мәшәкатьле, анда яшәүчеләрнең пропискаларын һәм башка күп төрле документларны үзгәртү белән бәйле һәм бу кешеләрдә ризасызлык тудыра.

Казансуның уң ягында яңа төзелә торган урамның исеме юк, төзелеш документларында ул нинди дер кодлы номер белән генә билгеләнеп йөртелә иде. Мэриядә бу урамга Сибгат Хәким исемен бирү турында карар уңай хәл ителде һәм мин әле ике-өч кенә йорты төзелә башлаган кварталның үсешен, аның тулы бер проспектка әверелүен кызыксынып күзәттем. Тиздән анда зур, биек йортлар калкып чыкты, стадион, ял һәм күңел ачу учреждениеләре, пляж барлыкка килде.

Радио-телевидениедән Сибгат Хәким урамын еш искә алып сөйли башладылар, матбугатта яздылар. Үз урамың барлыкка килүен күрү җанга рәхәтлек, күңелгә хушлык бирә.

Бер елны Тарих институты коллективы белән без Сибгат Хәким урамына юкәләр утыртуда катнаштык. Хәзер анда минем үз юкәм үсә.

Казанда безнең күршеләребез һәм дусларыбыз исемендәге урамнар барлыкка килде. Кайчандыр Аккош күлендәге дачаларда бергә яшәгән бу кешеләрнең урамнарыннан узу күңелдә сәер тойгылар уята...

Иртәләрен мин Татарстан радиосын җибәрәм, анда гел элекке җырларны тапшыралар. Еш кына Сибгат Хәким шигырьләренә иҗат ителгән җырлар да яңгырый. Кайчагында кем җыры икәнен дә игълан итмиләр, ләкин мин аларны белеп торам, чөнки заманында әтиемнең шигырьләрен татар хәрефләренә көйләнгән «Москва» машинкасында үзем бастырып, аларның беренче укучысы булган идем. Әтием шулай итеп, минем күңелдә яшәвен дәвам иттерә.

Кем портреты?

Бер журналист телефон буенча гына интервью алганда, үзенчә кыланып сорап куйды:

– Сезнең кабинетта баш өстегездә кем портреты эленеп тора?

– Сибгат Хәкимнеке.

– Шәймиевме, Ельцинмы дип сорыйм, – дип кабатлады.

Ул чакта да хәзерге шикелле үк Татарстанда бөтен түрәләр Президент портретын, кайберләре ике Президентныкын – Россиянекен һәм Татарстанныкын элеп куя торганнар иде. Ә минем баш өстендә – әтиемнең портреты. Миңа аның портреты ошый. Ул әле хәзер дә өйдәге эш бүлмәмдә минем баш өстемдә эленеп тора. Әтием анда исән чагындагы кебек үк, җиңелчә генә елмаеп карый, әйтерсең лә, шулай мине күзәтә...

– Юк, Сибгат Хәкимнеке, әтиемнеке, – дидем мин, кабатлап.

Миңа һәрчак үз уйларымны һәм гамәлләремне аның карашы белән тәңгәлләштерергә туры килә. Аның тормышта бар нәрсәгә карата да, нинди генә катлаулы булмасын, үз карашы бар иде. Анда аның планетар фикерләү рәвеше булды – гомере буе авыл турында, хәтта уналты гына йорттан торган тыкрык хакында гына язса да. Мине ул гаҗәпләндерә, мин аны аңларга тырышам; миңа калса, күп уйланулардан соң мин моның серенә төшендем булса кирәк. Һәм ул шактый ук өстә ята булып чыкты.

Татар авылы – ул кешеләр арасындагы төп мөнәсәбәтләр төенләнгән микрогаләм, алар бер үк принципларда, шәһәр яки республика, яисә тагын да зуррак дәрәҗәдә кабатланалар гына. Әгәр дә кеше үз авылында, үз урамында лидер була ала икән, киләчәктә ул зур коллектив җитәкчесе булып та китә ала, шәһәр яки республика белән идарә итәргә дә сәләтле була. Чыңгызхан, әгәр дә кеше ун сугышчы өстеннән командалык итә ала икән, йөз сугышчыга да җитәкчелек итә; мең кеше белән идарә итүне дә аңа курыкмыйча ышанып тапшырырга мөмкин, дип әйткән.

Татарстанда беренче затларның авыл белән бәйле булулары очраклы түгел, алар гап-гади крестьян гаиләсеннән чыкканнар, аграр институтларда укып, югары белем алганнар. Фәнни эшкә килгәндә, Казан университетының өстенлеге зур, ләкин аграр уку йортларын тәмамлаучылар җиргә, халыкка, аларның мәнфәгатьләренә якынрак, ихтыяҗларын яхшырак белә. Аларга җәмгыять белән нәтиҗәле идарә итү нигезендә яткан мөнәсәбәтләрне төзү җиңелрәк бирелә. Ләкин бу татар авылларына күбрәк кагыла. Рус авыллары белән хәл башкачарак, аларда мөнәсәбәтләр башкачарак корылган. Аларда алпавытлар хакимлек иткән, алар крестьяннарны бастырып торганнар, шуңа күрә руслар авыллардан шәһәрләргә күчү җаен караганнар. Рус авылларының елдан-ел кими баруы очраклы хәл түгел.

Мәзәкләр

Әти турында ул исән чагында ук төрле мәзәкләр сөйләнә иде. Алар яхшы, күбесе, нигездә, тормыштан алынган. Мин башка язучылар хакында шундый җылы мәзәкләрне бик белмим. Яшь шагыйрьләр аларны сөйләргә бик ярата торган иде. Күбесе аныңча итеп, аның сөйләү рәвешен китереп сөйләргә тырыша.

– Әтиең турында мәзәк ишеткәнең бармы?

– Бар, әлбәттә, – дим.

– Менә тагын берсен тыңла.

Әтидән бер мәҗлестә сорыйлар: «Сибгат абый, татарларның өч бөек шагыйрен атагыз әле?» – диләр. Ул уйланып тора да болай ди: «Беренчесе инде аның билгеле – Тукай. Икенчесе – Җәлилдер. Ә өченчесе... Егетләр, әйдәгез әле, күтәреп куйыйк».

Бүрек турында да мәзәк сөйлиләр иде. Урамда «Башка берни дә кирәкми» дигән шигырен уйлап йөргәндә, башыннан бүреген салдырып киткәннәр. Башка кирәк түгел икән, нәрсәгә киеп йөрисең аны, имеш...

– Чынлап та булганмы шундый хәл?

– Булган. Бер генә тапкыр да түгел. Мех фабрикасы аңа тагын бүрек бүләк итәргә булган. Без өйдә куркып калдык: затлы бүреген алабыз дип, үзен кыйнап китәргә дә мөмкиннәр бит. Шуңа күрә ул гади колакчынлы бүрек киеп йөрүне хуп күрә иде. Ул, гомумән, гади киенеп йөрде. Шулай бервакыт дачага аны телевидениегә төшерү өчен килгәннәр. Аны таба алмыйча йөриләр икән. «Кайда соң ул?» – дип, өйгә кергәннәр. «Ишегалдында йөридер», – дибез. «Юк, анда күренми. Иске плащ кигән каравылчыдан башка кеше күрмәдек», – диләр.

Ул кеше чынлап та әти булып чыкты.

Икенче бер тапкыр аны Җиңү көненә багышланган тантаналы җыелышка чакырдылар, орден-медальләреңне тагып кил, дип кисәттеләр. Ул озак карышты, яңа пиджагында тишекләр ясыйсы килмәде. Ахырдан медальләрен пиджагының эчке ягына тагып барды. Аның шунда төшкән фотосы соңыннан кирәк булган саен төрле басмаларда чыккалап торды.

Фронтның Курск дугасы кебек хәтәр урыннарында сугышмаган бик күпләрнең медальләре әтинекеннән күбрәк иде. Соңыннан мин бу хакта сорагач, ул миңа гади генә итеп: «Медаль тагып, фотога төшүчеләрнең күбесе штаб тирәсендә йөрүчеләр. Миңа сугышта штабтан читтәрәк, алгы позицияләрдә булырга туры килде», – дип аңлатты.

Бик еш кына алар иптәше белән дошман позицияләре янына күзәтү өчен дозорга җибәрелгәннәр. Немецларның нишләргә җыенуларын белеп, хәбәр итеп торыр өчен. Бүләкләү турында докладнойлар язганда, гадәттә дозордагыларны оныта торган булганнар. Әти орденнар артыннан кумаган.

Ул хезмәт герое да була алыр иде. Өлкә комитеты аны Язучылар союзы рәислегенә дә кыстап караган. Ләкин ул теләмәгән. Съезд буласы көннәргә туры китереп, санаторийга китеп барган. Аңа яхшы фатир, персонал машина, Хезмәт Герое дәрәҗәсе вәгъдә итәләр. Ләкин бәйсезлеге, шәхси азатлыгы аның өчен барысыннан да мөһимрәк иде. Ул беркайчан да хакимияткә каршы бармады, чыгышлар ясамады, үз фикерен үзендә тотарга тырышты.

Әтием, әлбәттә, минем өчен үрнәк иде. Әмма аның язмышын кабатлау мөмкин түгел. Заманнар үзгәрде, мин андагы кебек талантка да ия түгел. Ләкин мин бала чактан әтигә лаеклы булып үсәргә тырыштым. Хәлдән килгән кадәр шуңа омтылып яшәдем. Чөнки миңа еш кына «Сибгат Хәкимыч» яисә «Рафаэль Хәкимыч» дип мөрәҗәгать итәләр иде. Кайберәүләр шаяртып булса, икенчеләр хәтта моны ялгыш икәнен дә сизмиләр иде. Аның күләгәсе һәрвакыт минем янда йөрде. Тора-бара мин моңа күнектем һәм аларга гаҗәпләнми дә башладым. Шулай бервакыт әтием

биографиясендә кайбер нәрсәләрне тәгаенләргә кирәк булды һәм мин интернетка кереп, «Сибгат Хәким» дигән мәкаләне ачтым. Карасам, анда әти урынына минем фотоны элгәннәр. Бу инде арттырып җибәрү булып тоелды.

Гаҗәеп буын

Безнең бакчада соңыннан классик булып киткән язучылар яшәде. Әтинең үз туйлары хакында шигыре бар. Ул туй 1939 елда, ил өстендә кара болытлар куерган бер заманда булган. Польша инде Гитлерның аяк астында таптала.

Табында төп сый – гап-гади авыл катыгы. Аңа үзенчәлекле тәм һәм төс кертү өчен вак итеп турап, кызыл чөгендер салынган. Иң якын дуслар җыйналган. Моның ише мәҗлес белән кемне дә гаҗәпләндерүе кыен. Анда катнашучыларның күбесе өчен бу соңгы очрашу булып чыга.

Кайчакларда мин катыкка, ваклап туралган пешкән кызыл чөгендер салам да күз алдына китереп утырам: нәрсә турында сөйләштеләр икән бу булачак классиклар яшь, дәртле чакларында? Бәлки, татар халкының үсеше өчен мөмкинлек бирә торган республика турындадыр. Бөтен гомерләрен шушы эшкә багышлаган кешеләр тагын нәрсә турында сөйләшергә мөмкин соң?

Мин халыкның кимсетелгән язмышы, Сталин вакытында аның бөтен хокуклардан мәхрүм ителеп, автономия кысаларына кысрыклап кертелүе хакында сөйләшүләрне күп ишеттем. Хәзер әтинең дусларыннан күбесе әдәбият хрестоматияләрендә урын алды, аларны университетларда өйрәнәләр. Ә ул чакта алар гап-гади танышлар, күршеләр, дуслар булып кына яшиләр иде.

Бала чагымда мине җәй көннәрендә саф һава сулап килергә авылга җибәрәләр иде. Малайлар белән чабышып йөргәндә тамак ачыга, үтереп ашыйсы килә башлый; өйгә кайткач, миңа баздан катык алып чыгалар. Ул шулхәтле куе, хәтта кашык та басып тора; ипи белән шул катык минем көндезге ашым була торган иде. Аннан соң тагын урамга йөгерәм. Ә кичен барыбыз да куе токмачлы аш ашарга өстәл тирәсенә җыйналабыз. Башта аның шулпасын чөмереп бетерәбез, аннары токмачына ябышабыз. Авылда әнә шулай бар да гади, ләкин татарның бөтен зыялылары шул авылдан чыккан кешеләр.

Безнең дачада яшәгән классиклар да авылдан чыкканнар. Алар Тукай, Дәрдемәнд, Сәгыйт Рәмиев традицияләрен дәвам иттерүчеләр һәм әдәби хрестоматияләрнең калын битләрен тудыручылар. Бүген аларның урынын яшьләр алды. Мин алар турында берни дә белмим диярлек, кайчакларда кайберләре белән аралашырга туры килгәләсә дә. Минем хатирәләрем элекке буын тирәсендә калды.

Сибгат Хәкимнең Тукай турында иң яхшы поэмаларының берсе «Кырыгынчы номер» дип атала. Анда мондый юллар бар:

Өем тыныч. Аккош күле тыныч.
Тыныч түгел нигә бу җаным?
Чорны чорга якын куеп карыйм,
Вөҗданына аның – вөҗданым.
Өч гомерен аның яшәп җирдә,
Чагыштырыр эшем бармы соң?
Җырны җырга якын куеп карыйм,
Намусына аның – намусым.
Хакыйкатькә – хакыйкатьне, җанны,
Эзли күңел үзенең иясен,
Әйләнәмен аның тирәсендә,
Галәмдәге гади иярчен.
Эзли күңел, ник ул җитми һаман?
Ник борчуда уза күп айлар?

Калдырып зур мирас, нәрсәнедер
Алып китте кебек Тукайлар...

Хәзер минем Боровое Матюшинодагы бакчамда башка күршеләр, үзләренчә атаклы кешеләр. Бары тик җәйләрен кызы һәм оныклары белән Казанга кайткалап торучы Чулпан Җәлил генә миңа ал хыяллар белән тулган ваемсыз яшьлегемне искә төшерә.

Барысы да шулкадәр зур тизлектә артта калды. Һәм шулкадар зур тизлектә зәвыксызлык, казна талаучылар һәм вак интригалар заманы килде. Кешеләр, нигездә, кибетләрдә бәяләрнең үсүе һәм үзләрендәге чирләр турында сөйләшәләр. Күңелсез.

Бәрәңге

Дачада без еш кына эти белән икәү генә кала идек. Әни абыйның алты сотый участогы булган дачасына җир казырга китә. Әти белән безгә күп нәрсә кирәкми. Ул ашарга әзерли белми. Ахыр чиктә бәрәңге пешерә. Шулай итеп, көн саен бәрәңге генә ашап тора. Бәрәңгедән башка аның өчен көндезге аш тулы булмый. Бу гадәт аңа 30 нчы еллардан кереп калган. 1937 елда аны утыртмаганнар, ләкин эштән куганнар, комсомолдан чыгарганнар. Типографиядә җыелган беренче китабының матрицасын сүткәннәр. Китабының чыкмый калуы аны коткарып калган да. Аның дусты Муса Җәлилне дә вакытында Мәскәүгә китеп баруы гына коткарган.

Әти авылга китәргә уйлаган, ләкин парторг аны кая гына булса да эзләп табачакбыз дип кисәткән. Ул Федосеев урамындагы төрмә каршындагы беренче йортта яшәгән, хәзер анда тарих институты урнашкан. Төннәрен төрмәдән кычкыру тавышлары ишетелеп торган, күрәсең, кемнедер җәзалаганнар. Әтинең якын дуслары Фатих Кәрим белән Хәсән Туфанның шушы төрмәдә очрашулары хакында сөйлиләр. Имеш, Фатих Кәримнең аягында автомашина көпчәге резинасыннан кисеп ясалган, тимер чыбык белән урап куелган кием булган. Моның чынлап та шулай булуы бик мөмкин.

Туфан инде ул чакта ук классик булган һәм репрессия өчен шул җиткән. Аны башта утырталар, аннары Себергә сөрәләр. Анда ул көтү көтә, сыерлар сава һәм аларның сөтен эчеп, үзен ач үлемнән саклап кала. Фатих Кәримне «Аникин» поэмасы советка каршы язылган әсәр дип гаеплиләр. Анда чик сакчысының японнар кулыннан һәлак булуы хакында зарарсыз бер күренеш бар. Шуның өчен авторны гаепле дип табалар, имеш совет сугышчылары дошман кулыннан һәлак булырга тиеш түгел. Фатих Кәрим төрмәдән сугышка барып керә һәм Кенигсберг крепостен штурмлаганда һәлак була. Штурмга командалык иткән данлыклы Жуков солдатларны кызганып тормый. Фатих Кәримнең пуля тишкәләгән шинеле музейда эленеп тора.

«Әти, син алай язмыйсың...»

Гомеренең соңгы елларында мин әтигә шигырьләрен һәм мәкаләләрен язу машинкасында бастырып бирә идем. Аңа Язучылар союзы машинисткалары янына йөрү кыенлашты; сугышта, окопларда ятуларның тәэсире үзен сиздерә иде. Мин стандарт «Москва» машинкасына татарча хәрефләр урнаштырдым. Шуннан башлап һәр көнне диярлек өстәлемдә өске почмагына «3 д.» яки «3 д. тәрҗемә итәргә» дигән күрсәтмәсе белән шигырь һәм мәкаләләре күренә башлады. Мин аның мәкаләләрен генә тәрҗемә итә идем.

Әти русчаны яхшы белә, грамматик яктан хатасыз, ләкин журналистларча яза. Үзенең язу стилен ул русчада кабатлый алмый иде. Ничектер бервакыт аның рус телендә үзе язган мәкаләсе туры килде. Мин моны белмичә: «Моны кем язган? Бу синең стиль түгел», – дип сорадым.

– Үзем яздым, – ди.

– Әти, син бит болай язмыйсың, – дим.

Аның русча язганын яңадан төзәтеп чыгарга туры килде. Шулай итеп, мин аның бер сүзен дә кыскартып булмый торган кыска һәм ачык стилен үзләштердем. Ул бернинди дә катлаулы җөмләләр төземичә, бизәкләмичә, ләкин тәрҗемә итәр өчен гаять катлаулы итеп яза торган иде. Чыгыш ясаганда да, үз стилен саклап, аңлаешлы гади җөмләләр белән сөйләргә тырыша иде. Ул язган текст буенча чыгыш ясаучылар еш кына тотлыгып кала торганнар иде.

Әти язганнарны тәрҗемә итү белән шөгыльләнү миңа Президент киңәшчесе булып эшләгәндә, нык ярдәм итте. Миңа еш кына сәяси темаларга гына түгел, Минтимер Шәймиев өчен төрле темаларга, әйтик, яңа Конституция, икътисад, әдәбият, тарих өлкәләре буенча чыгышлар әзерләргә туры килде. Шулай итеп, мин универсал тәрҗемәчегә әйләндем. Кайвакыт мин тыныч кына каршылык күрсәткән булам. Ничектер бер шулай ул миңа Тукай юбилеенда сөйләр өчен чыгыш тексты язарга кушты. Мин мондый чыгышлар әзерләр өчен Фәннәр академиясенең махсус институты бар, анда Тукай буенча белгечләр, профессорлар төркеме эшли, дигән булам. Ул миңа алардан эшләтеп алган текстын күрсәтә һәм:

– Укып чыга аласың, теләсәң файдаланырга да мөмкин, ләкин иртәгә үзең язган текстны китер, – диде.

Әлбәттә, мин үзем дә Тукай турында яза алган булыр идем. Миңа Тукай турында әти язган мәкаләне тәрҗемә итәргә туры килде. Бервакытны миңа хәтта Тукайның Мәскәүдә чыга торган җыентыгы өчен әти булып, кереш мәкалә язарга да насыйп булды.

Бөек шагыйрьнең юбилее уңаеннан рус телендә чыга торган җыентык өчен Татарстан китап нәшрияты әтидән кереш мәкалә язуын сораган. Ул аны язды, мин тәрҗемә иттем. Шунда әтигә Мәскәүдән дә шундый ук китап өчен кереш мәкалә язарга сорап мөрәҗәгать итәләр. Әти миңа әйтә:

– Минем башка әйтер сүзем юк, телисең икән, үзең язып җибәр, – ди.

Шуның алдыннан гына әти Тукай турында фикерләрен магнитофонга яздырган иде. Мин аларны эшкәртеп, «Көзге җиде кич» дигән язма әзерләдем. Ул кичләрнең берсе Тукайга багышлана иде. Мин аны үземчә «җилгәреп» эшләп чыктым да әтигә күрсәттем. Ул аны төзәтеп тә тормыйча кулын куйды һәм мин аны редакциягә җибәрдем. Шулай итеп, Сибгат Хәкимнең мин язган мәкаләсе барлыкка килде.

Мин акрынлап, бу рольгә кереп беттем. Бер заманны радиокомитетта миннән Сибгат Хәкимнең Тукайга мөнәсәбәте турында сөйләвемне сорадылар. «Аның тавышы белән сөйли алмассыз микән?» – диделәр.

Мин шаккатып калдым.

– Ничек инде аның тавышы белән?

– Ул сөйләгән шикелле итеп.

– Ә-ә-ә... Була ул...

Шулай итеп, радиодан әти булып чыгыш ясарга туры килде.

Рафаил ХӘКИМОВ

ШИГЫРЬ ЭЗЛӘП КИТТЕ

Гомере буе шигырь белән җенләнеп яшәде Фәиз.

Без аралаша башлаганда, ул инде шигърияттә үз кыйбласын ачыкларга өлгергән, үзе дә каләм тибрәтеп, образ-метафора-чагыштыру кебек төшенчәләрнең ни икәнен белеп, шулардан шактый оста файдаланып, кызыклы гына шигъри табышлары белән шәриктәшләре арасында өметле шагыйрь булып танылып килүче бер студент иде.

«Яфрак сибеп, уйнап,
Яшь каеннар рәте
Үргә менеп килә –
Көзнең шат сурәте».

Яки:

«Төне үтсә дә,
ае калган онытылып
офыгында».

Моның ише матур сурәтләрне без, өлкән агайларның шигырьләрендә генә очраткан студентлар, Фәиз сабакташыбызга әнә шулай олылап, бераз гына көнләшеп тә, ихтирам белән карый идек.

Шагыйрьлеген тагын да камилләштерүгә, шигърият турында күбрәк, тирәнрәк белергә омтылуы Фәизне башкалар иҗатын өйрәнүгә алып килде. Башта ул шактый гына вакытлар Равил Фәйзуллин шигърияте белән җенләнеп йөрде. Р.Фәйзуллинны ул алтмышынчы елларда татар шигъриятенең иҗтимагый тормышта, укучылар алдында абруе күтәрелүгә алып килгән үзгәрешләрне башлап җибәрүче, хәрәкәткә китерүче кеше дип бәяләде. Фәиз аның шигъриятендәге үзенчәлекләрне билгеләүне һәм шигърият сөючеләргә күрсәтеп бирүне үзенә максат итеп куйды. Шагыйрь иҗатын ул кайта-кайта, озаклап өйрәнде. Нәтиҗәдә, аның «Аңлаем дип шагыйрь җанын...» исемле язмасы, соңыннан шуны ук тулыландырып, киңәйтеп эшләгән «Күзләрем һаман шулмы?..» дигән, шагыйрь иҗатын шактый колачлы чагылдырган саллы мәкаләсе дөнья күрде.

Р.Фәйзуллиннан соң Фәиз шулай ук 60 нчы елларда шаулап-гөрләп шигърияткә килгән Ренат Харис, Рәдиф Гатауллин (Гаташ), Гәрәй Рәхим, алардан соң мәйданга чыккан Мөдәррис Әгъләмов һәм Зөлфәт, Эдуард Мостафин һәм Харрас Әюпов иҗатларына тәфсилле анализ ясап, укучылар алдында алар шигъриятенең үзенчәлекле якларын ачып күрсәтте.

Әнә шулай итеп Фәиз Зөлкарнәй әдәбият дөньясында үз сүзе, кыйбласы, мәсләге булган яшь тәнкыйтьче булып танылды.

1984 елда аның шушы мәкаләләрен һәм шулай ук үз яшьтәшләре, шәриктәшләре иҗатына багышланган, гомумән, сиксәненче еллар әдәби процессына күзәтү ясаган язмаларын туплаган «Кешем, асылың кем?» исемле беренче китабы дөнья күрде.

Шунысы кызык, Фәизнең барлык язмалары да беренче мәкаләсенә баш итеп алган «Аңлаем дип шагыйрь җанын...» дигән исемгә тугры калып, бары тик шигърияткә, шагыйрьләребез иҗатын өйрәнүгә багышланды.

Шигырьне, аның камиллеген, тәэсир итү көчен тәэмин итә торган поэтик алымнарны өйрәнергә утырып, ул «Әверелеш: шигырь парадокслары» дигән хезмәтен язды. Әйе, бу гади тәнкыйть мәкаләләре тупланмасы гына түгел, бәлки, тәнкыйтьчеләребез

тарафыннан бөтенләй өйрәнелмәгән мәсьәләләр хакында сөйләүче төпле, җентекләп тикшереп язылган фәнни хезмәт дип аталырга лаеклы җыентык иде. 1988 елда Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган әлеге җыентык шигырь төзелешен, аның тышкы формасын, график гәүдәләнешен ачып бирү җәһәтеннән шигырь сөючеләр өчен генә түгел, гомумән, әдәбият теориясе белән шөгыльләнүчеләр, студентлар өчен дә бик файдалы һәм кирәкле бер басма булды.

Фәизнең шигырьне, шагыйрьләрне аңларга һәм аңлатырга тырышуы аның һәр язмасында, һәр китабында торган саен колачлырак, үткенрәк, тирәнрәк һәм төплерәк була барды. Ул беркайчан да үзен кабатламады. Кулына каләм алган саен яңа мәсьәләләр күтәрә, сораулар куя, аларга карата үз фикерен, карашын әйтә килде. Аның фикри офыгы киңәйгәннән киңәйде, каләме үткенләнгәннән үткенләнде, иманы ныгыганнан ныгыды. Аның иҗатына яңа темалар килеп керде. Ул хәзер шигырьне төзелеше, поэтик үзенчәлекләре, әдәби-эстетик эшләнеше ягыннан гына түгел, бәлки милли үзенчәлекләрен ачыклау, сәяси бушандыру җәһәтеннән чыгып та тикшерә башлады. Аның шушы мөһим мәсьәләләргә багышланган әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм парчалары 1991 елда Татарстан китап нәшриятында «Чакма чакмый ут чыкмый» дигән исем белән аерым җыентык булып басылып чыкты.

Ни кызганыч, Фәиз Зөлкарнәй үзе исәнендә нибары шушы өч китабын дөньяга чыгарырга өлгерде. 90 нчы елларга аяк баскач, ул «Идел» журналының баш мөхәррире булып эшләде. Бу җаваплы вазифа – яшьләр, милләт, халык язмышы хакында журналның мәсләген, кыйбласын саклый торган язмалар, әдәби әсәрләр турында даими кайгыртып, шуларны оештырып яшәү, шуның өстенә журнал чыгару эшендәге матди кыенлыкларны (ә алар 90 нчы елларда аеруча күп булды) хәл итү эше – Фәиздән зур көч һәм вакыт таләп итте. Эштән арып-талып кайткач, кулга каләм-кәгазь алып, нидер язу түгел, аларны күрәсе килмәгән сәгатьләре дә күп булгандыр. Әмма Фәиз әдәбиятка җаны-тәне, бөтен барлыгы белән бирелгән кеше иде шул. Журнал өчен ул милләт, халык язмышын кайгырткан шактый гына публицистик мәкаләләр дә язды. Шул ук вакытта шигырьне дә ташламады. Ташламады гына түгел, мәкаләләрендә шигырьне һәм тәнкыйди, һәм теоретик яктан өйрәнгән Фәиз аңа шагыйрь буларак кабат әйләнеп кайтты. Ул яңа бер дәрт, илһам белән шигырьләр иҗат итәргә кереште. Студент елларында язган шигырьләрен яңадан эшләп чыкты. Поэзияне тәнкыйтьче буларак өйрәнгән елларында туплаган белемнәре белән коралланып үзенчәлекле, башкаларны кабатламаган яңа әсәрләр иҗат итте. Шигърияттә дә сүзен әйтергә, үз сурәтен тудырырга, үз зәвыгын күрсәтергә омтылды.

Ф.Зөлкарнәй заманында үзе теләп өйрәнгән – 60 нчы елларда мәйданга чыгып, татар шигыренә график чаралар ярдәмендә, ягъни форма ягыннан үзгәрешләр ясарга омтылган шагыйрьләр иҗатына аваздаш поэтик стильне үз итте. Әйтергә теләгән фикерен үзенчәлекле формага төреп бирергә тырышты. Аның шигырьләре традицион түгел. Шуңа күрә кемнәргәдер аңлашылып та бетми торгандыр. Ләкин бирелеп, дикъкать белән һәм аңларга тырышып укыганда, алар аңга да, йөрәккә дә барып җитәләр.

Фәиз эзләнде. Фикерен төрлечә әйтергә тырышты. Төрле формалар уйлап чыгарды. Традицион калыпка салган, һәр юлы баш хәрефтән башланган, ноктасы, өтере, һәр тыныш билгесе үз урынында утырган шигырьләре дә бар аның; җөмләне баш хәрефтән башлап, җөмләсе тәмамланмаганлыктан, икенче юлын юл хәрефтән генә дәвам иткән шигырьләрне дә очратасың; татар шигъриятендә бөтенләй очрамаган, каядыр Европа, Балтыйк буе шагыйрьләренең иҗади эзләнүләрендәге бары тик юл хәрефләреннән генә язылып, бернинди тыныш билгеләре дә куелмаган шигырьләре дә бар. Укып карасаң, алары да аңлашыла.

Кыскасы, үзенчәлекле шәхес иде Фәиз. Кабатланмас шәхес иде. Ул чордашлары, каләмдәшләре хәтерендә яши, иҗаты кабатланмас, үзенчәлекле әсәрләрендә татар әдәбиятының бай мирасын тәшкил итеп, китапларында саклана.

Рафис КОРБАН

Османов Диләвәр Ибраһим улы (1959) – кырым-татар шагыйре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2003), Кырым Автономияле Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2010). Диләвәр 1959 елда Үзбәкстанда, Ташкент өлкәсенең Бекабад шәһәрендә туа. Беренче шигырьләрен Үзбәкстанда яшәгәндә яза. Аларны Ташкентта кырым-татар телендә чыга торган «Йылдыз» журналында бастыра. 1979-1985 елларда ул Казанга килеп, консерваториягә укырга керә. Казанда яшәгәндә, аның шигырьләре Татарстанда чыга торган төрле басмаларда дөнья күрә. 1989 елда Диләвәр, реабилитацияләнгәннән соң туган җирләренә әйләнеп кайткан милләттәшләре янына, Кырымга кайтып китә. 1993 елда Д.Осман Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителә. 2009 елдан бирле ул кырым-татар телендә чыга торган «Йылдыз» журналының баш мөхәррире булып эшли. 2019 елда Д.Османның «Кырым» дигән шигырьләр китабы Р.Зәйдулла, Р.Рахман, Ф.Гыйләҗев, Р.Сәлах тәрҗемәсендә Татарстан китап нәшриятында татар телендә дөнья күрде.

Диләвәр
Осман

ТАТАРЛЫКНЫ ДӘВАМ ИТКӘН ЕГЕТ, КЫЗЛАР ТУАРМЫ?

Азат милләт юлында

Ант иткәнмен, сүз биргәнмен милләт өчен үләргә,
Белеп-күреп, милләтемнең күз яшене сөртергә.
Белми-күрми мең яшәсәм, корылтайлы хан булсам,
Янә бер көн мазарчылар килер мине күмәргә.
Ногман Чәләбиҗиһан

Җилфердәде күк байрагың, корылтайлы халык булдың,
Күтәрелдең, «Хаккым!» дидең, йортта халыктай бар булдың.
«Айгиди татар яшьләре», яңгырады «Ант иткәнмен»,
Белеп, күреп милләтеңне чакырдың ак ният белән.
Шундый көндә басып килгән кызыл гаскәр, алманнар,
Елгалардан сулар түгел, аккан безнең ал каннар.

Татарлыкны аскан-кискән, бозылган йорт, сарайлар...
Ногманнарның анты өчен корбан киткән бабайлар.
Корылтайны юк иткәннәр, яшь татарлар тотылган,
Күпме җаннар фида киткән, төньякның җене котырган.
Камау булган, тентү булган, «көтмәгәндә» үлгәннәр.
Тозакка эләккәндә дә ләкин баш имәгәннәр.

Йөз ел үтте, янә төште Хансарайга күләгәләр,
Татарлыкның җанын кисә төньяктан искән җилләр.
«Бастырык»тан, үзем беләм, һич котылмый Ногманнар,
Күк байракка яшен сөртә безнең газиз туганнар...
Ишетәмен янә фөрьяд гамьле, моңлы Кырымнан,
Яшь татарлар корбан киткән мең газаплы юлыннан...
Тагын ничә йөз ел узар, халыкның йолдызы сүнмәс,
Ногманны тудырган халык һичбер вакыт җиңелмәс!

Добруҗадан аваз килә

Добруҗадан* аваз килә, чикләр аша кичеп,
Шул Кырымга килеп җитә, бәгырьләргә төшеп.
Бу тавыш – чорлар авазы, татарның хак сүзе,
Заманында дөнья тоткан татарларның үзе.

Әкрен, арган тавыш белән серләреңне ачып,
Добруҗаңда ни бар, сөйлә! – йортка нурлар сачып.
Добруҗаның татар халкы – Чоңгарман** янә диме?
Әллә Кырымга аһ, диеп, Истанбулга китәрме?

Татар бишегендә үскән яңа нәселләр бармы?
Татарлыкны дәвам иткән егет, кызлар туармы?
Туган телнең кадерен белгән, байрак күтәргән бармы?
Көн туганда, ай кунганда, азаннар яңгырыймы?

Кырымнан төтәп чыккан ут Добруҗада янамы?
Иске гадәт, күк байракны милләт искә аламы?
Дөньяларны дүрт ягыннан йөреп чыккан нәселдән
Добруҗаның дүрт ягында татарлар күп гасырдан.

Өлкүсаллар, Ниязилар – Добруҗаның йөзе,
Шәһит китте Нәҗип Фазыл, Кырымда калды сүзе.
Һич сүнмәгән Добруҗада безнең татар галәме,
Бу туфракта баш имәгән милләтебез әләме.

...Добруҗадан аваз килә, татарлыкны эзли, һай!
Яшел йортка*** җитеп килә, җавап бир син, Хансарай...

Кырым гөлләре

Нинди генә илдә булмадым! –
Бер-берсеннән гүзәл үзләре.
Һәр җирдә тик эзәрлекләде
Кырым гөлләренең исләре.

Күрдем анда чибәр кызларны,
Килбәтләре затлы, төсләре.
Табыннарга ирек бирмәде
Кырым гөлләренең исләре.

Күккә ашкан йортлар күрдем мин,
Тыеп кына өлгер хисләрне!
Шыпырт кына игә китерде
Кырым гөлләренең исләре.

Добруҗа* – борынгыдан татарлар яши торган төбәк. Хәзерге Румыния һәм Болгария территорияләрендә урнашкан.
Чоңгар** – Кырымның төньягында урнашкан авыл.
Яшел йорт*** – Кырым күзаллана.

Иярепләр китәрдәй булдым, –
Балавыздай йомшак сүзләре,
Искә төште – аңга китерде
Кырым гөлләренең исләре.

Югалырмын туган туфракта,
Гөлгә күмелер мазар өсләре.
Миннән соң да хушланыр илдә
Кырым гөлләренең исләре.

Кырым-татар теленнән **Ркаил ЗӘЙДУЛЛА** *тәрҗемәләре.*



Сәйран Сөләйманов 1979 елның 18 февралендә Үзбәкстанның Фирганә шәһәрендә туа. 1991 елда аларның гаиләсе туган илгә – Кырымга әйләнеп кайта. 1996 елда Сәйран сәләтле балалар өчен ачылган лицейны тәмамлап, Кырым дәүләт инженер-педагогика университетының филология факультетына укырга керә. 2002 елда аны тәмамлагач, «Янъы дюнья» (Яңа дөнья) газетасында баш мөхәррир булып эшли башлый. С.Сөләйман – берничә шигырь китабы авторы. Әсәрләре кырым-татар, төрек, азәрбайҗан, татар телләрендә басылып чыккан. Сәйран Сөләйман күп кенә әдәби форумнарда, шул исәптән 2015 елда Казанда үткәрелгән төрки телле яшь язучыларның халыкара семинарында катнашты. Ул Г.Сковорода исемендәге (Украина) һәм Мәхмүт Кашгарый исемендәге (Төркия) әдәби премияләр лауреаты, Аурупа Иҗат Гильдиясе әгъзасы.

Сәйран
Сөләйман

МӘДХИЯЛӘР ЯЗДЫ ШАГЫЙРЬ...

Соңгы дәрвишнең уйлары

Канат куйдың, күк, чарасызларга...
Күңелдә буран, разыйлык кайда?
Чүәкләр тозда, өс-башым тузган,
Кояшым сүнеп, мәшрикъка байган?!

Тозлы чүәгем – гомремнең үзе,
Кая баксам да, тик дошман йөзе.
Ефәктәй җәйрәп яткан юлда
Бәхеткә кочак җәйдем – юк ул да.

Котылалмадым гайбәти кердән,
Япь-яшь башыма картлыгым иңгән.
Шөкер, йөрәгем әүвәлге калды,
Шатлыкларымны кайгылар чалды.

Алдымда ята чиксез озын юл,
Кемне күтәрә, кемне ега ул.
Юлчыга ташлар ату бер гадәт,
Һәм арысланнар иттән канәгать.

Ни гүзәл, Күкнең бәгърендә балкый,
Мәңге шәфкатьле сердәш Ай алтын...

Шул Кырымда

Шул Кырымда үз Зөһрәсен тапты Таһир,
Шул Кырымда мәдхияләр язды шагыйрь:
Булсын Гашыйк, булсын Бәкер яки Шакир.

Шул Кырымда сонетларын язды Адәм*,
Шул Кырымда сәүдә итте күпме адәм:
Булсын чабан, булсын солтан яки атам.

Шул Кырымда... Шул Кырымда...
Антларымны җан түремнән алып әйтәм:
Сөям сине, газиз Ватан,
Аерылышу юк италмас сөюемне,
Мин кайтаваз булып кайтам:
«Ватаным бер яшел утрау!..
Яшел утрау!» – диеп әйтәм.

Җилкәем

Күптәннән, бик күптән көлгән юк,
Гөлләрдәй күңелем таш булды.
Күзләрдән нур качты, һәм аның
Урынына сагышлы яшь тулды.

Яфрактай коелды елларым,
Бәгъремнән китмәде сызлану.
Өметем йомгагы сүтелде,
Җанымны мең телде кызгану.

Җилкәем, тавыш бир искәндә,
Ач миңа иң тирән сереңне.
Кирелек сиңа һич тиң түгел,
Яңгырат җанга хуш җырыңны.

Җилкәем, сер тулы, Җилкәем,
Мин синнән разыймын, әмма әйт –
Ни өчен сагышым таралмый,
Ни өчен үземә үзем ят.

Күгәрчен**

Йортына очкан күгәрчен кошы
Кинәт бер шахның кулына төште.
Ай күрде дә һәм кояш алды тик,
Алтын ояда утырган кошны.

Хак Тәгаләсе коткарды аны –
Бәхете кара күгәрчен кошын.
Читлектән азат ителде кошчык
Ачудан җаны айкалды шахның.

Туган йортына тиз кайтты кошчык,
Туры юл алып, очып төз генә.
Әмма, йорттан, аһ, хәрабә калган,
Әйтерсең, монда узган зилзилә.

«Шаһның читлеге алтын булса да,
Булса да төзек һәм дә бик иркен, –
Диде күгәрчен, – кадерле миңа
Үз корган оям һәм дә үз иркем!»

***

Шагыйрьләренең бишекләрен дә тибрәткән – милләт,
Татлы сүзләрдән йөрәкләрен дә изрәткән – милләт.
Каләмнәренә куәтен биргән, анысы да – милләт,
Шагыйрь кадерен белгәне дә белмәгәне дә – милләт.

Кырым-татар теленнән **Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** *тәрҗемәләре.*

* Адәм Мецкевичның мәшһүр «Кырым сонетлары»
** Алишер Нәваи музее

БЕР КЕШЕ – БЕРӘГӘЙЛЕ КЕШЕ!

Бер кеше нишли ала, ил кузгалса гына күл була, ягъни зур эшләрне башкарыр өчен күпләрнең катнашуы кирәк, дигән караш яши. Монда хаклык бар, әлбәттә. Чыннан да, олы нәтиҗәләргә китерә торган проектлар күп кешеләрнең акыл, физик, рухи көчен таләп итә.

Әмма кайчакта бер кеше – күпләр тотынмаган эшкә алынып, берүзе әллә ниләр майтарып гаҗәпләндерә, күпләрне сокландыра, илһамландыра... Тарихта да моңа мисаллар аз түгел!

Журналдагы фән эшлеклеләре турындагы сөйләшүебезнең бүгенге сәхифәсе шундый шәхесләрнең берсе – мәшһүр галим, дипломат, үз халкының асыл улы Тасин Таһир улы Җәмил хакында булыр.

Тасин – Тәһсин исеме бүген татарлар арасында сирәк очрый. Әмма тарих чоңгылларына төшкән саен гарәп теленнән кергән, мактау-хуплау мәгънәсен белдерә торган бу исем тарихи-мәдәни ядкарьләрдә очрый. Шуңа да без аны – оныткан, әмма читтә яшәүче татарлар арасында сакланган исемнәрдән дияргә нигез бар.

Менә шундый затлы исемле малай 1943 елның 21 сентябрендә Румыниядәге Дунай һәм Кара диңгез арасында урнашкан Мәҗидия шәһәрендә Таһир (1909-1987) һәм Эриана (1916-1989) гаиләсендә туа. Борынгы атамасы Карасу булган Мәҗидия – Констанцадан ерак түгел, элек-электән татарлар яшәгән урын буларак билгеле. Аларны Добруҗа татарлары дип тә йөртәләр. 2011 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, шәһәрдә 35 мең кеше яши, шуларның 71 проценты румыннар булса, төрекләр – 8,39 процент, татарлар – 8,09 процент тәшкил итә.

Тасинның нәсел-ыруы – Румыниядәге татарлар арасында иң йогынтылылардан санала. Бабалары – Гамил (Җәмил) һәм Гыйззәт, ерак бабалары – Габделкәрим һәм Җантимер (Хантимер) бу җирләргә Кырымнан 19 гасыр уртасында, Кырым сугышыннан (1853-1856) соң күчеп киләләр. Бакчасарайда фән белән шөгыльләнгән укымышлы бабасы Габделкәрим 1878-1886 елларда – Мәҗидиянең беренче мэры буларак мәгълүм. Кырымдагы Җанкәй өязендә җир-хуҗалык тоткан Җантимер монда күченгәч тә, Госманчы авылында игенчелек кәсебен дәвам итә.

Тасин башлангыч белемне Мәҗидиядәге татар мәктәбендә ала (1949-1956): бу елларда төбәктә милли башлангыч уку йортлары эшли, алар өчен хәтта яңа татар әлифбасы әзерләнә, дәреслекләр языла.

Укуын шәһәрнең югары мәктәбендә дәвам иткән (1956-1960) егет үзенең киләчәк юлын гуманитар фәннәр өлкәсендә күрә: 1960 елны Румыниядәге Яссы шәһәрендә урнашкан иң мәшһүр уку йортларыннан булган А.И. Куза исемендәге университетка укырга керә. Тарих белгечлеге буенча югары белем ала, 1965-1966 елларны Констанцадагы Эфорие-Суд урта мәктәбендә укыта, аннары Яссыдагы А.Д.Ксенополь исемендәге Тарих һәм археология институтында эшли башлый, тикшеренү өлкәсе итеп, урта гасырлар тарихын сайлый. 1971-1976 елларда аспирантурада укып, үзе белем алган университетта докторлык диссертациясе яклый. «Халыкара сәяси

мәйданда румын кенәзлекләре (1621-1672)» дигән бу хезмәте бик югары бәя ала, 1979 елны Румыния фәннәр академиясе аны бастырып та чыгара! Әлеге китап Европа тарих фәнендә Кырым ханлыгы тарихына яңача караш буларак кабул ителә.

Әлбәттә, кызыксыну даирәсе урта гасырлар белән бәйле тикшеренүче-галимне, иң беренче чиратта, архив документлары кызыксындыра. Чөнки бу чор тарихын һәм мәдәниятен күзаллау, кабат тергезү һәм фәнни әйләнешкә кертү, халыкка җиткерү өчен борынгы чыганакларны эзләү, табу, шәрехләү кирәк. Шуны яхшы аңлаган Тасин Җәмил Румыниянең башкаласы Бухарестка күченә, андагы Дәүләт архивларының үзәк идарәсендә эшли башлый. Румыния тарихы, илнең башка дәүләтләр белән багланышларын өйрәнү яшь галимне үз халкы һәм милләте тарихына алып керә: бу төбәкнең үткәнен – төрки халыклар, илләр-дәүләтләр яшәешеннән аерып алып булмасына төшенә ул. Моңа кадәр барланмаган-табылмаган йөзләгән-меңләгән документлар – ил тарихына да, төрки халыклар тарихына да үзгә күзлектән карау кирәклегенә ышандыра. 1977-1984 елларда шунда хезмәт куеп, дөнья кадәр фактик материал туплап, ул башкаладагы Йорг исемендәге Тарих институтына эшкә килә, 1984-1998 елларда шунда фән белән шөгыльләнә.

Әмма яраткан эшен, күңеленә канәгатьлек китерә торган тикшеренүләр өлкәсен тапкан Тасин Җәмилнең тормышын Румыниядә 1989 елны башланган революция тамырдан үзгәртеп ташлый.

Мәгълүм ки, 1989 елның 16 декабрендә Румыниядә коммунистик режимга каршы халык баш күтәрүе башлана, ул Румыния Социалистик Республикасының Президенты Николай Чаушеску хөкүмәтен бәреп төшерүгә китерә. 23 декабрьдә илдәге хакимият Милли коткару фронты кулына күчә. Шушы вазгыятьтә үз милләттәшләрен – татарларның язмышын кайгыртып, Тасин Җәмил шушы Фронтка килеп кушыла. Каһарман элгәргеләрнең геннары гаепләме, әллә Добруҗа татарларын туплаган бабасы Габделкәрим үрнәге тәэсиреме – ни генә булмасын, инкыйлабның беренче көненнән Тасин Җәмил илдәге этник азчылыкларның сәяси агымын җитәкләүчеләрнең берсенә әверелә.

1989 елның 29 декабрендә ул Румыниядәге төрек-мөселман һәм татарларның демократик Союзын оештыра. Демократик берлек Румыниядә яшәүче барлык төрек һәм татар халкын 4 билге – этник килеп чыгыш, тел, тарихи традицияләр һәм ислам дине нигезендә берләштерү бурычын куя. Татар-төркиләрдә милли үзаңны үстерү, киләчәк буыннар өчен аларның этник үзенчәлекләрен саклау, телен үстерү, мәдәниятен алга җибәрү максатыннан, Тасин Җәмил илдә барган сәяси вакыйгалар үзәгендә кайный. Ул румын парламентына сайлана (1990-1996) һәм Констанца өязенең вәкиле буларак, депутатлар палатасының Мәгариф, фән, яшьләр эшләре һәм спорт комитетында эшли башлый. Яшьләрне – үз милли мохитендә, үз традицияләрендә тәрбияләү омтылышы Румыния яшәешендә күп кенә яңалыклар китереп чыгара. Миллилек үсә, газеталар чыга башлый, яшьләр фәнгә, үз тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә тартыла! Әмма көн саен, сәгать саен калкып чыгып торган милли мәсьәләләрне чишү җиңел генә бармый. Бу вазгыять Тасин Җәмилне Кеше хокуклары, диннәр һәм милли азчылыклар проблемалары комитетына күчәргә мәҗбүр итә. Шушы ук мәҗбүрият Румыния парламентының НАТО Парламент ассамблеясындагы даими делегациясе (1991-1992) һәм Кара диңгез буе икътисади хезмәттәшлеге оешмасының (ПАЧЭС) даими делегациясе (1993-1996) әгъзасы булып, җиң сызганып эшләү кирәклеген көн тәртибенә куя.

Иҗтимагый-сәяси эш белән бергә Тасин Җәмил фән һәм мәгариф өлкәсен дә ташламый: 1991 елдан ул Констанцадагы «Овидий» университетында укыта: доцент (1991-1995), профессор (1995-2009), борынгы һәм урта гасырлар кафедрасы мөдире булып эшли.

Бу чорда Тасин Җәмил үзенең төп миссиясен Румыниядәге татарларның һәм төрекләрнең илдәге яңа иҗтимагый-мәдәни төзелештә, өр-яңа дәүләти конструкциядә үз урыннарын табуына, үсеш юлына чыгуына ярдәм итүдә күрә. Шуңа күрә дә ул

Добруҗа татарларының һәм төрекләренең Төркия һәм СССР таркалганда барлыкка килгән төрки дәүләтләр белән сәяси һәм мәдәни багланышлар урнаштыруын, үзара аңлашып яшәвен әһәмиятле саный, шушы юнәлештә чыгышлар ясый, аналитик күзәтүләр яза, тәкъдимнәр әзерли һ.б.

Аның бу концептуаль күзаллаулары – үзеннән үк гамәли адымнар таләп итә. Нәтиҗәдә, 1998 елны ул Румыниянең Азәрбайҗан Республикасындагы беренче вәкаләтле илчесе итеп билгеләнә, 2003 елга кадәр шушы вазифаны башкара. 2004-2007 елларда исә Румыниянең Төрекмәнстандагы илчесе булып тора. Шушы чорда Добруҗа татарлары белән элеккеге СССРда яшәгән барлык төрки телле этник төркемнәр, илләр һәм республикалар, аларның җитәкчеләре, фән һәм мәгариф оешмалары, бик күп билгеле шәхесләр белән бәйләнешләр урнаштыра, үзе шәхсән 1500дән артык дипломатик документ әзерли, югары халыкара дәрәҗәдә 30дан артык гыйльми һәм мәдәни очрашулар оештыра. Шулардагы килешүләрне тормышка ашыру өчен берничә фәнни һәм мәдәни оешма булдыра һәм аларны җитәкли. «Румын-Төрек гыйльми-мәдәни ассоциациясе», «Азәрбайҗан-Румын мәдәни ассоциациясе», «Румыниядәге төрек-татар гыйльми һәм мәдәни эшлеклеләр ассоциациясе» – шундыйлардан. Румыниянең гарәп илләре белән дуслыгы Лигасының вице-президенты, Кара диңгез буе Европа илләре җәмгыятенең вице-президенты, «Ефәк юлы» ассоциациясе вице-президенты, мәшһүр «Ревю Румен д'История» журналының редакция советы әгъзасы – шушы катлаулы эш-гамәлләрнең кайберләре генә.

Бер үк вакытта ул Констанца университетында проректор, докторлар әзерләү мәктәбенең җитәкчесе булып кала. Гаять тыгыз көндәлек хезмәт, күп көч таләп иткән иҗтимагый-сәяси эшчәнлек белән беррәттән, Румыниядә төрки халыклар тарихын өйрәнү фәнни мәктәбен булдыра. Әлеге нигездә, үзенең укучыларына таянып, 2005 елны Констанца университетында Евразия тикшеренүләре үзәген ача һәм бүгенге көнгә кадәр шуны җитәкли. 2009 елдан бүгенге көнгә кадәр – Клуж-Напокадагы «Бабеш-Больяи» университеты профессоры, һәм анда 2008 елны Тюркологик тикшеренүләр үзәген оештыра һәм төрки халыклар, дәүләтләр тарихына караган документларны бастырып чыгару өчен махсус фәнни журнал булдыра («Studia et Documenta Turcologica»: бүгенге көнгә 5 саны нәшер ителгән, алтынчысы әзерләнә). Аның тырышлыгы белән Румыниядә 2012 елдан Бабеш-Больяи университетында һәм Бухарестта, 2014 елдан – Констанца университетында татар тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү курслары оештырыла башлый.

Галим-тарихчы буларак, Тасин Җәмилнең кызыксыну өлкәсе гаять киң – румын-госманлы-татар багланышлары; төрки халыкларның (Төркия, Үзәк Азия, Кырым, Кавказ, Идел буе) тарихы, мәдәнияте һәм хәзерге хәле. Аның бу мәсьәләләргә багышланган 7 монографиясе, 100дән артык гыйльми язмалары бар, тагын 7 китап соавторлыкта әзерләнгән. Болардан тыш, урта гасырлар тарихына караган 8 том хезмәтләр әзерләүне җитәкли. Ул, татар, кырым-татар, румын телләреннән тыш, госманлы (иске төрек), хәзерге төрек, төрекмән, азәрбайҗан телләрен яхшы белә, шулай ук инглиз, француз, үзбәк, казакъ, кыргыз телләрен фән теле буларак иркен файдалана. Борынгы төрки телдән Европа телләренә документлар тәрҗемә итүе, анализлавы, фәнни бәяләве аны, шиксез, XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башында төрки мирасны фәнни әйләнешкә кайтаручылар арасында беренчеләрдән итеп күрсәтә.

Мондый киң колачлы материаллар төрки халыкларның үткәненә, тарихы һәм мәдәниятенә карата Европа историографиясендә яшәгән карашны тамырдан үзгәртәләр. Иң әһәмиятле моментларга гына тукталсак, Тасин Җәмил хезмәтләренең кайбер мөһим сыйфатлары дип түбәндәгеләрне билгеләргә мөмкин:

– Көньяк-Көнбатыш Европада озак вакытлар дәвамында төрки-татарларны монгол яулары белән бәйләп карау, шуңа да аларның Европа тарихындагы әһәмиятен киметеп карау хөкем сөрә. Галим бу карашның дөрес түгеллеген ачыклый. Архив документларына (рәсми кәгазьләр, патшалар арасындагы һәм дипломатик хатлар

һ.б.) һәм инглиз, төрек, француз телле галимнәрнең күпсанлы хезмәтләренә таянып, ул татарларның һәм аларның ерак бабалары кыпчаклар, команнарның Европада дәүләтләр формалашуда һәм үсүдәге мөһим ролен күрсәтә, ерак бабаларыбызның андагы ватаннарын саклаучы-яклаучы каһарманнар булуын исбатлауга ирешә.

– Румыниядә яшәүче хәзерге татарларның бабалары – кырым татарлары дип санау кабул ителгән була. Архив документлары исә румын татарлары этник бердәмлегендә, кырым татарлары белән бергә, буҗак (нугай) татарлары, кара нугайлар һәм ак нугайлар да, әле Казан ханлыгы заманнарында ук Идел буеннан күчкән (күчерелгән) татарлар да булганлыкны раслый.

Тасин Җәмил хезмәтләрендә Румыниянең көньяк-көнчыгышындагы Добруҗа һәм Украинага кадәр сузылган Буҗак – борынгы Кыпчак далаларының бер өлеше буларак өйрәнелә. Шуңа күрә дә бу җирләрдә 1500 ел дәвамында төрки халыклар яшәгәнлекне, аны үзләренең туган җире дип караганлыкны исбатлый ул. Буҗак XIII гасырның икенче яртысыннан Алтын Урда дәүләте составына кергән, монда мөселман шәһәрләре балкып торган. XIII гасыр ахырында нугай әмирзадәсенең Добруҗага килеп урнашуы, Исакчы шәһәрендә башкала төзүе, XIV гасыр уртасында Яңа-Сала кирмәнендә татарларның тагын бер мөстәкыйль дәүләт нигезләве – язма чыганакларда күзаллана, аннары археологик табылдыклар белән дәлилләнә.

Тасин Җәмил 1395 елны Аксак Тимернең Идел буена хәрәкәте тәэсирендә күп кенә татарларның, шулай ук, Добруҗага һәм Румелиягә качуын билгели, шушы заманнан ук Идел буе һәм Дунай татарлары арасында көчле бәгланышлар булуын документларда күзәтә. Әйтик, 1368 елның 22 июнендә Венгрия короле Людовик I татар сәүдәгәренә ярлык тапшыра: ул сакланган. Татарларның Никополь янындагы (1396) сугышта үзләрен каһарманнарча тотуы, Туктамыш ханның хәрби җитәкчеләреннән берсе Актау исеменнән алынган «Актау татарлары»ның XVI гасырда Госманлы гаскәрләре составында аерылып торуы һ.б. бик күп фактлар аның тарихи хезмәтләрендә бөртекләп җыела-барлана, яңадан-яңа дәлилләр белән ныгытыла.

XVIII йөзнең икенче яртысына кадәр татарларның дулкын-дулкын булып күченүләрен Тасин Җәмил ата-бабалары җиренә тартылулары белән аңлата. Әйтик, Госманлы һәм Кырым дәүләтләренең уртак җиренә әйләнгән Буҗакка 1502 елны төрек солтаны Идел буеннан татарларны чакырып китерә. Алтын Урда җимерелгән вакытта бирегә Җаек белән Дон арасында яшәгән күчмән нугай татарларының күпләп күченүе 1512–1514 елларга караган Польша архивлары документларыннан табыла. Галим татар тамырлы мирза Дмитрий Кантемирның 1568 елга Буҗакта 30 000 татар яшәве, солтан Әхмәт I-нең 1608 елгы Фәрманында – 50 мең саны күрсәтелү, 1618 елны Истанбулдан Парижга җибәрелгән дипломатик хисапта соңгы вакытта гына 15 000 татар күченүе телгә алынуны, итальян сәяхәтчесе Марко Бандининың XVII гасыр уртасында 60 татар авылын күрүен, шул ук елларда монда булган төрек сәяхәтчесе Әүлия Чәләбинең – 200 татар авылы, ә 1691 елны күренекле инженер-генерал һәм шпион Л.Ф. Марсиглиның – 300 бай татар авылын телгә алуын, XVIII гасыр уртасында консул Ч. де Пейссонелның исә, 500 татар авылын теркәвен һ.б. тагын бик күп чыганакларга таянып, шулай ук XVII гасыр уртасында бирегә булган Халепле Паульның мондагы халык тулысынча татар-мөселманнардан гыйбарәт дип күрсәтүенә нигезләнеп, Добруҗа һәм Буҗакның урта гасырларда, чыннан да, татарлар өчен – ата-баба тияге булуы, XVI–XVIII гасырларда документларда «Тартария», «Татар даласы», «Татар җире» дип аталуы ачыклана. Галим татарларның архив документларында – тырыш, кунакчыл, мәрхәмәтле дип күрсәтелүенә дә игътибар итә. Төркия архивларында сакланган күпсанлы шикаятьләргә анализ ясап, Солтанның татарларны чик саклаучылар итеп файдалануы, шуңа күрә халыктан килгән зарларга колак салмавы хакындагы нәтиҗәгә килә. Кантемир Паша гаскәренең 1624 елны Кырым гаскәрен җиңүгә ирешүен дә аның, нигездә, татарлардан оешуы белән аңлата.

Әлбәттә, Тасин Җәмил хезмәтләрендә ерак бабаларыбызның Европадагы

тормышын реконструкцияләүне кыскача гына сөйләп бирү мөмкин түгел. Аларда бик күп фактлар тупланган. Фәнни яктан ул төрки халыкларның дәүләт төзүче булуларын румыннар белән мөнәсәбәтле тагын бер кат дәлилли (1877-1878 елгы сугыш нәтиҗәләре буенча Добруҗа Румыния составына керә). Галим 1320 нче елларда беренче румын дәүләте, Валахиягә нигез салучылар – татарлар һәм аларның бабалары кыпчаклар (команнар), аларның җитәкчесе Токтимер углы Басараба булуны, әлеге династиянең XVI гасырга кадәр идарә итүен, алай гына түгел, 1330 елны Валахия кыпчаклар, Алтын Урда ярдәме белән генә венгрлар басымыннан котылуын яза. Тагын бер румын дәүләте – Молдованың да нугай татарлары тарафыннан оештырылуын документлар ярдәмендә дәлилли. Румын югары катлавы вәкилләре арасында кыпчак-татар исемнәре, Румыниядәге төрки топонимнар һ.б. дәлилләр, архив документлары, шулай итеп, румын халкы һәм дәүләтчелеге формалашуда һәм үсүдә татарларның ролен ассызыкларга ярдәм итә. Татарлар һәм төрекләр белән күпгасырлык бәйләнешләр ярдәмендә генә румын милли һәм сәяси үзаңының башка эре католик дәүләтләр (барыннан да элек, Польша һәм Венгрия) һөҗүменнән исән калганлыгы галимгә аларны саклаучы-яклаучылар буларак карарга мөмкинлек бирә.

Әлбәттә, безнең күзәтүләр – Тасин Җәмил фәнни ачышларының бик кечкенә бер чите генә. Гомумән алганда, аның тарихи хезмәтләре әле Татарстан фәненә акрынлык белән кайтачак дип уйларга кирәк.

Бу язма әзерләнгән көннәрдә генә Татарстан Фәннәр академиясенә галимнең тагын бер яңа китабы килеп ирешә. «Татарлар: төрекләр һәм румыннар белән мөнәсәбәтләр» дип аталган бу монография өч телдә: инглиз, румын һәм төрек телләрендә язылган (Клуж Напока университеты нәшрияты, 2021. 430 б.). Европаның бик бай архив материалларына нигезләнгән әлеге яңа китапта да урта гасырлар тарихы күзаллана. Әлеге хезмәт – галимнең актив эзләнүләрен дәвам итүе хакында сөйләп тора.

Әмма иң мөһиме – ул Европа тарих фәненә үз эшен дәвам итәрлек бик күп укучылар әзерли. Бер мисал китерик. Тасин Җәмилнең 60 еллыгына аның укучылары һәм коллегалары 2 том фәнни тикшеренүләр әзерләп бастыралар («Тарих һәм халыкара дәрәҗәдәге диплом эшләре». «Овидий» университеты нәшрияты, Констанца, 2003. 459 б.), 70 яшьлек юбилеена тагын бер китап дөнья күрә: «Тюркология өлкәсендәге заманча эзләнүләр һәм Евразия тикшеренүләре. Профессор Тасин Җәмилнең 70 яшенә багышлана» *(Клуж Напока университеты нәшрияты, 2013. 1056 б.)*.

Бүген Тасин Җәмил – Румыния Галимнәр академиясенең һәм Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы (академигы), 1988 елдан – Төркия тарих академиясенең (Түрк тарих курумы) мөхбир-әгъзасы, Румыниянең «Николай Йорг» исемендәге академик бүләге иясе, Мәҗидия шәһәренең шәрәфле гражданы, Баку халыкара университетының шәрәфле профессоры һ.б. бик күп исемнәргә, бүләкләргә лаек зат. Исеме – төрки дөньяның иң мәшһүр белешмәлекләренә, энциклопедияләренә кертелгән.

Ул актив фән тормышы белән яши: конференцияләрдә катнаша, китаплар яза, докторантлар әзерли. Француз теле укытучысы булган хатыны Нәфия, Швециядә яшәүче табиблар – кызы Эдис, кияве Диян, оныгы Денис аның һәр эш-гамәлен – иҗтимагый юнәлешле булсынмы ул, тәүлеккә 20шәр сәгать чыганаклар белән утыру булсынмы, үз халкын, татар халкын халыкара мәйданда күрсәтү булсынмы – хуплап, аның белән горурланып яшиләр. Татарстан да, татар халкы да бу зыялы шәхеснең фидакарьлеген, аның киләчәккә юнәлтелгән фәнни һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген белергә, танырга бурычлы. Чөнки ул – берүзе күпләр бергәләп башкарырлык эшләрне тормышка ашырган берәгәйле галим, фикер иясе, үз халкының затлы улы.

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,
академик, филология фәннәре докторы.

ӘМАНӘТ ИТЕЛГӘН ДӘФТӘРЛӘР

Әхсән хатлары... Китап киштәләремнең кул сузымы кадәр якын җирендә өем-өем булып тора алар. Һәрберсе – тулы бер дәфтәр. Араларында амбар кенәгәсе калынлыгындагылар да бар. Җәмгысы кырыклап хат. Беренчесе үткән гасырның 70 нче еллары ахырында язылса, соңгысы 2000 ел белән тәмамлана. Рәссамның егерме бишләп ел дәвамында язган хатлары, күңелен бушатып, кәгазьгә төшергән монологлары... «Гади хатлар гына түгел, рухи байлык дәрәҗәсендәге язмалар бит болар!» дип, эчке тоем белән сизенеп, хатларның бер өлешен инде 90 нчы елларда ук машинкада бастырган идем, соңрак, яңаларын да кертеп, янәдән компьютерда җыярга туры килде... Мин әлеге хатларга көн дә диярлек кагылам бугай. Кайчак берәрсен алам да янәдән укып чыгам. Үткән гомерләр искә төшә, вакыйгалар яңара, күңелгә нинди дер яктылык иңә, яхшы уйлар килә, җан чистара... Әхсән абый Фәтхетдинов (ул миннән дүрт яшькә өлкәнрәк иде) вафатыннан соң (2012) киштәдәге бу кәгазь өемнәре тагын да якынрак, кадерлерәк була башлады.



Хатлар! Хатлар!.. Дәһшәтле цунами кебек ябырылып килгән информация-хәбәр ташкыны астында калган бүгенге кешеләр өчен «хат» дигәннәре архаик сүз булып яңгырыйдыр инде. Бигрәк тә яшьләр өчен. Аңлашыла да. Теләсә нинди хәбәр-яңалыкны галәмнең теләсә кайсы ноктасына яшен тизлегеннән дә җитезрәк ирештерә торган электрон почталар бар бит! Фантастик казанышлар чоры! Бабаларыбыз, терелеп аякка басса, «ахырзамандыр бу!» дип шаккатарлар иде. Шулай да онытмыйк, хатлар кешелек үсешенең югары бер баскычын билгеләгән, күп гасырлар буе аралашуның төп ысулы булган. Кешеләр белән кешеләр, дәүләтләр белән дәүләтләр, кыйтгалар белән кыйтгалар хатлашып хәбәрләшкән. Янаулы хат-ноталар аша сугышлар ачылган, тарихи солыхлар төзелгән; кайчак бер хәбәр, бер сүз белән меңәрләгән җаннарның язмышы хәл ителгән... Шатлык-кайгы да, ачу-нәфрәт тә, өмет-ышаныч та – яшәешнең бөтен рухи төсмерләре дә чагылган аларда. Диңгез-океаннарда һәлакәткә очраган бәхетсез җаннар шешәгә язу – үзенчә хат кисәге салып, бөкеләп, берәр кеше кулына ирешмәсме дип, аны юкка гына дәрья суларына ыргытмагандыр инде...

Аралашу, хәбәрләшү – кешенең табигый ихтыяҗы. «Хат – ярты күрешү» дип тә әйтәләр. Миңа калса, көттереп алынган кадерле хатның кайчак тулы күрешүдән дә өстен торуы мөмкин. Хатлар дигәч, мәгълүм әйтем дә искә төшә: «Киләчәккә хатлар барсалар да, үткәннәргә хатлар бармыйлар». Ә бәлки, киресенчә – «үткәннәргә хатлар барсалар да». Ничек кенә уйласак та, үткәннәрдән бик күп хатлар, истәлекләр яңа буыннарга васыять рәвешендә ирешеп килгән. Ни аяныч, хакыйкатьнең күзенә карап искәртергә мәҗбүрмен: традицион хатлашу заманы кайтмаска җуела бугай. Кешелекнең бик зур югалтуы... Сүз дә юк, хатлар – беренче чиратта, үткәннәрнең газиз ядкаре, әмма әлеге кыйммәтләр дә киләчәккә хезмәт итә ала бит. Әле ничек кенә! Әлбәттә, аларны талантлы акыл ияләре язса, хатлар фикерле һәм гыйбрәтле булса. Әхсән Фәтхетдиновның бу хатларын шундыйлардан дип исәплим.

Сүз – гаять көчле корал. Бу – аксиома. Ул даруга да, агуга да тиң. Сүз каше-

не терелтергә дә, үтерергә дә мөмкин. Хатлардагы сүзләр аеруча тәэсирле. Сүз изгелек сакчысы да, шулай ук явызлыкның авызына җим салучы да була ала. Чагыштырып карасаң, шикаять-донослар да үзенчә бер хат формасы түгелме соң?! Әхсән хатлары мине төрле-төрле уйларга да этәрде. Уйларның моңсу гасабилылары да, яшәүгә көч бирә торган дәртлеләре дә килде башка. Әмма алар – иң әүвәл якты сагышлы хатлар, кешелекле хатлар. Һәммәсендә дә Кешедәге кешелекне уяту көче бар. Чөнки алар Табигатьнең талантлы баласы тарафыннан ихлас язылган. Ясалма шоуменнар шаукымы бер үтәр; ихласлыкка – яшәешнең кадерле һәм тансык сыйфатына җәмгыять гел битараф калмас әле.

Рәссам дустымның сораулардан гына диярлек торган хатлары да бар. Уйланылган алым: үз-үзенә сорау биргән булып, ул бит бездән җавап көтә. Проблемаларны чишү юлларын бергәләп эзлик, уйлашыйк, ди.

Үзара хат алышканда, гадәттә, көнкүрештәге – гаилә, туган-тумача, күрше-күлән тирәсендәге яңалыклар, үлем-китемнәр, кайларгадыр барып-кайтулар, гомумән, бүтәннәр өчен бернинди әһәмияте булмаган вакыйга-хәлләр турында бәян ителә. Ә Әхсән хатларында аларның эзе дә юк. Дөрес, тормышта файдаланыла торган кайбер әйберләр (әйтик, кадак, капка биге, таш кисәге һ.б.), күпләр игътибарга да алмаган нәрсәләр дә очрый ул хатларда. Әмма алар әдәби-эстетик кыйммәткә ия, фикерләрне ачыграк әйтергә булышучы детальләр, кирәкле «вак-төякләр». Әхсән Фәтхетдиновның фикер офыклары киң! Хатларда күтәрелгән проблемаларның тематикасы турында тәфсилләп сөйләргә җыенмыйм. Җентекләп укыган кеше күрер һәм аңлар. Шулай да гомум рәвештә генә язмаларның нигезен билгеләгән тема-юнәлешләрне күрсәтеп узам: Табигать һәм Кеше, Җәмгыять һәм Шәхес, Халык һәм Тел, Вакыт һәм Талант...

Дөньяда төпле фикер белдерергә сәләтле акыл ияләре аз түгел. Хәтта кечкенә генә авылда да хикмәтле сүзләр әйтүче, җор һәм тапкыр телле берәр кеше табыла. Иң мөһиме, ул сүзләрне кем, кайда, кемгә һәм ничек әйтүдә! Түмгәк-калкулыкка менеп тә ялкынланып сөйләргә була. Шул ук сүзләрне биек тау башыннан яки югары трибунадан да бөтен гавамга ишеттерергә мөмкин. Әхсән Фәтхетдинов язмалары да зур киңлекне таләп итә, халык ишетерлек биеклекне сорый. Шуларны истә тотып, бу хатларны, үземдә генә бикләп яткырмыйча, киңрәк аудиториягә чыгару, ягъни басмага әзерләү теләге уянды да инде.

Колачлап алырлык дәфтәр өемнәренә карыйм да, кайчакта соклану катыш оялуга охшаш уйлар да туа. Боларны кәгазьгә төшерергә күпме вакыт, күпме көч сарыф ителгән! (Бу дөньяда берәүнең дә артык вакыты юк!) Нинди максат куелып, нинди «җеннәр»е яздырган икән бу галәмәт озын хатларны? Башка берәүгә тәгаенләмичә, нигә миңа юлланган әлеге хатлар? Ул аларны почта яки кеше аша түгел, Казанга килеп, үзе тапшырып китә иде. (Почта әрҗәсенә салса, югалырлар дип курыкты микән?) Мин аларның берсенә дә җавап хаты язмадым. Дөрес, очрашкач, хат-дәфтәрләр хакында озаклап әңгәмәләшә, фикер алыша идек. Бәхәскә кергән чаклар да булгалады. (Күңелгә яшь килер дәрәҗәдә сагынам шул елларны!) Шулай да төп соравыма җавапны табып бетерә алганым юк. Дөньяга, яшәешкә кагылышлы уйларын белдерер өчен рәссам нигә хат формасына тукталган? Фикер әйтүнең бүтән ысуллары да бар бит югыйсә. Әйтик, әдәби әсәр, публицистика... Адресат сыйфатында һөнәри хезмәттәшләрен яки туганнарын түгел, ә нигә нәкъ менә мине сайлаган?

Әлбәттә, фаразларым бар. Бәлки, алар хаклыкка да туры киләдер. Әйе, Әхсән Фәтхетдинов – зур Шәхес, зур иҗат Кешесе. Гадәттә, андыйлар ялгызак була... Иҗат, – гомумән, индивидуаль, интим шөгыль. Кәефе хушланганда, сәгатьләр буе сөйләгән чаклары күзәтелсә дә, мин аны, гомумән алганда, шактый ук эченә бикләнгән кеше дип беләм. Һәркемгә дә ачылып китми иде ул. Үзенең «ияләр»е, «шүрәлеләр»е белән күбрәк аралаша иде. Күз алдына китерегез: көннәр, айлар дәвамында диярлек остаханәсендә япа-ялгыз. Гел эштә. Адәм баласы тавыш-тынсыз, мыштымнарча гына яши алмый бит. Йә

берәр музыка тыңлый ул, йә үз-үзе белән сөйләшә, йә үзе ясаган сыннарына сүз ката... Төп гомер – остаханәдә. Ярый ла, арып кайткач, күңел «түгәрлек» кешеләрең көтеп торса... Гаиләдә балалар юк, туган телдә сөйләшер зат юк (хатыны – гаять кешелекле ханым – Таисия Дмитриевна рус милләтеннән иде). Еш кына күпләп җыелган милли моң-сагышларны өйдә бушату җаен тапмыйча, алар белән кире «мәгарә»сенә кайткандыр Әхсән абыебыз...

Кеше гомер буе үзенә җандаш эзли. Таба аламы ул аны? Анысын һәркем үзе генә белә. Бәлки, озак хыялланган җандашны очратмыйча, дөньялыктан китеп тә барабыздыр... Әхсән абыйның бу хатлары, мөгаен, үз-үзе белән сөйләшүнең, фикердәш-җандаш эзләүнең бер рәвешедер (аларны мин аның күңел монологлары дип тә атыйм). Ни булган – шул булган инде. Хат-язмалар миңа адресланган.

Шикләнмичә расларга мөмкин: Әхсән Фәтхетдинов – күпкырлы, талантлы шәхес. «Алтын куллы кеше» диләр андыйларны. Тормыш алып барыр өчен бик эшлекле оста. Сәнгатьтәге казанышлары турында әйткән дә юк! Табигать аны төрле яктан сәләтле итеп яраткан. Шулай да ул үз-үзеннән, бигрәк тә иҗатыннан беркайчан да канәгать булмады. Кычкырып ук белдермәсә дә, сизелә иде. Сәбәбе нидә соң? Минемчә, аңа бирелгән талант орлыклары үз вакытында уңдырышлы туфракка салынып, тиешле шартларда үссә, ул, һичшиксез, даһилык үрнәге күрсәтер иде.

Фәкыйрь авыл мохите, сугыш чоры, ачлы-туклы балачак, үксез үсмерлек (гәрчә тома ятим булмаса да), вакытында кирәк дәрәҗәдә һөнәри осталык мәктәбе үтмәү, чит-ят җирләрдәге рухи ялгызлык... Кыскасы, шактый катлаулы язмыш. Ахыр чиктә Талант үзе менәрдәй биеклекне, шартлыча, Иҗат Эверестын тулысынча яулый алмыйча кала. Әлбәттә, вөҗданлы һәр чын сәнгатькяр моны авыр кичерә...

Хат-язмаларны укыганда, шуны да искәрәсең: Әхсәндә язучылык сәләте, фәлсәфи фикерләү куәте дә зур булган бит! Аның күзәтүчәнлек сәләтенә кайчак көнләшеп куясың. Элегрәк елларда ул үзендәге сүз сәнгате мөмкинлекләрен тоеп, аңлап та бетермәгән, ахры. Баштагы хатларда «язу эше – минем өчен бер газап-җәфа инде ул» дисә, соңрак, хатлары ишәйгәч, «язмыйча тора алмыйм» дигәнрәк фикерләр әйтә. Ул, – чыннан да, үз сүзен ишеттерергә омтылган каләм иясе. Бу китап белән танышкан кеше моның белән килешер дип уйлыйм.

Хатларның күләмнәре төрле булган кебек, алар арасында мәгънәви яктан да төрле дәрәҗәдәгеләре бар. Күп нәрсә иҗат кешесенең рухи кәефенә бәйле. Адәм баласы бер халәттә генә яши алмый. Әхсәннең күп хатлары – фәлсәфи трактатлар югарылыгында. Шулай ук урыны-урыны белән мәктәп иншаларын хәтерләткән юллар да очрый. Наив, беркадәр утопик уйланулары да юк түгел. Аңлашыла да, үзе еш кабатлый торган сүзләрне кулланып әйткәндә, «алар табигатьтәге сыман табигый дә». Истән чыгармыйк: ул, – күпләребез шикелле, совет чоры идеологиясе рухында, үз заманының мораль кодексын үрнәккә куеп тәрбияләнгән буын вәкиле. Бу буында, прагматик фикерләүдән бигрәк, хис-эмоция, хыялга бирелеп яшәү өстенлек итте шул.

Хатларда хат язучының үз йөзе генә түгел, адресатның (бу очракта хат алучының) да холык-фигыле, гомумпортреты күпмедер дәрәҗәдә ачыла бит. Үзеңнең кем икәнлегеңне беләсең килсә, дустыңның кемлеген әйт, диләрме әле?..

Бу урында өстәп, шуны да әйтәсе килә: иҗат әһеле, сәнгатьнең нинди генә өлкәсендә эшләмәсен, уңышка ирешим дисә, әдәбиятны яхшылап белергә тиеш. Бу – бик мөһим шарт. Әдәбият, нигездә, сәнгатьнең бөтен төрләре өчен чишмә башы булып санала. Алтмыш еллап иҗат гомерендә мин үзем дә әдәбият-сәнгатьнең бик күп күренекле затлары белән аралаштым. Әмма араларында әдәби мирасны тирәнтен аңлап, туган телнең нечкәлекләрен тоеп иҗат итүчеләр сирәк очрады. Дөрес, сагынып искә алырдай шәхесләр дә бар иде. Композиторлардан – Җәүдәт Фәйзи, Сара Садыйкова, Фасил Әхмәтов, Шамил Шәрифуллин (алар белән пьеса, либретто яки җыр текстлары турында рәхәтләнеп бәхәсләшергә мөмкин иде); рәссамнардан – Бакый Урманче, әлбәттә, Әхсән Фәтхет-

динов, Кадим Җәмитов театр дөньясыннан – Габдулла Шамуков, Празат Исәнбәт... Хәзерге яшьләргә һөнәри үсеш юлында менә дигән үрнәк остазлар. Аларны онытмаска иде! Туган телебез язмышы авыр хәлдә торган хәзерге чорда бигрәк тә!..

Алда әйтелгәнчә, Әхсән Фәтхетдинов хатларының төп өлеше үткән гасырның соңгы чирегендә язылган. Без әле шәхси яктан әллә ни таныш булмаган чакта аларны күп юллаган ул. Ә танышып, еш очраша башлагач, хатлар сирәгәйгән... Шулай да кыска хат-хәбәр рәвешендә язышу аның вафатына кадәр даими дәвам итте.

...Хатлар турында яза-яза, үзем дә бераз хәттатка әйләнеп барам бугай. «Эпистоляр жанр» төшенчәсе хакында да уйланыла, элегрәк укылган борынгы әсәрләр, кыйсса-дастаннар, юлъязмалар, васыятьнамәләр дә хәтергә килә. Күктән иңдерелгән вәхиләр дә искә төшә хәтта. Чыннан да, Шәрык яки Гареп дөньясында хат-юллама, мөрәҗәгать рәвешендә иҗат ителгән әдәби өлгеләрне күпләп китерергә мөмкин. Әйтик, Горацийның ода-багышламалары, Әхмәд ибне Фадлан язмалары, Заһир Бигиев, Фатих Кәрими сәяхәтнамәләре үзенә күрә хат-истәлек түгелмени?! Әнә Габдулла Баһадиршаһның «Батырша хаты» турыдан-туры эпистоляр жанрга карый. Совет чорындагы «Киләчәккә хатлар» (Һади Такташ), «Тапшырылмаган хатлар» (Гадел Кутуй), «Сугыш язмалары» (Хәйретдин Мөҗәй), «Әйтелмәгән васыять» (Әмирхан Еники), «Тукайдан хатлар» (Мөдәррис Әгъләмов)... Безнең һәр шагыйрьдә диярлек хат формасындагы шигырьләр очрый. Хәзер инде бу исемлеккә Әхсән Фәтхетдинов та керә булып чыга. Кем белә, бәлки, туган телебездә язылган мондый хатларның соңгы үрнәкләредер алар...

Әхсән Фәтхетдиновның вафатына да ун еллап вакыт үтеп бара (1939–2012). Ул үзенең Зур Шәхес, Зур Рәссам икәнен белеп бакыйлыкка күчкәндер. Авырлыклар белән, беркадәр соңлабрак булса да югары дәрәҗәләргә ирешә алды: Татарстанның халык рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Түбән Каманың мактаулы гражданины... Иң мөһиме – исән чагында ук ул халык мәхәббәтен яулады. 2002 елда сәнгатебез тарихында беренче тапкыр «Әхсән Фәтхетдинов» дигән (татар, рус, инглиз телләрендә) уникаль альбом чыгып калды. Россиядә һәм чит илләрдә аның дистәләгән күргәзмәләре оештырылды. 2016 елда Түбән Кама җирлегендә махсус бина төзелеп, даими эшли торган музей-галерея ачылды. Сүз уңаеннан әйтеп узыйк: андый музей-галереялары булган сәнгать ияләре Татарстанда берничә генә (Бакый Урманче, Әмир Мәҗитов, Илдар Зарипов, Константин Васильев һәм Әхсән Фәтхетдинов). «Әхсән хатлары» дип аталган бу китап та Рәссам исемен мәңгеләштерүдә тагын бер игелекле гамәл буларак кабул ителер, иншалла!

Ниһаять, китапның төзелеше һәм аны басмага әзерләү турында берничә сүз. Хатлар язылу вакыты буенча, хронологик тәртиптә бирелде. Алар кулдан, бик тыгыз итеп (кәгазь кытлыгын кичергән кешенеке бит!), үзенчәлекле стиль һәм гаять үзгә почерк белән язылган. Безгә күпмедер дәрәҗәдә текстолог вазифасын да башкарырга туры килде. Хатларда кабатлаулар да шактый. Шуңа күрә бераз җыйнаклаулар булды. Бериш фактлар, аерым эпизодлар, адресатка әйтелгән комплиментарь сүзләр дә беркадәр кыскартылды. Әмма эндәш сүзле башламнар, нигездә, сакланды. Уртак эчтәлекне баету йөзеннән хат авторының фикерләренә тәңгәл килгән үземнән берничә шигырь өстәүне дә урынлы дип санадым.

Хат – бик нечкә нәрсә. Аны төзәтеп булмый һәм ярамый да. Саксыз кагылсаң, кайбер нюанслар югалырга мөмкин. Шулай да кайбер җөмләләр, калькалардан арындырылып, татарча яңгырашлырак итеп камилләштерелде.

Кульязманы басмага әзерләгәндә, байтак кешеләрнең көче керде. Киңәшләре, конкрет хезмәтләре өчен шагыйрь Зиннур Мансуровка, журналист Расиха Фәизовага, мөхәррир Гүзәл Габдуллаҗановага һәм фоторәссам Рифхат Якуповка аеруча рәхмәтлемен! Аларның саваплы гамәлләренә Әхсән абый рухы шат булыр дип уйлыйм.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН

Габдрахман Әпсәләмовның тууына – 110 ел

БАТЫРЛАРНЫ ДАНЛАГАН КАЛӘМ ИЯСЕ

Алма-Атада Татарстан китап нәшрияты авторлары белән очрашу. Габдрахман Әпсәләмов укучыларына автограф өләшә. 1962 ел.

Күренекле язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Габдрахман Әпсәләмовның (1911 – 1979) тууына 110 ел тулу уңаеннан аның «Газинур» романы буенча 1954 елда эшләнгән радиотамашаны яңартып, эфирга әзерләдек. Әлбәттә, үз вакытында әдипнең «Сүнмәс утлар» (бу әсәре өчен ул Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була), «Күк күкрәр» романнары, «Миңа унтугыз яшь иде» , «Идел хикәяте» кебек повестьлары, дистәләрчә хикәяләре халык тарафыннан яратып, көтеп алып укылды. Популярлыгы ягыннан әле бүген дә «Ак чәчәкләр» романына тиңләшерлек әсәр күренми кебек.

Шулай да, язучының юбилее көннәрендә «Газинур» романына мөрәҗәгать итүебез очраклы түгел, чөнки әдипнең иҗатында Бөек Ватан сугышы темасы аерым бер урын алып тора, аның язучылык каләме фронт шартларында формалаша. Сугыштан соңгы буын яшьләре милләттәшләребез батырлыгы турында сөйләгән «Алтын йолдыз», «Мәңгелек кеше», «Агыла болыт» романнары рухында тәрбияләнеп үсте. 1951 елда дөнья күргән «Газинур» романы каһарманнары да шул чор малайлары һәм кызлары өчен бер үрнәк булды.

Әсәр басылып чыгып, озак та үтми, легендар актёрыбыз Хәким Сәлимҗанов аңа нигезләнеп, радиотамаша сценариен яза. Радиоспектакль 1954 елда яздырыла. Хәким Сәлимҗанов үзе режиссёрлык итә. Баш каһарман Газинур Гафиятуллин ролен Ибраһим Гафуров башкара. Анда шул заманның күренекле артистлары катнаша: Газиз Зыятдинов (Гафиятулла бабай ролендә), Гөлсем Камская (Гафиятулланың хатыны), Рәшидә Җиһаншина (Миңнурый), Хәлил Әбҗәлилов (Сабир бабай), Абдулла Фәтхуллин (Галәк карт), Нәҗиб Гайнуллин (Гали, партком секретаре), Фоат Халитов (Сәлахи, колхоз рәисе), Госман Әхмәтҗанов (Газизҗан), Зариф Закиров (Мотыйк), Һидият Солтанов (Сәлим), Галимә Ибраһимова (Гөлли һәм Катя), Айрат Арсланов (алып баручы).

Журнал укучылары игътибарына тәкъдим ителә торган язма исә әдипнең Бөек Ватан сугышы темасына язылган тагын бер зур әсәре – «Кызыл йолдыз» романына бәйле. Биредә сез язучының үз тавышын ишетерсез. Ул әсәрнең язылу тарихын бәян итә. Аннары күренекле нәфис сүз остасы Әзәл Яһудин укуында романнан өзек бирелә. Әлеге чыгышлар магнитофон тасмасына 1960 еллар уртасында язып алынган.

Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.

ЯКТЫ ЯШЕН БУЛЫП ЯЗЫЛДЫ...

Хәзерге Чүпрәле районының Иске Кәкерле авылы тарихында тирән эз калдырган игелекле сәүдәгәр Атаулла Әсәдулла улының Алия исемле кызы күрше Татар Төкесе авылының Шәрәфетдин Нуретдин улына кияүгә чыга, һәм 1921 елның 24 декабрендә аларның Зәки исемле уллары дөньяга килә. Туган як табигатенең һәр могҗизасына сокланып үскән менә шушы малай көннәрнең берендә Зәки Нури дигән зур шагыйрь булып танылa.

Язучының тормыш юлы катлаулы, мажаралы, фаҗигале вакыйгаларга, икенче яктан – җиңүләргә, тантаналарга бай. Төке болыннарында печән чабып, урак урып, урман кисеп, олпат гәүдәле, тимер беләкле егеткә әверелгән Зәки 1937 елда Лубян урман техникумына укырга керә. Студент елларында каләм тибрәтә башлый. Бу дөньяның гел яктылыктан-нурдан гына тормаганлыгын да менә шунда аңлата тормыш егеткә: шаяртып кына әйткән бер сүзен «тиешле» урыннарга житкерүчеләр табыла, һәм Зәки, хөкем ителеп, 1938 елда Ерак Көнчыгышта диңгез порты төзелешенә җибәрелә. 1940 елда кайта һәм Шомыршы урман хуҗалыгында эшли, шуннан соң гына техникумны тәмамлауга ирешә.

1941 елның маенда армиягә алына. Сугышның беренче көннәреннән үк канкойгыч бәрелешләрдә катнаша. 1941 елның августында чолганышта калып, партизаннар отрядына кушыла. 1946 елда З.Нури туган якларына кайта һәм башта Буа урман базасы, аннары Тархан леспромхозы директоры булып эшли.

1949 елдан шагыйрьнең гомер юлы Казанда дәвам итә: ул «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасының баш мөхәррире урынбасары, Татарстан китап нәшриятында редакция мөдире, Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант, җаваплы секретарь, рәис, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булып эшли.

«Эшләрегез кеше күңеленә якты яшен булып язылсын!» – дип эндәшкән иде әдип үзенең бер шигырендә. Шушы сүзләре белән ул үз кыйбласын, калебен, җирдә яшәвенең максатын да бик ачык аңлатып биргән икән бит. Чыннан да, Зәки Нури дигән исем халкыбыз хәтеренә якты яшен булып язылып калды.

Язучының тууына 100 ел тулу уңаеннан Татарстан радиосы фондында язмалар барлап чыгылды. Безнең архивта бүгенге көндә аның шигырьләренә иҗат ителгән 14 җыр саклана һәм алар әледән-әле тапшыруларыбызда файдаланыла. Шунысы да игътибарга лаек: «Җилләр иссәләр» (Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы), «Туган җиремә» (Нәҗип Җиһанов), «Болытлар» (Котдус Хөснуллин), «Гомер бер генә килә ул» (Фәрит Хатыйпов) кебек җырлары бүгенге җырчыларыбыз тарафыннан да яратып башкарыла. Шулай ук әдипнең шигырь бәйрәмнәрендә, төрле әдәби кичәләрдә, каләмдәшләренең юбилейлары уңаеннан ясаган чыгышлары архивта аерым урын алып тора. Журнал укучылар игътибарына Зәки Нуриның үз укуындагы шигырьләре тәкъдим ителә. Язма 1970 елларга карый. 1980 елда Татарстан радиосы фондына граммофон тәлинкәсеннән күчереп алынган.

Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.

Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

Шатлыклар

Яңа йортка күчеп килдек. Төеннәрне чишеп-сүтеп, әйберләрне урнаштырып ятканда, ишек шакыдылар. Ачсам, бер ир заты басып тора. Кулындагы чәчәкләрен сузып:

– Исәннәрме! Яңа фатир белән котлыйм сезне! Күршегез булабыз, – диде ул.

– Рәхмәт, рәхмәт! Үзегезне дә котлыйбыз! Исән-сау, тынычлык белән яшәргә язсын! Түргә узыгыз!

– Юк, узып тормыйм. Урнашыгыз әле, аннары күрешербез, – дип, күршем шундук чыгып китте.

Чәчәкләрен вазага куйдык. Безнең чәчәк яратканны белгәннәр, диярсең.

Мондый игътибарга күңелебез булды, әлбәттә. Бирсен Ходай, яхшы кешегә охшаган. Эшкә җиңнәребезне тагын югарырак сызганып тотындык. Анысын – монда, тегесен тегендә куя-куя, кым-кырыч киләбез. Тик теге чәчәкләргә күз төшкән саен ниндидер канәгатьсезлек сизәм. Кеше, зурлап, нинди матур букет бүләк итте, туган-тумачалардан да алдан яңа фатир белән котлады, ә без һаман үз эшебез белән мәшгуль. Юк, ярамый болай, кешечә түгел бу.

Эшне туктатып, үзара киңәшеп, аларны да котларга кирәк дигән уйга килдек. Ни бүләк итәргә? Чәчәккә каршы чәчәк бирү килешмәс. Белмәгән кешеләр алдында ким-хур буласы да килми. Кинәт стенага элеп куйган бизәкле тәлинкәгә күзем төште. Менә ул бүләк! Чәчәге дә үзендә, шиңми дә, стенаны да бизәп торачак!

Минем белән өйдәгеләр дә килеште. Шул тәлинкәне алып, күршеләргә кереп киттем. Аларны яңа фатирлары белән котлагач, аны күршем кулына тоттым. Ул аларга бик ошады. Хәтта хатыны: «Карале, нинди гүзәл нәрсә!» дип әйләндерә-әйләндерә карады. Аның бәясе дә «гүзәл» шул, дидем эчтән генә.

Шул көннән башланды безнең чын күршелек. Бер-беребезне туганнардай күрдек.

Алар безнең өй туе мәҗлесенә зур стена сәгате алып керделәр. Ә без аларныкына ике урындык бүләк иттек. Аннары, минем туган көнемне үткәргәндә, аларның кухня өстәле безнең кухняга күчте. Рәхмәт, зурладылар! Безнең дә калышасыбыз килмәде, әлбәттә: хатынының кырык яшьлегенә бер кәнәфиебезне кертеп куйдык. Икенчесен мәчеләре бәбиләгәч бүләк иттек. Шахтёрлар көнендә безгә үз кәнәфиләрен керттеләр. Аласыз булгач аласыз, зур бәйрәм бүләгебез шушы дип, сүзләрендә нык тордылар.

Шулай дип этә-төртә торгач, нишлисең, алдык. «Күрше хакы – тәңре хакы», диләр бит.

Үзебезнең креслоны аларга Космонавтлар көне хөрмәтенә бүләк иттек. Танкистлар көнендә алар безгә – япон магнитофоннарын. Ә безнең төсле телевизорыбыз аларга ГКЧПның җиңелүен бәйрәм иткәндә кереп утырды. СССРның таркалуы, БДБ оешуына бер ел тулу бәйрәмен билгеләп үткәндә, күршебезнең суыткычы безнең кухняга күчте. Зур бүләк! Ничек җавапсыз каласың?! Яңа елга үзебезнекен аларга бүләк иттек.

Кыскасы, күршебез белән шулкадәр тату яшәдек, бер бәйрәмне дә ялгыз гына каршыламадык! Һаман бергә-бергә, һаман якын туганнар кебек. Шулай яши торгач, безнең бөтен нәрсәбез – аларга, аларныкы безгә күчеп бетте. Стенкага, стенадагы келәмнәргә тикле!

Әй, күңелле дә икән күршеләр белән тату яшәве! Аларга килеп кергәч, үзеңне фатирыңда шикелле сизәсең: һәрнәрсә таныш, һәрнәрсә якын, үзеңнеке... Хатыны киемнәр үтүкләп ята икән, карыйсың – үтүге дә таныш, тактасы да... Кече кызлары беренче сыйныфка укырга кергәч бүләк иткән идек. Идәндәге линолеумнарына тикле синең фатирныкы... Монысын бер Африка хатынының берьюлы биш бала табуын бәйрәм иткәндә биргән идек.

Әйтәм бит, күңелле нәрсә икән бу! Хәер, эш бүләктә генә дә түгел. Аларны бер-береңә бүләк иткәндә әйткән сүзләр ни тора! Нинди матур-матур теләкләр әйтелде, күпме рюмка чыңнары яңгырады! Онытылмас минутлар! Шуңадырмы, әллә әйберләребезне сагына башладыкмы, керәсе генә килеп тора шул күршеләргә!..

Үзегез беләсез, кеше тормышында бәйрәмнәр шактый җыела. Ләкин инде бүләк итәрлек әйберләребез бетте. Нишләргә? Озак баш вата торгач, бер карарга килдек. Туктале, дидек, без генә түгел, алар да сагынадыр үз әйберләрен! Шулай булгач, «күрше хакы – тәңре хакы» дигәнне тагын искә алырга кирәк...

Шулай уйладык та, Балыкчылар көнендә аларга үз суыткычларын бүләк иттек. Сөенүләрен күрсәң! Елый-елый үптеләр аны! Сагынганнар. Ә алар торгынлык елларын искә алып, бәйрәм иткән көнне кухнябызга үзебезнекен кертеп куйдылар...

Һәм китте шуннан! Ике ел дигәндә, бөтен нәрсәбез дә – үзебезгә, ә күршеләрнеке үзләренә әйләнеп кайтты. Иң соңгысы булып, бизәкле тәлинкәбез стенага менеп кунаклады.

Күршеләр белән тату яшәү ничек рәхәт! Шатлык өстенә шатлык өелеп тора!

Әхәт САФИУЛЛИН

Редакциядән:

Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.

ПАРЧАЛАР

Маркиз «А»дан башлый

Шагыйрь Равил Фәйзуллин иҗатта гына түгел, көндәлек тормышта да «шаккатризм»нар ясарга ярата. Хәтерлим, гомеренең бишенче дистәсен әкренләп ваклый башлаган чакта, төгәлрәк әйткәндә, 1984 елның августында ул күпләрне яңадан гаҗәпләндерде.

Алдан килешенгәнчә,Үзәк мәдәният һәм ял паркында бер төркем каләм ияләре җыелды. Сөзәк юл буйлап Казансу ярына төштек. Анда безне шактый олы катер көтеп тора иде. Хәйран калдык. Иделдәге Маркиз утравына барасыбызны белгәч, ис китүләр тагын да көчәйде. Менә шундый тарихи урында үзенчәлекле бәйрәм оештырылсын әле!

Гәрчә әдәби-спорт чарасы эчтәлеге салынса да, бу сәяхәттә сәйранлыкның барлык гамәлләре кылынды: шашлык кыздыру да, шәраб уртлау да, мәзәк сөйләү дә, җыр сузулар да... Ә инде куаклыкта чуен коелмасына охшаш «А» хәрефенә юлыгу бергәләп күңел ачуның градусын бермә-бер арттырып җибәрергә сәбәпче булды. Җитмеш сантиметрлап биеклектәге ошбу саллы табылдыкны баш өстенә күтәреп, кәеф-сафа корып утыручы каләмдәшләр хозурына чыгып басарга җөрьәт иттем. Хәрбиләрчә үрә катып, башлангыч сыйныф укучысыдай, бөтен атауга яңгыраттым: «Ахунов – писатель с большой буквы!»

Дан-дәрәҗә диңгезендә байтак йөзгән Гариф абый үзгә ләззәтлек белән гөлдер-гөлдер көлеп җибәрде. Мәҗлес «президиумы»ндагы Сибгат Хәким исә, үз-үзен көчләгәндәй, бик тыенкы гына елмаеп куйды. Нишлисең, әгәр агачлыкта «Х» хәрефе табылса, Сибгат аганы шулай зурлар идек. Әмма күпне күргән «Маркиз иясе» алфавиттагы тәүге билгене әзерләп торган. «Писатель с большой буквы» тәкъдир бүләген сыйпый-сыйпый карады, соңыннан аны өйгә алып кайтачагы хакында белдерде.

...Новаторлар урамындагы йортның подъездына кергәч, авыр «ганимәт»не аркама салып, Ахуновлар яшәгән фатир катына күтәрелдем. Ишекне көттермичә ачкан Шәһидә апа: «Бәрәч, бу ни бу?» дигән сүзләр белән әсәрләнүен белгертте. Иңбашымны сызлата башлаган «А» хәрефен янә өскә чөеп, күптән түгел Маркиз утравында горуранә әйткәнемне чатнатып кабатладым: «Ахунов – писатель с большой буквы!»

Уенын-чынын аңлап алган хуҗабикә ихтыярсыз шаян дулкынга кушылды: «Ниһаять, «А»сы кайтты, Хунов кайда?» Баскычтан менүче Гариф абый «Монда, әнисе!» дип җаваплады. Аннары Шәһидә ханым, өйгә керешли, дәрес бирә башлады. «Минем Гарифым мондый күгәргән күрсәтмә әсбапларга мохтаҗ түгел, аны хәзер бөтен СССРда зур әдип буларак таныйлар, – диде ул, ирен яклап. – Тын океандагы Маркиз атауларына барсагыз гына инде... Полинезиядә татар әдәбиятын әлегә начаррак беләләр...»

Менә сиңа кирәк булса! Баксаң, «Маркиз» исеме белән аталган утрау Иделдә генә түгел икән бит. Җәгърафия тиешенчә өйрәнелмәгән. Гөлшәһидә апаның кызыклы тәкъдимен Равил Фәйзуллинга мотлак җиткерермен. Оештырсын. Җәмәгатьчелекне тагын гаҗәпләндерер. Суны бөтенләй күрмәгән кеше кебек, мохит диңгезендә йөзеп тә алыр... Бездәге Маркиз «А»дан башлады. Бәлки, Полинезия әрәмәлегендә икебезнең дә күңеленә хуш килерлек табылдыкка – калыпта коелган «М» һәм «Ф» хәрефләренә тап булырбыз.

Их, яшиселәр алда әле!

Ятышып бетмәгән аталма

Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары булып эшләгән чакта шәһәр башкарма комитетыннан белгечләрчә киңәш итүне сорап шалтыраттылар. Кайбер элмә такталарны татарчалаштырырга ниятлиләр икән. Шуларның берсе – «Аптека» ләүхәсе. Янәсе, ошбу «урыс сүзе»ннән арыныр вакыт җитте. Үзләре «Даруханә»гә өстенлек бирмәкче. Теге җаваплы хезмәткәр безләрдән мәслихәт көтә: «Шушылай язу дөресме?»

Шундук хуплаудан тыелып калдым. Бала вакытта ук аңга сеңгән «әптик» сүзе безнең сөйләмнән тота-каба куып чыгаруны теләми кебек. Бераз уйларга кирәк...

Адәм баласының күңелендә нindидер тапшыргыч бармы?! Махсус төстә өеннән чакырып китергәндәй, кабинетыма Шәриф Хөсәенов килеп керде. Әһә, нәкъ үзе! Ул язучы гына түгел, исем алган табиб та. Бездән күбрәк белә – җәһәт ярып салыр. Рәсми оешма тәкъдимен кунагым кире какты.

– Ай, наданнар! Башны катырмасыннар әле. Анда дарулар гына сатып бирелми ласа, – дип тиргәнде ул. – «Аптека» атамасы борынгы грек телендә әйберләр саклый торган урынны аңлата. Склад...

– «Даруханә» әйтелеше дә шул эчтәлекне чагылдыра.

Миңа кысылмаска иде. Һәрдаим үз дигәнендә торучан әдип катгый рәвештә аңымны ача башлады:

– Менә синең якындагы берәр аптекага кереп, бәвел җыя торган савыт алганың бармы?

– Әлегә юк шикелле...

– Акчаңны түгәргә язмасын. Әмма әйт әле: писсуарга кардәш «утка» дару булып саналамы?

Аннары ТАССРның атказанган табибы гадәти аптекада сатылган, вәләкин дарулар җөмләсенә кермәгән дистәләп нәрсәне атады.

– Ышанмассың, әле кичәгенәк аптекага кагылып чыктым, кирәкне алдан кайгыртып, кырык данә презерватив сатып алдым, – диде үзсүзле Шәриф агай. – Әйдә, хәлдән таеп егылган сырхау картка шуның дару икәнлеген аңлатып карыйк. Кыскасы, «аптека»ны җиңел генә «даруханә»гә әйләндерү мәсьәләнең асылына төшенмәү сыман күзаллана. Чамалыйсыңдыр, тәкъдим ителгән исемегез җисеменә ятышып бетми.

Икенче көнне мин хөрмәтле Шәриф Хөсәеновның төпле фикерен шәһәр башкарма комитетының тәрҗемә эшенә алынган түрәләренә җиткердем. Язучының дәлилле шәрехенә игътибар бирүче табылмады. Хәзер башкаланың адым саен диярлек очраган даруханәләре яныннан узганда әдипнең дәвага бернинди катнашы булмаган әйберләр исемлеге искә төшә. Шул исәптән дәртле бәндәләр тарафыннан бик яратып кулланылган, аптекада оялыбрак алына торган теге интим нәмәрсә дә...

Телдән төшмәүче гыйбрәт

Шулай берчак республика парламентының чираттагы көзге сессиясендә каләмдәшем Туфан Миңнуллинның чыгышын тыңларга насыйп кылды. Анда алдагы елның бюджеты тикшерелә иде. Язучыбыз байтак өстәмә чыгымнар таләп иткән мәдәниятне шулкадәр яклады ки, бик кысмыр күренгән баш финансистның да күңеле ихтыярсыз эрегәндер. Залда кемнәрдер мыгырдап куйгач, стадион белән театрны үзара чагыштырып, уйландыра торган нәтиҗә китереп чыгарды. «Җәнҗал куптаручан җанатарлар гаугалы матч ахырында өерелеп сугыша башлый, – дип күрсәнде ул. – Ипле тамашачылар исә спектакльдән соң матур гына кайтып китә...»

Мин Туфан Миңнуллиннан әлеге нотыкны «Мәдәни җомга»га бирүен үтенгән идем. Әдип аны алып килде. Тиз-тиз караштырып чыктым. Театр алдындагы мәйданда кыйнашның булмавын чагыштырмалы төстә раслаучы сүзләр, ягъни теге гаҗәеп

гыйбрәтле күзәтү кәгазьгә нигәдер төшерелмичә калган. Автордан төпченеп сорадым. «Анысы халыкка болай да таралыр ла», – дип аңлатты ул исе китмәгән сурәттә. Аннары безнең сөйләшү, пьесадагы шикелле, диалогка тарта башлады.

– Туфан абый, шулай да әйт әле: нилектән стадионда бәргәләшләр күбәйде?

– Монда ниндидер парадокс күрәм. Мәдәният элек-электән «калдык принцибы» буенча яшәүгә дучар ителгән, спортка исә хәзер төрле яклап ниһаясез миллионнар ишелә. Һәм спонсорлардан да. Бүген шар сугучының айлык хезмәт әҗерен СССРның халык артисты төшендә дә күрми.

– Димәк, аерым максатларда күпләп түгелгән акча кайбер очракта уңай нәтиҗә бирми.

– Бу хак ич. Әлеге шактый ук катлаулы мәсьәлә тәрбия дәрәҗәсенә дә барып бәйләнә. Юкса бәндәнең сәламәт тәнендә сәламәт акыл булырга тиеш. Әмма атлет гәүдәле егет, юк-бар өчен, сине тукмап китәргә мөмкин. Урыслар әйтмешли, сила есть, ума не надо. Гелән сәмәндә коену аларны масайта гына.

– Ә спорт сөюче гади кавем нигә шулай чыгырдан чыга соң?

– Ихтимал, бәгъзеләрнең шул кансызлыгы белән бериш фанатлар да йогышлана. Уенда комарлык та үз йогынтысын ясыйдыр.

– Сәхнәдә дә бит уйныйлар. Әйтик, «Галиябану» спектаклендә Исмәгыйль Хәлилгә алтатарын төбәгәч, театр әхрамына килүчеләр икегә бүленеп дөмбәсләшмәде.

– Сәнгать кешеләрнең хисен әхлак кысасында тота... Барысы да бер чиктән икенчесенә ташланудан, һөнәрмәндләр хезмәтен бәяләүдә чик-чама белмәүдән киләдер. Берәүләр бал да май эчендә йөзгәндә, кемнәрдер фидакярлекләре өчен рәхмәт тә ишетми. Кайсыдыр язучы искәртеп үткәнчә, бу замандагы спорт галәмәтләре – физкультураны абсурдка җиткерү ул.

– Туфан абый, син гавами спортка каршы түгелдерсең бит?

– Ты что?! Хәзер ансыз яшәп булмый. Вәләкин спорт тирәсендәге хәттин ашулар әлеге хәрәкәтнең асыл мәгънәсен киметә. Сабан туе ярышларының әүвәлдән килгән гаделлеге дә, чын олимпия рухы да һәрчак сакланырга тиеш...

Гадәттәгечә, тере табигатьле Туфан Миңнуллин озаклап утырырга яратмый иде. Депутат каядыр ашыкты... Инде байтак еллар үтте. Дөрестән дә, аның стадион янындагы бәргәләшләр турында сөйләве халык теленә ныклап керде, ошбу гыйбрәтле күзәтү төрле чыгышларда да бик урынлы искә алына. Кызганыч, күңелсез нәтиҗәләр яшәүчәнлеген югалтмый. Физик күнегүләрдә чыныккан кемсәләр гаепсез кешеләргә ешрак гайрәт чәчә, допинг кулланган килеш олимпиадаларда җиңүгә омтылган хәрәмчеләр саны арта, дөнья спорты оешмаларында коррупциягә бирелү очраклары кимүгә табан бармый, мөһим карарлар чыгарганда ике яклы стандартлар әледән-әле өстенлек ала...

Менә шундый хәлләр, Туфан Абдуллович! Синең теге искерми торган шаккатырлык сөйләгеңне югарыгы мөнбәрләрдән һәмишә тәкрарларга туры килә.

Шәле тарихында «Франция эзе»

Исемең кемнәр куйган?.. Мәгълүм халык җырындагы ошбу сорауны татар кызлары җәһәтеннән генә түгел, асылы ачылып бетмәгән авыл атамаларына мөнәсәбәтле рәвештә дә бирергә мөмкин. Әйтик, иң зур салаларыбызның берсе булып саналган Шәле үзен шулай исемләүчене нигә һаман яшереп тота? Әлеге топонимик берәмлеккә ниндиерәк мәгънә салынган?

Бу уңайдан галимнәрнең берничә фаразы бар. Аларына тукталырга теләмим. Әле гавамда да төрле шәрехләр йөри. Берәүләр авыл исемен шәлегә, ягъни ярдырылмаган дөгегә бәйләмәкче. Ай-һай, монысы бик бәхәсле. Җылы яратучан үсемлекне игәр өчен безнең якларда тиешле шартлар юк. Шәледә яшәүчеләр дөгегә түгел, элек-электән бәрәңгегә өстенлек биргән. Икенчеләр аңлатканча, яңа салага нигез салучылар янына, теләсә нәрсә сорап, якын-тирәдән капчыклы руслар килгәләп торган. Артыгын

кыланган очракта, аларга кисәтү ясалган: «Не шали, быррат!» Шәле әйтелеше, имеш, шулай тарала.

Не шали, дигәннән, Чечнядагы алагаем олы Шалины да, адашлыкка нигезләнеп, үз җиребездәгесе белән туганлаштыручылар күренгәли. Янәсе, аларның һәр икесендә дә бердәй холыклы кешеләр яши. Әйе, нәрсәнедер расларга омтылганда алымнар төрлелеге кирәк. Әнә, язучы Марат Закир Шәле этимонын якындагы Мишә елгасына китереп бәйли. Зураеп килүче авыл башта Мишәле намен йөрткән, «ми»нең артыклыгы беленгәч, халык аны Шәле дип кенә атый башлаган.

Күпләп җыелган әлеге фаразларны башымнан чыгарып торган идем. Франциядә яшәүче танышым беркөнне телефоннан шалтырата. Хәл-әхвәл белештек, озаклап сөйләштек. «Хәзергә саубуллашыйк, – дип түгәрәкләде ул. – Шәлегә җыенам...» Бәтәч! Аптырап киттем, аннары өстәдем: «Алайса, каләмдәшем Камил Кәримов белән без дә килербез, шунда телләр чишелерлек кенә пирәшләп тә алырбыз».

Парижда гомер итүче милләттәшем мәшәкатьләнмәскә кушты, әлеге очрашуның чыгымлы булуы хакында искәртте. «Син анда нинди расходлар турында сөйлисең, – дидем мин, каршы төшеп. – Казаннан ярты сәгатьлек кенә юл бит...» Ниһаять, аңлаштык. Шәле түгел, шале! Баксаң, шәһәр читендәге дача йортларын французлар шулай атый икән. Чит-ят җирдә тамыр җибәрергә өлгергән ыругдашым үзенең җәйге өенә баруны күздә тоткан.

Телефон аша сөйләшүдән айный төшкәч, теге фаразлар янәдән хәтергә килде. Карасана, бернинди максатсыз элемтәгә чыккан «француз татары» безләргә өр-яңа эзләнүләр юнәлешен күрсәтте ләбаса! Мәсьәлә почти чишелде. Иренмичә күзаллагыз: күпмедер вакыт Франциядә яшәп алган татар аксөяге, Казан ханлыгына кайтып, Мишә елгасы тирәсендәге матур урында йорт төзетә. Әлбәттә, бераз кыланырга яраткан зат, король илендәге кебек, аны шале дип атый. «Француз» кушаматлы зыялының корылмасы янәшәсендә тора-бара башкалар да өй торгыза. Әүвәлге заманда менә шул рәвешле бүгенге Шәле авылына нигез салына. Аңлашылганча, аның тарихында «Франция эзе»н тома сукырлар гына күрмәс.

P.S. Әлеге гөман кылуларга мыек астыннан көлеп караучылар булса, алар кире кагылгысыз чын-хак фаразларын җәмәгатьчелеккә тәкъдим итсен.

Төртмешләр

• Яман атлы Шаһгали җенси яктан кысыр булган, әмма аның токымы һәрбер заманда да яши.

• Тарихтан үзләренә файдалы гыйбрәт алсын өчен, кайбер иләмәннәрнең «арт сабагын» укытырга кирәк.

• Газиз кавемебезне канга батырган Явыз Иванның һәйкәл булып күтәрелергә бернинди дә хакы юк, гыйбрәт өчен, ул Кремль диварына ахыр чиктә «Я здесь был» дигән сүзләрне генә язарга мөмкин.

• Әгәр Мономах бүреген мәчеткә атсалар, аны күпләр кереп алырга тырышыр.

• Гап-гади кендек әбисе шикелле, кирәкле вакытта кирәкле урында булырга өлгерсәк, игелекле гамәлләребез ишәеп китәр.

• Инфляция әйтерсең допинг куллана – пенсияне һәрвакыт артта калдыра.

• Иманы тотрыксыз булган җәмгыятьтә компьютер иблис коралына әйләнер.

• Утыра торган әгъзасы белән уйлаучы кемсәләр хәрәм акчага алтын унитазлы бәдрәф төзетә.

• Дөньяга килгән сабыйның беренче ришвәте бала табу йортында ук бирелә.

• Яшьлек юләрлеге белән башкарылган кайбер тәвәккәл эшне хәтта аксакал зирәклеге белән дә кабатлап булмый.

Зиннур МАНСУРОВ

2021 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ

2021 елны Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итү турында. №2

2021 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №5

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Галиуллин Р. Яңа елда яңа ниятләр. №1

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Марат Әхмәтов: «Өметебез – фидакарьләрдә» *(ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов белән Рөстәм Галиуллин әңгәмәсе)*. №4

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ахир. Камилә. *Бәян*. №9

Әхмәтгалиева А. Дулкыннар. *Документаль повесть*. №3

Әхмәтгалиева А. Бик. *Повесть*. №12

Бакиров М. Итек. *Хикәя*. №8

Батулла Р. Мур кырылышы. *Кинороман*. №№1-2

Галимуллин Ф. Сары каеш билләрдә. *Автобиографик бәян*. №№4-5

Гыйматдинова Н. Йә, кем кызганыч? *Повесть*. №7

Җиһангирова Ш. Кышкы бер төн. *Хикәя*. №12

Зыялы С. Рәнҗеш. *Хикәя*. №3

Исмәгыйлев Х. Фәйзулла. *Повесть*. №8

Корбан Р. Каргыш. *Повесть*. №1

Кара К. Килмешәк. *Бәян*. №7

Кәбиров М. Дәва. *Повесть*. №2

Кәбиров М. Кайту. *Повесть*. №6

Мирһади Г. Гитара. *Хикәя*. №11

Низамов И. Гөнаһлы бер көн. *Хикәя*. №9

Нуриев В. Казаннан – мияу. *Хикәя*. №10

Рахман Р. Татар кызы. *Роман*. №№9-11

Сабирова Л. Кол. *Хикәя*. №8

Садриев Ф. Синең белән янәшә. *Хикәя*. №3

Сәгъди Р. Алло, кем әле бу?! *Роман*. №№4-5

Хан А. Сабакташлар. *Хикәя*. №11

Ханнанов Р. Күләгәсезләр. *Хикәя*. №7

Хәмзин А. Ниһаять... *Бәян*. №6

Хөснияр З. Мәдинәгә медаль бирәләр. *Повесть*. №5

Шәйдуллина-Мурат Р. Карт шомырт хатирәсе. *Роман*. №№1-2

Шәфигуллин Р. Качкын. *Бәян*. №6

ШИГЪРИЯТ

Әхтәмова Г. Өмет уты балкып торсын җанда. *Шигырьләр*. №12

Бәшәр Р. Бозлык чорын исән-сау кичәсе бар… *Шигырьләр*. №12

Вәлиева Л. Хәят бакчам җете төсләр тулы... *Шигырьләр*. №6

Гайнетдинова Г. Яшим җирдә сөеп бу тормышны. *Шигырьләр*. №1

Гаташ Р. Өч Тукай яшен яшәгән Гаташмын... *Робагыйлар, уйланулар*. №3

Ганиев Н. Зур суларда дулкын биек була. *Шигырьләр*. №2

Гыйбадуллина Л. Дәвам. *Шигырьләр циклы*. №7

Гыйззәтуллина Ф. Коллык зинданы. *Поэма*. №9

Җамал Р. Чәчәктә булсам да күзләрен... *Шигырьләр*. №10

Җамалетдинова Ф. «Илем» дияр өчен ил кирәк... *Шигырьләр*. №1

Җәлил М. Бер үгет. *Шигырь*. №2

Җәлилова Э. Гомернең төш кенә булуы ихтимал... *Шигырьләр*. №11

З а р и ф Ф . Киләчәккә кем соң юл салыр?!. *Шигырьләр*. №12

З ә й д у л л а Р. Каратай робагыйлары. №6

З ө л к а р н ә й Л . Идегәй итеге. *Кунычтагы ильязма*. №4

И б р а һ и м Б . Кем чоры бу... *Шигырьләр*. №10

И к с а н о в а И . Юл булдымы – учак кабынган... *Шигырьләр*. №1

К ә ш ф и Л . Ут өстендә биючеләрдер без... *Шигырьләр*. №8

К о р б а н о в а Г. Кышларның төннәре бик озын... *Шигырьләр*. №12

Л е р о н Л . Вакытны шул булмый туктатып... *Шигырьләр*. №2

Л е р о н Л . Күңелемә шигырь оялады... *Шигырьләр*. №11

М а н с у р о в З . Тиккә ваем чикмәс идем... *Шигырьләр*. №7

М и р з а М . Адәм баласы. *Бишьюллыклар*. №11

М о р а т Г. Күкрәп шыткан язның тын аһәңе... *Шигырьләр*. №8

М ө җ ә һ и т . Кабатлансын догалар... *Шигырьләр*. №2

М ө х и я р Р. Һәрбер таңның үзгә матур җыры... *Шигырьләр*. №6

М ө х ә м м ә т ш и н Г. Үткән еллар кайтавазы. *Шигырьләр*. №10

Н ә г ы й м Д . Мең кабат карадык үлемнең күзенә... *Шигырьләр*. №8

Р а х м а н Р. Кешенең кыйммәте – илендә... *Шигырьләр*. №3

Р ә х м ә т у л л а С . Сагыну. *Поэма*. №5

С ә г ы й д у л л и н а Л . Яшә дә – сөйми кара!.. *Шигырьләр*. №9

С и т д ы й к о в а Ә . Көн күрү – яшәүме бу җирдә?! *Шигырьләр*. №7

С ө л ә й м а н . Имән шаулый гасырларда... *Шигырьләр*. №3

С у ф и я н о в А . Без югалткан сүзләр – күктәме?.. *Шигырьләр*. №6

Ф ә т т а х о в а Л . Кеше һәрчак сайлау белән сыналуда… *Мәсәлләр*. №5

Х а р и с Р. Мин – мильон яшьлек кеше! *Шигырьләр*. №5

Х ә б и б у л л и н а Л . Синсез һава миңа агу төсле... *Шигырьләр*. №7

Х и с а м и е в а А . Ак кәгазьдән нәни очкыч ясыйм... *Шигырьләр*. №11

Ш ә е х Л . Офыклардан кояш күренә... *Шигырьләр*. №4

Ш ә р и ф у л л и н а Э . Кагылмагыз телгә! *Шигырьләр*. №9

Я к у п о в а С . Тамыр кайда – шунда танырлар. *Шигырьләр*. №8

Я н с у а р Л . «Мин сөйләшәм илем белән...». *Шигырьләр*. №9

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Х ә к и м З . Хаталы хат. *Пьеса*. №8

ЯҢА ИСЕМНӘР

Ә б ү д ә р о в а Л . Умарта. *Повесть*. №3

Ә х м ә д и е в Р. Бары синңа җиңеләсем килә. *Шигырьләр*. №5

Б и л а л о в И . Мәдинә тавы. *Повесть*. №№10-11

Г ы й м а е в а И . Тәрәзәмә йолдыз кунды... *Шигырьләр*. №3

З а к и р о в а Р. Мәгънәсе ни яшәвеңнең?.. *Шигырьләр*. *(Ф.Җамалетдинованың кереш сүзе белән)*. №7

Х ә л и у л л и н Б . Вакыт комны ташка әйләндерә... *Шигырьләр*. *(И.Иксанованың кереш сүзе белән)*. №6

«АҺ, ТУГАН КАУМЕМ ГАЗИЗ!»
ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

В ә л и е в а Н . Кояш исле балачак. *Хикәя*. №9

Г ә р ә е в а - А к ч у р а А . Истанбул малае. *Повесть*. №№4-5

Җ и һ а н г и р о в а Ш . Килен капкасы. *Хикәя*. №2

К ә р и м о в а Р. Колымада. *Хикәя*. №6

Р а х м а н Р. Карга карынын кем белгән. *Хикәя*. №7

Р ә й х а н Х . Прасковья. *Хикәя*. №11

С ә ү б а н о в а С . Әткәм чыбыркысы. *Хикәя*. №10

Х ә л и м о в а И . Бер гомеремә – ике дөнья. *Хикәя*. №3

Ш ә р и п о в Ә . Мәрсия. *Хикәя*. №8

Ю н ы с о в а А . Хатыннар сүрәсе. *Бәян*. №12

ЕРАКТАГЫ УТЛАР

З ә к и е в А .Тегермән. *Хикәя*. №1

Мәҗитова В. Алмалар алланганда. *Хикәя*. №8

Сөләйманов Р. Айдар илендә ниләр бар? №1

Сөләйманов Р. Бер матурлык чыганагы. №8

Тормыш иттек читтә... *(Рушания Абрахимова, Шәфикъ Иматдинов, Оксана Ильюп, Ифира Хәлимова, Гөлсинә Ханәфи, Фаил Гыймадов, Гөлсөя Бәдгиева, Фәрит Әхмәдиев шигырьләре)*. №3

Хәлиуллина А. Өзелгән кыллар моңы. №11

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Әхмәтов М. Халкым миңа газиз, газиз туган төяк! *Шигырьләр. (Р.Корбан тәрҗемәләре)*. №9

Бедюров Б. Мин бу җирнең һәр төсенә гашыйк... *Шигырьләр. (Р.Вәлиев тәрҗемәләре)*. №11

Гошалы Ә. Һәр авазда да сүз ясап булмас. *Шигырьләр. (Р.Сәлах тәрҗемәләре)*. №10

Данилов С. Мин туган идем карда.. *Шигырьләр. (Р.Зәйдулла тәрҗемәләре)*. №6

Зәйдулла Р. Саха учагының җылысы. №6

Ишмөхәммәтов Б. Яу сындырмас дусише күп булганны. *Шигырьләр. (Р.Корбан тәрҗемәләре)*. №8

Кадрия. Зур халыклар җырлый минем җырымны... *Шигырьләр. (Р.Корбан тәрҗемәләре)*. №9

Каһарманова М. Сәлам. *Хикәя*. №6

Осман Д. Татарлыкны дәвам иткән егет, кызлар туармы? *Шигырьләр. (Р.Зәйдулла тәрҗемәләре)*. №12

Семендер Ю. Әҗәткә дип бирелми вакыт... *Шигырьләр. (Р.Зәйдулланың кереш сүзе белән)*. №1

Сөләйман С. Мәдхияләр язды шагыйрь... *Шигырьләр. (Ф. Гыйләҗев тәрҗемәләре)*. №12

Тепуков К. Таулар йоклый күптән, төш күреп... *Шигырьләр. (Р.Корбан тәрҗемәләре)*. №11

Тумат С. Хатирәдән күңел җылына. *Шигырьләр. (Р.Зәйдулла тәрҗемәләре)*. №6

Укачин Б. Алтай илем! Мин бит синең улың! *Шигырьләр. (Р.Вәлиев тәрҗемәләре)*. №11

ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР

Диндаров И. Хикәяләр. №8

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Гайнуллина Г. «Чыбыркы тәртипкә чакыра...» *(Зиннур Хөснияр иҗатына күзәтү)*. №7

Галиуллин Т. Бәхетне эзләп табалар... №11

Ганиева-Гыйниятуллина А. Гаделлекне маяк иткән әдип *(Фоат Садриевка – 80 яшь)*. №3

Каюмова Г. Камил геройлар остасы *(Ризван Хәмиднең тууына – 80 ел)*. №8

Мансуров З. Өзгәләнгән күңел иҗтиһаты. №1

Рахмани Р. Солтан Шәмси: заман сынаулары аша... №7

Рахмани Р. Еракка китүләр... сагындыра *(Мөдәррис Әгъләмовның тууына – 75 ел)*. №12

Хафизов С. Бер бите – Шәрык, бер бите – Гареп... №2

Хәбетдинова М. «Чүп базары»нда яңгыраган шагыйрь тавышында нинди аһәңнәр ишетелә?.. №11

Йосыпова Н. Юк, тыелып торма, шагыйрь, бар тавышың белән оран сал *(Гәрәй Рәхим иҗатына күзәтү)*. №7

ҖӘҺӘТ ТӘНКЫЙТЬ

Заһидуллина Д. Ленизa Вәлиева шигырьләре. №6

ФӘН

Заһидуллина Д. Татарның фән йолдызлары. №11

Заһидуллина Д. Бер кеше – берәгәйле кеше! №12

СӘНГАТЬ

Бакырга уелган уйлар... *(Рәссам Александр Иванов белән Айсылу Имамиева әңгәмәсе)*. №2

Хәмидуллин Л. Урта Азиядәге шәп татарыбыз *(композитор Латыйф Хәмидинең тууына 115 ел)*. №7

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТЛАР

Галиуллин Т. Канатлы иҗат. №4

Гыйбадуллина Л. Былбылларын эзләп, таңнар туа. №4

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 135 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Әбүдәрова Л., Янсуар Л. Тукай шәхесенә шәрехләр. *Эссе.* №2

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА – 135 ЕЛ

Таиров Н. Бөек шагыйрьнең рус телендәге беренче тәрҗемәләре һәм биографиясе. №4

Тукай нәселе киләчәккә бара... *(Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Мөдәррис Әгъләм, Рәдиф Гаташ, Разил Вәлиев, Харрас Әюп, Газинур Морат, Гөлүсә Батталова, Айрат Суфиянов, Сирень Якупова, Булат Ибраһим шигырьләре).* №4

«КАЗАН УТЛАРЫ»НЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Бәйрәмова Ф. Милләтнең әдәби авазы. №11

Вәли-Барҗылы М. Матурлык һәм бәхет кочагында. №8

Вәлиев Р. Яктырак яна «Казан утлары». №12

Гаташ Р. Шигърият, синең хакка!.. №7

Низами Р. Сүнмәс утлар яктысы. №9

Харис Р. Әдәби хәрәкәт үзәгендә. №10

«КАЗАН УТЛАРЫ» – МИНЕМ ЯЗМЫШЫМДА»

Әмирханов М. «Мичкәдә дары бетмәгән әле». №11

Гыйматдинова Н. «Син тәкәббер кыз икән...». №9

Зәйдулла Р. «Казан утлары» фатихасы белән. №7

Миңнегулов Х. Гомерлек юлдашым. №12

Морат Г. Ул мине шигырь белән дуслаштырды. №8

Сафин Ф. Юнәлеш бирүче басма. №10

КОТЛЫЙБЫЗ

КЛАРА БУЛАТОВАГА – 85 ЯШЬ

Акмал Н. Укучыларыннан бүләк булып ирешсен. №3

РӘДИФ ГАТАШКА – 80 ЯШЬ

Фотоархив: Рәдиф Гаташның тормыш мизгелләре. №3

РЕНАТ ХАРИСКА – 80 ЯШЬ

Фотоархив: Ренат Харисның тормыш мизгелләре. №5

ГӘРӘЙ РӘХИМГӘ – 80 ЯШЬ

Фотоархив: Гәрәй Рәхимнең тормыш мизгелләре. №7

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВКӘ – 75 ЯШЬ

Имамов В. Чатыр таудан дөнья шәп күренә *(Бер сәяхәт тарихы).* №10

Фотоархив: Марсель Галиевнең тормыш мизгелләре. №10

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВАГА – 65 ЯШЬ

Гайнуллина Г. Үзгә дөнья сурәте. №10

«ЧОЛБОН» ЖУРНАЛЫНА – 95

Корбан Р. Саха кардәшләребезнең таң йолдызы. №11

ЮБИЛЕЙЛАР

ГАМИЛ АФЗАЛНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Афзалова Н. Авыл белән бәхилләшү. №5

Афзал Г. Шигырьләр. №5

Акмал Н. Аның урыны әле дә буш тора. №5

РАФАЭЛЬ МОСТАФИННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Фәйзуллин Р. Якты шәхес. №5

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

(Сәхифәне Нәсим Акмал алып бара)

МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА – 130 ЕЛ

Милли музыкаль драманың атасы. №11

КӘШШАФ МОХТАРОВНЫҢ ТУУЫНА –125 ЕЛ

Туачак әсәрләр каһарманы. №7

ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ ТУУЫНА – 120 ЕЛ

«Киләчәккә хатлар» килә тора. №1

ГОМӘР БӘШИРОВНЫҢ ТУУЫНА – 120 ЕЛ

Җидегән чишмәләрнең серен ачкан әдип. №1

МӘРЬЯМ РАХМАНКУЛОВАНЫҢ ТУУЫНА –120 ЕЛ

Күңелдән җуелмас моң иясе. №11

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА – 115 ЕЛ

Бар җырымны илгә багышладым.... №2

ИБРАҺИМ САЛАХОВНЫҢ ТУУЫНА –110 ЕЛ

Чын дөреслек алып кайткан әдип. №8

ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ ТУУЫНА – 110 ЕЛ

Батырларны данлаган каләм иясе. №12

ГАРӘФИ ХӘСӘНОВНЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Табигатьне иркәләгән каләм. №6

ӘДИП МАЛИКОВНЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Утлар кичкән садә күңел. №8

ЗӘКИ НУРИНЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Якты яшен булып язылды... №12

САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ ТУУЫНА – 95 ЕЛ

Туган якка уза кош юллары... №10

ГАБДЕЛХӘЙ САБИТОВНЫҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ

Сүз тәмен тоярга өйрәтте... №6

ХӘНИФ ХӘЙРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ

Талмас канатлар куйды. №9

РӘШИТ ГӘРӘЙНЕҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ

Туган як җырчысы. №4

МИДХӘТ МИНШИННЫҢ ТУУЫНА – 85 ЕЛ

Туксанынчы еллар тавышы. №9

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВНЫҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

Ул каләмен манды бәгыренә... №4

ТӘҮФИКЪ ӘЙДИНЕҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

Кыйбла юлын сызып калдырды. №5

РӘШИТ ЯГЪФӘРОВНЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Халкым дип янып яшәде. №2

МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВНЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Тузга язган сүзләр генә калды. №10

РӨСТӘМ АКЪЕГЕТНЕҢ ТУУЫНА – 70 ЕЛ

Янды бер шәм таңнарда... №3

РАФАЭЛЬ СӘХӘБИЕВНЕҢ ТУУЫНА – 70 ЕЛ

Затлы җырчы, олуг шәхес. №7

ХӘТЕР

Корбан Р. Үлемсез шигърияте калды. *(Харрас Әюпнең тууына – 75 ел)*. №8

Корбан Р. Шигырь эзләп китте *(Фәиз Зөлкарнәйнең тууына – 70 ел)*. №12

Хәкимов Р. Сибгат Хәким урамында *(Сибгат Хәкимнең тууына – 110 ел)*. №12

ХӘТЕР ЯКТЫСЫ

Әхмәтҗанов Р. Күкрәп керик яңа гасырларга. *Шигырьләр*. №4

КИТАП КҮЗӘТҮ

Заһидуллина Д. Тукай юбилеена – кыйммәтле бүләк. №4

Заһидуллина Д. Әмирхан Еники – төрек телендә. №8

Минһаҗева Л. Сукмаклар буталганмы?.. №7

Фәйзуллин Р. Әманәт ителгән дәфтәрләр. №12

ӘДӘБИ МИРАС

Гаффар Ә. Чигенмәс елга. *Фаҗигаи поэма*. №1

Шаһиди Б. Ефәк хисләр. *Шигырьләр. (Г.Рәхимнең кереш сүзе белән)*. №1

ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН

«Мәхәббәттә кайчак ялгызлар без...». *Хатларны Г.Сафиуллина укыды.* №10

ҖАНИСӘП – 2021

Заһидуллин И. Россиядә халык санын алу тарихы. №№2,3,4,5

Заһидуллина Д. Без белгән һәм белмәгән Мәҗит Гафури. №6

Заһидуллин И. Керәшен татарларының мөселманлыкка кайту хәрәкәте. №7

Заһидуллин И. Төрле чор җанисәп мәгълүматларында татарларның саннарында аермалар һәм моның кайбер сәбәпләре турында. №8

Заһидуллин И. 1897 елгы беренче гомуми халык санын алу: татар җәмгыятен үзгәрткән чара. №9

Заһидуллин И. 1917 елгы инкыйлабка кадәр җанисәпләр: йомгак урынына. №10

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Бәйрәмова Ф. Татар галименең аянычлы язмышы... №9

Кәримов К. Брест. 22 июнь... *Очерк*. №6

ЗАМАНДАШЫБЫЗ

Нәсыйхова Л. Шигырьләрне җиргә язам... №1

Нәсыйхова Л. Туганлык кадере. №9

Нәсыйхова Л. Шагыйрьләрне мәңгеләштерүче. №3

МИЛЛӘТТӘШЛӘР

Гафиятуллина Ф. Эшкә бирсәң чын күңел. №3

Гафиятуллина Ф. Алтын башкалада кунакта. №5

Гафиятуллина Ф. Әти кеше иткән егет без. №6

Н ә с ы й х о в а Л . Шушы туфрактан без. №5

Н ә с ы й х о в а Л . Үз җирендә солтан. №6

Н ә с ы й х о в а Л . Татар зыялылары, берләшегез! №7

АК ҖИЛКӘН

Каләм тибрәтү – бушану чарасы. *(Алинә Хәбибуллина белән Айзилә Сабирова әңгәмәсе)*. №8

БӘЛӘКӘЙЛӘР

Бәләкәй Фирзәр. *Алмаз Хәмзин язып алды*. №8

УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

С а ф и н Р. Безнең рухта тау-кыялар биеклеге... *Шигырьләр*. №2

БАЛАЛАР КИТАПХАНӘСЕ

Ш ә р а п о в а Й . Туган телемне өйрәнәм. *Шигырьләр*. №4

КАЙТАВАЗ

Б ә й р ә м о в а Ф . «Ана» – документаль әсәр. №3

Г а б д е р ә х и м Ф . Тамчыда чагылган олуглык. №6

ПЕЧӘН БАЗАРЫ

М а н с у р о в З . Парчалар. №3

М а н с у р о в З . Парчалар. №12

С ә ү б а н о в а С . Көя даруы. *Юмористик хикәя.* №7

ШАЯН СӘХИФӘ

Б а т т а л о в а Г. Уены-чыны бергә. №6

Г ы й л ь м е т д и н о в а З . Уены-чыны бергә. №10

К ы я м о в И . Уены-чыны бергә. №2

С а ф и у л л и н Ә . Уены-чыны бергә. №12

Ю л ч ы . Уены-чыны бергә. №7

«Илең турында уйла» әдәби конкурсының җиңүчеләрен бүләкләү тантанасыннан фоторепортаж. №1

ТР Язучылар берлегенең XIX корылтаеннан фоторепортаж. №4

Юбилейга барышлый: Фотоархив. №9,10,11, 12

«Казан утлары» архивыннан. № № 1, 2, 5, 6, 8, 9, 10, 11, 12 *Сәхифәне Р.Фәйзуллин алып бара.*

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12. *Сәхифәне В.Нуриев алып бара*.

Яңа китаплар. № №3,4,6,8,9,11. *Сәхифәне Г.Морат алып бара*.

Хушлашу сүзе. Рәфикъ Юныс. №2 ; Гәрәй Рәхим. №10

Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ СӨЙЛӘШҮ

Татарстан Язучылар берлегенең киләчәктәге эшчәнлеге, башка иҗат берлекләре белән хезмәттәшлеге турында сөйләшү булды. Анда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, ТР Дәүләт Советының мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов, ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин катнашты. Сөйләшүне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды.

МАРСЕЛЬ СӘЛИМҖАНОВ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Марсель Сәлимҗанов исемендәге премияләрне тапшыру тантанасы булып узды. Быел бу олы бүләккә Г.Камал театры артисты Илдар Хәйруллин, драматург һәм режиссёр Салават Юзеев һәм «Живой город» заманча сәнгатькә ярдәм фонды директоры Инна Яркова лаек булды. Лауреатларга премияне Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова тапшырды.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫНА – 30 ЕЛ, ЛӘБИБ ЛЕРОНГА – 60 ЯШЬ

«ТАТМЕДИА»да «Безнең мирас» журналына – 30 ел, аның баш мөхәррире, шагыйрь, прозаик, драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, «Фидакарь хезмәт өчен» медале иясе, М.Җәлил исемендәге республика, Абдулла Алиш, Фатих Хөсни, Гамил Афзал исемендәге әдәби премияләр лауреаты Ләбиб Леронга 60 яшь тулуга багышланган кичә булып узды. Чарага журналның авторлары, язучылар, галимнәр, республикабыз газета-журналлар баш мөхәррирләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, Л.Леронның иҗатташ дуслары җыелган иде. Редакция коллективын, аның җитәкчесе Ләбиб Леронны Республика матбугат һәм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев (ул баш мөхәрриргә «ТАССРның 100 еллыгы» медален тапшырды), «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, ТР Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, «Идел-пресс» полиграфия-нәшрият комплексы генераль директоры Әнәс Әскәров, Татарстанның халык шагыйрьләре Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, язучы Данил Салихов, галимнәр Индус Таһиров, Хатыйп Миңнегулов, галимә Фәнзилә Җәүһәрова, республикабыз газета-журналлары баш мөхәррирләре исеменнән «Мәдәни җомга» газетасы баш мөхәррире Вахит Имамов, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең милли тапшырулар хезмәте җитәкчесе Миңназыйм Сәфәров, җырчылар Филүс Каһиров, Азат Тимершәех, Рузилә Бәдретдинова котладылар. Кичәне Айсылу Лерон алып барды.

КАР ИЛЕНДӘ ШИГЪРИЯТ БӘЙРӘМЕ

Саха Республикасы мәркәзе Якутск шәһәрендә «Үрүн хаар алгыһа» («Олы кар сөенече») халыкара шигърият фестивале булып узды. Ул 2012 елдан башлап Саха Республикасы хөкүмәте, Саха Язучылар берлеге, Төньяк-көнчыгыш федераль университеты тарафыннан оештырыла. Ике елга бер тапкыр үткәрелә. Быел Шигъри сүз дөньяның төрле кыйтгаларыннан язучыларны алтынчы тапкыр җыйды. Фестивальдә Татарстаннан каләм ияләре Рафис Корбан, Рүзәл Мөхәммәтшин катнашты.

Россия һәм Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге халыклары әдәбиятларын үстерү, пропагандалау, үзара багланышларны ныгыту кебек максатлар куеп оештырылган фестиваль күп кенә чаралардан гыйбарәт иде: Милли китапханәдә шигырь кичәсе, Матбугат йортында «Евразия музасы» дип аталган «түгәрәк өстәл» утырышы, Төньяк-Көнчыгыш федераль университетында, Платон Ойунский исемендәге әдәби музейда очрашулар, экскурсияләр, Саха әдәбияты классиклары бертуган Семён һәм Софрон Даниловларның туган ягы – Таулы (Горный) олысына сәфәр һ.б.

Кунакларны Саха Республикасы хөкүмәте рәисе урынбасары Сергей Местников кабул итте. Анда милли әдәбиятларны тәрҗемә

итү, аларны киң катлау укучыларга җиткерү, төбәкләр арасында мәдәни элемтәләрне ныгыту мәсьәләләре күтәрелде. Үзара хезмәттәшлекне үстерүгә зур өлеш керткән аерым иҗатчыларга Саха Республикасының дәүләт бүләкләре тапшырылды. Татарстаннан язучы Рафис Корбан Саха Республикасы башлыгының Рәхмәт хатына лаек булды.

«ЧОЛБОН»ГА – 95

Саха Республикасының төп әдәби журналы булган «Чолбон» редакциясе 95 еллык юбилеен билгеләп узды. Әлеге чарада Татарстаннан «Казан утлары» журналы баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин белән Башкортстаннан «Шоңкар» журналы баш мөхәррире Айгиз Баймөхәммәтов катнашты. Кунаклар «Саха–Печать» нәшриятында Саха Республикасының милли телдә чыга торган журналларының баш мөхәррирләре белән берлектә «түгәрәк өстәл» уздырды, Саха Республикасына нигез салган Максим Аммосов музеенда булып, анда «Чолбон» журналына багышланган күргәзмә белән танышты, Саха Республикасы Башлыгының Администрациясе җитәкчесе Афанасий Владимиров белән күреште, «Хәерле иртә, Якутия» тапшыруында туры эфирда чыгыш ясады һәм Саха Республикасының Милли телевидениесе өчен әдәбиятлар бәйләнешы турында интервью бирде, Саха Республикасының дәүләт әдәби музеенда халык язучылары белән очрашты, «Айяр» китап нәшриятында булды. «Россия – моя история» тарихи паркында «Чолбон» журналының юбилеена багышланган төп чара узды. Рөстәм Галиуллин «Чолбон» журналының баш мөхәррире Гаврил Андросовка һәм коллективка «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Шамил Садыйковның Рәхмәт хатын тапшырды.

ӘСТЕРХАНДА ОЧРАШУЛАР

«Казан утлары», «Безнең мирас» журналлары һәм «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррирләре Рөстәм Галиуллин, Ләбиб Лерон, Вахит Имамов, Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе, Бөтендөнья татар конгрессының комитет башлыгы Ленария Мөслимова Әстерхан өлкәсендә күпсанлы очрашуларда катнашты. Аерым алганда, «Әстерхан өлкәсендә авыллар һәм бистәләрнең барлыкка килүе» дигән темага фәнни-гамәли конференция, Ярлы Түбә, Сүләнкә, Канга, Карагалык авылларында, Әстерхан шәһәрендәге Татар үзәгендә, Габдрахман Гомәри музеенда һ.б. татар җәмәгатьчелеге белән «түгәрәк өстәл»ләр оештырылды.

Казан кунакларын Әстерхан өлкәсенең «Дуслык» татар җәмгыяте оешмасы рәисе Әнвәр Алмаев белән Әстерхан өлкәсе татар автономиясе рәисе, «Әстерхан–24» телеканалының генераль директоры Динара Мәҗитова каршы алды һәм озатып йөрде.

ҖИДЕНЧЕ КИТАП

«ТАТМЕДИА» бинасындагы «Әдәби кафе»да Илшат Билаловның яңа гына дөнья күргән «Тауда язылган язмыш» китабын тәкъдим итү булды. Бу – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсе» сериясеннән басылып чыккан җиденче китап. Илшат Билалов – табиб. Рус әдәбияты классиклары А.Чехов, М.Булгаковлар да табиб булганнар. Татар әдәбиятында табиб-язучылардан иң әүвәл Ш.Хөсәеновны искә алабыз. Ак халатлы каләм ияләреннән бездә тагын Н.Каштан, Р.Мәннан, Н.Әхмәровлар да бар. Яңа китап бәйрәмендә «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, ТР Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, язучылар Камил Кәримов, Равилә Шәйдуллина-Мурат, Роза Мулланурова, «Шәһри Казан» газетасы баш мөхәррире Радик Сабиров, тарих институты хезмәткәре Фәния Фәйзуллина, музыкант, педагог Хәйдәр Сафин, журналист Люция Хәбибуллина, җәмәгать эшлеклесе Галишан Нуриәхмәт, «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Вакыйф Нуриев һ.б. чыгыш ясадылар. Соңыннан автор үзе сөйләде. Яңа китап тәкъдим итү бәйрәмен язучы, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Рафис Корбан алып барды. Журнал редакциясе бу сериядән китаплар чыгаруны ноябрь аенда да дәвам итте. Язучы Айгөл Әхмәтгалиеваның «Һәркемгә бер кояш» китабы дөнья күрде.

2021 елның 7 ноябрендә 68 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә, прозаик, журналист, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Абдулла Алиш, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты **Фәйрүзә Әсгат кызы Мөслимова** вафат булды.

Мәрхүмәнең җәсәде Самосыроводагы Мөселман зиратында җирләнде.

Сәхифәне **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: повесть А.АХМЕТГАЛЕЕВОЙ «Замок»,
рассказ Ш.ЗИГАНГИРОВОЙ «Зимняя ночь»;
стихи Г.КУРБАНОВОЙ, Р.БАШАРА, Ф.ЗАРИФУЛЛИНА, Г.АХТЯМОВОЙ.
«Литературный конкурс «Ах, милей родной народ!»:
рассказ А.ЮНУСОВОЙ «Женские суры».
«К 100-летию журнала «Казан утлары»: статья Р.ВАЛЕЕВА.
«Казан утлары» - в моей судьбе»: статья Х МИННЕГУЛОВА.
«Встречая юбилей»: фотоархив.
«Литературная критика»: статья Р.РАХМАНИ, посвящённая 75-летию М.Аглямова.
«Память»: статья Р.ХАКИМА, посвящённая 110-летию С. Хакима;
статья Р.КУРБАНА, посвящённая 70-летию Ф. Зулькарная.
«Литература родственных народов»: стихи Д.ОСМАНА и С.СУЛЕЙМАНА в переводе Р.ЗАЙДУЛЛЫ и Ф.ГИЛЯЗОВА.
«Наука»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.
«Обзор книги»: статья Р.ФАЙЗУЛЛИНА.
«Бесценные голоса»: статьи к 110-летию Г.Абсалямова и 100-летию З.Нури.
Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.
«Сенной базар»: рассказы-миниатюры З.МАНСУРОВА.
Страница сатиры и юмора: юмористический рассказ А.САФИУЛЛИНА.
Из фотоархива журнала.
Библиографический список произведений, материалов, опубликованных в 2021 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Зимний вечер в Казанском Кремле; фото И.АБРАМОВОЙ.

IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: story by A.AKHMETGALEEVA «The Lock»,
story by Sh.ZIGANGIROVA «Winter Night»;
poems by G.KURBANOVA, R.BASHAR, F.ZARIFULLIN, G.AKHTYAMOVA.
«Literary contest «Ah, my dear native people!»:
story by A.YUNUSOVA «Women's Suras».
«To the 100th anniversary of the magazine «Kazan Utlary»: article by R.VALEEV.
«Kazan Utlary» is in my destiny»: article by Kh.MINNEGULOV.
«Meeting the anniversary»: photo archive.
«Literary critics»: article by R.RAKHMANI (dedicated to the 75th anniversary of M.Aglyamov)
«Memory»: article by R.KHAKIM dedicated to the 110th anniversary of S.Khakim;
article by R.KURBAN dedicated to the 70th anniversary of F.Zulkarnay.
«Literature of kindred peoples»: poems by D.OSMAN and S.SULEYMAN translated by R.ZAIDULLA and F.GILYAZOV.
«Science»: article by D.ZAGIDULLINA.
«Book review»: article by R.FAYZULLIN.
«Priceless voices»: articles to the 110th anniversary of G.Absalyamov and the 100th anniversary of Z.Nuri.
The column is headed by N.AKMAL.
«Hay Bazaar»: miniature stories by Z.MANSUROV.
Page of satire and humor: humorous story by A.SAFIULLIN.
From the photo archive of the magazine.
Bibliographic list of works, materials published in 2021.
Diary of social and cultural life.
On our covers: Winter Evening in the Kazan Kremlin; photo by I.ABRAMOVA.

Тышлыктагы сурәтләр

Тышлыкның беренче битендә: Казан Кремлендә кышкы кич.
И.Абрамова фотосы.